# КАЗАН УТЛАРЫ

1
ЯНВАРЬ
1980




*КАЗАНДА СОВЕТ ВЛАСТЕН ИГЪЛАН ИТУ.*

М. РӘХИМОВ рәсеме

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**1**

ЯНВАРЬ
1980


## Бу санда


И. ЮЗЕЕВ. Мәхәббәт китабы . . . . . . . . 3
М. ХӘСӘНОВ. Шөгеровлар. Романнан өзек . . . 19
Н. ИЗМАЙЛОВА. Уянучы җыр. Шигырьләр . . 65

ЯЗУЧЫ БАРЛАС КАМАЛОВКА 50 ЯШЬ

Б. КАМАЛОВ. Актуган Габсаттары. Повесть . . 68

КЛАССИК ПОЭЗИЯДӘН ҮРНӘКЛӘР

Бабур газәлләре . . . . . . . . . . . . . 93

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Карт мукшы. Хикәя . . . . . 97
Х. КАМАЛОВ. Куян күзе нигә кызыл! Хикәя . . 104

БӨЕК РУС ЯЗУЧЫСЫ А. П. ЧЕХОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

А. П. ЧЕХОВ. Ата. Хикәя . . . . . . . . . . 110

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

САМАТ ШАКИР. Баһадирлар юлы . . . . . . 116

«ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕЛӘР» КОНКУРСЫНА

М. ГӘРӘЕВ. Шамил батыр. Очерк . . . . . . 120

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Н. АКМАЛОВ. Әгәр ышансагыз... Хикәя . . . . 126

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. МИҢНУЛЛИН. Яшьлекне сагыну . . . . . . 130
Р. КУКУШКИН. Яңа шигъри ачкыч эзләп... . . 135

СӘНГАТЬ

Ф. ШӘМСЕТДИНОВА. Татар симфоник музыкасы үсеш юллары . . . . . . . . . . . 145



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Э. БАРИЕВА. Бәйләнеш серләрен ачканда . . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. ХАЛИТ. Язучының әдәби-эстетик фикер хәзинәсеннән . . . . . . . . . . . . . . . 156
Л. ХӘЙДӘРОВА. Озак яшәүнең сере . . . . . 159
ШАКИРОВ С. Газета һәм әдәбият дуслыгы . . . 162
Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Адымнар . . . . . . . . 164

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Х. МАКСУД. Ил белән бергә . . . . . . . . . 167
З. ХӘЙРУЛЛИНА. Җыр булып яңгыраган язмыш 171

Безнең сафка . . . . . . . . . . . . . . . 174

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Түребездә — белорус классиклары . . . . . . 176

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ш. САЙКИН. Кушаматлар тарихыннан . . . . . 181

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Ф. ЯРУЛЛИН. Мыштым Гайсә. Юмореска . . . 185
Г. АФЗАЛ. Утырышу. Шигырьләр . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова (җаваплы секретарь), Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 25/IX-1979 ел. Басарга кул куелды 21/XII-1979 ел. ПФ 09056. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94800 экз. Заказ Ц-388. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

## Илдар Юзеев

# МӘХӘББӘТ КИТАБЫ

*Җырларымны иҗат иткән чакта,*
*мин гашыйклар хисен кичердем,*
*корбаннарга бардым, яндым, көйдем.*
*Кабат тойдым сөю көчен мин.*

«Мәхәббәт» дип әйтү белән, беләм:
яңа җыр көтәсез җырчыдан...
Мәхәббәт ул—телдән төшми торган
иң борынгы моңлы җыр сыман.
Уй-хисләрнең иң җылысын эзләп,
саф дөньяга карап юл чыгам.
Шатлыклар да очрар, кайгылар да,—
һич куркытмый юллар газабы.
Бармы Җирдә мәхәббәтнең башы,
бармы мәхәббәтнең азагы!
Иң беренче Җиргә кемнәр туган,
иң беренче кемнәр яраткан,
Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүннәрнең
сөю җырын кемнәр тараткан!
Кешелекнең сөю тарихына
ничек, кай юллардан китәргә,
мәхәббәтнең туган көне итеп
кайсы көнне игълан итәргә!
Беренчеләр, башлап сөючеләр:
Адәмме син, әллә Хавамы!
Без бүгенге: «Сөям» диючеләр—
сезнең мәхәббәтнең дәвамы.
Иң беренче тапкыр ләззәтләрдә,
газапларда янган гашыйклар!
Сезнең хисне дәвам иткән егет
сөю җырын сезгә багышлар.

## Мәхәббәткә ничә яшь?

«Мәхәббәткә ничә яшь?» дисәгез,
мәгарәдә ташлар дәшмәстер...
Мин җырларны тыңлыйм: ул, мөгаен,
моңлы көйләр белән яшьтәштер.
«Мәхәббәткә ничә яшь?» дисәгез,
таудан аккан сулар дәшмәстер,
агышларны тыңлыйм, ул, мөгаен,
челтерәүләр белән яшьтәштер.
«Мәхәббәткә ничә яшь?» дисәгез,
тынып калган вулкан дәшмәстер,
ул, мөгаен, мәңге тынмый торган
күңел хисе белән яшьтәштер.
«Мәхәббәткә ничә яшь?» дисәгез,
иске каберлекләр дәшмәстер,
ул, мөгаен, дошманлыкны җиңгән
ике гашыйк белән яшьтәштер.
«Мәхәббәткә ничә яшь» дисәгез,
минем замандашлар дәшмәстер,
ул, мөгаен, үзенә сөю килгән
һәрбер гашыйк белән яшьтәштер.

**Мәхәббәтнең эзлим шәҗәрәсен,**
**мәхәббәтнең эзлим юл башын,**
**юлларымда—телсез салкын ташлар,**
**легендалар гына юлдашым.**
**«Кем баласы!» диеп сорасагыз,**
**мин—мәхәббәт, сагыш баласы...**
**Мине иҗат иткән гасырларга**
**кай юллардан, ничек барасы!**
**Сөю турындагы риваятьләр,**
**сөю турындагы хыяллар**
**бәлки мине, һич тә тарсынмыйча,**
**узганнарга илтеп куярлар!..**

## Адәм белән Хаваның очрашуы

Җир йөзендә бер йөрәк бар: Адәм яши...
Тик шулай да бер адәм ул тормыш түгел.
Табигатьтә өстен көчләр-ерткычлыклар,
кыргыйлыклар, вәхшилекләр хөкем сөрә.
Җир буйлатып килә Адәм бер ялгызы...
Ком-сахралар, дала-кырлар, таулар аша.
Карурманнар, дәрья-сулар артта кала...
Кая бара? Ни эзли ул чиксезлектә?
Көннәр, төннәр алышына. Кояш чыга.
Кайнар ком-таш табаннарны пешерсә дә,
һаман бара көнчыгышка таба карап,—
көткәне нәкъ шул тарафтан чыгар сыман.
Ни телисең—өзеп ал да авызга кап...
Юк, һаман да тукталмыйча бара Адәм.
Искиткеч бер серле хыял тарта аны,
тарта аны... Ул үзе дә белми, нәрсә?
Кояш бата... югарыда йолдыз калка.

Бер вакытны, сызылып алсу таң атканда,
могҗизадан хәйран калып туктый Адәм.
Туктый Адәм, күзләр зур-зур ачылганнар,
авыр күсәк ихтыярсыз төшә кулдан...
Нәрсә соң бу: күпме гомер кичереп тә,
Җир йөзендә мондый хәлне күргәне юк:
тай ялыдай елым-елым ике толым...
Кара күзләр—ап-ак карда ике йөзем...
Тулган айдай күкрәкләре тирбәләдер,
чәчәк сыман ачыла гөл-керфекләре...
Җиргә яңа туган сыман карый Адәм:
бу нинди ямь, нинди балкыш күрелмәгән...
Серле дөнья тәкъдим итә баласына
табигатьнең бар сафлыгын, нәфислеген.
Юкка гына эзләгәнсең зәңгәр күктән,
эзләгәнең син яшәгән Җирдә икән...
Ашкынуың, җилкенүең шуңа: җаның
нәзакәтлек, җылылык һәм назлау көткән.
Назлау көткән... Ул да йөргән бер ялгызы...
Өмет өзгәч үзе сине эзләп киткән.
Ул да сине ничә еллар өзелеп көткән,
ерткычлыктан яклау көткән, саклау көткән.
Курку катыш соклануын җиңә алмый
чигенә дә... тыелалмый карый аңа.
Үзенә баккан ике күлдәй түгәрәктән
чыга алмый... тарта аны кайнар дулкын.
Нәфислекнең каршысында бер сын тора:
боздай аксыл, уттай алсу шәп-шәрә тән...
Күкрәкләре—тимер калкан, беләкләре—
мең ерткычны юк итәрлек чукмарлардай.
Икәүнең дә күкрәгендә йөрәк тибә,
теләп тибә бу минуттан аерылмаска...
һәм ике җан бер-берсенә тартылалар,
атылалар бер-берсенең кочагына.
Тартылырлар иде алар бер-берсенә
үтәлмәслек урман, утлы тау булса да,
атылырлар иде алар бер-берсенә
өзгәләргә җыенса да мең арыслан.
Бу—яшәүгә омтылышны тыя алмас
өскә яуган кыя ташлар, кыяматләр...
Сыя алмас бу куаныч Җир йөзенә,
сыяр бары бәхет көткән ике җанга.
Җирдә туа С Ө Ю дигән иң гали хис,
тормыш күрке, гүзәл тойгы, акыллы Ямь...
Ике җанны очраштырган Табигатькә
һәм очрашкан Адәмгә дан, Хавага дан!

**Рәхмәт сезгә, мифлар, легендалар,**
**көч бирдегез ерак китәрлек,**
**сездән башка шигъри архивымда**
**дәлилләр юк исбат итәрлек.**
**Ә чынында исә кешеләрдә**
**нинди хисләр туган иң элек!**
**Сөюдән дә алда нәфрәт туган**
**һәм дошманлык туган, көнчелек...**

## Мәхәббәт туган көн

Җир йөзендә гамьсез-салкын көн туган да төн туган...
Ызгышлардан, талашлардан, тартышлардан Җир туйган.
Һәр җанлы нәрсә дәшә күк: кем туган да кем туган?
Берсен-берсе эзләп тапкан сөенечле өн туган!
Беркайчан да булмаганча бу кешеләр гүзәл ник?
Тәндә туа, аңда туа, җанда туа гүзәллек!
Аһ, нилектән шул кадәре аяк баскан Җир җылы?
Җир җылы да шатлык яшен сыйпап искән җил җылы!
Һай, бу күкләр, һай, бу җирләр—зур икән лә, киң икән,
киң икән лә, ике җанның күңеленә тиң икән.
Җан җылысы яктыртадыр диңгезен, дала, күген,
аллаларның сөюеннән ким түгел, артык түгел!
Бу гали хис, бу гали уй тик ике җанда туган,
ике җанда гына түгел, гүя җиһанда туган.
Сокланып карыйлар Җиргә чиратлап Кояш, Ай да,
очрашулар, табышулар, аңлашу—менә кайда!
Котлый икәүне табигать иң ихлас гөлләр белән,
җан белән тән һәм дә акыл кавышкан көннәр белән.
Һич тә тыялмый ике җан ташыган уен-хисен,
юк әле Җирдә бу хиска Мәхәббәт дигән исем.
Чигенә артка таба нәфрәт, дошманлык, көнчелек,
тик үзе дә белми әле, күтәрелә кешелек....

**Кыргый бәгланышлар хөкем сөргән,**
**тыныч кына аккан дөньяда**
**иң көчле дәрт, моңсу шатлык туган,**
**фаҗигаләр арткан дөньяда.**
**Каннан—канга күчкән сөю дәрте,**
**ул дәрт килә буын-буыннан,**
**күпме ашкынулы кайнар хисләр**
**җир астында калып суынган.**
**Бәхетлеләр эзләп табышканнар,**
**кавышканнар—нәсел ялганган,**
**берләр мәхәббәттә бәхет тапкан,**
**берләр мәхәббәттә алданган.**
**Мәхәббәтнең археологы булып,**
**бик борынгы хистә казынам...**
**Сөю җиле кагылып куя сыман**
**болгар бабаларым язынннан.**
**Искергән дип, бәлки кул селтәрсез,**
**яшь дусларым, сезгә җыр илтәм.**
**Адәм баласының фаҗигасен**
**гыйбрәт өчен кабат терелтәм...**

## Хан кызы Карачәч

Хан кызы Карачәч
уналты яшендә.
Яшер дә буеңны,
уеңны яшермә.
Синдәге гүзәллек
түзәрлек түгел лә,
күңелгә кер дә кал,
түгелмә, чәчелмә.

Хан кызы Карачәч,
толымнар—тезеннән,
сүзеннән—җыр ага
дөньяга, ил-йортка.
Хан кызы Карачәч,
көлмәге—яшелдән,
яшергән хан аны...
Һәм җаны тынычтыр.

Омтылма, яшь койма,
таш койма ураткан,
югалткан башларын—
ташларны үтәлгән.
Хан Тимер үзен дә,
кызын да саклаган,
ил-йортның ачкычын
үзендә саклаган.
Әйткән, ди: «Сайрап кал,
сайлап кал яшьлектә,
кем ошый җаныңа—
ханыңа әйт кенә...»
Хан кызы Карачәч,
уналты яшендә,
яшер дә буеңны,
уеңны яшермә:
әйт, җаның кем аулап,
кем яулап киткәнен,
куркусыз баһадир
Җиһангир икәнен.
Хан кызы Карачәч,
карачы, карачы:
күрше хан яу башы
Җиһангир батырдан
киләдәр яучылар,
хан чыга каршыга:
барсы да коралсыз,—
ачыла капкалар.
Бәхетле Карачәч,
карачы көзгегә,
түз генә, чәчеңне
туйга дип тарачы.
Карачәч—Җиһангир...
җиһан бер сөенсен,
туйга дип җыенсын,
туенсын җиһан бер...
Тыңлыйлар тын гына,
шым гына хан сүзен:
«Хак сүзем: хан кызын
кѳтмәсен Җиһангир.
Бик беләм: Җиһангир
баһадир яуларда,
яуларга теләсә
минем дә йөрәкне,
теләкне җиткерсен
хуҗасы Акташка:
баш тартсын ызгыштан,
сугыштан, талаштан...»
...Ник тирән сулыйсың,
елыйсың, Карачәч?..
Атаңнан мәрхәмәт
сорыйсың, Карачәч?..
Хан шашкан, тилергән
тимердән—йөрәге:
«Карар нык! Карар нык!
Аңа—юк! Аңа—юк!»
...Нәкъ әнә шул чакта
юл чыкты чапкыннар,
күрше хан, көчле хан,
үчле хан Акташтан.
Җиһангир камады,
янады яу булып,
«Дау булып, яу булып
килдек без, ач, Тимер!»
Кирмәне[1] йозакта—
тирәли йөрерләр,
тимерләр бирелми,
бөгелми Тимерләр!
Җиһангир җиде көн,
җиде төн дигәндә,
камаудан тукталды,
тын калды яугирләр.
Нишләргә? Әмәл юк!
Фәрман юк чигәргә!
Менәргә—баскыч юк,
ачкыч юк—кирмәнгә...
...Гүзәл кыз Карачәч
бәхетен югалткан...
Югалткан дисезме?
Менә хат! Ул тапкан!
«Кадерлем Карачәч,
мин килдем, кара, дәш,
күз яше аралаш
ялварам: ишек ач!
Мин сине сагындым,
табындым тик сиңа...
Ишекләр йозаклы...
озакмы түзәрем?
Бәхетсез итәләр
киртәләр юлларда,
мәхәббәт ачкычы
тик синең кулларда...
Кадерлем Карачәч,
мин кѳтәм, кара, дәш,
күз яше аралаш
ялварам: ишек ач!..»
Карачәч, ник тындың?
Омтылдың азмы син?
Язмышы ярыңның
әнә шул ачкычта.
«Таш йөрәк» атаңнан,
Ватаннан, ил-йорттан
мәхәббәт югары,
юллары—ачкычта...
Тапты ул бүлмәне—
күрмәде беркем дә.
Үрелде ачкычка,
юл кыска—бәхеткә...
Капкалар—ачылган,
басылган—тузаннар,

[1] Кирмән — крепость.

узганнар—җимереп,
асылган—туганнар...
Җиңелгән Тимер хан,
Тимерләр бөгелгән,
каргышлар яуганнар,
ауганнар танышлар.
Яр кетә Карачәч,
дар кетә—кардәшләр.
Җиһангир—матур, яшь...
Карачәч—кочакта...
Бәхетле ике яр—
нурлылар айдан да.
Туй кетә ике яр...
Ике дар — мәйданда.
Кан-каргыш җыйган ир—
Җиһангир канәгать...
«Тыңлагыз! Фатиха
бирәчәк Тимер хан!..»
Карачәч—мәйданда.
Кем анда? «Әтием!»
Тимер хан тын торды...
Кычкырды: «Сатлык җан! Тфү!»
Мәйданда аннан да,
моннан да мең аваз
кабатлый бергәләп:
— Мең нәләт! Мең нәләт!
Дарларда чайкалган,
айкалган гәүдәләр
кабатлый бергәләп:
— Мең нәләт! Мең нәләт!
Кыйналган, тапталган,
саф калган адәмнәр
киләләр үрмәләп:
— Мең нәләт! Мең нәләт!
Гүзәл кыз Карачәч,
карачы ил-йортка,
һәммәсе атылган,
ватылган, кол булган...
Күзләре ачылган,
шашынган Карачәч
йолкадыр чәчләрен,
яшьләрен агызып:
«Әтием!.. Ил-йортым!..»
Мәйдан тын... акыртын
гәүдәләр үрмәләп,
бергәләп: «Мең нәләт!
Мең нәләт!»
Ни чара? Юл кая?
Елмая Җиһангир,
бәхетле балкый ул:
«Бар, ки туй күлмәген!»
Карачәч гүзәлме?
Түзәрме Карачәч?..
Сүз бара артыннан:
«Сатылган! Сатылган!..»
Күз алды—карадыр,
барадыр баскычтан,
артыннан үрмәләп
«мең нәләт!» барадыр.
...Баскычның башыннан,
ташыннан кирмәннең
бер гәүдә атылган...
Атылган, атылган.
Сүз бара артыннан:
«Сатылган... сатылган...»
Гүзәл кыз Карачәч...

**Тарих бабай бик карт, хәтере начар,**
**искә алуларны яратмый...**
**Яшь булса да, яшьлек—тарих кебек,**
**бер үк ялгышларны кабатлый.**
**Беркөн миңа шундый сөю килсә**
**һәм сораса: «Ярмы, Илеңме!»**
**Җиңәлмәслек ташкын хисләремнең**
**колы булып калыр идемме!..**
**Сөю—илаһи көч...**

**Бер минутлык сөю хисеннән**
**иң-иң гали акылияләре**
**акылыннан шашкан, исергән.**
**Сөю Җирнең иң-иң диванасын**
**кинәт акылына утырткан.**
**Сөю туңган, бозлы йөрәкләргә**
**мәңге сүрелмәслек ут төрткән.**
**Һай, мәхәббәт,**
**колны—патша,**

**патшаны кол иткән мәхәббәт,**
**олыны—кече,**
**кечене олы иткән мәхәббәт!**
**Сөю—дөньялыктан ваз кичкәннәр—**
**монахларны юлдан яздырган,**

телсезләрне кинәт телле иткән,
тел остасын телдән яздырган.
Шушы олы хисне кичергәннәр—
бәхетлеләр, сезгә мин дәшәм!
Үз хисенә кол булганнан түгел,
янып көл булганнан көнләшәм!
Сөю—илаһи көч, әле беркем
янмый чыгалмаган ул уттан,
көл булганнар—җырга, кол булганнар
ил-йорт каһәренә юлыккан.
Гашыйк җаннар яңа гомер биреп,
киләчәкне җылытып киткәннәр.
Ах, кызганам сезне «сөю юк» дип,
дөньялыкта гомер иткәннәр....

## Карт буйдак монологы

Их, егетләр, нигә, нигә соң мин
җиргә элегрәк тумаган?
Миллион еллар соңлап туганга да
мәхәббәттә бәхетем булмаган.
Йөрәгемә кулны куеп әйтәм:
юк ул—мәхәббәт!
Эзләгәнен тапкан дисез мәллә
җиде хатын алган Мөхәммәт!
Мин Мөхәммәт кебек кыланмадым,—
заманча бер өйләнеп карадым,—
шул бер хатын белән яшәүнең дә
тәмуг икәнлеген аңладым.
Ах, егетләр, әйтсәм әйтим инде,
бик үк шәптән түгел безнең эш:
Азиянең бер илендә бугай,
бер хатында—җиде ир, имеш.
Кеше җирдә мәхәббәтен эзли:
кулланмаган чара калмыйдыр,
акылдан да өстен машиналар—
ЭВМнар таба алмыйдыр.
Фәннең көчен җигеп, Мөхәммәтне
терелтсәләр, әйтер Мөхәммәт:
«Җитмеш җиде хатын алсагыз да,
юк, иптәшләр, юк ул мәхәббәт!»
Зөләйха да үзенең мәхәббәтен
төштә күргән, өндә күрмәгән,
ире эштән бераз төшереп кайтса:
«Бар, кире кит!» диеп өрмәгән.
Ләйлә-Мәҗнүн?.. Әйе, егет кызның
йөзен күрү өчен шашынган,
тән күрсәтү ул чак гөнаһ булган...
Хәзер... бар да макси ачылган.
Ярый... Ләйлә килен булып төшсә,
сөю дигәннәре сыналса,
килен белән явыз каенанасы
көне-төне җәнҗал чыгарса?..
Ромео һәм Джульетта дисез?

Бергә яшәп кенә карасын,
холодильник-тормыш һәм көнкүреш
тиз суытыр алар арасын.
Юк, бөтенләй булмаган дип әйтмим,
сөю өчен шундый чор булган —
Җирдә икәү—Адәм белән Хава—
сөю сүздә түгел, чын булган.
Җир бетереп эзләп йөрисе юк,
сөю килер диеп көтмә дә...
Бердәнберең Хава басып тора...
Башкаларга өмет итмә дә...
Адәм белән Хава бик бәхетле...
Мин көнләшәм, үлеп көнләшәм,
шартлар идем, ул чак көнләшүнең
юк икәнен әгәр белмәсәм.
Адәменнән күзен алмый Хава—
карамыйча башка чараң юк...
карар иде, ятка карар иде—
Җир йөзендә башка адәм юк.
Хыялланмый Адәм башка ярга
үз Хавасын алыштырырга,
мөмкинлек юк, юк шул мөмкинлекләр
чит-ятларны караштырырга.
Хавадан да чибәр берәү дә юк,
дөньяларда тик бер кыз гына,
аннан гүзәлләрне эзләсәң дә,
табалмыйсың,—яшә, түз генә!
Адәм белән Хава шундый тату:
шалтырамый—савыт-саба юк.
Менә бу ичмасам чын ярату:
иркә-назга чик һәм чама юк!
Җәнҗал чыгаруда катнашмыйлар
каенаналар, килен, кодалар.
Хава кәҗәләнми... тәннәр шәрә...
бик килешле, арзан модалар.
Хава, башкалардан калышмыйм дип,
бишәр меңлек алка такмаган,
Адәм «хатыныма багышлыйм» дип,
мөлкәтеннән колак какмаган.
Үз дачамда кишер үстерәм дип,
язын-җәен балчык-тирестә
ятмаганнар, Адәм белән Хава
тук булганнар сөйгән килеш тә.
Ник бәхетле булмасыннар алар?
Кушылабыз, аерылабыз, диеп,
ЗАГСларга кермәгәннәр дә,
яратышкан алар, мәхәббәтнең
ни икәнен белмәгәннәр дә.
Ник бәхетле булмасыннар алар?
Ул чак һава урынына хәмер
сулый торган Адәм тумаган,
«аны миннән артык сөясең» дип,
Хава аны өйдән кумаган...
Ник бәхетле булмасыннар алар?
Адәм белән Хава йөрәгенә
язылмаган закон уелган:

«хатын—муен, ир—баш» дип талашу
килмәгән дә алар уена.
. . . . . . . . . . . .
Ах, егетләр, нигә, нигә соң мин
әнә шул чорларда тумаган?!
Бу дөньяга соңлап туганга да,
мәхәббәттә бәхетем булмаган.
Адәм булсаммы мин... табар идем
үз Хавамны—бердәнберемне!
Буйдак булып, адәм арасында
әрәм булып йөрер идемме?

**Гашыйк булу—ул гомернең язы,**
**ә кавышу—алтын көзедер,**
**кыш та, җәй дә сүрелмәгән хисләр—**
**кайнар мәхәббәтнең үзедер.**
**Яшьлектә дә килә, картлыкта да,**
**кайчак бик тә иртә кабына...**
**Хатирәләр алып китә мине**
**ал сиреньле бала чагыма.**

## Сирень чәчәге

Мәхәббәтнең нәрсә икәнлеген
мин иртәрәк, ахры, аңладым.
Җырым бөреләнгән үсмер чагым,
гашыйк булган чыклы таңнарым...
Һәр язны мин сагынып көтеп алам
сиреньнәрнең чәчәк атуын.
Мәңге кайтмас...
Юкка көтә күңел
үсмер чакларының кайтуын.
Ташулар да кайтыр,
сиреньнәр дә
чәчәк атар... Һәр ел ни көтәм?..
Яшьлек дусларымның образларын
хыялымда кабат терелтәм.
Очрашулар насыйп булса әгәр,
искә алып еллар-айларны,
мин кочаклар идем малайларны,
кызларны һәм... дустым Айдарны.
Рәсемнәр дә инде тоныкланган,
килми инде сәлам-хатлар да,
мөмкинлекләр юк шул кочакларга,—
яшьли сөйгән ярлар ятларда...
Үсмер чактан күңелемдә калган:
«бердәнберем мине ташлады...»
«Сине яратканга күз атмыйсың,
син яраткан—сөя башканы».
Күпләр өчен бу—буш сүзләр иде,
күпләр мәхәббәттә уйнады.
(Кемдер шул уенны дәвам итте...
Аерылды узгач туйлары.)
Директорга сине чакырулар...
Ромеомы? Таһир? Кем соң син?
Сөю, имеш... Ташла... Оныт... Укы...

Ундүрт яшьтә чынлап кем сөйсен?..
Кичер, Айдар, мин дә сине башта
юри кылана дип уйладым.
Тик соңыннан белдем, тик соңыннан:
җитди булган икән уйларың.
Шул чагында сине аңламаулар
үзәгемне өзә әле дә...
Вакытлыча түгел, мәңгелеккә
күңеленә кергән Фәнүдә.
Ул чакта без җан дус түгел идек:
уртак түгел иде серләр дә.
Тик сизендем: кайчак Фәнүдәсе
авырып килми калган көннәрдә,
нидер яза иде бездән качып,
мин партадан карыйм үрелеп,
авыз ерам...
Кинәт җанны били
серле сүзләр миңа күренеп:
«Ул яраткан сирень чәчәкләрен
вакытлары җитми өзәлмим,
сөйгәнемнең нурлы карашларын
бер минут та күрми түзәлмим».
Бу җыр иде,
Айдар йөрәгеннән
ташып, тулып чыккан җыр иде.
Мин табынам,
мин ышанам җырга...
Димәк, мәхәббәт тә чын инде.
Фәнүдәдән чибәррәк кызлар
булганнардыр бездә, мөгаен,
әмма Фәнүдәбез барсыннан да
ягымлырак иде, мөлаем.
Тамаклар ач. Өсләр бөтен түгел,—
тәннәр затлы кием күрмәде...
Нур балкышы иде Фәнүдәнең
сирень чәчәкле ал күлмәге.
Үзе гашыйк булган егет сыман,
кабаланып, каушап, ашыгып,
арадашчы булып, Фәнүдәгә
күпме сөю хаты ташыдым.
Ә Фәнүдә ята, бик кечкенә
сары сандугачтай, ояда...
Хатны ала. Укый. Җавап бирми.
Битен каплый. Сөя... Ояла...
Һәм озата, урыныннан торып,
«рәхмәт» дигән җылы сүз белән.
Фәнүдәкәй һаман авыр сулый...
Терелер ул... Айдар, түз, беләм...
Җавап табалмаслык авыр сорау
телгәлиДер безнең бәгырьне:
ничек соң без аны сакламадык,
ничек соң ул әле авырды?

...Сугыш елларының авырлыгын
җилкәбездә татып өлгердек.
Без качмадык... ялан аяклардан
авырлыкка каршы йөгердек.

Искә төшер: бозлы суга батып,
тиздән ерып язгы басуны,
кырык чакрымдагы бер колхоздан
чәчү орлыклары ташуны.
Алмасак та, китте безнең белән,
үзе генә иде кызлардан,
безне—малайларны—дәртләндереп
бозлы судан барды иң алдан.
Ул елны яз бик тә салкын килде,
иркә кошлар кире кайтмады,
Фәнүдәнең сөйгән куаклары—
сиреньнәре чәчәк атмады.
Җәйгә чыккач без лагерьга киттек:
Айдар, мин һәм... калды Фәнүдә...
Иреннәрен тешләп елмаюы
истә әле, истә әле дә.
«Ул яраткан сирень чәчәкләрен
яз җитсә дә табып өзәлмим.
Сөйгәнемнең нурлы карашларын
бер минут та күрми түзәлмим».
Айдар дусның бөтен уе-хисе
Фәнүдәгә генә тартылган.
Ике көннән ул лагерьдан качты...
Мин дә киттем аның артыннан.
Ул елны яз бик тә салкын килде,
сайрар кошлар кире кайтмады,
Фәнүдәнең сөйгән куаклары—
сиреньнәре чәчәк атмады.
Көчтән килсә, кояшларга кадәр
илтер идек салып иңнәргә...
Юк шул...
Фәнүдәбез сирень сыман,
өкрен генә сула мендәрдә.
Айдар сыйпый аның чәчләреннән:
— Фәнүдә... Фәнүдә...
Тыелалмый кайнар яшьләреннән:
— Фәнүдә... Фәнүдә...
Бәлки әле болай булмас иде, —
кайтып җитәлмәдек, кичектек.
Шул чак Фәнүдәнең өзелеп әйткән
соңгы ике сүзен ишеттек:
— Яратам... яратам...
Ул елны яз бик тә иртә килде,
сайрар кошлар кире кайтмады,
Фәнүдәнең сөйгән куаклары —
сиреньнәре чәчәк атмады.
Сөйгәненең җылы туфрагына
дустым Айдар ятып үкседе:
«Нигә, нигә мине ташлап киттең,
мин ярата идем бит сине!..»
Шул көннән соң күпләр Фәнүдәнең
рәсемен алып түргә элделәр,
ә кичләрен мин чыгарган җырны
өйдән-өйгә җырлап йөрделәр:
«Ал сиреньле күлмәк, иртәләрдә
имән киртәләргә кем элде?

Сөю дигән орлык чәчәкләнми
салкын туфракларга күмелде».
Шушы җырны җырлап Айдар дустым
авылыбыздан китеп югалды.
Хатлар да юк... җылы хәбәрләр дә...
Беркем белми... кая юл алды?
...Заман безгә шактый кырыс булды,
үстермәде назлап-иркәләп,
без югалттык әти-әниләрне,
абый-апаларны иртәрәк.
Югалтулар безне өлкәнәйтте,
олы уйлар безне зурайтты,
авырлыклар безне иелдерде,
сабырлыклар безне турайтты.
Һәммәсенә түздек, чыдадык без,
юкса, түземлек тә юк артык...
Мәхәббәтне без иртәрәк таптык,
кайберебез иртә югалттык.
Айдар дускай, кайгысына батып,
югалдымы әллә бер эзсез?..
...Безнекеләр алар сынатмаслар,
килеп чыгар, менә күрерсез!
Еллар үтте... Дуслар өйләнделәр,
күп яралар инде төзәлде.
Сиреньнәрен иртә җуйган дусны
эзләмичә күңел түзәрме?
Айдар исән! Мин уйлаган идем:
«яшьлек белән ара өзелгән»...
Бергә чакны, димәк, онытмаган,
сәлам хаты алдым үзеннән:
«...мин өйләндем,
кыз да, малай да бар...
эшемнән тәм табып яшәвем...
Тик сагынам, өзелеп сагынам мин
яшьли сөйгән сирень чәчәген.
Шул олы хис алга илтә мине,
каютада рәсеме әле дә...
Боз тауларын ерып, юл күрсәтеп,
алдан бара кебек Фәнүдә.
Күпме онытырга тырышсам да,
юк, барыбер онытып булмады,
күңелемдә чәчәкләнгән сирень
салкын язларда да сулмады.
Фәнүдә дә, сирень чәчәгедәй,
аз яшәде ямьләп дөньяны,
ул гомеремнең язын гына түгел,
көзен, кышларын да нурлады.
Синең җырны мин үзгәртеп җырлыйм:
«имән киртәләргә кем элде?
Сөю дигән орлык яшәр өчен
йөрәгемә минем күмелде».
Хисем теләктәше, сердәш дустым,
сине уйлыйм шушы минутта...
Атом бозваткычы штурманы
Айдар Муллин.
Сау бул.
Онытма».

...һәр язны мин сагынып көтеп алам
сиреньнәрнең чәчәк атуын.
Мәңге кайтмас...
Юкка көтә күңел
үсмер чакларының кайтуын.
Ташулар да кайтыр,
сиреньнәр дә
чәчәк атар... һәр ел ни көтәм?
Яшьлек дусларымның образларын
хыялымда кабат терелтәм.

. . . . . . . . . . . . . . . .

Авылыма кайттым. Бергә үскән
җан дусларны табыйм кайлардан?
Таныш рәсем.
Сирень чәчәкләре.
Мәрмәр ташта бер сүз:
«Айдардан».
Башны иеп мин бик озак торыйм.
Хисләр олы. Беркем дәшмәсен.
Һәм тын гына, тып-тын кабатлыйм мин:
«Айдар мәхәббәте яшәсен...»

**Мәхәббәт ул тәннең, акыл, хиснең
өлгерүе, тулып ташуы,
чынбарлыкта туган хыялларның
канатланып күккә ашуы.
Канатлары ныгып өлгермәгән
нәни кош та күккә омтыла...
Омтыла да түбән егылып төшә,
канатлары сына... ул тына.
Күптән түгел шәһәр эчендәге
йорт сүтелгән иске нигездән
бер хат таптым: сез дә танышыгыз,
яшерәлмим аны мин сездән.**

## Унбиш яшьлек әни

*Кызыма хат*

Кызым,
әле берни аңламыйсың...
Син — биләүдә.
Сиңа гына язам,
укымасын берәү дә.
Әнкәң язган бу хат
унбиш ел барыр...
Аңларсыңмы шул чак
ана күңелендә ни барын...
Яшь топольләр
йөгереп уйныйлар,
алар язны көтә,
яфракларын коймыйлар.
Шул топольләр кебек
яшьлек илендә
язны көтеп калыр идем дә...

Яфракларым туйган уеннан,
вакыты җитми иртә коелган.

...Бала чак!
Туйдым синнән —
унбиш яшькә җиткән кыз бала.

Тоям:
күкрәгемдә
тыелгысыз дәртләр кузгала.
Бала чак!
Сине ташлап йөгерерләр иде,
яшь топольләр чаба белмиләр...

Әнкәй,
нигә «бала» дисең,
ә малайлар «бала» димиләр.
«Яшьлек килер, диләр,
җитсен унсигезең, егермең...»
Көттем...

Түземнәрем беткәч,
үзем каршы йөгердем,
малайларны узып...

Әллә кимме алардан!
Кыркылган чәч,
    джинс чалбардан.
Топольләрем
язны көтегез:
сез түземнәр...

Минем — яшьлегемә
йөгереп барып әйтер сүзем бар:
«Мин бит көтәм сине, иртә кил,
иртә дә кил миңа, кич тә кил...»
Малайларның тавышы:
«Син — яшьлектә... эч тә көл!..»
Татлы чыганакка
иреннәрне тидердем...
Яшьлек... бу — син идең...

Эчкән саен сусап тилмердем.
Яшьлек!
Шундый рәхәт синдә,
кагыйдә дә, закон, чик тә юк...

Мә, ал мине,
мин — синеке!
Курку да юк синнән, шик тә юк!
Яшьлек!
Калам синдә,
кайнар хисләреңә камалып.
Җитте, туйдым...
Чиген, балалык!
Яшьлек!
Иркен — дөньяң,
шаулы — диңгезең...
Мин — ирекле...
Әни?!
Мин — үзем!
Яшьлек!

Җырлы, шомлы кара төннәрең!
«Сөям сине!» дигән төннәреңнең
ниләр яшергәнен белмәдем.
Яшьлек!
Юлларыңда—адашканмын,
бала чактан түгел,
үз-үземнән качканмын.
Яшьлек...
Ник йөгердем алдан мин?..
Ямьле төннәреңә,
тәмле телләреңә алдандым.
Сүрелделәр
яшьлек таңнары...
Җырсыз тындым,
төнге сандугачлар аңлады.
Кайтам,
ачы яшьләр түгеп,
«татлы» төннәргә.
Башны ташка куям:
хурлыгымны сөйлим кемнәргә?
Дөрес җырлагансың, әнкәй:

«Вакыты җитми чәчәк атмый
бакчадагы гөлләр дә»

Яшьлек...
ачы җилләр исә ул яктан...
Ятып үксим
күкрәгемне кыскан ояттан.
Топольләрем
җилфер-җилфер яфрак ярганнар,
яшьлек язын каршы алганнар.
Тып-тын
кайтып киләм яшьлек туеннан...
Өметләрем, яфрак ярыр-ярмас
бөре килеш коелган.
Яшьлек...
Йөгергән лә идем каршы чыгып,
көткән идем талчыгып,
бөгелдем мин җилдә —
нечкә талчыбык.
Качам —
мәктәп хөкеменнән,
кеше күзеннән.
качам — әни кайгысыннан,
үзем-үземнән.
Качам — яшьлегемнән,
яшьлегемә һич тә ачу юк,
качам — балалыктан,
тик... баладан гына качу юк...
Гаеп — миндә,
яшьлектә — хата юк...
Унбиш яшьлек әни... Ата — юк...
Топольләрем,
шаярыгыз, яфрак ярыгыз,
яшьлек уенына чакырмагыз —
үзегез барыгыз...

Әйе, уйнар чагым, сөяр чагым,
әмма узган яшь чагым,
ачыла тик
бала назларына кочагым.
Иртә килгән газапларны
аңлый алмас бирәү дә...
Мине киләчәктә аңлар кеше
синдер, бәлки, биләүдә?..
. . . . . . . . . . . . .
Кызым, син бу хатны
укыр яшькә килеп җиттең...
Ач конвертны...
Мине хөкем ит...
Унбиш яшьлек кызым,
сиңа гына әйтер сүзем бар:
топольләргә кара:
язга йөгермиләр, түземнәр...
Алар
чыдамлыкны тамыр итәләр,
яфраклары җилдә йөгерсә дә
сабыр итәләр...
Яшьлек — сафлык...
Кадерен белсәң генә саклана...
Кызым,
яшьлегеңә
соңлама да, чыгып чапма да...

*Ахыры киләсе санда.*

Мәхмүт Хәсәнов

# ШӨГЕРОВЛАР

1

Мәхүбә түти иртәнге кояшка сокланып зал тәрәзәсе янына килде. Иң элек җиңел пәрдәләрне як-якка тарткалап куйды, аннары болындай киң залның тоташ бер ягын биләп торган тәрәзәләрне ачып җибәрде.

Бүлмә эченә җиләс һава һәм тәрәзәләргә үк орынып үскән сәрби агачларының чак кына әчкелтем исе тулды. Мәхүбә түтинең ансыз да мөлдерәмә күңеле тагын да күтәрелде.

Шул чак искәрмәстән генә ишек ачылудан пәрдәләр җилфердәп китте, тәрәзә төбендә шау чәчәктә утырган гөлләр авып төшә яздылар.

— Әни! Әни дим...

Мәхүбә түти җәһәт кенә ишеккә борылды:

— Фу-у, билләһи! Өнемне алдың... — Шунда ук ул кызы Нәҗибәгә шауламаска кушып: — Тс-с! — дип, имән бармагын иреннәре янына китерде, кеше йоклый, янәсе.

Озак йөгерүдән маңгаена бөрчек-бөрчек вак тирләр бәреп чыккан Нәҗибә әнисенең бу кисәтүен колагына да элмәде, нәкъ баягы кебек, бөтен бүлмәне бер итеп сөйләнүен белде:

— Әни, әтине уят. Тиз бул! — Аның еш-еш сулыш алуыннан кыска җиңле аксыл төстәге күлмәге астындагы күкрәкләре күтәрелеп-күтәрелеп куялар иде.

Каушаудан һаман да бер урында катып торган Мәхүбә түти, ниһаять:

— Нәрсә бар? Ни булды дим бит мин сиңа?..— дип сорады.

— Менә телеграмма! — Нәҗибә тигез булып кояшта янган шәрә беләге белән маңгаен сыпырып алды, чәчләрен рәтләгәндәй итте.

— Ай, ходаем! Андый-мондый хәвефле хәбәр юктыр ич?

— Бар шул...

— Әстәгъфирулла! Нәрсә булган? Телеграмма кемнән?.. Әйт тизрәк.

— Мин үзем дә төшенеп бетә алмадым әле.— Нәҗибә, телеграмманы кабат кулына алды.— Кыскасы шул: безгә, ягъни Шөгеровларга, ниндидер мистер килә. Америкадан...

---

Романнан өзекләр.

Мәхүбә түти бу хәбәрдән соң, тотынып калырга җай эзләгәндәй, як-якка кулларын җәеп җибәрде.

— Ай-й, ходаем! Бу ни дигән сүз тагын?!. Безгә диденме? Бездә нәрсә калган ди ул әмеркәнгә?..

Шул чакта ишек катындагы тумбочка өстендә торган телефон шалтырады. Көтелмәгән хәбәрдән тәмам югалып калган Мәхүбә түти коелып төште. Трубканы Нәҗибә алды.

— Ал-ло! Әйе, әйе. Шөгеровлар квартирасы тыңлый. Кайсы Шөгеров дисезме? Корбан Шөгеровлар квартирасы.— Сөйләшү барышында Нәҗибәнең йөзе житдиләнгәннән-житдиләнә барды.— Әй-йе. Ишеттек. Яңарак кына телеграмма да алдык. Белмибез. Үзебез дә белмибез. Телеграммада кайсы Шөгеровка икәнлеге анык әйтелмәгән. Белмим. Бары тик «мистер Шөгеровка» диелгән. Бәлки бабайгадыр. Герой нефтьче бит. Нәрсә? Әйе, Ногман абыйга булуы да бик ихтимал. Ни әйтсәң дә, РИТС[1] начальнигы. Белмибез. Бер нәрсә дә белмибез. Бер нәрсә дә белмибез дим. Аптыраш та йөдәш монда. Ярар, әйтермен. Әтигә әйтермен дим. Хәзер уятабыз. Хушыгыз!

Сабырлыгы беткән Мәхүбә түти Нәҗибә сөйләшеп бетерүгә сорау бирде:

— Каян шалтыраттылар?

— Нефть-газ чыгару идарәсеннән. Нинди-дер «Кара алтын» короле, нефть магнаты килүе турында аларга да хәбәр иткәннәр.

Бу хикмәтнең серенә төшенә алмыйча тәмам гаҗиз булган Мәхүбә түти кулларын шапылдатып куйды.

— Минә сиңа тора торгач бер амин! Нәрсә булыр бу?..

Шул вакыт йокы бүлмәсеннән йорт хуҗасы Корбан чыкты. Ул пижамнан гына. Буй-сын килешле. Илле яшьнең өстендә булса да, гәүдә төз. Җилкәләр атлетныкы кебек. Беренче күрүдә үк бу кешенең нык ир икәненә ышаныч туа. Менә ул чал суккан чәчләрен сыпыргалап куйды да, өйдәгеләргә дәште:

— Нәрсә күреп пәри туе ясыйсыз? Бер хатын — өермә, ике хатын — давыл шушы буладыр инде.—Бу сүзләрне ачуланмый-тузгынмый гына әйтте Корбан.

Нәҗибә әтисе янына килде.

— Әти! Телеграмма бар. Безгә ниндидер миллионер килә. Америкадан.

— Нәр-сә-ә?! — Корбанның йокысы качып кына калмады, йөзенә берьюлы төкселек чыкты, кашлары җыерылды.—Америкадан дисеңме? Ни сөйлисең син?

Аннары, нинди тузга язмаган нәрсә лыгырдыйсың син дигәндәй, Нәҗибә кулындагы телеграмманы тартып алды. Җентекләп укып чыгып, әйләндергәләп тә карагач:

— Безгә түгелдер бу, кызым. Миллионер кадәр миллионерлар белән нинди алыш-бирешебез булсын ди безнең? — дип куйды да, искәрмәстән генә бик әһәмиятле нәрсәне исенә төшергәндәй, чәпелдәтеп маңгаена сугып алды.— Тукта, тукта! Америкадан диден бит әле? Бабаңа ич бу хәбәр! Аның әтисе, ягъни мәсәлән, минем бабай — Рамазан карт күпмедер вакыт Америкада яшәгән. Бабаңадыр, мөгаен. Бар әле, кызым, әлдереп кенә янына барып кил. Шундый-шундый хәлләр, диген.

— Бәлки сиңадыр, әти,— диде Нәҗибә, бер дә алай йөгереп чыгып чабарга ашыкмыйча.—Син дә атаклы нефтьче ич. «Почетлы нефтьче» дигән исемең дә бар... Үзең депутат. Мөгаен, сиңадыр. Узган юлы, чит ил делегатлары килгәч тә иң элек участокта булганнар иде ич.

Ул арада сүзгә Мәхүбә килеп кушылды.

---

[1] РИТС — район инженерлык-технология службасы.

— Бәлки Ногмангадыр? Ә?..— диде ул әһәмиятле сүз әйткәндәй итеп.— Яшь булса да урындагы кеше, нәчальник...

Корбан хатыны ягына кулын гына селтәде: синдә генә малайның алтыны, янәсе. Ул тагын нәрсәдер өстәргә теләп карчыгы ягына да борылган иде, тик өлгерә алмыйчарак калды, телефон шалтырады. Трубканы ул алды.

— Әй-йе!—Сул кулының учы белән телефон трубкасын каплады да, үзара әңгәмә коручы карчыгы белән кызына җикеренеп алды.— Тавышланмагыз әле! — Бары тик шуннан соң гына сүзгә кереште.— Ә-ә, Виктор Семенович! Исән-аманмы! Әйе. Алдык.— Һы-ы, алай икән! Нәрсә? Менә бит, ә! Үзебез дә аптыраган. Нәрсә? Каршы алырга дисезме? Соң. Анысында эш калмас. Ярар дим. Хәзер җыенам, алайса.

Корбан телефон трубкасын куйды. Тирләп чыккан маңгаен сөрткәләде. Аннары гына өйдәгеләргә сөйли башлады:

— Яңарак кына «Татнефть» берләшмәсеннән хәбәр иткәннәр. Сезгә атаклы бер нефть компаниясе хуҗасы, эре капиталист китте, тиешенчә каршы алыгыз, дип кисәткәннәр. Шәһәр комитеты вәкилләре, идарә җитәкчеләре хәзер аэропортка баралар. Мине дә үзләре белән алырга булдылар. Кая, сиңа әйтәм, киемнәрне чыгар. Теге, рәешкә кия торган костюмны бир. Орденнары тонықланмады микән инде?.. Ә син, кызым, бар, бабаең янына йөгер.

Әмма Нәҗибә чыгып китә алмый калды, ут капкандай кабаланып, керә-керешли үк тирләрен сөртеп, Шөгеровларның яшьрәк буын вәкиле, район инженерлык-технология службасы начальнигы Ногман белән аның сылу хатыны Гөлгөл килеп керделәр.

Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашулар да әпен-төпен генә чыкты. Кайнар табигатьле, үз дәрәҗәсен бик белүчән Ногман сорауны гадәтенчә кабыргасы белән куйды.

— Әти! Бу ни дигән сүз тагы? Бу нинди хәбәр? Бөтен Ак-Кала гөр килә. Нинди чакырылмаган кунак ул?

Бу көтелмәгән яңалыктан башы катыбрак киткән әти кешенең дә җавабы коры чыкты:

— Мин үзем дә синнән нәкъ шул турыда сорамакчы идем. Син бит ни дисәң дә, әнием әйтмешли, урындагы кеше...

Корбан кабалана-кабалана киенүен белде. Шулай да, сүз уңаенда, Ногманның ничек килүе белән кызыксынып куйды.

— Машина белән,— диде тегесе.

— Алайса, бар, бабаңа элдер. Кәефе булса, алып ук кил.

Ногманның алай җәһәт кенә чыгып элдерергә нияте юк, аның әле әйтәсе сүзләре, ачыклыйсы мәсьәләләре бар икән.

— Мин һаман да бер нәрсәгә төшенә алмыйм, без нәрсәгә кирәк булдык икән аңа?

— Үзеннән сорарсың,— диде һаман да әле галстугын рәтләп бәйли алмыйча азапланган Корбан.— Хәзер Ак-Калага килеп төшәчәк дип, яңарак кына шалтыраттылар.

Ногманның үз тугызы тугыз.

— Менә бит, ә! Авыртмаган башка тимер тарак шул буладыр инде. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән ниндидер миллионер...—Үзен яклаучыны да, фикеренә кушылырга омтылып торучыны да күрмәгәч, ул күңелендәгеген ачыклабрак әйтергә булды.— Берәр мөгез чыгарырга йөрмиме икән? Белмәссең аларны. Бабай әйтмешли, абруйлы исемебезгә тап төшереп куймыйк...

Бу сүзләр Мәхүбә түтине чын-чынлап сагайтты. Ул минем улым һәр чактагыча хаклы дигәндәй, ияген кагып куйды.

Ниһаять, Корбан киенеп бетте. Ул да Ногман сүзләрен колагы яныннан гына уздырып җибәрмәгән икән.

— Курыкма! — диде ул, тавышына чак кына үчекләү сыман киная өстәп.— Үзең төз булсаң, күләгәң кыек булудан өрекмә.

— Капиталист бит ул. Телгә керсәк...

Ата кеше янә улын бүлде:

— Керсәк керербез инде. Хәзер, син, мистер әфәнде, капиталист башың белән безгә килеп йөрмә инде, дип телеграмма сугып булмый.— Ул шифоньер көзгесе каршысына килеп кабат төзәтенде дә, карчыгына мөрәҗәгать итте.—Сиңа әйтәм! Килгәнне керт, алдына ипи-тоз куй, дигәннәр борынгылар. Белмәссең, бәлки чыннан да безгә киләдер. Килгән кунакның язугы юк. Һәрхәлдә, аш-су, табын хәзерли торыгыз. Йөзгә кызыллык килерлек булмасын.

— Мөмкин булырмы икән!

Барысы да дәррәү ишек ягына борылдылар. Анда җыйнаграк кына гәүдәле, йөзе генә түгел, ачык изүеннән күренеп торган күкрәкләре һәм беләкләренә кадәр чегәнгә охшап кояшта янган бер егет басып тора иде. Чәче кебек үк чем-кара мыегы сызылып киткән. Гадәттә үзенә ышанган кешеләрдә була торган туры карашлы күзләр. Бу егет Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институтының яшь белгече Рәхим Галимов иде.

— Корбан ага, мин сезгә килгән идем,— диде кунак, барысы белән берьюлы исәнләшкәннән соң.

— Рәхим ит! Әйдә, түрдән уз.

— Узып тормам. Шуны гына хәбәр итеп чыгыйм дидем: куст-насос станциясенең дүрт агрегаты да тулы куәткә эшли башлады. Химреагент агрегаты көйләнде, дозатор куелды. Кыскасы — башланды!

— Хәерле сәгатьтә булсын берүк! — дип куйды Корбан.

— Рәхмәтнең иң зурысы сезгә, Корбан ага!

Ул арада сүзгә Ногман кушылды. Башта сүзнең кайсы куст-насос станциясе турында баруы белән кызыксынды. Белүгә дөрләп кабынып ук китте.

— Позвольте! Ә кем рөхсәт итте? — дип сөрән салды ул.

— Сынауны 15 нче куст-насос станциясе участогында үткәрү турында сөйләшенгән иде бит инде,—диде Галимов.

Ногманның тавышы отыры көчәя барды.

— Кем белән? Кайчан?

— Идарәнең баш инженеры Власенко белән, — диде егет, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып. — Аннары, минә, участок начальнигы буларак, Корбан ага белән дә...

—Берни дә белмим, — дип карулашты Ногман. — Ишетәсезме, берни дә белмим! Икенче квартал тәгәлләнергә торганда куст-насос станцияләрен туктатырга беркем дә кушмас. Бу—йөзләрчә скважинаны нефть бирүдән туктату дигән сүз. Нииндидер колак ишетмәгән, күз күрмәгән тәҗрибәләр үткәрү өчен дәүләт планын өзмәсләр. Андый юлга басарга әтинең дә башына тай типмәгәндер. — Аннары тавышын чак кына уйнаклата төшеп янә сүз башлады ул. — Гаҗәп хәл! Барысы белән дә сөйләшенгән, бөтенесе белән дә килешенгән, служба начальнигы — мин генә бер читтә калганмын.

— Нишләп читтә каласың ди инде. Бу турыда син дә белдең. Бу сынауны Иванов участогыннан үзең күчердең ләбаса! — Бу сүзләрне тавышын күтәрмичә генә әйтте Корбан ага.

Көчлене көрәш көтә диләрме әле? Ачуын көчкә тыеп торган Галимов та авызын йомып тормады, үзе һөҗүмгә күчте.

— Бик яхшы белә ул! Кылана гына. Сукыр бер тиенгә тормаган принцибын гына яклый. Җыен тузга язмаган сәбәпләр табып сынауны соңгартты. Хәзер, әнә, бөтенләй аяк чалырга маташа... Әмма без үзебезчә иттек!

— Слушай, син! — дип җикерде Ногман, сүзнең бер дә үз файда-

сына юнәлеш алмавын сизенеп. — Ничек сөйләшәсең әле син? Бу ни бу? Үтенечме, әллә бугаздан буып таләп итүме?

Рәхимнең җавабы әзер иде:

— Монда формулировка нечкәлекләренең әллә ни әһәмияте юк.

— Бар! Бик бар! Хәзергә әле мин служба начальнигы.

— Кызганычка каршы.

— Һәм барысы өчен мин җавап та бирәм. — Аннары ул ачудан, гарьләнүдән буылу дәрәҗәсенә житеп, Корбан ягына борылды. — Әх-х, эти! Андый җаваплылыкны үз өстеңә алырсың дип уйламаган идем.

— Кемдер алынырга тиеш бит,— дип, иләп кенә әйтте эти кеше.

Ногман башлаган фикерен әйтә алмый калудан курыккандай өстәде:

— Менә күр дә тор, эти, кычкырып янабыз әле без бу тәҗрибә белән. Бу сынаулар бик кыйммәткә төшәчәк. Аннары кемдер диссертация якларга тели дип, җыен килде-китте тәҗрибәләр ясап ятарга бу бит эксперименталь лаборатория яки институт түгел.

Рәхимнең теле бу юлы да авызына сыймады.

— Хәзер безнең барлык промышленность предприятиеләре дә фәнгә нигезләнгән эксперименталь лаборатория. Һәркайда эзләнү, иҗат итү...

— Житте! Акыл сатма, зинһар! — дип кычкырды Ногман ачу белән янган күзләрен Галимовка текәп. — Ул да гыйльми дәрәҗә дип йөргән була бит әле...

Тормозларын чыелдатып, тәрәзә каршына килеп туктаган машина тавышы аның фикерен чуалтты.

— Әнә!—диде Корбан ага, ут капкандай өтәләнеп.—Мине алырга килеп тә життеләр. Әйдә, Ногман, син дә юлыңда бул.

Бүлмә эче кинәт тынып калды.

## 2

Күзләрең генә түзсен, өй эче тулы кояш. Һәркайда ул: ялтыратып буялган идәндә дә, шифоньер көзгесендә дә, аяклы телевизор экранында да, хәтта озынайтылган өстәл өстендәге фужер-рюмкалар һәм төрле савыт-сабаларда да.

Элегрәк: кунак килсә казан ас, ал кулыңа табагач, дия торган булганнар. Ул күркәм гореф-гадәт әле дә көчен югалтмаган.

Килен базга төшеп киткән арада, Мәхүбә түти Нәҗибәдән баягынак булып узган әйткәләшүнең сәбәбе турында сорашкандай итте. Ана күңелендә ай-һай ла авыр тәэсир калдырды бу әйтешү. Низагның сәбәбен кем-кем, ә аның кызы бик яхшы белергә тиеш. Бераз җилбәзәгрәк булуга карамастан, Нәҗибә бит ир-атлар белән беррәттән, инне иңгә куеп, нефть чыгаручы оператор булып эшли. Билгеле, ана кеше баштарак аның бу һөнәренә каршы төшебрәк маташкан иде дә, этисе кулы астында эшләячәген белгәч, тынычланды тагын.

Нәҗибә чыннан да хәбәрдар булып чыкты. Әлеге Рәхим атлы егет катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру юлларын эзли икән. Моның өчен ул ниндидер моңарчы күрелмәгән яңа төр химик реагент тәкъдим иткән. Әгәренки сынаулар уңышлы үтсә, егет гыйльми дәрәҗә, ә нефтьчеләр менә дигән яңа ысул алачаклар икән.

— Алай өметле эш белән йөргәч нигә соң абыең каршы?

— Начальниклыгын күрсәтмичә кала, янәсе.

— Дәшмә! Туган абыең турында шулай дияргә ничек телең әйләнә. Бераз ордым-бәрдем булса да, акыллы ул...

Шул чак төрле савытлар, пыяла банкалар асып, Гөлгөл килеп керде.

— Һай-й, килен! Алай берьюлы күтәрмәскә иде. Каячы алып куешыйм әле.

Үтә дә чая кызы белән килене бергә туры килгәндә эшнең барыбер рәте-чираты булмаячагын яхшы белгәнгәме, Мәхүбә түти Нәҗибәне йомшак икмәк-күмәчләр алып кайтырга йөгертте. Шунын өстенә әле анын килененә бер-ике авыз сүз дә әйтәсе бар иде.

Уптым-илаһи башламады. Башта яңарак кына беренче тешләрен күрсәткән нәни оныгы Борһанның сәламәтлеге белән кызыксынды. (Оланга Корбан аганың Бөек Ватан сугышында һәлак булган өлкән абыйсының исемен куштылар. Рахман карт гозере). Үлепләр сагынган, бик инде күрәсе килә икән Мәхүбә түтинең. Аннары, сүз уңаенда гына әйткән кебек кенә, тормышлары турында сорап куясы итте.

— Нәрсәдер җитми, әнкәй,—диде Гөлгөл, телемләп тураган редисларыннан күзләрен алмыйча гына. Аннары Мәхүбә түтине юатырга теләгәндәй, өстәп куйды. — Әллә инде эшкә кереп карарга...

Әни кеше «нәрсәдер җитмәвен» үзе дә бик яхшы күрә, монын өчен күзлек киеп торасы юк. Берара дәшмичә торды да, бик тә басынкысабыр тавыш белән телгә килде.

— Иң башта гаилә турында, аны саклау турында уйларга кирәк, килен. Гаиләнең бәхете дә, бәхетсезлеге дә ир белән хатын кулында. Үземә килгәндә, күбрәк өлеше хатын-кызлар кулында дияр идем мин. Миңа, килен, катлаулы, озын тормыш юлы үтәргә туры килде. Төрлесе күрелде. Ахыр чиккә җиткәндә дә: балалар хакына, элеккеге яратышуыбыз хакына дип, салкын кан белән уйлап, үпкә-ачуны эчкә йотарга өйрәнергә кирәк. Хатын-кыз — зур көч ул. Шуны бел, килен, ялгышу юллары ай-һай ла күп, иксез-чиксез, ә менә хакыйкать, дөреслек, чынлык юлы бер генә. Һәркем дә аны табу бәхетенә ирешә алмый. Тел төбемне аңлыйсыңдыр, тиз кыза, дуамаллана дип, артык каты бәрелә күрмә Ногманга. Ягымлырак бул. Назыңны кызганма. Өй җанлырак булсын. Үзең күреп торасың, хезмәте ифрат та авыр. Бик яшьли зур җаваплылыклар алырга туры килде шул аңа...

Нәҗибә кайтты. Өермә бәреп кердемени! Өй эче шунда ук ыгызыгы белән тулды. «Икмәк-күмәчләрен әллә баскыч төбеннән генә алып керде инде!»—дип уйлап куйды Мәхүбә түти. Хәзер инде башлаган сүзне дәвам итү турында башка да китерергә мөмкин түгел иде.

— Гөлгөл җаным, әйт әле,—дип шәрран ярып башлады Нәҗибә, — кунакны син ничегрәк күз алдыңа китерәсең? — Гөлгөл җилкәләрен генә сикерткәч, үзе үк дәвам итте. — Мин аны менә болайрак итеп күз алдыма китерәм: өстендә елкылдап торган смокинг, муенда — менә мондый бант, башта цилиндр. Авызда беләк юанлыгы сигара. Ә үзе кыска аяклы, апара корсаклы.

— И-и, кит инде! — диде Гөлгөл төксе генә.

— Ә ник? Абый әйтмешли, капиталист ич ул! — Шундый инде ул Нәҗибә, һәр вакыт шат, башын артка атып көләргә аңар гына куш.— Шаярам гына, Гөлгөл җаным! Карасаң, сокланып туймаслык бер кешедер әле. Бәлки... туган тиешле кешебез кайтадыр.

Бу юлы инде Мәхүбә түти түзмәде:

— Тфү, тфү!.. Авызыңнан җил алгыры. Җүнле сүз әйтәме дисәң...— дип ачуланып алды

—Ә ник, әни? Өлкән бабай берничә ел Америкада яшәгән ди ич. Бу фани дөньяда ниләр генә булмас дисең. — Аннары ул Гөлгөлгә генә ишетелерлек итеп.—Берәр чибәргә күзе төшкәндер дә... Иеме?— дип мутланды.

— Җитте, диләр сиңа! Әнә, эшеңне кара. Нинди булса шул булыр, әтиең әйтмешли, килгән кунакның язгы юк.

Берара мәйханә килеп алдылар: кухнядагы аш-сулар тикшерелде, духовкадагы камыр ашларын карадылар. Әмма олы якка чыгу белән Нәҗибәнең теле янә авызына сыймады.

— Чыннан да, ниндирәк икән? Яшь микән? Чибәр микән? — Шунда ук тавышын уйнакландырып дәвам итте. — Хәер, яшьлеге корсын иде лә! Өйләнмәгәнме икән диген син! Икмәктер газим, тәки башын әйләндереп, Америкасын оныттырыр идем.

— Тфү-ү, биллаһи! Син җилкуарның авызыннан бер сыңар гына булса да җүнле сүз чыгармы, юкмы?!

Әнисенең сүзләрен колагына да элмәде Нәҗибә.

— Әгәр дә мәгәр, Нәҗибә апагыз, миллионер хатыны булып алсамы, ну-у, яшәп тә күрсәтер иде. — Кинәт ул күркә кебек кабарып, борынын яман чөеп идән буйлап китте. Әйләнеп өстәл янына килде. Җирәнгән сыман итеп, өстән аска карап, беркавым Гөлгөлгә карап торды. — Син кем?

Шаярырга дисәң тегесе дә төшеп калганнардан түгел:

— Минме? Мин, галиҗәнаб — миллионерша. Сезнең туган тиешле кешегез булам инде, ягъни киленегез...

— Фи-и! Килен дә булдымы туган! Килен кеше ким кеше, алабайга тиң кеше, димәсләр иде аны.

— Һай-й, Нәҗибә апа, җаныкаем! Койган да куйган госпожа миллионерша инде менә.

Бу юлы Мәхүбә түти дә түзмәде, тавыш-тынсыз гына көлеп алды. Шулай да ул Нәҗибәне җиңелчә әрләп алды:

— Һай, җитәр сиңа, кызым, тукта дим. Шул җилкуарлыгың аркасында адәм рәтле тормыш та кора алмадың...

— Һай-й, алла! Ирдән уңмаганга мин гаеплеменни!

— Шундый җилъяклы булсаң, уңмассың да! Иртә уңмаган кич уңмый, кич уңмаган һич уңмый, димәсләр иде аны.

— Уңармын! Унга чыгармын, уңганчы чыгармын. Ачуымны бик китерсәң... шул миллионерга ияреп Америкага китеп барырмын. Икмәктер газим менә, шул булыр. Кәсеп итсәң, насыйп була, ди ул.

— И-и, телләре шуның! Тилчә чыккыры! — Мәхүбә түти тәмам өметен өзгән кеше сыман итеп Нәҗибә ягына кулын гына селтәде.

Шул вакыт тышта машина килеп туктаган тавыш ишетелде. Иң беренче булып тәрәзәгә Нәҗибә барып капланды.

— Әни! Бабай килде.

Сизелеп тора, өйдәгеләр өчен бу зур вакыйга иде.

Күп тә үтмәде, ишектә Рахман карт күренде. Аның артында Ногман. Өйдәгеләрнең барысы да картны ишек янына барып каршыладылар.

— Әйдәгез, әйдә, бабай!

— Түрдән узыгыз!

— Менә, бу тирәгәрәк утырыгыз!..

Рахман карт бусага аша атлап керү белән өйгә ниндидер пакьлек иңгән кебек булды. Яше сиксәннең өстендә булуга да карамастан, килеше-торышы, буй-сыннары бик килешле. Өстендә чесуча пиджак, кара чалбар. Аягында җиңел сандаллар. Өстенә ятып торган пиджагының күкрәк кесәсеннән чак кына югарырак Алтын Йолдыз тагылган. Орден-медаль ише нәрсәләр юк. Башында чак кына кырын салынган велюр эшләпә. Мыек чолгыйлары матур итеп кыскартылган, чиста итеп кырылган. Чал сакалы пөхтә генә итеп, нәкъ татарча, түгәрәкләндереп калдырылган.

— Исән-имин генә яшәп ятышмы?

Сәламне беренче булып Мәхүбә түти алды.

— Бик шөкер әле хәзергә, әткәй! Үзең ару гына йөрисеңме?

— Хәзергә аякта әле. — Карт яшьләр ягына борылды. — Исәннәрме, оланнар!

Күгәрченнәр кебек гөрләшә торгач, ниһаять, картны йомшак кәнә-

фигә китереп утырттылар. Мәхүбә түти һаман да шул тирәдә кайнашты.

— Каячы, балалар, бабагызга чәй хәзерләгез әле!

— Юк, юк! — дип карышты карт. — Мәшәкатьләнмә, килен, әле яңарак кына табын яныннан куптым.

Өйдә калганнарның хәл-әхвәлләре белән кызыксыну башланды. Бераздан әңгәмә кискен борылыш ясап, әлеге дә баягы, кайтып төшәсе кунакка күчте. Моның сәбәпчесе Ногман иде. Бу хәбәрнең бераз пошаманга төшерүен яшереп-нитеп тормады ул.

— Аптырама да, йөдәмә дә, — дип, салмак кына башлап китте Рахман карт. — Эш кешесенә мең төрле кешенең эше төшәр, ди. Килә икән, килә бирсен. Нәрсә шул кадәр пошаманга калдың әле? Димәк, йомышы төшкән.

Ногман аклангандай итенде:

— Ниндидер бизнесмен диләр бит...

— Булса соң! Океан арты кунагы тикмәгә генә йөрми торгандыр. Йөртерсең капиталистны юкны бушка аударттырып!

Абажур аша яктылык сирпелеп торган кебек, Рахман картның да әле һәр сүзендә, тавышында, хәрәкәтләрендә акыл, зирәклек, фикер байлыгы сизелеп тора иде.

— Каягыз әле... — диде ул урынында кыймылдап. — Телеграммага мин дә күз төшереп алыйм. Чыннан да Шандор дигәнме?

Күз ачып йомганчы телеграмма аның кулында иде. Берме, икеме тапкыр укып чыкканнан соң гадәттәгечә сабыр-тыйнак тавыш белән әйтә салды:

— Болай булгач, оланнар, бар да аңлашылды.

Яшьләр, әллә белә иденме дип, дәррәү шаулашып алдылар.

— Мин белмим, — диде Рахман карт янә җайлап кына сүзгә керешеп. — Әмма, минем әтием, ягъни сезнең дәү бабагыз, Шандорларның берсен бик яхшы белгән. Аңа ияреп, хәтта Америкага ук киткән булган...—Шушы урынга җиткәч ул яшьләрне чынлап торып өнсез иткән сүз ычкындырып ташлады. — Әгәр дә хак булса, безнең ыруга, ягъни безнең нәселгә «Шөгеров» дигән фамилияне дә шул Шандорларның берсе биргән, дип сөйли торган иде әткәй мәрхүм.

Шунда Нәҗибә:

— Ишетмәсәң ишет, колагың булса тишек, — дип куйды.

Ногман да урындыгын бабасы янынарак шуыштырды:

— Ничегрәк булган соң ул хәл? Сөйләче, бабай.

— Сөйлә инде, бабай!

Карт, сүз башын таба алмаган сыман, берара тын утырды. Аннары башлады.

— Узган гасырның сиксәненче елларында бөтен дөньяны «нефть бизгәге» биләп ала. Безнең бу яклар да читтә калмый. Америка геологы һәм капиталисты Шандор килеп чыга...

Шул вакыт Ногман нәрсәдер исенә төшерергә теләгәндәй:

— Шандор, Шандор... Нишләптер, бик таныш исем кебек, — дип куйды.

Сүзе бүленгән Рахман карт елмайды. Аннары әйтте:

— Таныш булмыйни! Безнең нәсел чыккан Шөгер авылы өстенә аварга торган тау исеме ич.

— Бәс! Чыннан да шулай бит!

Барысының да күзе яңадан картка текәлде. Ул уйламаган- көтмәгән җирдә өзелеп калган сүзен дәвам итте:

— Соң, шул! Әлеге капиталист, әтинең туган авылы Шөгер белән Сарабиккол авыллары янында, берьюлы ике скважина бораулый башлаган. Өчме, дүртме ел дәвам иткән эш. Минем әтием шул Шандорга бораулаучы булып эшкә ялланган. Әнә, каян тиңентен килә безнең

нәселдә нефтьчеләр династиясе! Шуннан шул. Җир-ана океан артыннан килгән килмешәккә үз хәзинәсен ачмый, җиде йозак артына яшерә. 200—300 метр чамасы бораулаганнан соң, Шандор инструмент-җиһазларын сындырып, җир астында калдырып, кире кайтып китәргә мәҗбүр була. Менә шул...

— Син, бабай, безнең ничек итеп «Шөгеровлар» булуыбыз турында сөйләмәкче идең, — диде Ногман. Һәм шунда ук өстәде. — Ничек соң әле без моңарчы бу турыда белмәгәнбез?

Карт мыек астыннан гына елмайды.

— Нәрсәгә кирәк иде соң ул? Әллә фамилияң ошамыймы?

— Алай димим ич. Ничек итеп Шөгеровлар булганбыз дип кенә соравым.

— Ошамаса да берни эшләр хәл юк. Ата-ана белән исем-фамилияне сайлап алмыйлар, булганына шөкерана кылырга туры килә.

Сөйлә дә сөйлә дип, яшьләр тагын кысрыклый башлагач, карт ризалашты. Нәкъ баягы кебек итеп салмак-тыйнак кына, сүзләрен сайлап кына башлады.

— Әти, мәрхүм, ул турыда мәзәк итеп сөйли иде. Аның әтисенең, ягъни минем бабайның исеме — Мөэмин-мөхәммәт булган. Шул. Мистер Шандор эшкә ялланучыларның исем-фамилияләрен терки башлаган. Әтинең фамилиясен дөрес итеп яза алмыйча тәмам иза чиккән теге. Бер кабатлата, ике, өч... Алай да эш чыкмагач, тота да: «Татар», дип язып куя. Бу хәл дә ярдәм итмәгән. Чөнки ялланучылар арасында татар бер минем әти генә түгел, шактый. Ахыр чиктә Шандор, әтинең Шөгер авылыннан икәнен исәпкә алып: «Шугурский» дип теркәгән дә куйган. Соңрак инде, башкаларның фамилиясенә охшатып, Шөгеров дип йөртә башлаган. Менә шуннан бирле без Шөгеровлар булып киткәнбез.

Рахман карт бер мәл тын утырды.

— Ә инде әтинең Америкага ничегрәк барып чыгуына килсәк, янә гыйбрәтле хәл. Ачлык-ялангачлык куган аны туган якларыннан. Җеннәре өзелгәнче эшли торганнардан бит безнең нәсел. Әти дә эшкә бик уңган була. Уңган кеше — ун кеше, диләр бит. Шандор чат ябыша моңа, эш, акча вәгъдә итеп Америкага чакыра. Җан асрарлык та чут калмагач, әти ризалык бирә. Нишләсен! Элек бик фәкыйрь булган безнең бу яклар. Йөдәү-җитмәүчелектән адәм баласының башы чыкмаган. Менә шул, оланнар, Америкадан әти беренче революция алдыннан гына кайта. Шушында башлы-күзле була. Мин дөньяга килгәч, безне ала да, ал-лю-ю, Баку ягына!.. Шунда революцияне каршылый. Шунда кулына корал алып пролетар Шөгеров булып йөри. Яшь Совет властен яклый. Соңыннан инде атаклы нефтьче булып китә. Күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган, ничәмә-ничә илләр кичкән, тугыз дәрья суын эчкән, күп төрле телләр белгән ифрат та чая, батыр, дөньясын авызлыкларлык кеше иде, мәрхүм...

Тормозларын яман чыелдатып машина килеп туктаганы ишетелде дә, әңгәмә өзелде. Һавада очкан күбәләкләр кебек, ярым пышылдап әйткән сүзләр генә колакка чалынды:

«Кайттылар! Алар!..»

Барысы да диярлек аякланды. Басып торганнары ишеккә таба атлап куйдылар. Бу минутта барысы да фәкать киноларда, телевизорларда гына күрергә туры килә торган чын капиталист күрергә җыенганнар иде.

Бераздан ишектән ах-вах килеп, тирләп-пешеп Корбан ага кайтып керде. Аны урап алып шунда ук мең төрле сораулар белән күмеп ташладылар. Кайсыдыр хәтта: «Чын миллионермы?» — дип сорап куйды. Икенчесе шунда ук: «Юк, юри-мүри миллионер», — дип җавап кайтарды. Корбан ага гына җавап бирерлек хәлдә түгел, тәмам

әлсерәгән, хәлдән тайган иде. Иң әлек ул түше тулы орден-медальләр белән бизәлгән костюмын салып куйды. Күлмәк изүләрен ычкындырды. Шуннан соң гына утырып телевизор карый торган караватдиванга барып ауды. Чак кына хәл җыйгач турайды һәм җилкәсеннән тау төшкән кеше сыман тирән итеп бер сулыш алды да, бер тын белән бер генә сүз әйтте:

— Килде!..

Яңадан сораулар ява башлады. Иң төплесен Рахман бабай бирде, океан арты кунагының нинди йомыш белән килүе кызыксындырды аны.

Корбан ага як-якка җәеп салган аякларын җәһәт кенә җыйды, гәүдәсен турайтты. Аннары остазы сорауларына җавап бирергә җыенган шәкерт кебек, Рахман картның йөзенә туп-туры карап, кунакның нинди йомыш белән килгәнлеген аңлата башлады. Кыска гына итеп әйткәндә, ул түбәндәгедән гыйбарәт икән. Бу якларда булганда, Шөгеровларның бабайларын Америкага алып киткән өлкән Шандорның үлгәндә васыятьнамә итеп калдырган язуын ачып карасалар, күрәләр: Рамазан Шөгеровның да фидакарь хезмәтен онытмаган, мирасыннан аңар да күпмедер өлеш чыгарган. Мистер Шандор шул әманәтне үтәргә дип килгән икән.

Бу хәбәр янә барысына да аяз көнне күк күкрәгәндәй тәэсир итте.

— Шуңа дип атап килгәнме?— дип сорап куйды кайсыдыр.

— Юк. Зуррак йомышлары да булган, ахры. Аларның концернnары безнең Түбән Кама нефть-химия комбинаты белән бәйләнештә икән. Берьюлы нindидер сәүдә договорларына кул да куясы бар ди...

Корбан ага, сүз уңаенда, кунакны өч-дүрт машина белән зурлап каршылаулары турында сөйләп китте. Хәзерге вакытта кунакны «Девон» кунакханәсенең дүрт бүлмәле люксына урнаштырганнар. Шәһәр башкарма комитеты кунак карамагына дип, әле яңарак кына кайткан «Волга»сын билгеләгән. Чөнки мистер Шандор гади бер бизнесмен генә булмыйча, АКШ департаментының почетлы әгъзасы да икән.

Кабат: «Үзе ниндирәк? Яшьме, картмы? Килеш-килбәте ничегрәк? Үзе генә килгәнме?» — дигән сораулар ява башлады.

Корбан ага бу юлы да бер авыз сүз белән җавап бирде:

— Төп-төгәл ике сәгатьтән үзе бездә кунакта булачак, шунда күрерсез, — диде.

## 3

—Алар төгәл халык. Төгәллек — аларның аерылгысыз сыйфаты!— дип, Ногман әледән-әле сәгатенә караштырды.

Корбан аганың кунакны каршыларга дип чыгып китүенә дә шактый вакыт үтте инде. Тагын берничә минуттан кунак килергә тиешле вакыт та җитәчәк. Киеренкелекнең чамасы юк. Бөтенесе дә аяк өсте. Табын да, аш-су да әзер.

Нәҗибәнең искәрмәстән генә:

— Килделәр! — дип шәрран яруыннан барысы да коелып төште. Мәхүбә түти исә: «Ай-й, ходаем!» — дип, авып ук китә язды.

Ул да булмады, Нәҗибәнең:

— Уф-ф, үләм! Негр ич, — дип кычкырып җибәрүе янә барысының да өнен алды.

— Юк, юк, апакаем! Шоферы гына негр. Әнә, машина ишеген дә негр ачты. Әнә... милионер үзе. — Гөлгөл оста репортер кебек тезде дә тезде.— Әнә, эткәй дә. Әнә, идарә начальнигы Виктор Семенович. Ә менә боларын белеп бетермим. Шәһәр башлыклары, ахрысы...

Ишектә иң беренче булып Корбан ага күренде. Ул:

— Мистер Шандор, әйдәгез, рәхим итегез! — дип, кунакны өйгә үтәргә чакырды.

Ниһаять, кайчаннан бирле түземсезлек белән көтеп алган кунак үзе дә күренде. Аның артыннан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Төхфәтуллин Хәлил Әмирович бусага аша атлап керде. Кунакның буй-сыны яшьләрнеке кебек зифа. Гәүдә төз. Кием-салымы үзенә сылап куйгандай ятып, килешеп тора. Өстендә күкбаш чәчәгенә охшаш төстәге костюм. Күз явын алырлык ап-ак күлмәк. Манжетлары күренеп тора. Муенында куе зәңгәр төстәге җыйнак кына бант. Шул бантта елык-елык килеп ниндидер күзгә күренми торган кыйммәтле ташлар җемелди. Әгәр дә мистер Шандорның ак чигәләрен, чал суккан чәчләрен һәм күз тирәләрен бизәгән җыерчыкларын күрмәсәң, аны һичшиксез егет кеше дип уйлар идең.

Ул арада Корбан ага кунакны түрдә басып торган Рахман карт янына алып китте.

— Менә, мистер Шандор, Шөгеровлар нәселенең иң өлкәне. Минем әтием!

Кунак иң элек карт Шөгеров алдына килеп баш иде. Аннары нәкъ мөселманнарча итеп ике куллап күреште. Бары тик шуннан соң гына:

— О-о, мистер Шөгеров! Исәнмесез-саумысыз!.. — дип, саф татар телендә исәнләште.

— Әйдүк, әйдүк! Исән-имин генә килеп җиттегезме? Бездә кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач, диләр. Бик, бик шатбыз. Әйдүк, кем, түрдән рәхим итегез!

Кунак янында торган җыйнак кына гәүдәле яшь ханым картның сүзләрен бары тик мистер Шандорның үзенә ишетелерлек итеп тәрҗемә итте. Яшь ханым мистер Шандорның тылмачы икән. Исеме Җәмилә. Махсус чакыру буенча әле яңарак кына Казаннан килеп төшкән. Педагогия институтының чит телләр кафедрасы хезмәткәре.

Менә мистер Шандор Мәхүбә түти алдында басып тора. Мәхүбә түтинең куллары аның кулында. Мәхүбә түти дә елмая. Ә үзе: «Шулай яшәп ятыш, менәтерәк дөнья көтәрлек уллар, кызлар үстердек», — дип сөйләнгән була.

Ниһаять, мистер Шандор сүзгә кереште. Ул иң элек дөнья тотнагы хатын-кызлар, аналар алдында түбәнчелек белән тез чүгәм дигән кебегрәк тантаналы сүзләр әйтте дә, күзләрен түшәмгә төбәп, гыйбадәт кылгандагы сыман, очы-кырые күренмәгән сүз башлады.

Сөйләде дә сөйләде. Мондый хәлне моңарчы күргәннәре булмагангамы, баштарак, ничектер, сәеррәк тоелды. Күпмедер вакыт нотык тотканнан соң, мисс Җәмилә, тәрҗемә итегез, дип сүзне тылмачына тапшырды.

Шул ук мизгелдә сылу ханымның авызыннан үз телебездә, дисбе сыман тезелгән сүзләр коела башлады.

— Дөньяда хатын-кызлар күп, кешелекнең яртысын алар тәшкил итә, — ди икән мистер Шандор. Аннары болай дип дәвам итә: — Әмма хатын-кызларның берсенә бөтен кешелек мәдхия укый: Ул — ана! Чөнки әниләр, нәкъ кояш кебек, бар нәрсәнең башы, тереклеккә җан бирүче... һәм башкалар һәм башкалар.

Нәҗибә белән Гөлгөл җилтерәтеп кул чаптылар.

Танышу дәвам итте. Ниһаять, чират Нәҗибәгә җитте. Ул шундый итеп киенеп-ясанган, башта мистер Шандор аңа карап, ирексездән туктап калды.

— О-о, мисс, исәнмесез! — дип сокланып куйды.

— Саумысез, сэр.

— Сез дә Шөгеровлар нәселеннәнме?

— Әй-йе, сэр.

— Менә сез нинди икән татар хатын-кызлары! Болай булгач, бар да аңлашылды, — диде мистер Шандор, сүзенең эчтәлегенә серле мәгънә салып.

— Нәрсә аңлашылды, сэр?

— Америкада булган бабаегызның берни белән дә санашмыйча туган иленә ашкынуына хәзер төшендем кебек. Ә бит бабай аңа йортжирләр вәгъдә иткән, өйләнергә өндәп караган...

Кунакның соңгы сүзләре тәрҗемә ителгәннән соң әңгәмәгә Рахман карт кушылды.

— Эх-х, кем, мистер туган! Каламы соң?!. Чит-ят җирдә яшәү түгел, үлүе дә авыр, ди. Билгеле, кояш кайда да бер, диләр. Әмма туган иле булган кешегә кояш икеләтә яктырта. Адәм баласы туган җире, изге туфрагы, суы, урманы белән бәхетле.

Кунакны Гөлгөл белән таныштырдылар. Танышу, аның инженер Ногман Шөгеров хатыны икәнлеген белү, сылуларның сылуы булып саналган Гөлгөлнең кулын кысу белән чикләнде. Мистер татар хатын-кызларына тагын бер кат мәдхия укымыйча булдыра алмады.

Сүзгә янә Рахман карт кушылды. Ул күзләре белән генә елмаеп: «Иллә мәгәр мут та кеше икәнсең!» —дип, кунакка бармак янап алды.

Мистер Шандор ялт тылмачы ягына борылды: нәрсә ул «мут», янәсе. Җәмилә тәрҗемә итү белән рәхәтләнеп кычкырып көлеп җибәрде.

— Мут дисез, алайса? Шәп әйтелгән! Хөрмәтле мистер Шөгеров! Кешегә сәламәтлек, илһам, куәт, аның күзе аша керә ди бит. Бездә хәтта сау-сәламәт булыйм дисәң, яшел үләнгә, агым суга, сылу хатынкызга кара, дигән мәкаль дә бар.

Рахман әйтте:

— Гаиләң, бала-чагаларың бармы соң? Бардыр, билгеле.

— Бар, бар, хөрмәтлем. Бар! Шушындый сылуларны күреп йөрәгең ешрак типми икән, ул чагында беттең, син инде кеше түгел, ә ярым мәет...

Танышуны дәвам иттеләр. Ниһаять, чират Ногманга җитте. Корбан аганы гомере буе гид вазифасын үтәгән диярсең. Үз эшен җиренә җиткереп башкара.

— Менә, хөрмәтле мистер Шандор, Шөгеровларның дүртенче буыны. Әмма соңгысы түгел. Тупырдап торган оныгыбыз да бар.

Ногман мистерны танцыга чакырырга теләгән кебек бик килешле генә итеп башын иде. Кунакның сузган кулын кысты. Әмма яшь Шөгеровның нindидер җаваплы урында инженер булып эшләве турында ишеткәч, кунак туктап калды.

— Мистер Шөгеров, әгәр дә рөхсәт итсәгез, сезгә соравым бар иде.

— Рәхим итегез, сэр!

— Кайда белем алдыгыз дип сорамакчы идем мин.

— Мәскәүдә.

— О-о! Нәрсә бетердегез?

— Губкин исемендәге нефть институтын.

— Ә анда ничек керә алдыгыз? — Кунак урынсызрак сорау биреп уңайсыз хәлгә калган кеше сыман итенде. — О-о, аңлашыла. Гафу, гафу! Мистер Шөгеровлар нәселеннән икәнлегегезне хәтеремнән чыгарганмын.

— Монда династиянең катнашы булмады, сер.

— О-о, әлбәттә, әлбәттә!

Ул арада унган, дәгъвасыз Мәхүбә түти, картының терсәгенә генә кагылып, кешеләрне табын янына чакыра башларга кушты.

Шау-гөр килеп өстәл тирәсенә утырыштылар. Түр башында — мистер Шандор белән Рахман карт.

— Хөрмәтле кунагыбыз, мистер Шандор, — диде Корбан ага табында сүз җанланып киткәч, — бу яклар сезнең өчен чит-ят җир түгел, монда, якында гына, сезнең бабагыз, ягъни өлкән Шандорның сатып алган тавы да бар.

Бу хәбәр әллә нишләтеп җибәрде кунакны. Урыныннан сикереп торды: «Ничек?!» дип сорау бирүен үзе дә сизмичә калды.

Корбан ага мистер Шандор ягына күз төшереп елмайды да, чак кына сабыр итегез, барысын да төшендерермен дигән сыман, дәвам итте.

— Халык Шөгер авылына орынып торган шул тауны әле дә булса «Шандор тавы» дип йөртә. Океан артыннан килгән бабагыз турында: җүнле, кешелекле иде, дигән фикер, төрле риваятьләргә бәйләнеп, буыннан-буынга күчеп килә. Хәер, халыкның күңеленә хуш килерлек кеше булмаса, калфак энҗесе сыман табигать бизәге булып торган тауга аның исемен бирер идемени?!.

Бу хәбәр кунакны тәмам тетрәндерде, ахрысы. Җәмилә ягына кырыная төшеп, Корбан ага әйткәннәрнең барысын да җөпләп, ияген кагып утырган мистер Шандорның күзләре дымланды. Беравык, күңеле тулган кеше сыман, башын түбән иеп утырды. Тик озакка түгел. Әнә ул, күңелендә нинди хисләр кайнавын елмаюы белән аңлатырга теләгәндәй, яңадан ай кебек балкып табын түрендә утыра.

— Сүзегезне бүлгән өчен гафу итегез, мистер Шөгеров, — диде ул, Корбан агага мөрәҗәгать итеп. — Ул тау хәзер дә бармы?

— Кая китсен ул? Үз урынында тора бирә.

— Һаман да «Шандор тавы» дип йөртеләме диюем.

— Әйе. Һаман да Шандор тавы дип йөртелә. — Корбан ага кабат елмайды да өстәде. — Ул турыда, әнә, эти миннән күбрәк белә. Аның белән бер гәпләшерсез әле. Күтәрдек бу тостны, кадерле дуслар.

Кемнәрдер тостны хуп күреп, җиңелчә генә кул чабып алдылар. Аннары тост әйтү өчен сүз мистер Шандорга бирелде.

Ул аягүрә басты. Сүзгә керешкәнче, куен кесәсеннән шактый саллы китап сыман нәрсә чыгарды. Табындагыларның кайберәүләре: берәр сәгатьлек лекция сөйләмәсен тагын дигәндәй, үзара елмаешып куйдылар. Кунак кесәсеннән алган кенәгәгә карамыйча гына сөйли башлады:

— Хөрмәтле әфәнделәр! Ханымнар, кунаклар! Бу якларда кайнар эзләре калган бабаем, разведка эшләре алып барганда, зинһен дәфтәре булдырган. Ул анда татар халкының кайбер гореф-гадәтләрен язгалаган. Татар телен дә өйрәнгән булса кирәк: шактый күләмле сүзлек тә төзегән. — Мистер Шандор әлеге китапны кулына алды. — Менә ул дәфтәр. Үзем белән алып килдем. Шушы язмаларында бабай: татар халкы бик фәкыйрь яши дип язган...

Кунакның сул ягында утырган Рахман карт мистер Шандорның сүзен раслагандай болай дип куйды:

— Әй-йе! Әти мәрхүм: тормышыбыз шундый бетешкән, исеннән исерерлек иде, дип сөйләгәне хәтеремдә.

— Бу зинһен дәфтәрендә, мәсәлән, — дип дәвам итте мистер Шандор, — сезнең бабайларыгыз тормышы турында мондый сүзләр бар. Өй урынына җиргә иңеп утырган җир идәнле бер алачык. Аның сыңар тәрәзәсенә үтәдән-үтә күренмәле нинди дер тире тартылган...

— Анысы карындык инде аның, — дип, янә тавыш биреп куйды Рахман карт.

Шандор кулындагы дәфтәреннән күзләрен алмыйча дәвам итте:

— Менә тагын: өйләрендә өреп очырырлык та ризык булмас иде... Шунда ук: кечкенә керсәләр, шул алачыкларын яктырту өчен чыра яндыралар иде дигән сүзләр дә бар...

Баядан бирле кыбырсып утырган Ногман түзмәде, кунакның сүзен бүлдерде:

— Гафу итегез, сэр! Сез киләчәге булмаган халык турында сөйләгән кебек итеп, һаман да үткән заманны сурәтлисез.

Онытынның урынлы-урынсыз сүз бүлүен Рахман карт бик үк килештереп бетермәде, ахрысы, аны урынына утыртты.

— Зарар юк, әйтсен! — дип әлеп алды кунак. — Яшь буын һәркайда да шулай. Чак кына тынгысыз, чак кына дуамал, чак кына мәшәкатьлерәк була торгандыр инде. — Мистер Шандор, фикер җебен югалтудан курыккан сыман, яңадан дәфтәрен кулына алды. — Әйтергә теләгәнем шул. Васыятьнамә язганда бабаем шуларның барысын да күзаллаган булгандыр инде. Һәм, хәлләнеп-тернәкләнеп китмәсләрме дип, ярыйсы гына сумма билгеләгән.

— Буржуй булса да адәми тойгысы булган икән мәрхүмнең...— дип куйды Рахман карт.

Кунак сүзен кыска тотты.

Тосттан соң өч-дүрт минут үтүгә, мистер Шандор яңадан игътибар үзәгендә иде инде. Әлеге кенәгәсе яңадан кулында.

— Хөрмәтле әфәнделәр һәм ханымнар! Бабаемның зиһен дәфтәрендә тагын менә мондый сүзләр бар: «Татарлар нечкә күңелле, бай хисле, гаять моңлы халык...» — кунак китабыннан күзләрен алды да, ни әйтергә теләгәнен бу юлы да елмаюы белән аңлатты.

— Аның заманы моң-зар тулы булгандыр инде, кем, мистер әфәнде. Хәзер яшәү дә, җыры да бүтән, үзе дәртледер, үзе илһамлыдыр...

Рахман бабай фәлсәфә саткан арада Корбан ага карчыгына гына аңлаешлы ишарә ясады. Минут үттеме икән, аның кулына ялтырап торган җиз телле тальян гармун менеп кунаклады. Ансыз да җыйнак гармун, Корбан ага кулында уенчык кебек кенә булып калды.

Өй эче тулы кунакларның шау-шуы әкренләп тынды, уен-көлке басылды. Һәм, ниһаять, күңелләрне үзенең сихри моңы белән күмеп, һәркемне күзгә күренми торган тылсымлы җепләре белән бәйләп, «Иске кара урман» көе яңгырады.

Җырны Корбан ага үзе башлады. Тиз арада аңа Ногман кушылды.

> Заманалар авыр, михнәтләр күп,
> Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Ул да булмады, җырга Нәҗибә белән сылу Гөлгөл иярде. Ә аларга табын янында утыручылар да кушылды. Хәтта тылмач Җәмилә дә җырлый иде.

> Карурманны чыккан чакта,
> Кисеп алдым пар каен;
> Ай-й, айрылмаек, дускаем!..

Уннарча тавыш белән күтәреп алынган көчле ташкын, өй эченә генә сыеша алмыйча, ачык тәрәзәләр аша Ак-Каланың киң урамнарына ташып чыкты. Кемнәрнедер, барыр юлларын бүлеп, хәйран-тамаша кылып туктап калырга мәҗбүр итте.

Иң шаккатканы, әлбәттә, мистер Шандор иде. Үз ихтыярын такмаса да, хуҗалар аның теләген ярты сүздән аңладылар. Бердән, хуҗаларга хөрмәт-рәхмәте чиксез булса, икенчедән, үзе өчен бөтенләй ят милләтнең могҗизалы, үзенчәлекле, әмма һичшиксез тетрәндергеч җырын ишетү бәхетенә иреште.

Җыр мең төрле кошлар сайравыннан, күкеләр кычкыруыннан уянган җәйге урман шаулаган сыман авазлар белән тәгәлләнде.

— О-о, яхшы! Браво, браво! Бик яхшы. Рәхмәт! — дип, мистер Шандор урыныннан ук кузгалып, Корбан агайга баш иде.

Шуннан соң берничә минутка тәнәфес игълан ителде. Шау-гөр ки-

леп урыннарыннан куптылар. Ир-атлар, ачык балкон янына килеп, тәмәке кабыздылар.

Шул чак ирләр төркеме янына Гөлгөл йөгереп килде:

— Әткәй, сезне телефонга сорыйлар...

— Әйе, тыңлыйм... — диде Корбан ага телефонга гадәттәгечә тыныч кына. Әмма бу тынычлык шунда ук икенче бер халәт белән алышынды. — Нәрсә?!. Кайчан, хәбәр иттеләр? Кайсы скважина? Ник аны алданрак шалтыратмадыгыз? Ну-у, егетләр!.. Хәзер үк барып житәрмен. Кичекмәстән нефтьне туктату чарасын күрегез. Нәрсә?!. Һы-ы, алай икән!.. Шул гына житмәгән иде ди. Хәзер килеп житәрбез. Бригаданың башка члennарын да жыю чарасын күрегез. Тиз булыгыз!

Нәжибә әтисе янында иде инде.

— Нәрсә, әти?

— Бөтенләй көтелмәгән урыннан нефть бәреп чыккан.

Бу хәбәр Ногманны да өнсез итте.

— Нәрсә?! — диде ул, катгый-кырыс тавыш белән.— Димәк, авария? Кайсы участокта?

— 15 нче куст-насос станциясе районында.

Ногман шушы сүзне генә көтеп торган кебек элеп тә алды:

— Әһә-ә! Менә, ниһаять, башланды да: Рәхим Галимов тәжрибәсе бу, башка берни дә түгел. Әй, әти!.. Бер түгел, мең әйттем мин сиңа. Алынма, дидем, рөхсәт итмә, дидем. Менә нәтижәсе! Аның шушылай төгәлләнәсе көн кебек ачык иде.

— Бәлки әле башка сәбәптер, — диде Корбан ага төксе генә. — Шундыйрак хәл Узган елда да булган иде.

Ногман аны ярты сүздә бүлде.

— Узгандагы тәжрибә бүгенге өчен начар киңәшче.

Озак сөйләшеп торырга вакыт та, мөмкинлек тә юк иде инде. Корбан ага рәеш киемнәрен сала башлады. Нәжибәгә дә тиз генә киенергә кушты.

— Мин дә сезнең белән, — диде Ногман, шунда ук чыгып йөгерергә жыенгандай жилкенеп.

Ул арада алар янына Рахман карт та килеп житте.

— Нәрсә? Ул-бу бармы әллә?

— Әйе, бар, — диде Корбан, эленеп торган эш киемнәрен йолкып алып. — Бөтенләй көтмәгән-уйламаган, консервировать ителгән скважинадан нефть бәреп чыккан. «Маяк» колхозының сугарулы көтүлеген баса ди хәзер.

— Н-дә-ә!—дип куйды карт, чигәсен кашыштырып.— Нишләп скважинаны гына япмыйлар икән соң?

— Бөтен бәла дә шунда, яба алмыйлар ди. Скважина тәмам «таланып» беткән, задвижкасына кадәр сүтеп, демонтировать итеп алганнар ди.

Корбан ага, улы ягына борылып, тиз генә машинасын кабызырга кушты. Тегесе, менә шулай да була ул дигәндәй, үзенең ризасызлыгын белдереп сукрана-сукрана чыгып китте.

— Син, әти, кунакларыбызның мәжлестәше була тор инде. Ничек булса да күңелләрен күр. Без әллә ни озакламабыз, кайтып житәрбез.

— Барыгыз, бар! Ничу монда. Беренче чиратта — эш! Кунаклар өчен борчылмагыз, үзем карармын.

## 4

Тәбын янында нибары өч кеше калды: Рахман карт, мистер Шандор һәм тәржемәче Жәмилә.

Гөлгөл, килен кеше буларак, дәү әтисе тирәсеннән читтәрәк булу ягын карады. Ул кухняда, Мәхүбә түти янында кайнашты.

— Вәли үз эшендә, Гали үз эшендә дигәндәй, әйдә, мистер әфәнде, икәү генә кәефләнеп утырыйк әле.

— Була ул, хөрмәтле мистер Шөгеров!

— Һай-й, бәхетең арткыры! — Рахман карт кунак ягына борылып ук утырды. — Карап-карап торам да, хет алдың, хет артың, әйтим әле, зерә дә чос кеше икәнсең. Баштарак, килде китте кеше түгел, миллионер, тиңсенмәс, диебрәк уйлаган идем. Юк, карусыз бәндә икәнсең.—Аннары Рахман карт, искәрмәстән генә җитдиләнеп, — мистер Шандор!.. Бер генә сорау бирергә җөрьәт итим әле, — диде.

Тегесенең авыз ерык, берне түгел, меңне бир, янәсе.

— Актык чутта, әйтик, ул васыятьнамә дигән нәмәстә нигә моңарчы исегезгә төшмәде икән дип сорамакчы идем мин. Әманәт җан саклар ди бит.

Мистер Шандорның йөзендәге ваемсыз елмаю җил тузгыткандай юк булды. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, кунак мондый сорауны, әлбәттә, көтмәгәндер. Әмма ул үзен бик тиз кулга алды. Күзләрне чагылдырып, тирә-юньгә нурлар чәчеп торган кыйммәтле таш куелган алтын балдаклы имән бармагы белән ике каш арасын кашыгандай итте дә, җайлап кына сүзгә керешт:

— Әй-йе, мистер Шөгеров, күп еллар үтте, күп сулар акты. Бабаемның үлүенә дә тиздән кырык ел тула. Бу сорауга җавап биргәнче, безнең илне, безнең экономиканы күзаллау кирәк. Кризис, бигрәк тә әледән-әле кабатланып торган энергетика кризисы, экономик экспансия дигән нәрсәләрне яхшы белергә кирәк. Бездә экономика нәкъ йөгән-ияр күрмәгән кыргый ат кебек. Күп вакыт чәйнәп тә тормыйлар, кабып кына йоталар. Безнең нефть бизнесы аҗруча буталчык, һич белеп булмый, бизнесменнар сугышалармы, әллә сөешәләрме? Никадәр каты куллы бабай да бер-ике тапкыр бөлгенлеккә төшә язды. Бабай үлгәч, эти бәхетсезлеккә тап булды... Конкурентлары юлларыннан алып ташларга теләгәннәр аны: машинасын бәрдереп челпәрәмә китергәннәр. Әти хәзер дә коляска белән генә йөри.

— Н-дә-ә! Сезгә дә акча колһуалла укып кына табылмый икән шул.

— Бездә, ирекле бизнеска корылган илдә, конкурентлык законнары катгый һәм мәрхәмәтсез. Анда аерым кешеләрне юк итү чебен үтерүгә дә тормый. — Мистер Шандор тынып калды. Аннары картның йөзенә сынаулы караш белән текәлеп сорап куйды. — Мистер Шөгеров! Мин сезгә шактый ук күңелсез нәрсәләр турында сөйлим булса кирәк, ә?

— Зарар юк, — диде Рахман карт, — дәвам итегез.

— Тик дөрес аңлагыз, мистер Шөгеров. Бу сүзләрне мин акланыр өчен түгел, хәлне ачыклау өчен генә әйтәм. Әтием, ярым мәет булуына да карамастан, өлкән Шөгеровны эзләткән. Берничә тапкыр Баку белән элемтәгә кергән. Чөнки Шөгеров бабайга язган хатларынын берсендә, Бакуда нефть скважиналары бораулаучы булып эшлим, дип хәбәр иткән. Әмма Бакудан да төпле җавап килмәгән. Аннары инде бөтен капиталистик илләрне котычкыч кризис күләгәсе каплады... Андый вакытта кеше кайгысы бетә. Библиядә дә: кеше, башта үзүзеңә ярдәм ит, дигән сүзләр бар. Хак сүзләр! Кемгәдер ярдәм кулы сузганчы үзеңнең бай, үзеңнең бәхетле булуың шарт. Югыйсә, ярдәмеңнең куанычы, бәхетеңнең тулылыгы булмаячак... — Бер мизгелгә генә сузылган паузадан соң кунак тирән итеп көрсенгән кебек итеп әйтте, — ә аннары инде, белгәнегезчә, сугыш! Бездә, Россиянең ярты халкы кырылып бетте, дип сөйләделәр.

Рахман бабай да үзалдына гына сөйләнгән сыман итеп болай диде:

— Н-дә-ә!.. Ул сугыш афәте, ул сугыш зилзиләсе безнең Шөгеровлар нәселен дә читләтеп узмады. Ике улым кайтмады...

— Без дә шулайрак булгандыр дип уйладык. Чөнки күпме генә кызыксынсак та, сезнең турыда канәгатьләнерлек җавап ала алмадык.

Рахман карт мәҗлестәшен бөтенләй ишетмәгәндәй сөйләнүен белде. Бу минутта анын тавышы бигрәк тә картларча иде.

— Их-х, нинди баһадирлар иде! Аларның батырларча һәлак булулары турында хәбәр алгач, военком янына барып, мине дә фронтка җибәрүләрен сорадым. Күпме генә үтенсәм дә, күпме гозерләсәм дә ишетергә дә теләмәде. Ничәнчедер тапкыр баргач әйтте бу, үзең, Рахман туган, син үзең нибары бер солдат. Ә син чыгара торган нефть меңләгән самолетны һавага күтәрә, тоташ тимер ташкын булып дошман өстенә ябырыла торган меңнәрчә танкны хәрәкәткә китерә. Әгәр дә җиңүебезне тизләтергә телисең икән, ике кеше, өч кеше кадәр эшлә, диде бу. Шулай иттем дә. Тәүлекләр буе буровойдан чыкмаган чаклар күп булды. Культбудкага бары тик радио тыңларга гына керә идек. Шуннан бирле сугыш минем күз алдыма шул тәлинкәле кара репродуктор булып килеп баса. Күптән гамәлдән чыккан шул репродукторларны кайда да булса күргәндә әле дә булса йөрәгем жу-у итеп китә.

Сүзгә кунак та кушылды:

— Әй-йе! Минем дә бер туган абыем Европада башын салды. Гомуми дошман — фашизмга каршы көрәштә Икенче фронт ачылгач һәлак булды.

— И-и, гомерләр! — дип кабат башлады Рахман карт. — Искән җилмени, уза да китә икән. Хәзер инде, әнә, төпчек улым Корбанның оныгы бар. Без картаймый кем картайсын.

— Шул инде, мистер Шөгеров! Дөнья — дәрья, вакыт — давыл, буыннар дулкыны берсе икенчесен алыштырып кына тора.

Рахман карт шунда бик әһәмиятле нәрсәне исенә төшергәндәй:

— Мистер Шандор, безне ничегрәк табуыгызны сөйләп бетермәдегез бит әле, — дип куйды.

— Ә-ә, әй-йе! — дип элеп алды тегесе. — Барысы да бабайның әлеге көндәлек дәфтәреннән башланды. Анда ул ике сүзнең берендә «татарлар» ди. Безнең нефть компаниясе Түбән Кама нефть-химия комбинаты белән эшлекле элемтәгә керде. Катлаулы технологик җиһазлар саттык. Шунда мин Түбән Кама шәһәренең кай тирәдәрәк булуы белән кызыксындым. Татарстанда диделәр. Вәкилебезнең чираттагы килүендә сезнең белән, ягъни Шөгеровлар белән, кызыксынуын үтендем. Беренче уңай хәбәрне шунда алдым. Аннары инде Мәскәүгә, үзебезнең илчелеккә мөрәҗәгать иттек. Алар СССР нефть промышленносте министрлыгы белән элемтәгә керделәр. Һәм, менә, мин сездә кунакта утырам.

Икесе дә чын күңелдән көлешеп алдылар.

— Үзең әйтмешли, браво, мистер Шандор!

Мәҗлестәшләр бер-беренә сәламәтлекләр теләделәр. Әңгәмә дәвам итте. Сүз һәр континент, һәр җәмгыять, һәр сыйныф өчен уртак булган мәхәббәткә күчте.

— Мәхәббәт — ул хосусый милекнең бер төре, — диде Шандор. — мәхәббәт мәсьәләсендә «минеке» дигән төшенчәне без хәзергә инкарь итә алмыйбыз. Хәттә сез дә. Һәркемнеке була ала торган, яки анда кулдан-кулга күчеп йөрүче сылуларны без башка исем белән атыйбыз. Хаклымы мин, мистер Шөгеров? Ә?

«Бу ут күз белән итәк-чабуыңны җыештырыбрак утырмасаң, барып чыгарсың, нибуч...» дип уйлап куйды карт. Әмма сер бирмәде. Янында утырган кунагын җилкәсеннән кочаклап, үзенә таба якынайт-

ты. Аннары, елмаеп-нурланып утырган Җәмиләгә мөрәҗәгать итеп, болай диде:

— Кызым, әйтеп бир әле үзенә. Чуштеки, ниҗитте кеше түгел ул. Молодец, дияр идем мин аны!

Кунакка да бу зирәк карт белән утыруы шактый кызык иде булса кирәк, һәрхәлдә, ул канәгать, йөзеннән елмаю төшми.

— Мин түгел, хөрмәтлем, сез молодец! Сезне әле бер дә туксанынчы яшьне куа дип әйтмәссең. Үзегез әйтмешли, мөхтәрәм кеше сез. Мәскәүдә нефть промышленносте министры янында булдым. Йомыш белән. Хәтта ул, Рахман Рамазанович минем якын дустым, диде.

Бу сүз картка җитә калды.

— А как-же! Безнең якларда булганда минем янга сугылып чыкмыйча киткәнен хәтерләмим. Безнең Дмитрий Илларионович алтын кеше ул!

Мистер Шандор картның түшендәге Алтын йолдызларның нәрсә өчен бирелгәнлеге белән кызыксынды.

Картның җавабы кыска булды:

— Нәрсә өченме? Эшләгән өчен.

Кунакка янә кызык, янә мәзәк.

— Эшләмәгән кеше юк ул, мистер Шөгеров. Әмма һәркем «Герой» түгел бит.

Рахман бабай кем беләндер бәхәсләшкән кебек җавап кайтарды:

— Димәк, мин башкаларга караганда әйбәтрәк эшләгәнмен булып чыга. Зинһар, гафу итә күрегез, бераз мактанып җибәрдем бугай. Бетте, бетте! Бел, алайса, кем, мистер әфәнде... — Ул күкрәгендәге медальләргә төрткәләп, — менә, монысын Бакуда бирделәр. Диңгезгә кереп «кара алтын» фонтаны бәрдердек. Икенчесен монда, туган якларымда алдым. «Ромашкино» дип йөртелә торган атаклы нефть ятмасын ачуда катнашкан өчен бирделәр.

— Әй-йе, мистер Шөгеров! Дан, шөһрәт дигән нәрсә җиңел генә бирелмидер инде ул.

Рахман карт җилкәләрен генә җыерып куйды.

— Төрлесе булгандыр инде, кем, әфәнде. Мин үзем һичкайчан да дан-шөһрәт артыннан кумадым. Дан дигән чир белән авырган кешедә алга, яңалыкка омтылыш кебек изге бер көч сына, яшәешнең яме калмый. Ә гомер бер генә бирелә. Тормыш ул җил уйнатып уза торган тигез асфальт кына түгел. Сез дә, әнә, бик ансат кына яшәмисез икән ич: чәйнәшәбез, тузгынабыз, дисең...

— Сез хаклы, хөрмәтлем. Бездә тоташтан көрәш! Мәрхәмәтсез көрәш... Нишләмәк кирәк. Безнең гасыр тимер бишектә туган. Шуңа күрә дә контрастларга юмарт ул. Безгә авыр, ә менә информацияләр ташкыны, йолдызлар урынына ясалма иярченнәр астында туган буынга тагын да яманрак булачак.

Океан артыннан килгән кунакның миллионер башы белән менә шулай әңгәмә корып утыруы Рахман картка бик ошый, күңеленә бик хуш килә иде булса кирәк.

— Карап-карап торам да, шактый акыллы кеше син. Чын әгәр!

— Рәхмәт, рәхмәт, хөрмәтлем!

— Вәт, рәхмәт төшкере!.. — дип башлады Рахман карт, очып китәрдәй булып җилкенеп. — Шул тиклем җирдән безне эзләп килдем диген, ә?!

— Вәгъдә — иман, васыять — изге, диләр бездә.

Рахман бабай күзләренә чак кына хәйлә-мәкерлек чаткылары чыгарып дәвам итте:

— Күп еллар үткән, үзең әйтмешли, күп сулар аккан, үткән эшкә салават дип, бу кадәр мәшәкатьләнеп йөрмәсәң дә ярасы булган. Ях-

шы якка бераз ялган да ярый ди бит. — Н-дә-ә!.. Әйтик, әлеге акчаны без алмадык ди. Ул чакта нәрсә?

— Алай итмәссез дип уйлыйм. Бабаемның Шөгеровларга дип адарынган акчасы ул.

— Әммадәки без хәзер синең бабаң белгән Шөгеровлар түгел.

— Барыбер. Шөгеровлар нәселе.

Шул чакта Рахман картка әллә нәрсә булды. Кинәт кенә читкә борылып йөзен куллары белән каплады. Мистер Шандор да каушап калгандай булды, өлкән Шөгеровны үзенә таба борып йөзен ачты. Тегесенең күзләре дымланган иде.

— Нәрсә булды, хөрмәтлем?— диде кунак, тавышын мөмкин кадәр йомшартып.

Карт исә оялып башын ияргә мәҗбүр булды.

— Зинһар, кем, мистер Шандор, гафу итә күр! Кичер. Әллә нәрсә шунда... Кагылып-сугылып, каңгыраеп бәхет эзләп җир читенә китәргә мәҗбүр булган әтием исемә төште. Туып-үскән җирләреннән бәгырь кылларын өзеп чыгып китүләре җиңел булгандыр дисеңме?.. Аның өзгәләнеп: бәхетне аны, улым, чит-ят җирләрдән эзләмә икән, дигән сүзләре әле дә күңелем түрендә. — Аннары Рахман карт кулын селтәде. — Ярар, кем... Ул турыда житәр. Әйдәче, булмаса, бер гөрләшеп утырыйк әле.

Мистер Шандор Рахман карттан бабасы турында, аның бая әйтелгән тауны ничегрәк сатып алуы турында сөйләвен үтенде.

— Ничек дип, шул инде. Көннәрнең берендә, үзе белән ниндидер чиновникларны ияртеп, Бөгелмә ягыннан килеп төшкән бу. Җыен җыйдыртканнар. Шунда бабаең Шөгер авылына орынып торган әлеге тауны сатуларын сораган.

— Сатканнармы?

— Башта ризалык бирмәгәннәр. Авыл картлары, ил терәкләре, аяк терәп каршы торганнар. Соңыннан бабаең, ияреп килгән рус чиновниклары киңәше беләндер инде, җыенда катнашучылар алдына икеме-өчме чиләк аракы китертеп куйган.

— Шул хәл иткәнме?

— Юк. Аракы да ярдәм итмәгән. Безнең татар халкы андый эш белән шөгыльләнми дип, янә кире борганнар бабаеңны. Соңыннан Шандор җан исәбеннән чыгып авыл халкының иманасын, ягъни оброкның бер төрен түләргә вәгъдә иткән.

— Түләгәнме?

— Сүзендә торган. Авыл картлары: тау башы барыбер уңдырышсыз, кысыр җир дип, риза булганнар. Бары тик шуннан соң гына әлеге тауга бабаең хуҗа булган. Вәгъдәсендә тора белгән кеше иде дип сөйләгәне бар әти мәрхүмнең бабаең турында. Алай гына да түгел, сабан туйларында, башка төрле бәйрәмнәрдә ярлы-ябага балаларына акча өләшә, конфет-прәннек ише әйберләр алып бирә торган булган. Менә шул. Әле дә булса халык ул тауны «Шандор тавы» дип йөртә.

— Күрергә мөмкин булырмы икән ул тауны?—дип сорап куйды кунак.

— Ә как же! Хет иртәгә. Үзем алып барырмын. Шөгер минем дә туган авылым бит.

— Рәхмәт, мистер Шөгеров. — Мистер Шандор чак кына уйга калган кебек утырды. Һәм шунда ук яңадан карт ягына борылды. — Тагын бер соравым бар иде.

— Рәхим ит, кем, хөрмәтле әфәнде.

— Нишләп шул тау янына килеп туктаган ул? Бабаемны әйтәм. Сәбәбе нәрсәдә?

— Тикмәгә генә түгел, әлбәттә. Аңача инде башкорт ягыннан килгән Надыйр Уразмәтов дигән бер бәндә шул тау итәгендә дегет базы казыткан булган. Хәзергечә итеп әйтсәк, битум чыгарган. Әмма ниндидер сәбәпләр аркасында эшен дәвам итә алмаган, китеп барган. Бөлгән икән дигән хәбәр таратканнар.

Рахман карт бу турыда хәзергә җитәр дигән кебек кулын селтәде. Аннары ул искәрмәстән генә «Шөгер» көенә кычкырып җырлап җибәрде.

Тальян гармун уйнаталар
Безнең Шөгер буенда;
Ятсам-торсам, керсәм-чыксам,
Тик син генә уемда...

Шөгерләргә барам әле
Шөгер суы тәмлегә;
Бир кулынны, мин дә бирәм
Аерылмаска мәңгегә...
Их-х-ма! Әйт шуны!

5

...Корбан ага үз кешеләре белән килеп җиткәндә, сызгырып-пошкырып газ катыш нефть фонтаны бәреп яткан скважина тирәсе җир валлар белән әйләндереп алынган иде инде. Моны, бульдозерлар ярдәмендә, «Маяк» колхозы механизаторлары эшләгән.

Мастер иң элек кешеләргә скважина янына килмәскә, бигрәк тә ут-күздән сак булырга кушты. Скважина һаман да әле кемгәдер ачулангандай ысылдый, тончыккан сыман авазлар чыгарып нефть фонтаны ата иде.

Корбан ага иске плащ алып баштанаяк бөркәнде дә, обваловка эченә керде. Шактый җыелырга өлгергән нефть күлдәвәсен ерып үтеп скважинага якынайды. Җир өстенә эңгер иңгәнгәме, берни дә күрә алмады.

Ул тиз генә үзләре утырып килгән вахта машинасының фаралары яктысын скважина авызына юнәлдерергә кушты. Ялт итеп ут кабынганны гына көткән кебек, тирә-юнь шунда ук караңгылык кочагына чумды.

Ләкин бу чара да ярдәм итмәде, ут көлтәсе бары тик аяк астын, шыксыз ялтырап яткан нефть күлдәвәсен генә яктырта иде. Яктылыкны скважинаның авызына күтәрү өчен машинаның алгы көпчәкләре астына махсус басмалар куярга туры килде.

Ләкин өзлексез ыргып торган фонтан аша скважина авызындагы торбаның диаметрын күз белән чамалап булырлык түгел иде. Бригада членнарының: «Мастер, кая үзебез!..» — дип туруларына да карамастан, фонтан астына Корбан ага үзе керде. Торбаны куллары белән капшап карады. Бәхеткә каршы, алып килгән арматура да, задвижка да скважина торбасы белән бер үк диаметрда иделәр.

— Фонтанны томаларга хәзерләнергә! — дип әмер бирде мастер.

Ул арада операторлар машинадагы җиһазларны җиргә бушаттылар. Скважина авызына арматураны утырту эшенә Саттар Кәрамов белән Геннадий Аракчеев алынды. Корбан ага аларга ярдәм итәргә булды. Башкалар да тик тормыйлар, кемнәрдер фланецларны хәзерли, хатын-кызлар һәркайсы ким дигәндә беләк буе болтларны барлыйлар, икенче берәүләре авыр ачкычларны хәзерлиләр.

Иң җаваплы минутлар якынлашты. Саттар белән Геннадий чишенеп ташлап трусиктан гына калдылар. Әмма башларына каска, аяк-

ларына итекләрен киеп алдылар. (Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең таләбе шундый). Егетләр, хезмәттәшләренең гөр килеп көлешүләре астында, тәртә сыман колга табып, фланецлы задвижканы күтәреп тә алдылар. Минут үттеме икән, егетләр инде нефть фонтаны астында иделәр. Алар күз алдында кап-кара төскә кереп, кешедән бигрәк, тырыш кырмыскаларга охшап калдылар. Фара уты яктысында егетләрнең чуеннан коелган сыман ялтырап торган гәүдәләренең очынып-җилкенеп хәрәкәтләнүләре генә күренде дә, ара-тирә: «Болт, гайка, фәләненче ачкыч», — дигән тавышлары гына яңгырап торды. Корбан ага алар янында иде.

Бу четерекле эш шактый вакытны алды. Көтеп торучылар өчен әлеге минутлар аеруча озак булып тоелдылар, ахрысы.

Иң элек Геннадийның: «Хәзер була!» — дигән көр тавышы ишетелде.

— Соңгы болтны ныгытабыз! — дип өстәде Саттар.

Ниһаять, Геннадийның нефть фонтаны астыннан:

— Булды! Все в порядке Корбан ага, ябып карыйммы? — дигән сүзләре яңгырады.

— Валяй, Геннадий!..

Фонтанның яраланган аждаһа кебек сызгырып ыжгыруы әкренләп кимеде, бераздан тончыккан сыман бөтенләй тынды.

— Молодцы, егетләр!

Бер-берен бүлә-бүлә сөйләшүләр, гөр килеп көлешүләр башланды. Ләкин әле бу шактый ук четерекле эшнең башы гына иде. Мәшәкатьнең олысын — бу нефть күлдәмәсенең эзе дә калмаслык итеп җыештыруны иртәгә, якты көнгә калдырырга булдылар. Анысы инде эшнең үтә авыры, күмәкләп керешә торганы.

Иң элек, шау-гөр килеп, егетләрне баштанаяк солярка белән юдылар. Күпмедер вакыт маташканнан соң, Саттар белән Геннадий, ниһаять, кеше кыяфәтенә керделәр. Шулай да алар, күлгә төшеп, су коенып менәргә булдылар.

Хатын-кызларга җитә калды.

— Нефть душы гына җитмәдемени әле!

— Хатыныңа да бераз эш калсын.

Корбан ага куе күләгә кебек кенә булып күренгән әрәмәлек янына якынлашканда операторлар суда мәш килиләр иде инде.

Корбан ага яшь таллыкка керде. Һавасы җанга рәхәт, сулап туйгысыз. Сукмак коры, әмма куаклыкларга кагылсаң шыбырдап борчак кебек эре чык коелып кала. Су өстендә ак томан әлпәсе. Күл эчендә чупырдаган егетләр үзләре күренми, сүзләре генә тирә-юньне яңгырата.

— Ах-х, шәплеге!

— Сөйләмә дә! Каймак диярсең инде менә.

Җәйге төнне тикмәгә генә бер саплам димәгәннәрдер. Әнә, тау ягы чак кына алсуланып торды да, күзләрне чагылдырып, кояшның беренче зөбәрҗәт нурлары күренде. Табигатьнең сокланып туймаслык бер мизгеле! Әлеге күл буендагы үзәнлектә хәзер катламланып иртәнге томан гына тирбәлә, кулыңны сузсаң, аның дымсу салкынын тоярсың кебек.

Җыенып кайтып китәргә генә торганда, «Маяк» колхозы председателе Җәүһәрә Сабировна килеп чыкты. Аны күрү белән нефтьчеләр: «Ну-у, булачак икән сафура бураннары!» — дип, бер мәлгә тынып калдылар.

— Күршеләргә сәлам! — диде председатель, машинасыннан чыга-чыгышлый. Килеш-килбәте ирләрнекенә тартым аның. Буй-сынга да тазаның. Әмма хәрәкәтләре житез, өлгер. Йөргәндә омтылып атлый, барып җиренә тизрәк барып җитәргә теләгәндәй, ашкынулы адымнар. Хольк-

фигыле хәрәкәтләренә бераз ятышмый сыман: ифрат та каты куллы диләр аны. Бигрәк тә исерекбашлар белән яман кылана, ди.

Корбан ага белән, бик күптәнге дусларча, кул кысышып исәнләште председатель.

— Син, Җәүһәрә күрше, йокы белән тату түгелсең, ахры,— дигән булды мастер, сүзне уратыбрак башларга җыенып.

— Вакыты шундый, Корбан абый.

— Шулайдыр, шулайдыр.

Димәк, председательнең үз шефлары белән ачышлы булырга нияте юк. Югыйсә, ризасызлыгын яшереп-нитеп тора торганнардан түгел ул, ник күзләрең атылып чыкмый шунда, турыдан яра.

Моны сизенеп алган Корбан ага кыюлана төште.

— Ә хәзер, Җәүһәрә туган, турысын гына әйт: безгә карата дәгъвагыз зурмы?

— Юк ла! Каян килеп зур булсын, ди. Егетләребез бик тиз чамалап алдылар.

— Аларга безнең рәхмәтебезне белдерегез.

— Шулай итәрбез.

— Менә, Җәүһәрә туган! — дип дәвам итте мастер.— Бер дә орынып торган күршеләр дип тормыйбыз, әледән-әле мәшәкать ясыйбыз үзегезгә.

— И-и, Корбан абый! Сезнең белән орынып торган күршеләр булуыбызга сөенеп бетә алмыйбыз. Сез күрсәткән яхшылыкларны, сез кылган игелекләрне, борынгычарак итеп әйтсәк, бер алла үзе генә белә.

— Рәхмәт, Җәүһәрә күрше. Кулдан килгән кадәр ярдәм итә алуыбызны шулай бәяли белгәч, бик рәхмәт инде.

— Әнә, туктаткансыз да бит инде,—дигән булды председатель. Ә үзе Корбан аганы култыклап скважина тирәсенәрәк алып китте. Җәүһәрәнең ниндидер йомышы барлыгын мастер шунда ук төшенде. Әмма сер бирмәде, сөйләнүен белде.

— Туктатып кына калмыйбыз әле аны. Бүген үк көндез килеп элек тамчысын да калдырмыйча нефтен суыртып алабыз. Аннары, тирә-юньне тигезләп, җирнең өске катламына кара туфрак түшәп куячакбыз.

— Бик һәйбәт! Бәлки әле йомып та калып булыр.

— Анысы булмас, кем, Җәүһәрә күрше.

— Ник алай?

— Алай йомып кала торган вакыйга түгел бу.

— Сезгә дә тел-теш тидерерләрме?

— Баштан сыйпамаслар, билгеле. Хәзер ул мәсьәләгә бик җитди карыйлар. Табигатьне саклау — илне саклау белән бер хәзер.

Җәүһәрә зарлы, инәлгән тавыш белән дәвам итте:

— Нинди гөнаһ шомлыклары булды соң әле бу?! Ничәмә-ничә еллар тик торган скважина иде бит ул. Без инде аның бар икәнлеген дә оныткан идек. Тора иде шунда киәксез торба башына ошап. Кинәт кенә нефть бәреп чыгуын күр инде, ә?

Корбан ага, ярты сүздә бөтенесен берьюлы аңлатып бирергә теләгәндәй, әйтте:

— Хикмәте бар аның кем, Җәһәрия. Яңа төр химик реагент куллана идек.

— Шулайдыр, шулайдыр. Тикмәгә генә мондый хәл килеп чыкмас.— Җәүһәрә тынып калды. Аннары, ни булса шул булыр дигәндәй, ярды да салды:— Корбан абый, зур гына йомышым бар иде сезгә. Килешеп бетмәс. Әмма башка чара юк.

Мастер елмаймыйча булдыра алмады.

— Сизәм бит, баядан бирле кыбырсып торуыңнан ук күрәм. Әйдә, әйтсәң әйт инде.

— Гаепкә алма инде, Корбан абый. Әлеге дә баягы, һаман «бир» дип кул сузу инде. Сезгә шефыбыз дип тә, депутатыбыз буларак та, ил олысы итеп тә мөрәҗәгать итү. Озын сүзнең кыскасы шул: бераз торба кирәк иде.

— Һы-ы, алай икән! Нинди рәк торба соң?

— Яз көне алган идек ич. Нәкъ шундыйлар.

— Күпме кирәк булыр?

— Яңа ферма бинасына су кертергә иде. Бер километр чамасы булыр ул ара...

— Эшләрбез,—диде мастер ипкә килгән кеше сыман итеп.—Моннан бер атна гына элек ике скважинадан мең ярым метр чамасы торба чыгарылды.— Корбан ага куен кесәсеннән блокнотын чыгарып, шуңа нәрсәдер сызгалады да, язган битен ертып алып председательгә тоттырды.— Менә шушы кәгазьне цех начальнигы Ишкәев иптәшкә бирерсең. Кайчан һәм каян алырга икәнлекне үзе әйтер.

— Нинди генә рәхмәтләр әйтергә инде сезгә, Корбан абый! Сездән күргән яхшылыкларны, картларчарак итеп әйтсәк, алладан да күрмәссең. Иллә мәгәр олы җанлы, киң күңелле кеше булырсыз икән!

Мастер ярар ла дигән сыман итеп кулын гына селтәде. Җәүһәрә Сабировна башта гафу үтенде, аннары саубуллаша башлады.

Корбан ага үз урынына, алдагы урыннарның берсенә кереп утыру белән, автобус кузгалып китте. Ул да булмады, гөр килеп, әле яңарак кына машинасына утырып авыл ягына китеп барган председатель турында гәп сатарга керештеләр.

— Валлаһи әгәр! Беттек, мин әйтәм, була икән хәлләр.

— Әйе, талканы коры диләр аның.

Шул чак Саттар, барысын да авызына каратып, Җәүһәрә Сабировна белән бер егет арасында килеп чыккан вакыйганы кызыклы мәзәк итеп сөйли башлады. Егет тә шул ук Зирекле авылыннан, ди. Әмма туган авылын ташлап Ак-Калада производствода эшли икән. Әлеге егет, Октябрь бәйрәмендә бугай, авылына кунакка кайткач клубка килә. Менә без кем, дип мактанырга кирәк бит, бераз кабып та килгән бу. Бөтен клубны бер итеп йөри ди теге: кызларны чырылдата, егетләрне дә тотып җилтерәткәли. Шунда клубка председатель килеп керә. Күпмедер вакыт әлеге егетнең кыланышларын күзәтеп тора. Аннары түзми, тегене якасыннан эләктереп ала да, иң элек бөтен яшьләр алдында зал буйлап сөйрәп тышка алып чыга, аннары, мәйдан тотарга күнеккән көрәшче кебек, егетне баш очына күтәреп ала да, болдыр баскычы аша пычракка тондыра, ди.

— Аңардан булыр.

— Кыяфәте килгән аның.

Ул арада автобус, кай җире беләндер Урал тауларын хәтерләтеп, яшеллеккә күмелгән текә калкулыкларны ярып үткән юл буйлап аска таба төшә башлады. Көмеш тасма кебек кенә булып ялтырап яткан инеш аркылы салынган күперне чыгу белән, юл тигезләнгән сыман булды.

## 6

...Район инженерлык-технология службасы начальнигы Ногман Шөгеровның аландай киң кабинетында производство киңәшмәсе бара. Начальник креслосы артындагы стенада 2 нче РИТСның скважиналар фонды схемасы. Ул бөтен стенаны биләп тора. Схема-карта нефтьчеләрнең үзләренә генә таныш булган шартлы билгеләр белән чуарланып

беткән. Икенче якта да төрле диаграммалар, графиклар һәм сызмалар. Өстәл өстендә телефон аппаратлары, микрофон, көчәйткеч һәм башка төрле элемтә приборлары.

Түрдә Ногман утыра. Һәр вакыттагыча пөхтә, чиста киенгән. Килеш-килбәт тә шәп. Йөзе җитди. Үзе сабыр-тыныч. Мондый халәт, гадәттә, позициясенең нык, үз эшенең хаклы икәнлегенә тирәнтен ышанган кешеләрдә була.

Монда мастерлардан тыш служба инженеры Наил Сабиров, партоешма секретаре Иван Говоров, өлкә газетасының үз хәбәрчесе Тажиев һәм Корбан агага таныш булмаган берничә кеше утыра иде.

Беренче информацияне службаның өлкән диспетчеры Федор Никитин ясады. Иң элек ул төнге вахтада торган диспетчерның докладноен укыды. Анда, кабинеттагыларны сагайтып кына калмыйча, чын-чыннан пошаманга төшерерлек сүзләр дә бар иде. 15 нче куст-насос станциясе районында, мәсәлән, бер скважинаның манифольд линиясе шартлаган, шул ук рәттә торган тагын ике скважина да «тынгысызланган», аларны төнлә автоматлар ярдәмендә ябарга, ягъни нефть бирүдән туктатырга туры килгән. Сәбәбе билгеле: 15 нче куст-насос станциясендә ниндидер сынаулар үткәрелә, продукт катламына нindидер химик реагент кудырыла...

Ногман өстәл артына торып басты. Тынлык урнашты. Йөзендә карангы күләгә ярылып ята аның. Менә ул өстәле өстеннән берничә бит кәгазь алды һәм катгый-кырыс тавыш белән тезә дә башлады:

— Иптәшләр! Яңарак кына Федер Николаевич әйтеп үткән күңелсезлекләрне хәзер атлаган саен көтәргә мөмкин. Иртәнге якта гына өстәлемә берьюлы берничә акт кертеп салдылар. Менә алар. Монысы, нефть җиһазларын прокат-ремонтлау һәм скважиналарга җир асты ремонты үткәрү цехыннан. Төнге вахтада ремонтчылар скважинага батырма насос төшергәндә, искәрмәстән нефть фонтаны бәрә башлаган. Нефть ташкыны астында калган эшчеләр яртылаш төшерелгән насосны кире чыгарырга мәҗбүр булганнар. Кабалану-каушау сәбәпле, уннарча һәм уннарча мең сум торган насосның кабелен эштән чыгарганнар. Акттан күренгәнчә, тирә-юньне нефть баскан, янәшәдәге иген басуына агып кергән. Ә монысы «Маяк» колхозында булган ЧП турында... Яңарак кына халык контролерлары группасы членнары алып кайтып бирделәр. Анда да бөтенләй уйламаган-көтмәгән, әллә кайчан консервировать ителгән скважинадан нефть бәреп чыккан, колхозның культуралы көтүлеген пычраткан. Ә бит якында, үзәнлектә генә, берничә колхозны су белән тәэмин итә торган сулыклар...

Корбан аганың йөрәге убылып киткәндәй булды. Җәүһәрәнең: бәлки әле йомып та калырбыз, дигән сүзләрен исенә төшерде ул. Димәк, халык контролерлары группасы членнары алар кайтып киткәч булганнар.

Ногман икеләнүне, каушауны белмәс тәвәккәллек белән сүзен дәвам итте:

— Сез, иптәшләр, мине дөрес аңларсыз дип уйлыйм. Мин яңа ысулларга, прогрессив алымнарга, гомумән, яңалыкка каршы түгел. Әмма андый, производствога бәйле булган сынауларны берничди хәзерлексез, алдан ук тиешле чаралар күрми торып үткәрүгә каршы. Каршы булдым, каршы булачакмын да. Кыскасы шул, әлеге «тәҗрибәләр» тудырган ЧПлар турындагы хәбәрләр югарыга да барып җитәргә өлгергән инде. Кемнең кем булуы белән санашып тормыйча, гаепләләргә карата тиешле чаралар күрелер, минемчә.

Бу сүзләрнең кем бакчасына таш ату икәнлекне кабинетта утыручыларның барысы да бик яхшы беләләр иде. Корбан ага да Ногманның тезгенне артык ычкындырмый торган каты куллылыгын белә, әмма хәзергедәй ачыктан-ачык ябырылуын көтмәгән иде.

— Һәркайсыгызга билгеле, иптәшләр, хәзерге вакытта ифрат та кызу темпларда үскән индустрия, фән-техника революциясе белән табигатьне акыллы рәвештә бер-берсенә бәйли белү кешелек өчен иң төп проблемаларның берсенә әверелде. Без, нефтьчеләр, табигатьне саклау мәсьәләсендә башлап йөрүчеләр булырга тиеш идек.

Ногман, кирәкле кешеләрен барлаган кебек, як-ягына каранып алды. Аннары фикер эзлеклелеген югалтмаска теләгән кебек итеп, сөйләвендә булды. — Монда, иптәшләр, өлкә газетасының үз корреспонденты иптәш Таҗиев та утыра. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, тикмәгә генә килмәгән ул. Журналистлар теле белән әйтсәк: проблема номер одинга кагылышлы теманы ул читләтеп уза алмас, язып чыгар дип уйлыйм. Нишләмәк кирәк, тиешле җәзадан котылды юк. Киләчәктә ачы сабак булыр.

Ногманның сүзе моның белән генә бетмәгән икән әле. Корбан ага ягына өтеп ала торган караш ташлап, сорап куярга булды.

— Их-х, эти! Мenә күрдеңме индениләр килеп чыкканны? Бер түгел, күп мәртәбәләр әйттем мин сиңа, ай-һай, эти, дидем, олы мәшәкать, зур җаваплылык аласың, дидем. Менә, күрдеңме инде?

Корбан ага җавапсыз калуны килештермәде. Урынсызрак булса да сорап куясы итте:

— Галимов үзе кайда соң әле?

— Аның монда нигә кирәге бар? Без монда үзебезнең производство мәсьәләләрен генә тикшерәбез.

Корбан ага әрепләшергә җыенган кеше сыман әйтә салды:

— Ләкин бит аның ул тәҗрибәсе аныкы булудан гына узган. Турыдан-туры безнең проиводствога кагыла түгелме соң?

Ногман, ачы елмаеп, тавышына кинаялек чыгарып әйтте:

— Син, эти, һаман да бу җирлексез тәҗрибәгә ышанган сыман итеп сөйлисең. Тел төбеннән шулайрак аңлашыла.

— Ә ник? — дип элеп алды эти кеше. — Ышанам! Уңышлы чыгачагын күңелемнең кай төше беләндер тоям да кебек.

— Ха-а! Тоя, имеш. Производство технологиясе турында сүз барганда интуиция яки гипотезалар белән генә эш итүдән сакланырга кирәк, эти. Югыйсә, аның бик кыйммәткә төшүе бар. Хәер, хәзер үк җимешләрен күрәбез инде.

Корбан ага улының сүзгә оста, субъектив кимчелекләрне дә объектив шартлар исәбенә йолу, юк итү сәләте барлыгын яхшы белсә дә, тиз генә биреләсе килмәде. Сүз-фәлән сорап тормады ул, урыныннан күтәрелде дә, тагын да үҗәтләнә төшеп сөйли башлады:

— Белмим, кем ничектер, әмма минем бу сынауларга карата үз фикерем бар. — Аннары тавышын тагын да көчәйтә төшеп дәвам итте: — Утыз елдан артык нефтьче булып эшләү дәверендә нинди генә яңалыклар, нинди генә прогрессив алымнар, нинди генә яңа техника, яңа технология производствога кертелмәде икән! Бер нәрсәгә ачык төшендем мин: яңалык никадәр зуррак, никадәр кыюрак булса, каршылыклар да шул кадәр күбрәк булды. Әгәр дә без эшебездә теге яки бу уңышка ирешкәнбез икән, бернинди икеләнүсез әйтергә була, бу барыннан да элек яңалыкны юлдашыбыз итү нәтиҗәсе. Әйтмәгәнем булсын, яңалыкны яклап, аңа тешем-тырнагым белән ябышып, моңарчы оттырмадым. Моннан соң да оттырмабыз, дип уйлыйм. Дөрес, бу соңгы сынаулар, чыннан да, хәзерлексез башланды. Әмма моңа инженер Галимовның тәкъдиме түгел, беренче чиратта без гаепле.

Юк, служба начальнигының йомшар исәбе күренмәде, этисенең сүзен урта бер җирдә бүлде дә, яңа көч белән ябырылды. Фарыз гамәл үтәгән кебек, тырышып-тырмашып әлеге якынлыкның нигезен

какшатты, бары тик кимчелекле якларын гына күрсәтте, иң хикмәтлесе шунда, ният-максатын яшереп маташмады, соңгы сүзен, килдекитте тәҗрибәләр ясауны барыбер туктатачакмын, дип төгәлләде. Ул бу сүзләрне шундый итеп әйтте, хәтта Корбан аганың да башында: «Болайга киткәч, мөгаен, туктатыр да», — дигән уй чагылып үтте.

Шул вакыт телефон шалтырады. Ногман трубканы алды.

— Ал-ло! Тыңлыйм. Әйе, монда. Ярар. Хәзер әйтермен. Хушыгыз!

РИТС начальнигы җәһәт кенә Корбан ага ягына борылды да, шактый коры тавыш белән: «Диспетчер шалтырата, сиңа машина нәрсәгә кирәк булды?» — дип сорау биреп куйды.

Корбан ага шунда ук чыгып китәргә җыенгандай яшьләрчә өлгер-житез хәрәкәтләнеп урыныннан купты.

— Әйе, машина миңа кирәк, — диде ул тынгысызланып. Аннары тирә-юнендә утыручыларның барысына да берьюлы мөрәҗәгать иткәндәй әйтә салды: — Иптәшләр янына барырга. Теге, «Маяк» колхозы янындагы скважина тирәсен чистартасы бар. Алайса, мин китим әле.

Беренче булып үз фикерен Ногман әйтте:

— Әгәр дә хәзер тикшерә торган мәсьәләдән дә әһәмиятлерәк эшең бар дип исәплисең икән, рәхим ит!

Служба начальнигы бераз арттырыбрак җибәрүен үзе дә сизенде, ахрысы, кабинеттагыларга мөрәҗәгать итеп:

— Нишлибез, иптәшләр? Җибәрикме? — дип сорап куйды. Аның бу соравы да, ничектер, мыскыл итү сыманрак булып яңгырады.

Корбан ага шофер янына кабинага кереп утыргач та тиз генә тынычлана алмады. Нинди дер гарьләнү хисе бимазалый иде аны.

Шәһәр артта калды. Машина көзге кебек ялтырап яткан асфальт юлдан җил уйнатып алга ыргыла.

Корбан ага күзләрен бер ноктага төбәгән дә тынып калган. Кәефе бик чамалы аның, күңелендә өермә. Ул җыелышта булып узганнарны кабат бер-бер артлы хәтер күзеннән кичерде. Ногманның гадәтхолкын яхшы белә дип уйлый иде эти кеше. Әмма бу кадәр үк алып узыныр дип уйламаган иде. Үз-үзен артыграк ярата башлаган, ахры, егет. Яман чир. Кемдер, үз-үзеңне ярату—үз-үзеңне үтерүгә тиң, дигән. Хәзергә әле соң түгел, сөйләшергә кирәк егет белән. Бер абруен югалтса, аны кайтарып алулары авыр булачак. Аңлашырга, бүгеннән үк исенә китерерлек итеп әйтеп карарга. Бабаеннан өне алынып тора, беркемнән дә шулай шүрләми Ногман. Әй-йе, бабае сөйләшеп карасын.

Корбан ага шундый уйлар белән мавыгып, «Маяк» колхозына килеп җиткәнен сизмичә дә калды.

### 7

...Корбанның бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы эштә булуы, шуның өстенә эшендә чак кына чатаклык килеп чыгу сәбәпле, кунак мәшәкате тулысынча Рахман карт өстенә төште.

Кичә бораулау эшләре идарәсе администрациясе мистер Шандор белән очрашу оештырды. Кунакны, алдан ук сөйләшеп куйганча, төптөгәл сәгать икедә Рахман карт алып килергә тиеш иде.

Билгеләнгән вакытта инде алар Ак-Кала бораулау эшләре идарәсенең өч катлы өр-яңа бинасы каршысына килеп туктаганнар иде. Кунакны баскычта чыгып каршыладылар. Идарәнең директоры Василий Григорьевич Курышев та шунда иде. Танышулар, кул биреп күрешүләр башланды.

Әчкә үттеләр. Холл тере миллионерны күрергә теләүчеләр белән

шыгрым тулы иде. Мистер Шандор чем-кара костюмнан. Күз явын алырлык ак яка. Цилиндрын кимәгән, ялан баш. Миңа ул, мөлаем гына елмаеп, гадәттәгечә, уң кулын күтәреп: «О, кей!» — диде. Зур төркем булып икенче каттагы директор кабинетына үттеләр.

Әңгәмәне дә шунда гына уздырмакчылар иде, әмма очрашуга катнашырга теләүчеләрнең күп булуын исәпкә алып, лекцияләр залына күчтеләр. Анда КПССның шәһәр комитеты, халык депутатларының шәһәр Советы, нефть һәм газ чыгару идарәләреннән килгән вәкилләр дә бар иде.

Кунакны, Рахман Шөгеровны, «Татнефть» берләшмәсеннән килгән иптәшне, тагын берничә кешене президиумга чакырып алдылар. Әңгәмәне бораулау эшләре идарәсе директоры Василий Григорьевич ачып җибәрде. Иң элек ул мистер Шандорны идарәнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән таныштырды. Бораулап үтелә торган һәрбер метр тау токымының күпмегә төшүе, аның үзкыйммәтен киметү юллары турында сөйләде. Коллективта күпме кеше эшләве, шуларның ничә проценты югары белемле инженер-техник работниклар булуын әйтте.

Аннары кунак сораулар бирде. Нефть катламының нинди тирәнлектә ятуы, бер скважинаның күпме вакыт бораулануы белән кызыксынды ул. Василий Григорьевич мистер Шандорның барлык сорауларына да канәгатьләнерлек, тулы җавап кайтарды. Тылмач Җәмилә ул әйткәннәрнең бер генә сүзен дә чәчми-түкми тәрҗемә итте.

Ул арада президиумга язма рәвештә бирелгән сораулар ява башлады. Күп иде алар. Алдагы рәттә утыручылар, президиум өстәленә үрелеп, берьюлы икешәр-өчәр кәгазь кисәге куйдылар. Бераздан әлеге сорауларга җавап бирү өчен сүзне кунакның үзенә бирделәр.

Мистер Шандор урыныннан күтәрелде. Сораулар язылган кәгазьләрне янына килеп баскан Җәмиләгә тоттырды. Ул һәр сорауны башта русча укыды, шунда ук тәрҗемә дә итә барды. Сорауларда энергетик кризис та, нефть бизнесы да, монополия дә, сәүдә палаталары да, валюта фонды биржалары да, хәтта нефть мафиясе кебек четерекле мәсьәләләр дә читтә калмаган иде. Рахман карт өчен бик үк аңлашылып бетмәгән: корпорация, концерн кебек сүзләр дә җитәрлек иде анда.

Кунак иң элек үзләренең нефть компанияләре, аның нефть запаслары, Америка экономикасында, политикасында һәм стратегиясендә тоткан урыны турында ике-өч җөмлә белән аңлатып бирде. Компаниянең нефть ятмалары, нигездә, өч урында тупланган. Шуларның иң зурысы, иң бае Аляскада, Маккензи елгасы дельтасында урнашкан икән.

Аннары кунак Америка нефтьчеләренең эш шартлары, сәгатенә күпме хезмәт хакы алулары турында сөйләп китте.

Очрашу эш сәгате чыккач кына тәмамланды. Соңыннан кунакка истәлекле бүләк бирделәр, түшенә Ак-кала бораулау эшләре идарәсе оешуга 25 ел тулу уңае белән чыгарылган значок кададылар.

Рахман карт очрашудан шактый соң һәм ярыйсы гына арып кайтты. Шулай булуга да карамастан, тәнендә ниндидер җиңеллек тоеп, күтәренке күңел, саф баш белән уянып китте. Торып юынды. Бакчаны әйләнеп керде. Әмма иртәнге чәен эчәргә өлгермичәрәк калды: капка төбенә мистер Шандорның шоферы негр Джим килеп туктады. Ул шәмәхә төстәге калын иреннәрен ерып, бөтен тешләрен берьюлы күрсәтеп, киң итеп елмайды.

...Менә алар яңадан юлда. Бүген дә, нәкъ кичәге кебек, алда негр янында Рахман карт утыра. Артта мистер Шандор белән Җәмилә.

Машина күзге кебек ялтырап яткан асфальт юлдан бара. Бүген алар Әлмәт, Бөгелмә якларын әйләнеп кайтырга булдылар.

Рахман карт тик кенә басылып утыра алмый, бер алга, бер янәшесендә утырган негрга күз сала. Джимның машинаны шулай өермә урынына куып һәм шаярган сыманрак итеп рульне сыңар кулы белән генә тотып баруын өнәп бетерми ул. Ничәмә-ничә тапкырлар инде эченнән генә: «Җәһәннәмгәме ашыга?..» — дип тиргәнде.

Ә як-якта республикабызның нефть районнарына гына хас күренешләр. Әнә, алда югары вольтлы электр линияләренең челтәрле манаралары. Әнә, анда-санда таралып, көн дими, төн дими ил байлыгы— нефть бирүче скважиналар чәчелеп утыралар. Күпләрендә, әле иелеп, әле тураеп җим җыючы торнаны хәтерләтеп, сиртмәләр чайкала...

Алда көмеш тасма сыман асфальт юл. Ниндидер кодрәтле көч аны нәрсәгәдер чорный кебек, әнә, юл күз иярмәслек тизлек белән машина астында калып юк була бара... Шул юлдан мең төрле йөк төялгән машиналар агыла. Менә, тирә-якка бензин, сөрем исе бөркеп, гаять зур авыр машина узып китте. Аңар шәм кебек төз торбалар төялгән. Бораулау торбалары. Димәк, ул кайсыдыр буровойга юл тота. Шунда ук үкереп, бер-бер артлы ике-өч авыр агрегат узып китте.

Юлның як-ягында таныш, күңелләргә якын туган як күренешләре. Әнә, әллә кайлардагы тау тезмәләре, рәшә аша зәңгәрсу төскә кереп, урман буйлары күренеп тора. Сул якта куе әрәмәлекләр. Ара-тирә елгачыклар, инеш сулары чагылып кала.

Шул чак мистер Шандор, картның җилкәсенә чак кына кагылып алгандай итте дә, кичәге очрашу турында сүз кузгатты. Әйтүенә караганда, бик ошаткан. Халыкның профессиональ эрудициясенә хәйран булган ул. Аннары тагын бер нәрсәгә игътибар иткән: кая гына бармасыннар, кемнәр белән генә очрашмасыннар, һәркайда Шөгеровларны беләләр, хөрмәтлиләр, олылыйлар.

— А как-же!—дигән булды Рахман карт уенын-чынын бергә кушып.—Без бит эш кешесе, ягъни һөнәр иясе. Һөнәр иясе—ил терәге, диләр бездә.

Кичә Җәмиләгә дә эш күп булды. Беренче тапкыр буларак кулына кечкенә генә куен дәфтәре белән каләм алды. Очрашуның ни дәрәҗәдә җаваплы икәнлеген ул да яхшы төшенгәндер шул.

Шунда Рахман карт Җәмиләдән:

— Кара әле, кызым, безгә ничек итеп килеп чыгасы иттең? Моңарчы бер дә күзгә-башка чагылганың юк иде? — дип сорап куйды.

Бу сораудан кыз чак кына уңайсызланды:

— Мине, Рахман абзый, тәрҗемәче итеп чакырттылар монда. Мин эшләгән институттан еш кына шулай тәрҗемәчеләр соратып алгалыйлар. Хәзер бит Казанга да бик күп илләрдән киләләр.

— Шулайдыр, шулайдыр.

— Шөгеровлар гаиләсендә өлкән яшьтәге кешеләр дә бар дигәч, татар телен дә яхшы белүче булсын, диделәр.

— Алай икән.

— Чынлыкта минем һич кенә дә кирәгем булмаган.

— Ник алай дисең әле, Җәмилә кызым?

— Соң, сез, Рахман абзый, рус телен дә нәкъ туган телегез кебек яхшы беләсез икән ич.

— А как-же! Мин бит пролетар кеше, ягъни эшче.

Шунда мистер Шандор аларның нәрсә турында сөйләшүләре белән кызыксынып куйды. Ә инде Җәмилә тәрҗемә иткәннән соң:

— Әй-йе! Сез Шөгеровлар чыннан да эш кешеләре, — диде үз сүзләренә үзе үк мөһер суккандай итеп.—Бабайның зиһен дәфтәрендә дә татарлар турында: уңган, булган, ифрат та эшчән халык, дигән сүзләр дә бар.

Рахман карт ни турындадыр уйланып, алга таба борылып утырды. Тел тибрәтеп әйтә алмаган фикерен күңеле белән тынычландырып

барды. Сүз уңаенда әлләэтием Рамазан турында да бер-ике авыз сүз әйтимме икән, дигән теләге туса да, үз-үзен тыеп калды.

Теләгән тәкъдирдә этисе турында әйтер сүзләре күп Рахман картның.

Революция алдыннан чыккан «Баку нефть промышленносте эшчеләренең эш көне һәм хезмәт хакы» исемле китапта Рамазан Шөгеровның да исеме телгә алынган. Чөнки Рахманның этисе Рамазан РСДРП ның Баку комитеты әгъзасы булган, «Нефть промышленносте эшчеләре союзы»нда актив катнашкан. Бу союз нефтьчеләр арасында агарту һәм аларга медицина ярдәме күрсәтү эшен яхшырту мәсьәләләре белән җитәкчелек иткән.

Александр Митрофанович Стопанинның әле телгә алынган китабында нефтьчеләрнең түзә алмаслык авыр шартларда, көненә уникешәр-уналтышар сәгать эшләүләре, кое тирәнлегендәге бер скважина бораулаганда гына да уртача унлаган кешенең һәлак булуы яки гомергә гарип булып калуы турында язылган. Бу китапка Ленин югары бәя биргән, хәзер дә ул Ильичның Кремльдәге кабинеты китапханәсенең киштәсендә тора, дип сөйлиләр. Ә китапның авторы Александр Митрофанович Стопанинның көле салынган урна — Кызыл мәйданның Кремль стенасында.

Рахман картның күзләре алга төбәлгән. Алга томырылган машинаның тәрәзәләре артында, күз ачкысыз буран котырынган авазлар чыгарып, зәһәр җил ыжгыра. Шул әрсез җил картның да уйларын әкренләп сүтә, тузгыта сыман.

Әйе, Рахман шушы төбәктә туса да, балачагы, яшьлеге Россиянең нефть башкаласы — Бакуда үтте. Шунда диңгезне яратты. Бу якларга кайткач та оныта алмыйча иза чикте. Ул Каспий диңгезенең кояш астында җәйрәп күзләрне чагылдырып ятуларын, аның әле зәңгәрсу, әле яшькелт төскә керүләрен, чал башлы дулкыннарны, җил тузгытканда хасил булган тозлы тамчыларын, каядыр офыкка китеп эрегәндәй күздән югала торган корабларына кадәр ярата иде. Диңгезнең ярларына сыеша алмагандай, ярсып котырынулары турында әйткән дә юк, андый чагын хозурланып карап торулары үзе мәңге онытылмаслык хәйран-тамаша иде.

Ялан аяклы малай чагында Рахман үзише дуслары белән диңгезнең Биби-Әйбәт дип аталган култыгында балык чиерттерергә ярата иде. Шаярырга, күңел ачарга җай чыгып кына тора. Әгәр дә инде балык капмаса, берәр иске көймәне алалар иде дә, сүс кисәкләрен яндырып, су астыннан күбекләнеп-бокырдап газ чыгып торган урыннарга ут төртеп уйнарга яраталар иде. Алар бу уенны үзләренчә «су яндыру» дип атыйлар иде. Кем утының ялкыны биегрәк үрли — шул җиңүче.

Унҗиде яшь тулар-тулмас Рахман эшче булды. Биби-Әйбәт култыгын күмделәр. Су чигенгән урыннарда буровойлар калкып чыкты. 1923 елның башында, кайчандыр алар балык чиерттергән урыннан көчле нефть фонтаннары бәрде. Диңгезне штурмлау әнә шул елларда башланды.

Рахман этисе янында бораулаучы булып эшли башлады. Бораулаучы дип әйтү бик үк дөрес тә булмас, чөнки ул вакытта скважиналарны бәрдереп, чүкеп казыйлар иде. Бу турыда сөйли-нитә калсаң, хәзерге яшьләр көләләр генә, ышанмыйлар. Нефть чыгаручыларны «тартальшиклар» ягъни «тарттыручылар» дип йөртәләр иде. Ул яман күренеш бүгенге нефтьчеләргә коточкыч төш булып кына керүе мөмкин. Андый ысул түбәндәгедән гыйбарәт иде. «Тарттыручы» коега чиләк төшергән кебек итеп бауга тагылган «желонка»ны скважинага төшерә. Җиләк белән «желонка»ның аермасы шул: әлеге савытның төбендә клапаны бар. Нефть тулганда клапан ачыла, чыгыр ярдәмендә өскә

күтәрелә башлаганда — ябыла. Чыгарылган нефть күләмен үлчәү өчен агач чаннарга тутырыла. Аннан агач улаклар буйлап «амбар» дип аталган чокырларга агызыла. Бары тик шуннан соң гына резервуарларга тутырыла. Аннары инде вагоннарга, баржаларга төяп кирәкле урыннарга озатыла. Нефтьнең иң кыйммәтле фракцияләре, матдәләре очып бетүе турында әйтеп торасы да юк. Иң яманы — бу эштәге кешеләрнең хәле. Стопани нефть чыгаруның бу ысулын үзенең китабында техник вәхшилек дип атаган иде.

Бәлки шундый авырлык белән табылганга күрәдер, ул заманда нефтьне тонналап түгел, ә потлап үлчәгәннәр. Советларның VIII Бөтенроссия съездына, Ленин исеменә Баку нефтьчеләренең ... фәлән-фәлән мең пот сыек ягулык чыгардык, дип рапорт бирүләрен өлкән кешеләр хәтерли торгандыр әле. Бу хәбәрне съезд делегатлары аягүрә басып, алкышлап каршы алганнар. Бүгенге көндә «Ак-Каланефть» идарәсе үзе генә дә елына революциягә кадәр бөтен патша Россиясе биргән нефтьтән артыграк сыек ягулык чыгара. Менә нинди ул бүгенге Ак-Кала!

Гомер буена да онытырга мөмкин булмаган тагын бер вакыйга. Анысы 1924 елның зәмһәрир салкын январь көннәренең берсендә була. Күңелләрне өшетеп, йөрәкләрне тетрәндереп: Ленин үлгән, дигән хәбәр тарала. Ул көнне диңгез дә, кая барып бәрелергә белмәгәндәй, ярсыган, үкереп ярларына ташланган, сыкраган, иңрәгән, елаган. Кая карама — халык, халык төркеме өстендә — кара тасмалы байраклар. Диңгезнең ярсулы шавына кушылып җыр яңгырый:

Вы жертво-ою па-ли в борьбе ро-ко-вой...

Еллар үтә торды. Карт большевик Рамазан Шөгеров та дөнья куйды. Ул вакытта инде Рахман үзе эти кеше, үзенең берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе чибәр өч баһадиры үсеп килә иде.

Тагын да соңрак дәһшәтле сугыш башланды...

Аяз күкне кара болыт каплап ил өстенә афәт килгән елларны исенә төшерү Рахман картның яңадан-яңа уй катламнарын актара, яңа хатирәләрен ача. Фашистның кан баскан күзе Баку ягында була. Сугышның беренче елларында фәкать Баку нефтен генә кулланыубыз беркем өчен дә сер түгел иде. Нефтьчеләрнең дә, нәкъ чолганышта калган Ленинградтагы кебек, «Тормыш юлы» дип аталган юллары бар иде. Баку белән Красноводск каналы арасын шулай дип йөртteләр. Шул каналда Бакудан килгән нефтьне танкерлардан, баржалардан тимер юл цистерналарына төйиләр иде дә, Караком чүлләре аша тылга, нефть эшкәртү заводларына озаталар иде.

Бөек Ватан сугышыннан соң Баку нефте тарихында яңа сәхифә ачылды. Корыч субайлар кагып, эстакадалар корып, нефтьчеләр диңгез киңлегенә юл салдылар. Бу хикмәтле эшкә Рахман да үзеннән өлеш кертте. Диңгез эчендә беренче фонтан бәрдергән атаклы мастер Михаил Павлович Каверичкин бригадасының иң алдынгы бораулаучысы иде ул. Шунда ул беренче Алтын йолдызга лаек булды.

Нәкъ шул елларда Рахман үзенең туган якларыннан зур нефть чыгарышырга кайт дигән чакыру алды. Ул гына бәлки аны тамыр җәйгән, ярты гомерен биргән урыннардан кузгата да алмаган булыр иде. Әмма әнисе Миңлекамал карчык ике сүзнең берендә: туган якларыма кайтып гүр иясе буласым килә, дип, аның җелеген корытты. Кайттылар. Әнисе туган авылы зиратында, карт каеннар төбендә, үзенең этисе белән әнисенең аяк очында урын тапты. Ләкин сугышта бер-бер артлы ике баласын югалтканнан соң акылы зәгыйфьләнер хәлгә җиткән хатыны Мәйсәрә генә һаман: «Улларым кайткандыр... Безне эзли торганнардыр, сиңа әйтәм. Кайтыйк туган нигезебезгә!..» — дип теңкәләргә тия, чынга ашмаслык гозерләре белән үзәкләрне телгәли иде.

Ул арада инде Корбан да башлы-күзле булды. Шуннан соң ел да үтмәде, хатыны Мәйсәрә дөнья куйды. «Син көт, әтисе. Кайталар улларыбыз. Юлда алар»... — диде соңгы сүзе итеп. Андый хәлләр әзсез генә үтмиләр икән. Гомер буена искә төшеп, йөрәккә кара кан саудырып, күңелләрне сулгытып, мәңге төзәлмәслек яра булып бимазалап торалар икән. Шулай итеп Рахман Шөгеров, сугышка киткәнче өйләнгән өлкән улы Борһанның хатыны Сабира белән бер түбә астында япа-ялгыз калдылар. Күпмедер вакыт үткәч килене дә: бигайбә, әткәй... сораучы бар, дип кияүгә чыгып китте. Менә шунда татыды Рахман карт ялгызлыкның нәрсә икәнен. Ул көннәрдә юанычы да, куанычы да эше булды аның.

Инде ялгызлыкка да ияләшәм дип кенә торганда, ни күрсен, килене Сабира кайтып төште. «Ялгызыңны гына калдырасым килмәде», — диде ул, авызына җиткән корсагын сыңар кулы белән каплагандай итеп. Шундый миһербанлы, шундый йорт җанлы кешегә ничек итеп күңелең эремәсен ди инде. Шуннан бирле янә бер түбә астында яшиләр. Хәзер инде Сабира да илленең өстендә. Әтисез дөньяга килгән Рабига да тормышка чыкты, инде күптән үзе әни кеше.

Әйтмәгәне булсын Рахман картның, чын мәгънәсендә уңган хатын булып чыкты Сабира, кулларыннан гөлләр тама. Холкы да менә дигән. Кемнең кем булуы белән санашып тормый, кешенең йөзенә бәреп әйтә, юхалану кебек шыксыз сыйфатларның эзе дә юк. Чаялыгы да бар, чәчрәп тора. Кыскасы, тормышны шундый итеп алып бара, Рахман карт шөкер әйтеп бетерә алмый.

Уй диңгезенә чумган Рахман карт Әлмәт шәһәренә килеп җиткәннәрен сизми дә калды. Машина, троллейбус йөри торган олы урам буйлап, каланың үзәгенә таба юнәлде. Ялт итеп торган киң мәйданга килеп чыгу белән мистер Шандор туктарга кушты. Үткер күз Джим машиналар туктый торган махсус урынны бик тиз абайлап алды.

Машинадан чыктылар. Кунак, аякларын яздырырга теләгән кебек итеп, әрле-бирле йөренә башлады. Мәйдан уртасына чыкты. Ленин һәйкәле янында туктап калды. Сыңар кулын маңгаена куеп ак колонналы Техника йортына, Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе биналарына карап торды.

Рахман карт та телгә килде:

— Безнең төп штабыбыз, — дип искәртеп куюны кирәк дип тапты.

Мистер Шандор аңлаганлыгын белдереп ияген какты.

Әлмәттә әллә ни озак юанмадылар. Кунак та анда-монда кереп чыгуны кирәксенмәде. Яңадан машиналарына кереп урнаштылар. Бу юлы инде Бөгелмәгә юл тоттылар.

Бастырып куйган пыяла тартмаларны хәтерләтеп, җәйге кояшның бөтен нурын үзендә чагылдырган сыман, ялт итеп торган тугызар катлы йортлар яныннан үттеләр дә, шәһәрне читләтеп уза торган олы юлга чыктылар.

Шул чак кунак, әле яңарак кына күргән тәэсиратларына бирелгәндәй, сүзгә кереште.

— Болай булгач, исәп-хисапны өзәм дә, тыныч күңел белән кайтым китәм мин, — диде.

Рахман карт та бер терсәген йомшак креслосының артына салып, аңа таба борылып утырды. Тамагын кырып куйды. Әңгәмәне ялгап китәргә ул да әзер иде.

— Мондый тормыш, хәзерге муллык, кем, мистер әфәнде, безгә күктән төшмәде. Шулай ук ата-бабалардан мирас булып та калмады, — дип салмак кына башлап китте ул. — Төрлесен күрергә туры килде. Тормыш булгач, ачысын да, төчесен дә авыз иттерә икән ул. Безнең бәхет, кем, мистер туган, фәкыйрьлек, йөдәү, җитмәүчелек, нужалы еллар иләгеннән үткән, сыналган бәхет. Шуңа күрә дә икелә-

тә кадерле ул безгә. Шунлыктан, кем, мистер, ниндидер анда исәп-хисаплар дип, юкка сүз әрәм итмә. Безгә әҗәткә берни дә кирәкми. Без булганына шөкрана кылып яшәргә күнеккән нәсел.— Шунда чак кына тавышын үзгәртә төшеп өстәп куйды:—Аннары, кем, ярыктан кергән буры, соңрак ишеккә сыймас, ди...

Әлеге сүзләр тәрҗемә ителгәннән соң мистер Шандор түзмәде:

— Я-я, алла! — дип кычкырып җибәрде. — Менә бит, ә! — диде ул кәефе кырылуын яшермичә. — Ләкин бит мин тәкъдим иткән әлеге сумма әҗәт тә, ярдәм дә түгел. Сез аны хәләл акчагыз дип кабул итә аласыз...

Карт үз сүзендә торды.

— Акча гарипкә тансык. Күргәнегезчә, без күптән инде мохтаҗлыкның нәрсә икәнен белмибез.

— Анысы хак.

— Безнең нәсел-нәсәп гомер-гомергә кеше кулына карап яшәмәде. Без һөнәр ияләре.

Кунак, үзсүзләнеп маташкан картны ярты сүздә бүлде.

— Мистер Шөгеров, алай уптым-илаһи гына тәкъдимемне кире кагарга ашыкмагыз әле. — Аннары искәрмәстән генә сорап куйды: — Бәлки куркасыздыр?..

— Нәрсәдән?

— Америкадан килгән ниндидер капиталисттан, нефть магнатыннан акча алдылар, дигән сүз чыгуыннан куркасыздыр?

— Нишләп куркыйк, ди! Урлап алырга җыенмыйбыз ич.

— Дөрес. Әмма мин бу акчаны сезгә бирмиенчә беркая да китмәячәкмен... — Мистер Шандор куен кесәсеннән чек кенәгәсен чыгарды. — Менә, чекка күз салыгыз әле, мистер Шөгеров...

— Бүтән хәсрәтегез булмаса, бу турыда артык сүз куертмыйк дигән идем бит инде.

— Ләкин бит сез минем ни өчен килгәнемне беләсез. Монда бик аз акча түгел... Банкта яткан арада баштагы суммага яңадан ике ноль өстәлгән. Бу акчаһа тулы бер утар салып керә аласыз...

Рахман картның җавабы әзер иде:

— Үзең күрдең, яшәгән йортым теләсә кем кызыгырлык...

— Ләкин бит ул дәүләт йорты.

— Мин үзем дә дәүләтнеке.

— Киреләнмәгез әле, мистер! Минем хәлемә дә керегез. Монда, күрегез, барыгызга да нәкъ менә без утырып йөри торган машиналар алырга җитәрлек...

— Миңа машина нигә кирәк ди?

— Үзегез турында гына уйламагыз.

— Ә оланнарның үз машиналары бар... — Рахман карт тынгысыз бер җилкенү белән чын-чыннан ачуланышырга керешә: — Син дә, кем, мистер әфәнде, алай сагыз кебек чат ябышма!.. Рас әйткәннәр икән сиңа, житкәндер канса-канис. Кыстарга мөмкин, әмма көчләргә ярамый...

— Ләкин бит Шөгеров бер сез генә түгел. Шөгеровлар, әнә, нихәтле, алар нәрсә дияр бит әле?

— Мин ни дисәм, шулай булыр. Хәзергә әле арада иң өлкәне мин!

— Көйгә килмәс җан икәнсез! Акчадан баш тартуыгызны бер яктан аңлыйм да кебек. Минем бабаем, мәрхүм: кешене тәмам бөлдерим, кешелектән чыгарыйм дисәң, аңар көн дә ярдәм ит, диярга ярата торган булган... Сезнең «КамАЗ» безнең экономикага да сизелерлек тәэсир ясады,—дип дәвам итте мистер Шандор.—Москвада «Бэни оф Уорлд корпорейшн» тагын бер банк ачкан. Монда килешли кереп чыккан идем. Беләсезме, кемне очраттым?

Ул бу сорауны шундый итеп бирде, Рахман карт та, Җәмилә дә җәһәт кенә аның ягына борылдылар.

— Дөньяның иң бай кешесен, Рокфеллерларның кечесен — Дэвид Рокфеллерны.

Рахман карт беркатлылыгы белән сорап куясы итте:

— Анысы кем тагын?

Кунак ялт итеп аның ягына карады.

— Ничек? — диде ул, үзенең гаҗәпләнүен яшерә алмыйча. — Сез аларны белмисезмени?

Рахман карт сорауга сорау белән җавап кайтарды.

— Без нишләп белергә тиеш ди аларны?

Кунак гаҗәпләнүдән киң итеп ачылган күзләрен Җәмиләгә юнәлтте. Тегесе Рокфеллерлар нәселен, хәтта берничә буынын яхшы белә икән.

— Әһә-ә! — дип кычкырып җибәрде мистер Шандор, учларын берберсенә ышкыштырып.—Әнә, мисс Җәмилә белә ич.

— Ул белер. Ул яшь кеше. Ә мин кичәге көн кешесе. Әнә, тәрәзә артында егерменче гасыр соңгы чирегеннән ваклый. Тәк что, минем белмәвем дә бар. — Аннары күз кырыйлары белән генә елмаеп, искәрмәстән генә сорау биреп куйды: — Алайса әйт әле, алар мине беләләрме соң? Ә?

Мистер Шандор рәхәтләнеп көлде:

— Уф-ф, үтердегез! Юктыр, минемчә, белми торганнардыр. Сез бит, мистер Шөгеров булсагыз да, миллиардер түгел.

— Ялгышасың, кем, мистер әфәнде. Әгәр дә бик беләсегез килсә, мин сезнең ул Рокфеллерыгызга караганда баерак та әле. Әйе, әйе! Авызыңны ерма, кем, мистер әфәнде! Моны исбат итү өчен әллә ни ерак барасы юк. Әйтче, зинһар, сездә шул Рокфеллер дигән бәндәгез исеме белән аталган урам бармы?

Кунак җилкәләрен генә сикертте.

— Н-дә-ә. Шул-шул! Ә менә Шөгеров исеме белән аталган урам бар. Сез яшәгән кунакханә, нәкъ шул урамга — Шөгеров проспектына карап тора. Аны «Шөгеровлар проспекты», дип атау дөресрәк булыр иде. Чөнки Корбан да шул урамда яши. Аның өендә дә. «Бу йортта «Ак-Каланефть» идарәсенең Почетлы нефтьчесе Корбан Рахман улы Шөгеров яши», — дип язылган мәрмәр такта куелган.

— Усал карт сез, мистер Шөгеров! — дигән булды кунак, бармак янап.

— Усал түгел, туры кеше мин, кем, Шандор әфәнде. — Рахман карт кунак ягына тагын да ныграк борыла төште.— Әйдә, дальше киттек, ди. Әйтче, зинһар, ул миллиардерга сездә һәйкәл куелганмы?

Мистер Шандорга кызык.

— Бу юлы да җиңдегез, мистер Шөгеров.

Карт, кунагы сүзләрен бөтенләй ишетмәгәндәй, җайлап кына дәвам итте:

— Билгеле, ул дөнья тоткан бәндәгезнең саф алтыннан үзенә һәйкәл койдырырлыгы да бардыр. Бәхәсләшмим. Хикмәт андамыни! Син, мистер туган, дөрес аңлый күр. Мактанчык карт икән дип уйлый күрмә. Скверда син күргән бюст миңа гына куелмаган. Мин аны хезмәтне олылау, хезмәтне данлаучы һәйкәл дип карыйм. Әй-йе, бездә хезмәт белән хөрмәт янәшә, бер-береннән аерылгысыз. Хезмәтем — бәхетем дә минем. Хезмәтем — гомерем буена яшәешемнең төп мәгънәсе булды. Син мине, кем, дөрес аңла. Мин әллә нинди батырлыклар эшләгән кеше түгел. Мин бары тик үз эшемне намус сафлыгым белән башкардым. Шуның өчен үз яшәешем белән халкым күңелендә урын яулый алдым, ихтирам казандым. Тәк что, синеңчәрәк итеп әйтсәк, мис-

тер Шандор, бу дөньялыкта беркем алдында бурычлы-әҗәтле булып калмадым.

Юлның як-ягында тоташ стенадай торган иманлекне чыгу белән, үзәнлек сыман булып күренгән урынны биләп алган Бөгелмә шәһәре күренде. Анда да әллә ни озак булмадылар. Үзәк урамнарны бер әйләнделәр дә, әбәткә дип ресторанга керделәр. Аннан чыгу белән кайту ягына борылдылар.

Инде Ак-Калага якынлашып киләбез дигәндә, кунак Корбан Шөгеровның кай яктарак эшләве белән кызыксынды. Юлның Зирекле авылы аша узачагы турында ишеткәч, эш урынына кереп мистер Корбан Шөгеровны да күреп чыгарга дигән тәкъдим ясады.

## 8

Бүген дә көн ыгы-зыгы, шау-шу белән башланды. Моның шулай булачагын Корбан ага күңеле белән сизенгән иде инде.

Ул автовокзалга башкаларга караганда иртәрәк килде. Килү белән диспетчер янына керде.

— Сәлам егетләргә!

— Хәерле иртә, Корбан ага.

— Шалтыратып аласы иде...

— Рәхим итегез!

Мастер район инженерлык-технология службасын сорады. РИТС-ның өлкән диспетчеры үз урынында. Корбан ага, җилкәсе аша аскан планшетка охшашлы сумкасын ачып, кичәге заявкасын алды да, бүген эш урынында булырга тиешле техниканың исемлеген укыды. Бер күчмә парландыру агрегаты, түгелгән нефтьне җыеп тутыру өчен цистерналы махсус машина, трактор ярдәмендә эшли торган насос агрегаты... Шушы урынга житкәч, дежур диспетчер Корбан аганың сүзен бүлде. Насос агрегаты кичә эш урыныннан кайтмаган, хәбәр итүләренә караганда, кайдадыр ватылып калган.

— Ә мин нишләргә тиеш?..—дип сорап куйды Корбан ага, эчендә зәһәрләнеп баш калкыткан ачуын басарга тырышып. — Насостан башка мин ике кулсыз...

Баш вата торгач, бу бәладән чыгу юлы да табылды. Корбан ага эшләячәк Зирекле авылы ягында тагын бер шундый агрегат бар ди. Ике ара, күп дигәндә, нибары биш-алты километр гына. Тик моның өчен мастер хәзер үк тракторчы Григорий Петрович Костинны күрергә тиеш икән. Югыйсә аның вахтага чыгып китүе бар.

Корбан ага автовокзал алдына чыкты. Умарта күче кебек гөжләп торган вокзал каршындагы мәйдан тагын да җанлана төшкән. Килеп тулган вахта машиналары кузгалып китәр вакыт якынлашты. Тирә-як мотор авазлары белән тулган...

Корбан ага тракторчы Григорий Петровичны эзли башлады. Ара-тирә шәһәр белән автовокзал арасындагы асфальт юлга күз төшереп алгалады. Аннан, нәкъ демонстрациядәге кебек, тоташ ташкын булып, вахтага баручы халык агыла.

Кеше инә түгел, тапты Корбан ага кирәк тракторчыны. Тик тегесе бер дә барам, ярдәм итәм дип атлыгып тормады. Үзлегеннән башка урынга күчеп эшләгәне өчен аңа болай да инде эләккәләгән, цех начальниклары берничә тапкыр инде аның путевкаларына кул куюдан баш тартканнар.

Корбан ага хәлне аңлаткач Григорий Петрович риза булды. Шундый күндәм, эшчән һәм итагатьле кеше инде ул. Барысы да аны ихтирам итәләр, яраталар, «дядя Гриша» дип үлеп торалар.

Мастер үзләренә билгеләнгән автобусны эзләп тапты. Хезмәттәшләре белән исәнләшкәннән соң, операторларны барлап кабат күздән

кичерде. Әһә, әнә, кичә эшкә чыкмыйча калган өйрәнчек егет тә шунда. Адәм баласы хатадан хали түгел ди, сөйләшеп карарга кирәк булыр үзе белән.

Мастер урынына кереп утырды да, шоферга кузгала башларга кушты. Юлда гөж килеп эш турында гәп сата башладылар.

— Ярар, барысын да урында хәл итәрбез,—диде Корбан ага операторларны тынычландырып.

Машина алга элдерә. Шул вакыт Корбан ага артына борылды да, әлеге егетне үз янына чакырып алып, каршысындагы буш урынга утыртты.

— Нәрсә булды, туганкай? — диде ул бик гадәти нәрсә турында сүз башлагандай итеп.

Автобустагылар тынып калды. Күтәрелеп бәрелү, сүгү, ызгыш көткәндә мастерның шулай юаш кына сүз башлавы егетне батырайтып җибәрде булса кирәк. Ул берни дә яшермичә күңелендә булганын әйтеп бирәсе итте. Мәхәббәт мәсьәләсендә боткасы пешми икән егетнең, кызы кире каккан булса кирәк. Шуңлыктан соңгы көннәрдә күзенә ак-кара күренми, ут йотып йөри икән.

— Һы-ы, алай икән!—дигән булды мастер. Аннары искәрмәстән генә: — Син бүген ашадыңмы? — дип сорап куйды.

Бу, ничектер урынсызрак булып яңгыраган сорауны көтмәгән егет, беркатлыланып җавап кайтарды:

— Ашадым..

— Нәрсә ашадың?

— Нәрсә дип... Кефир эчтем. Ипи... Аннары чәй.

— Димәк, тамагың тук, дөньяң түгәрәк?

— Әй-йе.

Шул турыга җиткәч мастерның тавышы чак кына үзгәрде кебек. Гадәттәгечә:

— Һы-ы, алай икән! — диде дә, тигез, әмма үзәкләргә үтәрдәй итеп әйтә салды. — Әгәр дә, әйтик, икмәк пешерүче дә ут йотып йөрсә, шул ук сыер савучыны берәр сволочы «ут йоттырса» нәрсә ашар идең соң син? Шул турыда уйлап караганың бармы?

Егет, сиздермәскә теләгәндәй, як-ягына каранып алды. Барысы да мастерның сүзен ишеткәннәр, барысының да йөзе җитди. Егет шул шелтәле авыр карашлар астында башын иярга мәҗбүр булды. Кыяфәте шактый кызганыч иде аның бу минутта.

Ул арада автобус асфальт юлдан төшеп, уңга борылды да, урман эченә керде. Монда юлның рәте юк, кая карама чокыр-чакыр. Аның каравы юл икеләтә кыскарды. Урманны чыккач аяк белән өстенә бастылармыни, кирәкле скважина инде алар каршында иде.

Күчмә вагон-культбудка үз урынында иде инде. Димәк, дежурлар төнлә белән тик ятмаганнар.

Корбан ага вагонның ишеген ачты. Операторлар үз телләрендә «штаб» дип атала торган культбудканың баскычын төшерделәр. Кемдер антеннаны эләр өчен вагон өстенә үрмәләде.

Күп тә үтмәде, якындагы урман эчен давыл сыман көчле гөрелте белән тутырып, тау кадәрле «КрАЗ» килеп чыкты.

— Сәлам, новаторларга! Исәнме, Корбан дус!

— Саумы, Вәдүт туган!

Баранка артында утырган Вәдүт Зиннуров белән Корбан Шәгеров егерме елга якын бергә эшләгән дуслар. Вәдүт тә башта Корбан кебек үк өлкән оператор иде. Әмма фронтта кичергәннәр үзенекен иткән, Вәдүтнең аяклары сызлый башлаган. Ул күчмә парландыру установкасына утырырга мәҗбүр булган. Уңган, тырыш, гаять дәрәҗәдә тынгысыз, эш дип янып яшәүче Вәдүт монда да сынатмый. Бу зур катлаулы агрегатта гадәттә шофердан тыш тагын машинист-слесарь

эшләргә тиеш. Әмма Вәдүт бу вазифаларны берүзе башкара. Ничек кенә башкара әле!

Вәдүт, агрегатын борып җайлырак урынга туктатты да, кабинасыннан сикереп төште. Аннары тирә-яктан түгәрәкләп җир өеме белән уратып алынган скважина янына килде. Андагы хәлне күреп Вәдүт: «Булган икән монда хәлләр!» — дип, хәтта сызгырып ук җибәрде.

Вахта килеп сәгать тә узмады, урман эченнән көчәйгәннән-көчәя барган таныш гөрелте ишетелде. Ул да булмады, урман авызыннан «дядя Костя»ның «Т-108» маркалы тимер тавы кадәрле тракторы килеп чыкты.

Шуны гына көтеп торган кебек барысы да эшкә керештеләр. Вәдүт агрегатын кабызып обваловкага таба торбалар сузды. Костин да тракторын насос агрегаты белән тоташтырып куйды.

— Башлыйбызмы?

— Давай, — диде Корбан.

Вәдүт иң элек агрегатның дизельләрен кабызды. Колакларны тондыргыч гөрелте купты. Вәдүт саклык белән генә пар җибәрде. Температурасы өч йөз градуска җиткерелгән пар, торбаларны, күз ачып йомганчы, ак төскә кертте. Әмма куерырга өлгергән нефть эченә торба башын батыру белән, үкереп чыккан пар шунда ук тынды. Аның караvы, торба башы батырылган урын, нәкъ вулкан авызы кебек быркылдап кайный башлады. Трактор ярдәмендә эшләгән насос агрегаты, җылытудан сыекланган нефтьне зур диаметрлы шланг аша суырып алып цистернага куып торды.

Корбан аганың күзләре манометр стрелкасында. Бер-берсенә ялганган торбалар көчле басым астында җан-фәрманга дерелдиләр, калтыраналар. Әмма мастер насосның эшләве, аның нефтьне бик акрын алуы белән канәгать түгеллеген әйтте. Дядя Гриша шунда ук агрегатны туктатты, клапаннарны караштырды. Ләкин гаеп аларда түгел иде. Бөтен бәла торба белән зур диаметрлы шланг тоташтырылган урыннан һава керүдә булган. Ул урынны кабат сүтеп, һава кермәслек итеп ныгытып, тыгызлап боргычлаган арада Корбан ага да, дядя Гриша да баштанаяк нефтькә буялып беттеләр.

Шулай җан тиргә батып эшләп яткан чагында скважина янына ялт итеп торган чем-кара «Волга» килеп туктады. Аннан Рахман карт, мистер Шандор һәм Җәмилә чыктылар.

— Исән-саулармы, туганнар? Эшләр бармы?

— Бара, Рахман абзый. Бара! Хәзергә сезнең хәер-догада.

— Һелоу, мистер Шөгеров!

Мистер Шандор Корбан ага белән кул кысышып исәнләште. Ике көн эчендә аны сагынып бетүен әйтте. Мәхүбә түти турында сорашты.

Дизель, мотор авазлары чак кына басыла төште. Эш бер мизгелгә генә туктап калды.

Рахман карт эш кешеләрен борчып йөргәне өчен аклангандай сөйләнүен белде.

— Минә кунакның күзен ачып дөнья белән таныштырып йөри идем әле. Кичә иртә таңнан промыселларда йөрдек...

— Бик яраган, эти.

— Шактый ук четерекле, бик тә канительле кунак булып чыкты әле бу. Әйткән сүзгә генә ышанмый, аңар үз күзе белән күрергә, куллары белән капшап карарга давай.

Корбан кунакны культбудкага чакырды. Баскычтан күтәрелгәндә үк сорау бирде.

— Я-ә, хөрмәтле Шандор әфәнде, күргән, танышкан кадәресе ошадымы соң?

— Мин шаклар каттым, мистер Шөгеров. Менә кайда ул байлык! Йа-а-а, ходай!.. Бабайны әйтәм әле, нинди хәзинә өстендә йөргән бит! Әле дә ярый, бу могҗизалар турында исән чагында ишетмәгән... Һа-а-а, бай да соң сез!

Ул арада мистер Шандор баштанаяк нефтькә буялып беткән Корбанны кабат күздән кичерде дә, сорап куйды:

— Мистер Шөгеров, сез мастер бугай бит?

— Әйе.

— Үзегезгә дә эшләргә туры киләме?

— А как-же! Мин өлкән оператор. Ягъни, оста. Ә эш остага буйсына.

Кунакның соравы бетмәгән икән әле.

— Сезнең эшкә кем контрольлек итә?

— Ничек инде? Аңлап бетермәдем.

— Күпме эш башкаруыгызны кем билгели, кем бәяли, дип сорамакчы идем.

— Үзебез. Дөресрәге, намусыбыз.

Мистер ирен кырыйлары белән генә елмайгандай итте.

— Мистер Шөгеров... — диде ул кабат Корбанга мөрәҗәгать итеп. — Сезгә тагын бер сорау бирергә теләр идем.

— Рәхим итегез!

— Дөресен генә әйтегез әле... Нефтьче булуны династия һөнәрен дәвам итү өчен сайладыгызмы, әллә нужа куштымы?

Бу юлы инде Корбан ага елмаймыйча булдыра алмады.

— Нужа кушты, мистер Шандор. Нужа!..

Кунак: «Дөрес тәрҗемә иттегезме?» дигән сыман итеп, Җәмиләгә сораулы караш белән беркавым текәлеп торды.

— О-о, кызык бу!.. — дигән булды ул. — Нужа дисез алайса?

— Әй-йе, нужа, Шандор әфәнде. Мин промыселга сугыштан соңгы авыр елларда килдем. Яшьли килдем. Ул вакытта илебезгә бик күп нефть кирәк иде... Белгәнегезчә, торгызу-тергезү еллары иде.

Кунак, ниндидер ярамаган эштә фаш ителгән кеше сыман:

— Ай-яй, яй! Дипломат сез, мистер Шөгеров, — дип кычкырып җибәрде.

— Ник алай дисез?

— Һәр сүзегез коммунистик пропагандага кайта да кала.

— Мин партияле түгел бит, Шандор әфәнде.

— Барыбер коммунист!

Кунак бу сүзләрне, бәхәсләшергә урын калдырмаска теләгәндәй кебек итеп, шундый ышаныч белән әйтте ки, барысы да елмаерга мәҗбүр булдылар.

— Мин, Шандор әфәнде, вөҗданым, намусым кушканны гына әйтәм, — дип дәвам итте Корбан. Шунда ук өстәде. — Аннары, нефтьче һөнәренә карата үз карашым бар. Гадел, кыю кеше генә яхшы, чын нефтьче була ала, минемчә.

Культбудка ишегендә Җәүһәрә Сабировна күренде.

— Исән-саулар гынамы, хөрмәтле күршеләр! — Әмма ят кешеләрне күрү белән артка таба чигенеп куйды. — Зинһар, гафу итә күрегез! Вакытсызрак чакка туры килдем, ахрысы.

— Зарар юк, Җәүһәрә күрше. Әйдәгез, керегез. Бу әфәнде безнең кунагыбыз, мистер Шандор. Танышып җибәрегез.

Җәүһәрәнең колхоз председателе булып эшләве турында ишеткәч кунак, янә: «О-о!..» дип хәйран калды.

Җәүһәрә сүзен кыска тотты. Янарак кына Ак-Калада булган. Кирәк кадәрле торбалар яздырып алган. Бүген үк ташыта башлый икән. Шул изгелекләре өчен депутат Корбанга мең-мең рәхмәтләр әйтергә дип кергән. Аннары, кинәт кенә күңелсезләнеп, кичә таң белән халык

контроль комитетыннан килеп акт төзеп китүләре турында хәбәр салды.

— Каян ишеткәннәр дә, каян белгәннәр диген син аларны?

— Андый нәрсәне яшереп булмый, — диде Корбан ага.

— Нәрсә булыр икән инде?

— Нәрсә булсын? Колхозга шактый түгәрәк сумма штраф күчерергә туры киләчәк.

— Менә бит, әй!

— Алай бик хафаланма, күрше. Дөньяда булмый торган хәл түгел.

Колхоз председателе ничек итеп искәрмәстән генә бәреп кергән булса, шулай ук җәһәт кенә, аннан-моннан гына саубуллашып, чыгып та китте. Мистер Шандор исә Җәүһәрә белән Корбан аганың әлеге әңгәмәсен бик җентекләп, бер генә сүзен дә игътибарсыз калдырмыйча тыңлаган. Үзе өчен ифрат та кызыклы булып тоелган бу сөйләшүнең асылына, төбе-тамырына төшәргә теләгән кебек, Җәмиләгә сорау артыннан сорау биргән. Җәүһәрә Сабировна артыннан вагон ишеге ябылу белән, кунак Корбан ага каршысына килеп басты.

— Мистер Шөгеров! — диде ул, үзе өчен бик әһәмиятле нәрсә ачыкларга җыенган кебек итеп.

— Тыңлыйм сезне, Шандор әфәнде.

— Сезнең Шөгеровларның эшчән нәсел булуына шигем юк. Бу турыда бабай да язып калдырган. Мине икенче нәрсә кызыксындыра. Ничек итеп, сезнеңчә итеп әйтсәк, парламент әгъзасы, ягъни депутат була алдыгыз?

Корбан ага тагын елмайды.

— Сез дә конгрессмен бугай бит?

— Әйе. Мин дә департамент әгъзасы. Ләкин бит мин бизнесмен. Минем капиталым бар. Шул күтәрә. Идарәче даирәләргә мин кирәк.

Корбан ага, кунакны бүлеп, сорау биреп куйды.

— Акчагыз кирәк. Шулаймы?

— Әй-йе, акчам кирәк. Минем миллионнарым кирәк. Шуңа күрә мине сайлыйлар. Ә менә сез ничек депутат була алдыгыз?

Мастер житдиләнә төште. Аннары җайлап кына сүзгә керешге.

— Мине хезмәтем күтәрде, — диде ул. — Без хезмәт кешеләре. Хезмәт—безнең тормышыбызның нигезе, ул безнең яшәешнең мәгънәсе.

Рахман карт та бер-ике авыз сүз кыстырып куюны кирәк тапты, ахрысы.

— Һәй-й, тиле! Эштән рәхәт, эштән туяр исәп кемдә булсын ди?!. Пенсиягә чыккач, ай эчендә ун еллыгымны картайдым. Ходай тәгалә бәндәсен каргыйм дисә, эштән аерсын икән.

Корбан аңлатуын дәвам итте.

— Без хезмәт кешеләренең фидакарьлеген тәкъдир итәбез. Безнең байрагыбызда, дәүләт гербыбызда урак-чүкеч рәсеме, хезмәт символлары.

Шандорның җавап белән канәгать түгеллеге йөзенә чыкты, гафу үтенгәндәй хәрәкәтләр ясады да, Корбан аганың сүзен бүлде.

— Көймәгә утыргач ишкәкче белән якалашма, ди мәкаль. Шулай да әйтмичә булдыра алмыйм: демагог сез, мистер Шөгеров!..

Мастер кычкырып көлә башлады.

— Ник алай дисез, хөрмәтле Шандор әфәнде?

— Һаман да нәрсәдер әйтеп бетермисез. Ә минем аңлыйсым, төшенәсем килә. Ишетәсезме? Баягы сөйләшүләрегездән мин бер нәрсә аңладым. Сез әлеге председательгә һәркайда дефицит булып саналган торбалар биргәнсез. Дөресме?

— Әйе, бирдем.

— Кем торбалары иде ул?
— Ничек инде, кемнеке? Безнеке, промыселныкы. Ягъни, дәүләтнеке.
— Ләкин бит промысел сезнеке, ягъни Шөгеровларныкы түгел. Анда бит әле сездән югарырак чиндагылар да бар. Бәлки инде ул торбаларны шефыгыз башка берәүгә биреп җибәргәндер. Әгәр дә инде мин кемгәдер, нәрсәдер бирәм икән, кемгә, нәрсә бәрабәренә биргәнемне бик яхшы беләм. Чөнки мин биргән нәрсәләр минеке. Әй-йе, минеке!
— Без барыбыз да хуҗа...— дип куйды Корбан. Әмма бу сүзләр, ничектер, ышандырырлык көчтә яңгырамадылар.
— Алай булмый ул, мистер Шөгеров. Бездә: син дә сэр, мин дә сэр... дигән мәкаль бар. Азагын әйтеп бетермим инде, яныбызда мисс Җәмилә бар.
Бу юлы да Рахман картның сабырлыгы сынды.
— Безнеңчә итеп әйтсәң: син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала кебегрәк була инде бу.
Шул вакыт рациягә җан керде. Корбан ага җәһәт кенә аппарат янына килде.
— Әй-йе!..— диде ул рация микрофонына.— Әйе, мин... тыңлыйм, Фәүзия. Нәрсә?!. Кайчанрак игътибар иттең?.. Басым һаман да шулаймы? Һы-ы, алай икән!.. Димәк, үзгәреш юк. Бәлки манометр гына ватылгандыр? Ә?.. Мастер һушын җыя алмыйча торган кеше сыман беравыкка тынып калды, маңгаен сыпырып куйды. Аннары катгый итеп әйтә салды,— Хәзер килеп җитәрмен. Үзлегеңнән бернигә кагыласы булма. Ишетсен колагың!.. Урында хәл итәрбез...
Бер генә минутка ыгы-зыгы купты. Корбан ага үзенең уң кулы булып саналган Саттар Кәрамовны чакырып калды. Нефтьне суыртып бетергәч башкарасы эшләр белән таныштырды. Һәркайсына мәгълүм булды: монда тулы хокуклы җитәкче булып Саттар калачак.
— Бераздан үзем шалтыратырмын,— диде мастер соңгы әмер-приказларны биргәннән соң.
Корбан ага ашыгып-каударланып, мистер Шандор янына «Волга»га кереп утырды. Вакытның бик тар икәнлеген һәркем төшенде. Машина яңадан юлда. Бая культбудкада чакта өзелеп калган әңгәмә машинада барганда да, ничектер, ялганып китә алмыйча азапланды.
Чөнки мастерның күңелен борчу биләп алган иде. Телефоннан яңарак кына шалтыраткан Фәүзия шомлы хәбәр әйтте. Йөзгә якын скважинаның нефтен бер урынга җыеп, кудырып торган насос станциясенең үзәк задвижкасы шөкәтсез авазлар чыгарып үкерә, ди, ә басымны күрсәтә торган манометр угы күптән инде билгеләнгән чикне узып хәрәкәтсез калган, ди.
Корбан ага бик яхшы белә ул задвижканы. Кадими заманында, скважиналар саны бик аз вакытта куелган иде ул. Әллә кайчан алыштырасы иде дә бит үзен, тик кая ул! Бу эш берьюлы йөзгә якын скважинаны тәүлекләр буена сыек ягулык бирүдән туктату белән бәйләнгән. Нефть чыганакларын бер генә секундка да туктатмау өчен көрәш барган бер вакытта, йөзләгән скважинаны томалаган өчен бер кем дә баштан сыйпамаячак.
Мастер күңеле белән күптән инде Фәүзия янында. Катлаулы җир асты коммуникацияләренең, нефтьчеләр телендә «кое» дип атала торган базында урнаштырылган әлеге задвижканы Фәүзия ничек итеп күрә алды икән?Аларның стеналары, гадәттә, Чупай ташы белән тышланып, өсләре капка кадәрле махсус тимер капкачлар белән томаланган була.
Бүген Фәүзия Мәҗитова үзенең төп вазифасы белән мәшгуль: скважиналардан аерым шешәләргә тутырып пробалар ала. Пробалар ла-

бораториягә тапшырыла. Шуның белән нефтьнең сулылык дәрәҗәсен, анда күпме тоз һәм башка төрле кушылмалар барлыгын беләләр.

Корбан ага Фәүзияне ярата, ихтирам итә. Тик ни хикмәттер, аның кебек карусыз, күндәм, уңган хатын-кызлар гаилә тормышында бәхетсез булалар. Фәүзия дә каяндыр Бакалы районыннан килеп сәүдә системасына эшкә кереп оялаган бер адәми затка тормышка чыккан иде. Элек тә өйләнгән, хатынлы кеше булган мур кыргыры. Елдан артык вакыт үткәч, Фәүзия кыз бала тапкач беренче хатыны килеп төште, зобаныйның. Бөтен дөньяны сасытты, Фәүзияне эт җыймас сүзләр белән халык алдында мыскыл итүләр турында әйткән дә юк, хәтта кул күтәргән дип тә сөйләделәр. Иң яманы шул булды: әлеге хатын, көндәшенең эшкә чыгып киткәнен генә сагалап торган да, бараактагы бүлмәсен ачып: «Закунный ирем тапкан мал!» — дип, Фәүзиянең рәешкә генә кия торган киемнәрен, алтын сәгатен, нефть һәм газ промышленносте работниклары көне уңае белән бүләк ителгән йөз сумлык келәменә кадәр алып чыгып киткән. Күршеләр дә җүнсез хатынның ах-вах килеп күтәренеп чыгып китүен карап калганнар, әмма ләм-мим сүз әйтүче кеше булмаган.

Ул вакытта Корбан ага 2 нче РИТС ның иптәшләр суды председателе иде. Әйдә, тиешле урынга язып биреп, әйберләреңне кире кайтартыйк, дип бер талпынып караган иде дә, моңарчы андый хәлләргә юлыкканы булмаган Фәүзия: «Кирәкмәс, Корбан ага! Күргәннәре-күрмәгәннәре шул булсын», — дип каршы төште. Вакланмыйча бәлки дөрес тә иткәндер.

Нәкъ шул көннәрдә Фәүзия белән тагын бер бәхетсезлек була. Ике генә бүрәнәдән оештырылган сал белән «блокада»да калган скважинага кергәндә, аяклары таеп китеп бозлы суга егылып төшә. Үпкәсенә салкын тиеп ике ай чамасы больницада ятып чыкты. Ул арада нәни кызын Ак-Кала районы авылларының берсендә яшәүче әни карчыгына кайтарып тордылар.

Фәүзиянең больницадан чыккан хәбәрен ишетү белән хезмәттәш дуслары эштән кайтышлый ук вахта машинасын аның барагына таба бордылар.

Бригада члennарын күргәч, авыруның йөзе яктырып китте, күзләрендә ярылып яткан моңсулык җил тузгыткандай юк булды.

— Хәзер, дуслар... чәй куям, — дип урыныннан ук күтәрелә башлады Фәүзия. Тик аңа кузгалырга да ирек бирмәделәр: берсе плитә астына ягып җибәрде, икенчесе чиләкләрне алып суга йөгерде, өченчесе өйне җыештыргандай итте. Ә Геннадий Аракчеев, запас әзерләп калдыру нияте белән, утынлыкка чыгып китте.

Тән авыруы гына түгел, тиз генә төзәлмәслек күңел җәрәхәте дә алган Фәүзия, иптәшләре булып киткәннән соң яртылаш савыгып калды. Тик Геннадий гына урамга чыгып автобуска утырышу белән: «Иптәшләр, аның тагын ике ягарлык утыны калды», — дип хәбәр салды. Икенче көнне үк операторлар машина белән Мәҗитовага утын китерделәр. Тагын бер көннән соң килделәр дә, әлеге утынны кисеп, ярып, әрдәнәләргә өеп киттеләр. Шулай булгач, ничек күңеле йомшармасын кешенең, ничек бөтен күңелен биреп эшләмәсен ул. Соңгы вакытларда Фәүзиянең боегып йөргәне дә, төшенкелеккә бирелгәне дә юк.

Бригадада шулай бер-берсенең хәлен белешеп торулар, кулдан килгән кадәр ярдәм итешүләр күптән инде матур бер йолага, гүзәл гадәткә кереп киткән. Монда шулай ук тәртип бозу яки эшкә җавапсыз карау кебек нәрсәләр сизелә-нитә калса, кемнең кем булуы белән исәпләшеп тору юк, күзенә карап шартлатып әйтәләр.

«Волга» олы юлдан алга чаба. Һәркем үз уена бирелгән. Корбан ага авызына су капкан кеше кебек дәшми-тынмый гына баруны ки-

лештермәде, янында утырган кунакны, көннәрне ничегрәк уздырасыз, дип сүзгә чакырды.

Ләкин әңгәмә тагын җанланып китә алмыйчарак калды. Корбан ага үзе үк олы юл уртасында машинаны туктатырга кушты. Ага кирәкле станция уң яктагы юлга орынып торган катнаш урман артында гына. Машина белән керсәләр шактый зур әйләнеш ясарга туры киләчәк, янәсе. Дөресен генә әйткәндә, сәбәп башка, андагы хәлләрне артык күзләр күрүен теләми иде ул.

Кошлар сайравыннан гөрләп тора урман. Җиләс күләгәгә кергәч, тәне, талгын суга чумгандай, рәхәтләнеп китте Корбан аганың. Изүләрен чишеп җибәрде. Сукмак булмаса да, кәтүләр йөреп сирәгәйгән агачлар арасыннан баруы бик җиңел иде. Ару-талулар онытылды.

Урманны чыгуга мистерның да күз алдында, күп сандагы корылмалары, шактый мәйданны биләп торган таш коймалары, һәркайсына егермешәр мең тонна сыек ягулык сыешлы резервуарлары булган дистанцион насос станциясе калыкты.

Корбан ага туп-туры әлеге зәхмәт задвижка урнашкан «кое» янына юнәлде. Каяндыр, җир астыннан пәйда булгандай, Фәүзия дә килеп чыкты. Исәнләшүләренең рәте-чираты булмады.

— Менә монда... — диде Фәүзия, өсте ачылып куелган таш баз янына килеп.

Мастер бар нәрсәне үз күзләре белән күрергә теләп, тимер баскыч буйлап газ исе аңкып торган «кое»га төшеп китте. Задвижканың шомлы авазлар чыгарып үкерүен ишетеп, манометр эчендәге укның күчәреннән ычкынып китәргә теләгәндәй бәргәләнүен күргәч, коты алынды, аркалары чымырдап, эчләре жу итеп китте. «Харап булабыз бит хәзер...» — дигән уй миен телеп үтте аның.

— Ә син нәрсә карадың?!. — дип җикеренде ул операторына.

Теләсә кай вакытта сабыр, ифрат та ипле була белгән мастерының мондый халәттә булуын беренче тапкыр күргәнгәме, Фәүзия югалып калды. Ул бары тик:

— Ә нишләргә тиеш идем соң мин? — дип, сорауга каршы сорау белән генә җавап бирә алды.

Корбан ага үзенең урынсызрак җикеренеп ташлавын шунда ук абайлады. Әмма гафу үтенеп, сүзләрне кире алып маташыр чак түгел иде. Чыннан да, Фәүзия нишләргә тиеш иде соң? Нишли ала иде ул? Шуның өстенә Корбан аңа һәрвакыт: «үзлегеңнән бернигә дә кагыласы булма», дип кисәтү ясап тора. Менә хәзер үзенә нишләп карарга соң? Нишләсә, ниндирәк адым ясаса ялгышмас икән?..

Вакыт көтми. Әгәр хәзер задвижка ярылып, ут-күз чыга калса, бар да бетте! Көчле шартлаулар тирә-юньдәге корылмаларны гына түгел, якындагы авылны да җир белән тигезләп ташлавы мөмкин.

Мастер шушы берничә минут эчендә хәлдән тайды, тыны буылудан шабыр тиргә батты. Тәненә сулу бирү нияте белән җәһәт кенә өскә калыкты һәм нинди генә чара күрергә дә аптыраганнан гаҗиз булып Фәүзиягә сораулы карашын текәде.

«Бу инженер Рәхим Галимов тәҗрибәсе тудырган бәла... — дигән уй чагылып үтте Корбан аганың башында. — Бүтән берни дә түгел...»

«Кое» кырыена чыгып тирләрен сөртештереп утырган җиреннән ул корт чаккан сыман сикереп торды да йөгереп-атлап операторлар йортына таба юнәлде. Ишекне бәреп кенә керде дә, мастер бүлмәсе өстәлендә торган рациягә барып ябышты. Үзәк диспетчерлыкның пульт идарәсе белән элемтәгә керде. Ул унбишенче куст-насос станциясенең дүрт агрегатын да туктатырга кушты.

Корбан ага урамга чыккач, кабат көчле басым астында калтырап-тетрәп торган задвижка янына төште. Ул арада бернинди үзгәреш булмасын яхшы белсә дә төште, төшмичә булдыра алмады, йөрәге

түзмәде. Курыкканга куш дигәндәй, бу юлы манометрның «җан кергән» угы басымның тагын да артуын күрсәтү ягына авышкан кебегрәк булып күренде мастерга.

Корбан аганың күңелен ниндидер афәт буласын сизенү шомы биләп алды. Төксе йөзенә кырыслык билгеләре йөгерде. Ул кабат ут капкандай өскә күтәрелде, кабат культбудкага таба йөгерде.

Бу юлы рациягә ябышмады. Инде нишләп карарга дигән сыман, маңгаен сыпыргалап, бүлмә буенча арлы-бирле йөренә башлады.

Шул чакта, шытыр-пытыр килеп, рациягә җан керде. Корбан ага йөгереп килеп трубканы кулына алды.

— Ал-ло!.. Мастер Шөгеров тыңлый, — диде ул, бик тә кирәкле, бик тә әһәмиятле, бу бәладән чыгу юлы турындагы күрсәтмәне ишетергә җыенгандай итеп.

— Корбан ага! Ишетәсезме?..

— Әйе, әйе, ишетәм...

Карлыкканга охшаш, бозылып ишетелгән тавыш дәвам итте.

— Агрегатларны туктатып дөрес иттегезме, дип сорамакчы идем мин. Ни өчен дисәгез... Бая гына химик-инженер Галимов, бер төркем иптәшләре белән, минем янга, идарә пультына кергән иде. Куст-насос станциясенең эшләү режимы белән кызыксынды. Ниндидер сынау үтә ди ич анда... Арада Бөгелмәдән, фәнни-тикшеренү институтыннан да, Казан дәүләт университетының нефть һәм газ геологиясе кафедрасыннан килгән иптәшләр дә бар иде. Оппонентлары булса кирәк...

Корбан ага үз әмеренең сәбәбен аңлатты, станциядәге хәлне сөйләде. Үзенең хәзер үк идарә белән элемтәгә керәчәге турында әйтте.

Аннары ул район инженерлык-технология службасына шалтыратты. Бәхеткә каршы, Ногман үзендә иде. Әтисенең нинди йомыш белән мөрәҗәгать итүен белгәч, ул бары тик: «Их-х, сине!..» — дип кенә әйтә алды. Хәзер үк килеп җитәргә вәгъдә итте.

Сүзендә торды служба начальнигы. Кырык-илле минут та үтмәгәндер, «Ак-Каланефть» идарәсенең баш инженеры Артур Павлович Власенко белән капка төбенә килеп тә туктадылар.

Әйе, тикмәгә генә алып килмәгән Ногман хуҗа кешене, тузга язмаган төрле сынауларга аяк терәп каршы торып дөрес иткәнлеген тагын бер тапкыр исбат итәргә теләгән. Әнә ул, баш инженерның бер артына, бер алдына төшеп, кулларын селти-селти тезепме тезә:

— Бер түгел, мең мәртәбәләр әйттем, Артур Павлович. Тыңламадыгыз, колак салмадыгыз сүзләремә. Барысы да шул Галимов штучкалары... Ул үткәрә торган сынау җимешләре...

— Җентекләп өйрәнмичә, асылына төшенмичә торып нәтиҗә ясарга ашыкмыйк әле, Ногман Корбанович.

Гарьчел Ногманга җитә калды.

— Хәзер күрәбез бугай инде нәтиҗәләрен...

Килеп тә җиттеләр, кул биреп исәнләшү белән, бер-бер артлы «кое»га төшеп тә киттеләр. Беренче булып Ногман күтәрелде. Аның төсләре киткән, борын тишекләре киңәйгән. Йөзендә ниндидер, котсыз, явыз кырыслык.

— Ну-у, әти!.. — диде ул йөрәк ачысы белән. Ярсу галәмәтедер, күңелендә кайнаган хис-тойгыларын аңлатырлык сүзләр таба алмады Ногман.

Власенко да баздан чыкты. Ул да ачулы.

— Безобразие!.. Күптән гамәлдән чыккан чуен задвижкаларның шушы көнгә кадәр алыштырылмаган булуы гаҗәп, Ногман Корбанович!

Тегесенең дә кайтып төшәргә исәбе юк.

— Әллә нинди планлаштырылмаган тәҗрибәләр, сынаулар үткәрелер дип кем уйлаган?..

— Уйларга кирәк. Алдан күрә белергә кирәк. Бу станция районындагы скважиналарның нефте кайсы установкага җыела?

Җавапны Корбан ага бирде.

— Өченче группалап җыю установкасына.

— Линиядә ничә скважина?

— Егерме ике...

— Хәзер үк өченче группалап җыю установкасын ябыгыз!

Корбан ага да, Ногман да, дөрес ишеттекме дигәндәй, авызларын ачып катып калдылар.

— Әй-йе, әй-йе! Хәзер үк ябыгыз, — дип кабатлады Власенко. Уртачарак буйлы, какча йөзле, әмма төгәл, иркен хәрәкәтле кеше ул. Менә ул башын күтәреп Шөгеровлар ягына кабат күз ташлап алды да, өстәп куйды:

— Бары тик шул чара гына ярдәм итсә итәр. Бүгенгә, дип әйтүем. Ә иртәгә бөтен станцияне туктатырга. Задвижканы алыштырырга. Сүз дә юк, график өзеләчәк. Нефть биреп җиткермәвебезнең сәбәбен, кайту белән, «Татнефть» идарәсенә аңлатырбыз. Белсеннәр... Башта шалтыратырбыз, аннары язмача аңлатырбыз... Ә сез, Ногман Корбанович, бүген үк эш графигы төзергә утырыгыз. График иртәнге җидедә минем өстәлдә ятарга тиеш. Задвижканы алыштыру өчен биш сәгать вакыт сезгә. Складта, нәкъ шушындый диаметрлы, югары маркалы корычтан коелган задвижкалар бар. Кайтышлый үк кереп карарбыз. Кирәкле техникага бүген үк заявкалар бирергә. Куәтле краннардан, бульдозерлардан, сварка агрегатларыннан тыш, янгын посты белән дә элемтәгә керергә. Кимендә ике-өч янгын сүндерү машинасы белән тәэмин итсеннәр...

Операторлар йортына барысы да бергәләп керделәр. Өченче группалап җыю установкасын туктатырга дигән әмерне баш инженер үзе бирде.

Алар «кое» янына чыкканда манометр угы «терелгән», хәтәр зонадан чак иде инде.

— Әмма бу, положениедән чыгу түгел, — диде Власенко. — Төнгелеккә дежур куярга онытмагыз.

— Үзем калам, — диде Корбан ага.

Баш инженер мастер ягына борылды. Корбан аганың бу адымын хуплавы аның йөзендә чагылды.

— Үзегез калу, әлбәттә, яхшырак булыр,— диде Артур Павлович.

Бераздан инженерлар кузгалдылар. Алар белән бергә Фәүзия дә кайтып китте.

## 9

Корбан ага юк эшне бар итеп янгын сүндергечләрне барлап чыкты. Станция мәйданын урап алган гидрантлардагы су басымын тикшерде. Бар да әйбәт, бар да нормада.

Мастер яңадан «кое» янына килде. Аска төште. Манометр угына күз салды. Ул тәмам тынычланган, бер кейгә генә талпынып алгалый. Корбан ага, күзләренә генә ышанмагандай, ике кеше колачы җитмәслек юан торбага колагын куеп беравык тыңлап торды. Нефть ташкыны да үз җаена гына ургылып ага иде.

Житмешләп скважинадан килә ул җир мае. Көн дими, төн дими, өзлексез рәвештә агыла да тора ил байлыгы. Шул җитмешләп скважинага Корбан ага хуҗа. Аларның һәркайсын биш бармагы кебек белә ул. Арада бик кадерлеләре, үз иткән, күңелгә якыннары да бар. Мәсәлән, моннан 17—18 километр ераклыктагы 1009, 1010, 1011 нче

сан белән йөртелгән скважиналар нәкъ шундыйлар. Истәлекле вакыйгага бәйлеләр. Ул разведка скважиналарын бораулаучылардан кабул итеп алып үзләштергәндә Корбан ага бер бик әһәмиятле рационализаторлык тәкъдиме керткән иде. Шул тәкъдим өчен аңар биш йөз сум бүләк тә бирделәр. Бу турыда хәтта газеталарга да язганнар иде..

Егерме елдан артык вакыт үтүгә дә карамастан, әле дә булса хәтерендә Корбан аганың. Көз көне иде. Аяк аслары сурыккан, кырпак кар төшкән чак. Төннәрен катыра. Әлеге скважиналарны язсыз файдалануга тапшыру турында уйларга да юк. Борын төбендә кыш. Кайчан шул кадәр ераклыкка траншеялар казып нефть магистральләре сузасың ди. Ә сыек ягулык кирәк. Шуның өстенә әле фонтаны ыргып торган әзер скважиналарны «консервлап» тоту үзе зур җинаять. Менә шунда Корбан буровойларны су белән тәэмин иткән торбаларны вакытлыча нефть кудыру магистральләре итеп файдаланырга дигән тәкъдим керткән иде.

Гадәттә ул торбалар, буровойлар башка урынга күчеп китү белән, траншеялардан казып алына да, автогеннар белән туралып металл ватыклары җыю пунктына тапшырыла торган иде. Никадәр хезмәт, никадәр торба әрәм-шәрәм ителә иде! Бу рационализаторлык тәкъдимен производствога кертү үзе генә дә елына уннарча мең сумлык экономия бирде: бары тик бер елда гына да егерме километрдан артыграк югары сыйфатлы торбага экономия ясады. Соңыннан бу алым республикабызның барлык нефтьчеләре тарафыннан да кулланыла башлады.

Шундый уйларга бирелеп, Корбан ага өскә күтәрелде. Көн сүнеп бара. Кояш ерактагы таулар артына төшеп юк булган. Мастер, ирексездән кып-кызыл кояш баешына игътибар итте. Офыктагы алсу шәфәкъ нуры нәрсәсе беләндер шомлы янгын шәүләсен хәтерләтә иде. Үзе җылы, дымлы, чат аяз булса да, әллә ниткән сәер кич иде бу. Күнел түрендә нәрсәнеңдер бимазалап, сызлый башлаган теш кебек сыкрап, борчып торуын тойды Корбан. Моның сәбәбен, җир өстен тантаналы тынлык басып, иген басулары өстен ажаган камчылый башлагач кына төшенде: бәй, бүген егерме икенче июнь икән ләбаса!..

Мастер ишегалдын күздән кичерде, тезелешеп утырган гигант резервуарлар янын әйләнеп килде. Янәшә тирәләрдән ул күзен бәйләп җибәрсәләр дә, бер генә тапкыр да сөртенмичә уза алыр иде. Әйе, бу төбәктә аның эзе калмаган бер генә карыш җир дә юктыр. Һәрбер урын кай ягы беләндер истәлекле, күптәнге таныш кеше кебек якын. Әнә, сул яктагы авыр томан төшкән үзәнлектә, Корбан берьюлы биш хезмәттәшен югалтты... Кайчандыр анда катламга су кудыру станциясе тора иде. Ул шартлады. Хәзер инде аның нигезен дә (кеше күзенә күренеп авыр хатирәләр уятып тормасын дигәндәй) чүп үләннәре басып киткән. Менә хәзер шул аксылланып торган томан эченнән биш ир-егет килеп чыгарлар да: «Корбан туган, син дә безнең белән идең ич, ничегрәк исән калдың?»—дип сорау бирерләр кебек иде. Корбан үзенә дә мең дә бер тапкырлар, теләгән тәкъдирдә дә ул фаҗигале хәлне булдырмый кала идемме, дип сораулар биргәләде.

Моннан егерме елдан артык элек, яңа елга аяк баскан көнне булды ул фаҗига. Корбан, өлкән оператор буларак, үзенең алты кешедән торган группасы белән кичкенә генә, иске автобуска утырып эшкә килде. Иң элек нефть катламына су кудыру агрегатларын ходка җибәрергә тиешләр иде алар.

Насос станциясенең ишегалдына кереп туктадылар. Моторының рәтләп тартмавына юл буе җенләнеп килгән шофер егет, машинасының капотын ача да, арт санын калкытып, ут кебек кызган радиаторы өстенә иелә. Өлкән яшьтәге чуваш Алексей дәдәй ишегалды түренә йөгерә.

Станциянең ишеген ачып керү белән күрәләр: бина эче зәп-зәңгәр, тынга кабарлык булып газ чыккан. Корбан шунда ук: «Зинһар, уткүздән сак булыгыз, газ!» — дип кисәтү ясый. Тәрәзәләрне алып агрегатлар залын җилләтмичә торып эшкә керешү турында уйларга да ярамый иде. Корбан, тәрәзә каршындагы өстәл өстендә торган телефон янына килә дә, диспетчерга шалтырата. Хәлне аңлата, бүлмә эчен газдан арындырмыйча торып агрегатларны җибәрә алмаячакларын әйтә. Хәтәр куәтле двигательләрне кабызганда очкын-фәлән чыгуы бар...

Нәкъ шул вакытта Корбан ишегалдында калган шоферның шапылдатып машина капотын япканын ишетеп калды. Аннан соң ниләр булганын хәтерләми...

Калганын мең төрле актлардан, протоколлардан һәм Алексей дәдәйдән ишетеп кенә белде. Аның сөйләвенә караганда, эш болайрак булган. Шофер эшен төгәлләп капотын яба да, кесәсеннән папирос чыгарып авызына каба. Шырпы кабыза... һәм авызыннан су катыш төтен бөркеп, станция бинасына таба юнәлә...

Калганын Алексей да хәтерләми. Куәтле шартлау дулкыны аны да ун-унбиш сажинга алып ата.

Авария булган җиргә идарә җитәкчеләре, медицина ярдәме күрсәтү машиналары килеп җиткәндә шоферның гәүдәсе суынырга да өлгермәгән була. Корбанның үзен, тәрәзә рамнарын муенына кигән хәлдә, җимерек бинаның тышкы ягыннан табып алалар. Кулындагы телефон трубкасын каерып ала алмыйча иза чигәләр. Җан ачысы белән кыскан булган, күрәсең. Колакларыннан кан киткән, телдән язган Алексей үзе каяндыр мүкәләп килеп чыга.

Бу фаҗигане тикшерү өчен вәкаләтле комиссия төзелә.

Ике ай больницада ятып чыкканнан соң Корбан Шөгеровны тикшерү органнарына чакырттылар. Әмма җавапка тартмадылар. Аңар карап Корбанның күңеле тынычланмады, бу фаҗигале хәлнең аның исеме белән бәйле булуы гомере буена борчыды, вөҗданын газаплап торды. Чыннан да, өлешчә генә булса да гаебе бардыр кебек тоелды аңа.

Корбан шушы вакыйгалардан соң тагын бер хәлне хәтерли. Анысы инде мәхәббәт мәсьәләсе... Аңынчы кем дә булса бар ул олы, чын мәхәббәт бар, дип әйтсә, әлбәттә, ышанмаган булыр иде Корбан. Бөтенләй уйламаганда-көтмәгәндә мона кадәр таныш булмаган, иллә мәгәр ләззәтле, шул ук вакытта газаплы чын сөю хисен кичерергә туры килде аңа. Үзенең Мәхүбәсенә өйләнеп Ногман белән Нәҗибә дөньяга килгәч булды ул хәлләр.

Мәңге төзәлмәс ачык яра булып калган ул мәхәббәтен исенә төшергәндә генә дә Корбан аганың йөрәге сулыгып-сулыгып әрни башлый. Ул истәлекләргә бирелү үзе генә дә бөтен күңелләрне айкап ташлагандай итә, фани дөньяларны оныттыра. Тормышының иң кадерле, әйтеп аңлаткысыз бәхетле минутлары, иң изге хатирәләре шушы тирәләр, шушы төбәк белән бәйле ич. Әнә, басулар сыртында тоташ стена кебек булып күренеп торган наратлыкта ул үзенең Айсылуын беренче тапкыр кочаклап үпте. Менә монда, әлеге оператор йортында, ике гашыйк үзләренең зөфаф төннәрен уздырдылар... Бар, гомер чутыннан чыгарып, сызып ташлап кара күңел түренә мәңгегә кереп утырган ул истәлекләрне!

Корбан ага җәйге төннең дымлы-тымызык һавасын күкрәк тутырып сулый-сулый тар сукмак буйлап басулар ягына таба атлады. Күк гөмбәзенә бихисап йолдызлар сибелгән. Траншея узган җирнең яңа кабер өстен хәтерләтеп торган калкулыгында чикерткәләр туе. Әле бая, кояш баер алдыннан гына, тыныч күк йөзеннән гаҗәеп аһәңгә әвереләп, тургайлар чыңы коела иде. Хәзер төн. Сәер тынлык. Уй иркенә

бирелү, бөтен гомеренне күз алдыннан уздыру, кат-кат хәтергә төшерү өчен моннан да кулайрак вакытның булуы мөмкин түгел. Уйларлык та, хәтергә төшерерлек тә нәрсәләр күп. Кирәгеннән артык күп...

Корбан ага егерме елдан да элегрәк булган вакыйгаларны күзаллый башлады. Ак-Каладан (ул чакта эшчеләр поселогы дип кенә йөртелә иде) утыз километр чамасы ераклыктагы разведка буровоена барып чыктылар. Бораулаучылардан скважинаны кабул итеп алдылар. Әмма үзләштерү эшләрен бер көн эчендә генә төгәлли алмадылар. Язгы юлда иза чигеп йөрмик дип, якындагы авылга кунарга керделәр. Татар авылы иде. Корбан ни булса шул булыр дип, каралтылары коелып төшкән иң фәкыйрь өйгә барып керде. Керде дә, идән уртасында басып торган яшь кенә кызны күреп туктап калды.

— Исәнмесез!

— Саумысыз...

Корбан коры тотты. Үзләренең нефтьчеләр булуын һәм куныл чыгарга фатир кирәклеген әйтте дә салды.

Җилкәсенә салган соры төстәге иске шәле белән уранып, үз-үзен кочаклап торган кыз да телгә килде. Ул ярдәм итә алмавына бик тә уфтанган сыман, нәзакәтьле генә итеп болай диде:

— Өйдә авыру бар шул... Әнием чирли.

— Һы-ы, алай икән!

Әмма шул вакыт чаршау белән генә бүлеп куелган почмак яктан сырхауның тавышы ишетелде:

— Кызым... Айсылу... — диде әлеге аваз өзеп-өзеп. — Керсеннәр... Керәбез дисәләр.

Айсылу... Менә кем беренче күрүдән үк Корбанның йөрәген яулап алды, әсир итте. Менә кемне югалтуга үкенеп бетә алмый да, чирек гасыр буена үз-үзен гафу итә алмый.

Корбан ихтыярын югалткан кеше сыман кызга текәлде дә катты. Болай торуның килешмәвен дә, кыз баланы оялтмас өчен күзләрен читкә алырга кирәк икәнлекне дә бик яхшы белә иде ул. Тик нинди гөнаһ шомлыгыдыр, булдыра алмады. Бигрәк тә матур кыз иде шул Айсылу. Иң күзгә ташланганы, әлбәттә, зәп-зәңгәр күзләре белән, шәле астыннан күренеп торган сары-ефәк чәчләре иде. Ап-ак йөзе дә үзенә килешеп тора. Ул, мин сиңа әйтим, чак кына бүлтәеп торган тулы матур иреннәр. Кочакка сеңеп бетәрлек җыйнаграк кына буй-сын. Тик менә кием-салымнары гына, ничектер, кеше өстеннән салдырып алганга охшап торалар, ятышсыз. Шундый сылулык һәм иске-москы, ямаулы киемнәрнең бергә гәүдәләнүе белән күңелдән һич кенә дә килешәсе килми иде.

Корбан, сүз югында сүз булсын дигән кебек, бораулаучыларның кемнәрдә яшәгәнлекләре белән кызыксынып куйды.

— Бер өлеше каршыда гына, Гыймран абзыйларда яшәгәннәр иде. Берничәсе югары оч Камәрләрендә... — диде Айсылу.

Корбан артына борылып, беренче ярдәмчесе Иванга иң элек Гыймран абзыйларга сугылырга, анда юллары уңмаса, югары оч Камәрләрен эзләп табарга кушты.

— Ә мин Алексей дәдәй белән монда калам, — диде ул.

*Ахыры киләсе санда.*

## Нурия Измайлова

### Унынчы җыр

Мин тугыз җыр яздым сиңа—
Туксан моң һәм туксан өмет.
Шул моң җанны бакча итте,
Кайнар чүлдә чишмә кебек.
Мин тугыз җыр яздым сиңа,
Йөрәгемне телеп-телеп.
Җырлармын да моңайтырмын,
Моңаер да килер диеп.
Якты күңелен алып килер,
Дөньяма нур керер диеп.

Һәм син килдең! Унынчы җыр
Шаулап ага кебек иде...
Тик мин көткән түгел идең!—
Күңлең кара көек иде.
Тик сүзләрең су иделәр—
Пыскып туксан өмет сүнде,
Тик күзләрең боз иделәр—
Бөгәрләнеп туңды серем...
Гөлбакчамда — шәрә дала,
Күтәрелә кара сөрем!
Сөремләнеп өмет сүнә...
Исән бары тугыз җырым —
Тыңланмаган, аңланмаган
Тугыз җырым — тугыз бүре!..
Мин тугыз җыр яздым сиңа—
Тугыз бүре талый җанны.
Аңланмаган туксан моңым
Боз таулары булып калды.
Тугыз бүре ажгырыша
Кара дала бушлыгында.
Унынчы җыр боз тавыннан
Ыңгыраша моңсыз гына...

●

Утыртасы иде беренчегә кертеп,
Укытасы иде «Әлифба»га төртеп.
Өйрәтәсе иде уйлау законнарын
Һәм дә сүз сөйләүдә миллион закон барын.

Мие тулы — ваклык,
Сыймас анда Мантыйк...
Ничек баштан башлыйк?
Ничек кире кайтыйк?

Әй, шул кара башны агартырга иде,
Мәгънәсезлек базын тазартырга иде!
Күзен ачсаң иде — якты нурлар бөркеп,
Үзенең кемлеген дә күрсәтерлек итеп!
Куйсаң иде шулай бөкерене төзәйтеп...
Китәр иде җирдән мәгънәле сүз әйтеп —
Аны тудырган гаепсез ананың,
Гаепле алланың хатасын төзәтеп!

## Кеше турында — кешегә

Ямьсез күреп, ямьсез дия күрмә —
Һәр чәчәкнең аның төсе бар.
Сөйкемсез сөяк буламы?—
Кешенең әнисе бар.

Бәләкәйне бәләкәй ди күрмә—
Һәр җимешнең аның төше бар.
Кеше бәләкәй буламы? —
Кешенең әнисе бар.

Баласына сүз тидермәс өчен,
Газиз җанын бирер кеше бар.
Бер бәләкәй генә адәмгә дә
Берәүләрнең таудай хисе бар.
«Мәрхәмәтле бул балама!» — диеп
Дога укып торган кеше бар.
Кимсетә күрмә кешене —
Кешенең әнисе бар.

## Унбер җәлилчегә

Андый җырлар калмас елап үлгәннәрдән,
Ышанам мин—сез елмаешып үлгәнсез—
Елау заты юк Җәлилнең җырларында,
Күз яшьләрен көн нурына яшергәнсез...

Елмайгансыз... Тик яшергән яшьләрегез
Көн нурыннан минем күзгә күчкән мәллә? —
Уйлыйм — елыйм, сөйлим — елыйм...
Мин бары тик
Сезне уйлап елар өчен үскән мәллә?
Кичерегез мин елакны. Ах, бу кояш
Бигрәк моңлы ядкарь сездән — исәннәргә...

## Язгы төндә

Сулар таша — бәхетләре тулган,
Бөреләре тулган талларның.
Ташып торыр чакта кем ул йөри
Күңел бушлыгыннан зарланып?!
Кочаклашкан таллар. Кыела җаннар
(Ялгызларга язгы төн харам).
Җырларга көй, еларга яшь эзләп,
Су буйлатып ялгыз мин барам.

Ә төн моңсу, Ләйлә күзләредәй
(Мәҗнүн гыйшкын оныта алмыймы?).
...Офык якта бер кош җем-җем итә,
Нурлар чәчә алтын каурые.
Телгә килә кинәт, канат кагып:

— Мин — мәхәббәт! Мин бар, мин исән!
Мин һаман — бер. Ләкин бәндәләргә
Җирдә хәзер юллар мең икән.
Ашыгалар икән, адашалар,
Күп эзлиләр икән, сайлыйлар.
Мин бит — берәү. Күп асыл кош күргәч,
Кыендыр шул мине танулар.
Тапсалар да, бик тиз югалталар,
Айныйлар шул, айныйлар хистән!
Акыл тирәнәйгән хис күлендә,
Сөю урманында уй үскән...
Кайда тиле Мәҗнүн, тугры Ләйлә?!
Алар күпне эзләп йөрмәде:
Гизгәннәре минем урман булды
Һәм минем күл — йөзгән күлләре.
Гизәләр дә хәзер бар дөньяны,
Килер-килмәс миннән китәләр.
Ә мин —исән! Ә мин — мәңгелек кош!
Ышанмагыз, үлгән дисәләр...
Җем-җем килеп бәрелә офыкларга,
Мәҗнүн гыйшкын оныта алмыйммы?
О мәхәббәт кошы! Кодрәтле кош!
Нур канатлы, алтын каурыйлы.
Үзгәрдек без, кичер! Һәм юл күрсәт —
Урманыңа ничек барасы?
Үзгәрсәк тә, без бит табигатьнең
Һаман шул ук нәни баласы...

## Шәһәрдә ат

Чана заманы димиләр,
Тәгәрмәчләр йөриләр.
Тыңласаң, котын чыгарлык —
Үкерәләр, гүлиләр.
Карасаң, өркеп качарлык —
Машина да машина.
Артта, алда, уңда, сулда —
Бар да чаба, ашыга.

Ә ул тыңлап та тормады,
Тормады каранып та,
Гаҗәпләнмәде юлында
Чанага карлар юкка.
(Монда чана юллары да
Ташлы асфальтлар икән...)

Кайсы авылның күк аты бу? —
Чәчәкле чана җиккән!
Курыкмады, өркмәде,
Горур тотып башкаен,
Тоякларын чат-чот итеп,
Чатнатып юл ташларын,
Чабып үтте малкаем!
Башын иеп калды аңа
Юл читендә карт каен:
Исләренә төшергәндер
Акландагы чакларын...
Шәһәрнең бөтен ташлары
Шаккатып карап калды!
Чәчәкле чана артыннан
Күземнән яшьләр тамды!

# ЯЗУЧЫ БАРЛАС КАМАЛОВКА 50 ЯШЬ



*Язучы Барлас Камалов 1930 елның январенда Татарстанның Чистай шәһәрендә туа. Аның бала чак һәм мәктәп еллары Буа районында үтә. Аннары — Казан, педагогия институты. Аспирантураны бетергәннән соң ул газета эшенә бирелә. Журналист буларак тормышның эчендә кайный, халык көнкүрешен якыннан торып өйрәнә, газета-журналларда дөнья күргән күп кенә очерклары — шуның нәтиҗәсе.*

*Барлас Камаловның 1959 елда басылган «Гомер иткәндә» исемле беренче әсәре дә журналистлар тормышын чагылдыра. Хәзер инде ул уналты повесть, йөздән артык хикәя авторы. Укучылар аның «Үр менгәндә», «Сыналыр чак», «Яшь имәннәр», «Яшьлек эзләре», «Күршеләр», «Ялыкмаслар», «Язгы күкрәү» һәм башка повестьларын яратып кабул иттеләр, язучының бу әсәрләрендәге геройлар — бүгенге кешеләр; эш-гамәлләре, уй-хыяллары белән җәмгыятьнең алгы сафында баручы, коммунизм төзү эшенә актив катнашучы яшьләр.*

*Язучы, коммунист Барлас Камаловка илле яшь тулды.*

*Тынгысыз рухлы каләмдәшебезне юбилее белән котлап, аңа корычтай сәламәтлек, киләчәк иҗатында уңышлар телибез.*

## Барлас Камалов

# АКТУГАН ГАБСАТТАРЫ

ПОВЕСТЬ



Газетаның хатлар бүлеге мөдире редакциядә уздырыла торган кызыклы хат уку сәгатендә чираттагы язма белән таныштырды:

— Менә Актуган авылыннан бер хат бар. Зөя буеннан. Габсаттар Халитов дигән карт турында. Аңа быел сиксән тула икән. «Авылыбызның мөхтәрәм кешеләреннән берсе. Сугыш орденнары да, хезмәт бүләкләре дә бар. Бик кешелекле. Әле дә булса колхозда эшли. Аның турында кинәнеп укырлык итеп язсагыз икән»,—дигәннәр. Азакта җиде имза...

Мөдир, сүзен бетергәч, күзлек пыялаларын ялтйолт китереп, бүлмәдәгеләрне барлап чыкты һәм карашын миңа төбәп:

— Синең өлешкә тигән көмеш бу, Харрас энем. Әтиең авылыннан. Кайтып кил нәселең тамыр җибәргән якларга,—диде.

Редактор бу фикерне хуп күрде.

Иртәгесен тимер юл белән Актуганга юл тоттым.

Поезд талгын гына тирбәтеп барган уңайга хатирәләр йомгагын сүтә башладым.

Беләм мин Габсаттар абзыйны, әйбәт беләм. Аларның өе этиләр йорты белән бер урамда ук. Беренче мәртәбә ул абзыйны дүртенче классны тәмамлаган җәйдә күргән идем. Моннан унике-унөч ел элек, ягъни алтмыш бишенче елның июнь ае. Ул чакта ук инде без калада яши идек. Бер көнне эти белән эни икесе берьюлы әйттеләр:

— Пионер лагерена киткәнче ике-өч атнага авылга кайтасың. Әбиең бик сагынган. Оныгым ник бер дә кайтмый дип үпкәләп хат язган әнә,— диделәр.

Минем түбә күккә тигәндәй булды! Шундук җыена башладым. Эни юл кирәк-яраклары хәстәрләде. Лашчы станциясенә кадәр билет алдылар. Әбигә күчтәнәчкә чәй-шикәр, өрек, лимон куйдылар, үзе дигәнчә тектерер дә сагынмалык итеп кияр дип, чәчәкле күлмәклек тә җибәрделәр.

Аркама нәни рюкзак асып, кулыма кечкенә чемодан тотып, Актуганга кайтып кердем. Кердем дип, эти мине Казаннан ук Габсаттар абзыйга ияртеп җибәргән иде. Ул абзый мине әбинең өенә кадәр китереп куйды. Әбине әйткән дә юк инде, бик куанып каршылады. «И-и-и! Харрас балакаем кайткан бит, ходайның әмере»,—дип гөлдерәп йөрде. Әле башымнан сыйпады, әле аркамнан кагып сөйде. Шатлыгыннан хәтта елап та алды. Тик, дөресен әйтергә кирәк, Габсаттар абзыйдан аерылып калу миңа читенрәк булды. Ник дигәндә, поездда кайткан бишалты сәгать эчендә дуслашып өлгергән идек. Ул миңа юлның буеннан-буена киек казлар, торналар хакында экиятләр сөйләп кайтты, умарта кортлары турында ниләр генә сөйләп бетермәде. Үзе сөйли, үзе елмая, ә күзләре сынаулы карый. Әби өennән чыгып киткәндә, Габсаттар абзый миңа кул биреп саубуллашты да:

— Минем янга умарталыкка кил, Харрас улым, яме. Зөя борылмасында гына ул, авыл башында,—диде. Билгеле инде, мин рәхәтләнеп риза булдым. Тик кәефем бик тиз бозылды. Габсаттар абзый капкадан чыгып китүгә, әби этине орышып куйды.

— Әткәеңне әйтер идем инде, багалмадай онытымны, күз нурымны шул денсез Габсаттарга ияртеп җибәрмәсә,—диде.—Башка авылдашлар юк иде микәнни соң?

Мин ул сүзләренең мәгънәсен аңламадым. Шулай да әбинең Габсаттар абзыйны яратмавы ап-ачык иде. Югыйсә онытын алып кайткан кешене тиргәп маташмас иде.

Юл кайтып чәйләгәч, әби белән икәүләшеп болдырга чыктык. Болдыр курчак театрындагы кебек: ян-як терәк баганалары сырлы-сырлы итеп юнылган, ак, зәңгәр, сары, кызгылт төсләргә буялган. Хәер, тәрәз йөзлекләрендә дә агач чәчәкләр, бизәкләр аз түгел. Ә капкачлары җете-зәңгәр итеп буялганнар.

Бәрәңге бакчасы буенда зур лапас, ә аның түбәсе астында колгалар тезеп ясалган печәнлек.

— Бабаң исән чакта, улым, елның бу вакыты житкәндә, монда печән дыңгычлап тутырган була иде,—дип куйды әби уфтанып.

— Хәзер ни, урак белән кыркыштыргалыйм да капчыкка төяп ташыган булам. Бөтенләй печәнсез калсаң, сыер бозаулагач, сарыклар бәрәнләгәч, читен була. Колхоз болай карт-корыны онытып бетерми, сәламын да, кармавай чөгендерен дә биргәли. Алланың рәхмәте яусын. Алай булмаса, япа-ялгыз башың белән сыер асрыйм димә. Ә бит сыйлы көнең сыер белән. Сөте-катыгы дисеңме, мае-каймагымы...

Әнә кытаклый-кытаклый оядан ак тавык очып төште. Өстемә кунмагае дип, кулларымны селкеп, читкә тайпылдым. Кул яссуы кадәр диярлек җете кызыл кикрикле әтәч, шомланып, кычкырып куйды.

Бәрәңге бакчасына чыктык. Бәрәңгеләрнең бер ишесе, әле бик сирәге, ак-шәмәхә чәчәк аткан. Бүтәннәренең бөреләре тулышкан.

— Әллә нигә, ходаның рәхмәте, бөреләрем күз ачып җибәрә алмыйлар,—диде әби.—Шау чәчәктә утырсалар соң...

Мин әбинең сүзләрендә ниндидер яшерен ямансулау тойдым. Әмма шундук күңелемә икенче сорау килде: чәчәк күп булса, нәрсә булыр иде соң?

Аннары без кишер, кыяр түтәлләрен карадык. Әби кытыршыланып ярылган бармаклары белән кояш кызуыннан хәлсезләнеп, әлсерәп, шәлперәеп калган зур яфракларны сыйпаштыргалады.

Шуннан ак мунча янына килдек. Аны салганнарына да алты ел икән инде. «Бабаң үзе исән чакта салдырды. Җитәр, Гайнелбанат, кара мунчада ысланырга, дигән иде мәрхүм. Урыны җәннәттә булсын! — диде.— Авылда ак мунча салуны әлеге дә баягы денсез Габсаттар кузгатып җибәрде шикелле. Югыйсә ул элек бик хәлле кешеләрдә генә була торганые».

Мин мунчаның карасы нинди булганын сорамакчы идем дә, ниятемнән кире кайттым. Көн кыздыра, Зөягә төшеп су коенасым килә иде. Ә Зөя суы әбиләрнең бәрәңге бакчасы артында гына:

— Бата күрмә!—дип кычкырып калды әби артымнан.—Саклангынны саклар дигәннәр.

Коенып кайтканда бәлагә тардым. Тыкрык буенда чебешләрен ияртеп бер оя күркә йөри иде. Мин алар янына килеп җитү белән, ата күркә өреп тутырган кебек кабарынды, кызыл муенсалары тагын да кызара төште, әллә нинди ят тавыш белән буынтыклы-буынтыклы итеп кычкырып җибәрде. Минем бу кошның болай аваз салуын моңарчы гел ишеткәнем юк иде. Йөгерә башладым. Күркәгә әйтерсең шул гына кирәк иде, күз ачып йомганчы куып җитеп, өстемә ташланды һәм икеөч тапкыр шундый итеп чукып алды, каравыл салып акыруымны сизми дә калдым.

Шул арада минем яныма әби йөгереп чыкты.

— Көш-ш-ш дим, көш-ш-ш, имансыз! Көш, көш-шө!

Чыбык болгап килгән әбине күргәч, күркә кире борылды һәм, аякларын сыгылдыра-сыгылдыра юыртып, чебешләре янына китеп барды.

— Хәтерләремнән гел генә чыгып киткән, багалмам. Кызыл пинжәгеңне салып бар димәкче идем бит. Кызыл төскә үчегә ул, мәлгунь. Корбан гаете көнне, кызыл читегемә җене кубып, үземне чак таламады.

Юл кайту мине йончыткан иде, өйгә кергәч беравык ятып кына торыйм дисәм, изрәп йокыга талганмын. Уянгач исә беркавым аптырап тордым: кайда мин? Шуннан соң гына исемне җыеп, тоныкына күренеп торган тәрәзәгә текәлдем. Әби өенең түр як тәрәзәсен төн карангысы каплаган иде инде.

Минем караватта кыймылдавымны тоеп, чоланнан әби йөгереп керде.

— Һай, улым, йокың әйләндеме? Уятырга жәлләп йөрдем. Әйдәле, җылы сөт эч әле, багалмам.

— Хәзер, әбкәй, һава гына иснәп керим...

Урамга чыксам, гаҗәпкә калдым. Төн таң калырлык матур икән. Эчке яктан, тәрәзә аша гына бик караңгы тоелган булган. Күктә йолдызлар җемелдәшә. Талгын җил исә.

Урамнан күңелем күтәрелеп кердем.

— Кердеңме, багалмам?—дип чүкердәде әби.—Мә, эчеп җибәр әле, эч... Яңа сауган сөтнең шифасы бихисап аның. Мә әле, мә, каймаклысы, имчәк төбе генә...

Сөтне эчтем эчүен, яратып эчтем, әбигә бик рәхмәт дидем, тик «имчәк төбе» дигәнен генә аңламадым.

Авылдагы беренче көнем шулай үтеп китте. Ул көнгә икенчесе, өченчесе ялганды. Әле һаман Габсаттар абзый янына бара алмадым. Турысын әйткәндә, әбидән шүрләбрәк йөрдем. Шулай булса да, күп кызыклар сөйли торган карт күңелемне гел кытыклап торды. Ниһаять, авылга кайтуыма бер атна тулган көнне, төш вакытында, әби түр якта өйлә намазына оегач, мин бакча артлап кына колхоз умарталыгына сыпырттым.

Габсаттар абзый мине вагонда кайткандагыча елмаеп, шаяртып каршылады.

— Килгәндә адашмадыңмы соң, кала егете? Безнең монда чат саен милиционер юк бит, юл күрсәтеп торырга...

Аннары озын буйлы, какча гәүдәле мөлаем Габсаттар абзый, салмак кына атлап, «бал җыючылар шәһәре»н күрсәтеп йөрде, бал кортларының хикмәтле хәлләрен сөйләде.

— Бер «йорт»та уннарча мең эшче корт яшәгәнен белмисеңдер әле син, егетем, ә,—диде абзый, чаларган мыегы астыннан гына көлемсерәп.—Белмәвең дә гаҗәп түгел, гаеп тә түгел. Белергә теләмәү генә гаеп. Шәһәрнекеләр авыл кешесе белгәннең байтагын белмиләр. Эшләре төшми, кирәкләре чыкмый.

Габсаттар абзый кулларын артка куеп атлый һәм һаман кортлар турында сөйли бирә.

— Сәгать өчкә колхоз идарәсенә чакырдылар. Син, егеткәй, су керә тор. Йөзә беләсеңдер бит? Алайса бик шәп, чума бир. Мин озакламам, аннары тагын гәпләшербез,—диде дә Габсаттар абзый китеп барды.

Мин көтәргә булдым. Зәядә рәхәтләнеп коендым, яр буендагы яшь агачларны, гәрәбә төймәдәй генә яшел алмаларны карап йөрдем. Тирәюньгә ялт-йолт караш ташлагач, яшел «төймәләр»нең бер-икесен өзеп тә алдым, татып та карадым. Бик тә әче булып чыктылар!

Габсаттар абзый һаман кайтмады. Мин инде аны сагынып беттем. Аның белән кызык та, күңелле дә. Ниндидер сөйкемле сөяге бар. Зур соры күзләрендә үзенә тартып торучан нур уйный. Ул сакал үстерми, мыек кына. Шуңа микән, үз яшенә караганда яшьрәк күренә. Мыегы гына түгел, чәче дә ап-ак. Тик чәчен һәр чак кырдырып тора икән. Куе кашлары да чаларган. Куйдырган тешләре күбрәк. Бит урталары эчкә батыбрак тора. Яңак калкыннары еректан ук күзгә ташлана. Озын-озын атлап йөри. Сөйләшкәндә сабыр сөйли, гүя һәр сүзнең тәмен татып кала. Тавышы йомшак, колакка ятышлы...

Умартачы абзый турында беравык уйланып утыргач, мин кесәмдәге линзаны чыгардым да бакчадагы өйнең стенасына, кояш кызуы белән яндырып, хәрефләр тезәргә керештем. Иң әүвәле «х» һәм нокта, аннары «ә» һәм нокта барлыкка килде. Чиратка «к» хәрефе дә басты. «Харрас Әсгатович Кирамов»ның иң кыска язылышы булачак. Ләкин соңгы ноктаны кую насыйп түгел икән. «Исемеңне истәлек итәсеңмени?» дигән тавышка сискәнеп пыяламны кулдан төшереп җибәрә яздым. Умартачы абзый әйләнеп кайткан һәм миңа каш җыерып, сәерсенеп карап тора иде.

Каты орышмады, орышса әйбәтрәк буласы иде. Оялтты.

— Имза сырлыймсың?—диде ул, кинәт эндәшеп.—Мәгәр, улым, бел: имзаны узганда-барганда, кая житте шунда сибеп йөрмиләр. Очар коштан төшеп калган тизәк түгел ул. Паспортыңа имза кую, хәләл көчең белән эшләгән акчаңны алганда имза салу күңелле. Стена пычрату әдәпсезлек кенә.

Шулай дигәч, Габсаттар абзый бераз эндәшми торды. Аннары гадәттәгедән дә сабыр, әмма үтә сипле итеп өстәп әйтте:

— Дөрес, тарих мактаган бер «әдәпсезлек»не дә белэбез. Рейхстаг стенасына байтак имза сырладык без кырык бишенче елның маенда. Штык белән дә, буяу белән дә. Гитлерчыларга хөкем карары итеп. Анысы инде гупчи башка мәсьәлә.

Умартачы өенә кергәч, Габсаттар абзый миңа журналлар, китаплар күрсәтте. Вак илэк төбе шикелле битлекне, төтәткечне үз кулларым белән тотып карадым, кәрәзләр күрдем, балавызның ни икәнен белдем. Алай гынамы соң! Габсаттар абзый мине юкә балы белән сыйлады.

Көн кичкә авышып барганда, иртәгә умарталыкка тагын киләсемне әйтеп, куанып кайтып киттем.

Кайтсам—ни күрим: әби утлы табага баскандай йөренә, хафага калган. Мине күрүгә елап ук җибәрде.

— Ни генә булды икән багалмама, дим. Әллә, мәйтәм, Зөягә...

Мин, булдыра алганча, әбине тынычландырырга тырыштым.

— Әбкәй, мин бит беренче класстан йөзү бассейнына, секциягә йөрим,—дидем.

— Ликциягә йөрисеңдер, улым, сүзем юк. Алай да бер хода үзе сакласын. Әткәңә-әнкәңә ни йөз белән күренермен дә, ниләр дип кенә җавап бирермен? Карының ачкандыр, әйдә, утыр. Ашым өлгергәнгә биш былтыр. Самаварым да җырлап утыра.

— Ачыкмадым мин, әбкәй,—дидем, комганнан кулыма су сала-сала. Бу нәрсәкәй белән юыну миңа бик читен иде.—Бер дә ачыкмадым. Габсаттар абзый мине бал белән, күмәч белән сыйлады, чәй эчерде.

Әбигә кушучлап балан каптырдылар диярсең, чырае сытылды.

— Син әле шул денсез тирәсендә әвәрәләнеп йөрдеңмени? Бүтән барыр булсаң, мин сине... Күрше Гайшә кызыннан бүген үк әткәңә хат яздыртырмын. Әдрисегез бар, әнә страхау кәгазьләре арасында гына. Бал дисәң, мин тәпәне белән алдыңа куярмын. Моннан кала, умарталыкка ике аягыңның берсен басасы булма!

— Ник алай дисең, әбкәй? Габсаттар абзый зрә дә кызык кеше. Мине озатканда әткәй белән дә Казан вокзалында әллә ни хәтле сөйләштеләр, көлешә-көлешә сыра эчтеләр.

Әби шәмәхә-зәңгәр тамырлары бүртеп торган кулының бармак очлары белән өстәл кырыена сугып куйды.

— Күп белмә, тиз картаерсың. Гомеренә денсез булды ул. Олыгайгач та акылга туймады. Ураза аенда гына әле колхоз радиусыннан аллага каршы сөйләде. Дин—агу, ди, экият, ди. Әстәгъфируллаһ тәүбә, тәүбә... Минем сүзем түгел, шул Габсаттарныкы. Бала-чага янына барып, мәктәптә сөйләргә дә иренми. Тегеләре дә шуның чабуына тагылгандай...

— Соң бит, әбкәй...

Әби миңа авыз ачарга да юл куймады, кулын гына селтәде.

Тагын берничә көн үтте. Әбине ахирәт карчыклары кунак чәенә чакырдылар. Мин, шуннан файдаланып, умартачы карт янына йөгердем. Габсаттар абзый мине бу юлы да гаҗәеп мөлаем каршылады.

— Кузгә-башка күренмәгәч, мин инде шик-шөбһәгә төшкән идем, егеткәй,—диде ул.—Әллә, мәйтәм, Казаннан килгән кунагымны Актуган кызлары кыерсыттылармы, дим.—Үзе минем аркамнан какты, тырпаебрак торган чәчләремнән сыйпап алды.—Авырып, сырхап китмәгәнсеңдер ич?

— Юк.—Шулай дидем дә, тотлыгып калдым. Яңакларыма, бит алмаларыма алсулык йөгерде. Дөресен әйтү бик кыен иде, ничек әйтәсең?! Әбиемне дә бик яратам бит мин. Әбкәй дә багалмам дип кенә тора.

Габсаттар абзый минем тел тешләп калуымны искәрмәде булса кирәк. Җәен малай-шалайга эш беткән мени! Ашарга да чакырып ала алмыйлар ич безне.

— Беләсеңме нишләрбез хәзер?—диде умартачы абзый, миңа тау чаклы серен чишәргә әзерләнгән шикелле.—Зөягә ат коендырырга төшәрбез. Эсселәдә малкай. Баярак кына районнан кайттым. Куа да төштем бугай...

Умарталыкта кирәк-яракка дип ат тоталар икән. Бик чибәр бахбай. Җирән кашка.

Ат коендыру дигәне бик мавыктыргыч, бик серле тоелса да, мин дөресен әйтми булдыра алмадым.

— Мин ат өстендә йөри белмим, Габсаттар абзый.

— Ат өстендә йөрү димә, егет, атланып диген, атланып... Белергә кирәк. Белмәсәң өйрәнерсең. Ир канаты — ат дигәннәр, үскәнем. Үзем өйрәтермен. Әйдәле!

Кашканы йөгәнләргә барганда, үзалдына сөйләнгән төсле, тагын әйтеп куйды:

— Белергә кирәк, белергә! Җирән кашка юаш ул, шүрлисе юк. Суны галәмәт ярата. Бүген синә аның тезгене таман, килер көндә, кем белсен, зурраган да майтарырсың. Бик бәхетле заман балалары бит сез.

Габсаттар абзый ямансулап куйгандай булдымы, мин, абайлап та җиткермәстән, аның йөзенә күтәрелеп карадым да сорадым:

— Сез бәхетле түгел мени, Габсаттар абзый?

Соравым аңа сәеррәк тоелды, күрәсең. Абзый миңа текәлеп елмайды да, берничә адым сүзсез атлады. Шуннан әйтте:

— Безнең буын үзенчә бәхетле, улым. Яңа дөнья коруны башлап җибәрүе белән бәхетле. Ә сез усубый. Яңа дөньяны гел камилләштерә барачаксыз. Тамак тук, өс бөтен, күңел көр килеш эш итәчәксез. Белемгә таянып. Ныклы нигезгә аяк терәп. Тора-бара аңларсың әле, аңларсың. Әйдә, Кашканы йөгәнлик әле.

Тышаулап җибәргән ат ялкау гына үлән чәмченеп йөри, әледән-әле үзен тынгысызлаган чебен-черкине койрыгы белән куа иде. Безне күргә, ул, башын күтәреп, кешнәүгә охшаш, әмма бик кыска аваз биреп куйды, колакларын кайчыдай уйнаткалап алды. Абзый аңа йөгән кигезде, бармаклары белән ялларын тараштыргалады, сыртыннан сыйпап куйды.

Әлеге көнне мин гомеремә онытмас кебек булдым. Әкәмәт икән ул агымсуда ат коендыру!

Зөя буеннан алма бакчасына, умарталыкка күтәрелгәндә, Габсаттар абзый миннән сораштыра менде. Янәсе, компассыз гына, Тимер казык йолдызына карап, кыйбланы таба алыр идеңме? Янәсе, йомры бүрәнә өстендә йоклый беләсеңме? Тагын әлләниләр... Әкәмәт абзый!

Мин кайтканда, әби өйдә юк иде әле. Аннары кайтты. Яулык читенә төйнәп бәлеш кисәкләре, конфетлар алып кайткан. «Авыз ит әле, балам. Аш иясенә савабы булыр»,—ди. Изге күңелле әби!

Беравык маташкач, өстәл буена барып утырды да, ике кулы белән ботына чабып куйды.

— Әй, хәтер дигән хәзинәң бер кими башлагач! Менә бит ул хак тәгаләнең хикмәте! Бөтенләй онытып торам. Пушталион Рокыя тилиграм биргән иде бит. Әткәңнән, ди. Кайтырга кушкан, җыеп җибәрсеннәр дип әйткән, ди.

Мин үзем дә бик шәп укыйм ич аны. «Путевка алынды. Кайт, этиең».

Әти-әнине, үз ишегалдыбыздагы иптәш малайларны сагынып өлгергән идем инде мин. Телеграмма килүгә сөендем. Әмма күңелнең әллә кайсы почмагында моңсулык та бар иде.

Пионер лагерена озата барганда, авылдагы хәлләргә кагылышлы сүз җае чыгып, мин этидән сорадым:

— Әткәй, әбиләр авылындагы Габсаттар абзый әйбәт кешеме?—дидем.

— Бик шәп, бик намуслы карт ул, Харрас. Үзе теләп Кызыл Армиягә язылган, Буденныйның атлы гаскәрендә сугышкан. Актуганда колхоз төзешкән. Гомерлек тимерче, хәзер, картлык баса төшкәч, умартачы. Күреп кайткансың ич, колхозга бал җитештерә, умарта кортлары үрчетә. Бик әйбәт абзый, улым, бик әйбәт.

«Кызык соң бу өлкәннәр! — дип уйландым мин.—Әти әнә нәрсә дип бара. Әби Габсаттар абзыйны «денсез» дип орыша...»

Еллар үтү белән, чыннан да, кеше күп нәрсәне бүтәнчә аңлый башлый. Габсаттар абзыйның: «Тормыш өйрәтә ул. Аңардан да шәп профессор юк», дигәне хак шул. Мин дә, студентлык чорын кичергәч, хәрби хезмәттә булып кайткач, тормышның һаман «имчәк төбе» сөтен генә эчереп тормавын да, күркә чукудан тегеләйрәк әрнүләр барлыгын да чамалый башладым. Имза куюның да авырлыгын беләм хәзер. Гап-гади мәкалә астына фамилияңне язу да ансат түгел. Аның үз газабы бар. Хәер, ләззәте дә зур. Хезмәт белән сәнгать бергә үрелгән чор кешеләре хакында сөйләү бәхет түгел мени? Менә бит әле тагын шуларның берсе турында язарга дип юлга чыгуым...

Габсаттар абзыйны туачак очеркымның герое итеп күз алдыма бастыруга, никтер, хәтергә иң беренче булып аның кушаматлары килде.

Гадәттә кешегә бер кушамат тагалар. Аның буыннан-буынга күчә торганы да, кешенең үзе белән бергә дөньядан китә торганнары да була. Һөнәргә кагылышлы кушаматлар да бар, кешенең холкы-фигылennән чыгып кушылганнары да байтак, ник тагылганлыгының сәбәбе билгесезгә әйләнеп калганнары да җитәрлек.

Ни хикмәт, Габсаттар абзый Халитовның кушаматы берничә. «Тимерче Габсаттар», «Умартачы Габсаттар» дигәннәрен аңлатып тормаска да, кушаматка санамаска да мөмкин. «Унөч» Габсаттар да диләр аны. «Бүре Габсаттар» дип тә йөртәләр.

«Унөч»е болай булган. Бөек Ватан сугышы беткәч, госпитальдан савыгып чыккан Габсаттар туган авылы урамына кайтып керә. Станциядән ике-өч чакрым җир Берлинны алган солдатка ни торган, җәяүләп кенә кайтып керә бу.

Әй сагынылган, әй зарыгылган! Сугыш елларының бинниһая авырлыгыннан биртелгәндәй, чүгеп, искереп калган өйләрнең һәр бүрәнәсенә кагылып, сыйпап узасы килә.

Җәйге челлә. Августның беренче атнасы. Өйлә вакыты. Урамда бер кеше күрмәссең. Уракчылар кыр станындадыр. Өйдә калган карт-коры, бала-чага төшке аш табынын урап алгандыр. Ашның өстәлгә килгәнен көтәргә түзем җитми торган еллар иде бит.

Кояш баш өстендә торып кыздыра. Көнбагышлар булып көнбагышлар аңа күтәрелеп туры карый алмый. Гүя аларның да күзе чагыла. Эре-эре яфраклары исә кызудан шәлперәешкән.

Янгын сарае янына җиткәч, Габсаттар каланчага менеп баручы бер хатын-кыз күреп алды. Елгыр Галия! Аны утыз елдан соң күрсәтсәләр дә танымый калмассың. Ялгыш кына кыз бала булып туган. Йөрүе дә ирләрчә, тавышы да килде-китте егетләрнекеннән болайрак, борын астына күе төкләр бәреп чыккан. Пәке тигезә күрмә, һәр көн кырынырга каласы. Ә бүген Галия дә чамасыз сөйкемле күренде Габсаттарга. Туктап карап торды. Пилоткасын арткарак этәреп, уң кулны каш өстенә күтәреп. Әллә нинди оркестрларың уйнаса да тыңламас иде Габсаттар бу минутта. Актуган авылының революциядән соң ук бастырып куйган каланчасына элгән чаң тавышы илаһи бер моң булып тоелды. Биштәрен җиргә куйды ул, сул беләгенә салган шинеленең шуып төшкәнен

дә сизмәде. Тыңлады, санап барды: бер, ике, өч... унбер, унике. Шунда чыдамады, бар тавышына кычкырып салды:

— Галия! Сук тагын берне, унөч булсын! Минем кайту хөрмәтенә!

Гомерләрендә каланчаның унөчкә сукканын ишетмәгән малай-шалай урамга йөгереп чыга, янгын сарае күршесендәге йортлардан карчык-корчык капка төбенә юнәлә. Ни күрсеннәр—Бүре Габсаттары белән Елгыр Галия кочаклашып күрешеп, хәл-әхвәл сорашып маташалар. Шуннан һәммәсе Габсаттар кайту хөрмәтенә чаңны унөч сугу белән салют биргәнлекне төшенәләр.

— Мин сорадым, Галия сукты,—ди Габсаттар, үзен сырып алган авылдашларына.—Ник сукмаска?! Гел унике генә булып торырга дигән мени? Җиңеп кайтыш лабаса!

Шул хәлдән соң көне-сәгате белән Габсаттарга «унөч» сүзе ябышып китә.

Ә «Бүре Габсаттар?» Монысы—ата-бабадан килә торган кушаматы. Габсаттарның әтисен дә «Бүре Шәйхаттар» дигәннәр. Бабасына да шул ат тагылган булган.

Әллә соң аларның нәсел-ыругларына гомер-гомергә явызлык, мәрхәмәтсезлек, аяусызлык, шәфкатьсезлек юлдаш булганмы? «Бүре»некеләр әүвәл-әүвәлдән үз кирәкләрен генә кайгыртып, ертлачланып, комсызланып, хәлсез-көчсезне бугазлап көн иткәннәрме? Каты бәгырьлелек белән телдән төшмәгәннәрме?

Юк, әлеге кушаматка боларның берсе дә нигез түгел. Шәйхаттар картны да, Габсаттарны да Актуган халкы олы йөрәкле, кече күңелле дип кенә беләләр. Батыр нәсел, кыюлар. Эшкә куллары ята, өздереп эшлиләр. Ялкауны өнәмиләр, көн үтсенгә йөргәннәр белән сүзләре кыска. Андыйлар белән уртак табынга утырырга ашыкмыйлар.

Сабыр канатлары тиз генә сына торганнардан түгел. Гаделләр. Мәгәр хаксызга кимсетүдән, нахакка рәнҗетүдән сак булганың хәерле. Сдачаны бирә беләләр, әҗәтле булып калмыйлар. «Бүре»некеләрне законсызга кыерсыткан адәм соңыннан үзе закон эзләп йөрергә кала да кала...

Габсаттар абзыйның оныгы—кызы Нурсариянең малае—колхозның гына түгел, районның атаклы механизаторы Фаяз да койган да куйган бабалары. Эшен тел-теш тидермәслек эшләр, мактанмас, күкрәк сукмас, күршесенә булышыр. Олыны олы дип белер, кечене кече итәр. Саранланмас, икейөзлеләнмәс. Ялагайлыкны бар дип тә белмәс. Сүгенмәс, оршынмас. Әмма нахакка намусына тукынып, чыгырыннан чыгарсаң, Фаязның төкреклэп төйнәлгән йодрыгы ничә кило тартканын исәпләргә каласың инде...

Кыскасы, холык-фигыльләреннән, кешегә мөнәсәбәтләреннән яралган кушамат түгел «Бүре» дигәннәре. Аучы булуларыннан килә. Гомерләре буена бүре аулаганнар алар. Кош-кортка сунарга йөрмәгәннәр, төлке-куян белән дә аз мавыкканнар. Аның каравы, бүре аулаулары белән тирә-юньгә мәгълүмнар.

Габсаттар абзый бу кушаматка ичмасам тырнак очы кадәр рәнҗеми. Әгәр дә үсенеп китә торган гадәтле кеше булса, әлеге кушамат белән горурлана да дияр идең. Үсенеп, чәчәләнеп китү, кеше алдында җильяклану аңа ят нәрсә.

Университетта укыганда, Әстерхан өлкәсеннән төзү отряды белән кайтып килешли, мин әби янына—Актуганга тукталып, берничә көн авылда ял иттем. Шул көннәрне Габсаттар абзый белән байтак нәрсә сөйләшергә туры килгән иде. Сүзгә бәйле сүз чыгып, мин аңа:

— Үз гомереңдә ничә бүре аттың, Габсаттар абзый?—дигәнем булды.— Бүре аткан кадәр фашистны да дөмектергәнсеңдер шәт...

Габсаттар абзый гадәтенчә салмак кына җавап бирде.

— Кызык әйттең әле син, Харрас. Бүресен-фашистын бер чуттан кушып сорадың,—диде һәм саран гына, ләкин бик мәгънәле итеп елмаеп куйды.—Бүресе туксанга якын, ну сиксәннән ким түгел. Унбиш яшьтән керешкән идем ул кәсепкә, әтигә ияреп йөри башлаган идем... Житмешкә чыккан елны да атканым булды. Дүртәр бүре үтергән елларым бар иде... Инде фашистына килгәндә, точно фәлән хәтле дию авыр. Шунысы хак: махы бирмәдем, улым Гаффар өчен үчемне кайтардым дип беләм. Мәскәүне саклаганда гомере өзелде аның... Улым дим икән, илем-көнем дип тә исәп йөртәм мин. Гаффарның үлеме—илгә килгән афәтнең бер кыйпылчыгы...

Бүре белән фашистны бер чамаданрак әйтүем абзыйга ошап киттеме, бу сүзләргә ул кабат әйләнеп кайтты.

— Менә син бүре диден дә, Харрас, шундук фашист дип тә куйдың. Охшашлыклар бар инде, бар. Тульке фашист бүре генә түгел бит ул...— Абзый фашистны тагын нәрсә беләнрәк чагыштырырга микән соң дип уйлап алды бугай, сүзсез торды. Аннары әйтеп бетерде.—Фашист фашист инде ул. Аерма зур бүре белән аның арасында. Бүрене бөтенләй кырып бетерү ярамый. Ул—урман санитары. Фашист дигән хәшәрәтләрне актык яралгыларына кадәр кырып себерү фарыз.

Шул очрашуыбызда мин Габсаттар абзыйдан тагын сорадым:

— Синең фронтта һәлак булган шагыйрь Фәтих Кәримнең «Тимер һәм Тимерче» дигән балладасын ишеткәнең бармы?

> Колхоз тимерчесе Саттарга,
> Яше үрләгәндә иллегә,
> Гранаталар тагып биленә,
> Туры килде илен сакларга.

—диелгән анда. Гел синең хакта язылган кебек.

Габсаттар абзый бик тиз җавап кайтарды:

— Беләм андый шигырь барын. Оныгымның кызы, Фаяз баласын әйтәм, шигырьләрен сәхнәдә сөйли. Яттан белә. Мин армиягә кырык икенче елның декабрендә киттем. Ул шигырь шул елны язылган. Сугышка кырык өчтә генә кердем. Курск дугасында. Шуннан Берлингача. Сапер. Минем яшь тә кырык бишкә үрли иде инде үрләвен фронтка киткәндә. Ел ярым броньда тоттылар бит. Сугыш башлангач МТС мастерскоена алдылар колхоз тимерчелегеннән. И бронь бирделәр. Ни талпындым фронтка! Ярый, военком күз күргән кеше иде. Озатты. Озатмый булдыра алмады.

...Зәмһәрир февраль киче иде. Габсаттар авылдан биш-алты чакрымдагы машина-трактор станциясенең ремонт утарыннан кайтып килә. Һәр тумыш көнне өеннән йөреп эшләгәнгә, бу юл аңа һәр түмгәге, һәр борылмасы һәм кагылмасы белән таныш. Күзен бәйләп җибәрсәләр дә, абынмый-сөрлекми кайтып керәчәк. Юл кырыеңа утыртып чыккан маякларның барысы иртән аның белән исәнләшәләрдер, ә кичен саубуллашып калалардыр төсле.

Барганда-кайтканда кара көздән бирле көн яктысы күргәне юк аның. МТС ашханәсендәге кәбестә шулпасына иш итеп өйләдә ашар ризыгын кыстырып өеннән чыгып киткәндә, әле көн яралмаган була; арып-талып авылга юл тотканда, янә караңгы төшә. Төн караңгысы кар яктысын басып алгандай итә. Суык алачыкта уттай кызган тимер чүкеп әвәрәләнә торгач, бер саплам кышкы көнне искәрми дә кала.

Соңгы елларда юл барса да уйга бата Габсаттар, юл кайтса да уйлана. Күңел яктысын әллә нинди шом томаларга әрсезләнә. Ил кайгысын күтәрешү белән бергә, үз борчуы да иңнәренә таш булып ята. Тамак ягы такы-токыга әйләнү, өс-баш чамалы булу, ягарга төткәзә алмый йолыккалану, хезмәтнең таш кисүгә тиңлеге өстенә, Гаффардан хә-

бәр юклыктан бәгыре әрни. Әнә бит, әнә, аяк астындагы кар да аяк атлаган саен аңа кушылып сызлана сыман: «Шыгыр, шыгыр... Авыр, авыр... Сабыр, сабыр...»

Габсаттар иске мәчеткә урнашкан идарәгә кайтып кергәндә, председатель Һиммәтбану иртәгәлеккә наряд бирә иде. Абзый кулындагы бияләйләрен салып билбавына кыстырды, колакчын бүрегенә, дуплы төн якасына сарган бәсне кагып төшерде дә зур учы белән такыр башын сыйпаштыргалап, ишек буена барып чүгәләде. Түшәмгә аскан унлы лампа тәмәке төтене таралган бүлмәне тоныкк кына яктырта иде.

Тимерчене шундук күреп алган колхоз председателе Һиммәтбану, сүзен бүлеп, аңа игътибар итте.

— Хәзер түгәрәклибез, Габсаттар абый, нәрәтне, хәзер,—диде.—Аз гына сабыр итә күр, яме.

— Мин ашыкмыйм, төн озын әле,—дигән булды тимерче. Кирәк тирәкне ега дип, председатель бик гозерләгәч, өенә дә сугылмый килүе иде югыйсә.—Тульке фонарьларның яхшыларын алсыннар...

Габсаттарны МТСка эшкә күчергәч, тимерчелектә бер мәл ярдәмче булып маташкан Елгыр Галия генә калды. Ул бүтәнен кыты-мыты китергәли, тик ат дагалый белми. Дию пәриенең үзеннән дә курыкмастай йөреп, ат аягына якын килергә шүрли иде. Шуңа күрә бу эшкә Габсаттарны чакырмый булдыра алмадылар.

Һиммәтбану, тимерченең күңелен табарга теләгәндәй, бригадирларга сөйләп китте.

— Габсаттар абый сүзебезне екмады, МТСтан кайтышлый керүе. Тәтешкә ашлык илтә барасы атларны дагалатабыз. Өчесен ничек тә дагаларга кирәк. Алары тау астына тозга төшәчәк. Кибеттә суган маңчырлык та тоз юк. Алып кайтмасак, эш харап! Фонарьларның адәм рәтлерәкләрен алыгыз, тымат кисеен оарыгыз. Анда әнә өй бүрәнәләре шартлый...

Председатель агымдагы сүзне шулай сөйләп торды, ә бәгырен кара хәбәр ачысы аяусыз кисә иде.

— Шушындый көнне бер эштән талчыгып кайткан кешене икенче эшкә жигәм бит, шушындый көнне!—дип өзгәләнде Һиммәтбану.—Хәерсез хәбәрне әйтсәм, атларны дагалый аламыни инде ул? Дагаламасаң—атлар Тәтеш тавы астыннан менә алмаячак. Бөтен колхозга бер чеметем тоз юк. Авыл тозсыз интегә, пешергән бәрәңгесен дә ашый алмый. Соңыннан ипләбрәк әйтермен инде...

Атларны дагалап бетергәндә, кышкы төн уртасы житкән иде инде. Председатель үзе дә азакка кадәр алачыкта булды, мәгәр бу төндә Габсаттарга авыз ачып сүз әйтә алмады. Иртәгесен дә йөрәге житмәде.

«Кара пичәтле» хат килгәнгә атна була дигәндә генә Габсаттарны үз кабинетына чакыртты. Анда да сүзне бик урау башлады. Илгә-көнгә килгән кайгының зурлыгын, тылда да авырлыкның бихисап икәнлеген телгә алды, бертуган абыйсының һәлак булу хәбәрен кабат искә төшереп, күз яшен тыя алмыйча йомшап та китте. Аннары боегып-җебеп калуыннан уңайсызланып, чыдарга, сабыр итәргә кирәк, шунсыз булмый дип сөйләде.

Габсаттар тормыш тоемы белән хәлне сизенде, председатель хатынның тел төбен чамалады. Төп сүзгә күчә алмый иза чигүен күреп торды. Шуңа күрә, ирлеген итеп, нык булырга тырышып, үзе сүз башлады.

— Һиммәтбану, бик ачыргаланасың, Гаффар турысында бер-бер хәбәр бармы әллә, наный?—дип, туп-туры сорады.

Председатель моны көтмәгән иде, бер мәлгә Габсаттарга карап сүз-

сез калды, гүя иреннәре ачылмас хәлгә килеп береккәннәр иде. Ул шундый киеренкелек кичерде, тыны кысылды, күзләрен яшь пәрдәсе сарды һәм каршысындагы Габсаттар томан эченә күмелгән кебек булды. Шуннан соң ул, авызын каерып ачтырган шикелле, үзәк өзгеч аваз салды.

— Ә-ә-әй, Габсаттар абый! Улың һәлак булган бит! Үтергәннәр фашистлар Гаффарны! Бигрәкләр дә җәл бит, Габсаттар абый!

Һиммәтбану пальто кесәсеннән ачкыч таба алмый интекте, аннары аны сейф бигенә кертә алмый йөдәде. Байтак маташкач кына тимер сак астыннан конверт алып, Габсаттарга сузды. Председатель кулындагы конверт, җан бирергә азапланган кош сыман, дерелди-калтырый иде.

Габсаттар хатны кулына тотты, мәгәр уку кадәресе хәленнән килмәде. Шул чак председатель бүлмәсе бусагасыннан атлаган мәктәп директоры, колхоз партоешмасы секретаре Хәтимә булышты. Кәгазьдә Гаффар Габсаттарович Халитовның ил азатлыгы өчен барган сугышта батырларча һәлак булуын хәбәр иткәннәр, җирләнгән урынын әйткәннәр иде.

Габсаттар Хәтимә кулыннан конвертны кире алырга кыймый торды. Кулын яндырып ташлар төсле тоелды. Ниһаять, акылын җыеп, ул аны иске пинжәгенең эчке кесәсенә салып куйды. Шунда тимерче йөрәгенә дөрләп ут капкандай булды. Габсаттар чыраен сытты, тешләрен кысты. Бәгыре көйрәүгә тәкате калмагач, йодрыкларын йомарлады, тырнак очлары уч төбенә батып керде. Йөрәк авыртуы тәненең барча күзәнәкләренә күчте.

— Эх, балалар, балалар!—диде ул, урындыгыннан кузгала алмыйча.—Шул яшегездән гүр иясе булырсыз дип үстергән идекмени соң без сезне? Тагын күпме гомерләрне өзәр икән инде бу фашист үләте?

Ирләр еламый димәгез, ләкин Габсаттар председатель белән парторг алдында яшь күрсәтмәде. Тимерчедә тимер ныклыгы бар дигәннәре хактыр, күрәсең. Аның таудан зур кайгысы янәшәсенә икенчесе килеп сыенган иде инде:

— Ү-ү-үзем-үзем инде, ү-үзем бер хәл. Ә-ә-әс-магөл апагызга ничекләр итеп әйтермен дим.—Ачуы купса, артыгын шатланса, я кайгырса, аның тотлыга торган гадәте бар.—Кы-кы-кызым Нурсариягә ни диярмен? Яман хәбәр күтәреп керердәй булгач, хет өйгә кайтып кермә инде менә!..

Габсаттарга теләктәшлек йөзеннән Һиммәтбану белән Хәтимә «әллә без барыйкмы булмаса?» дип караганнар иде дә, тимерче абзыйлары моны кирәкмәскә санады.

— Бүген түгел, бүген түгел,—дип кабатлады һәм, балтырына таш таккан төсле, авыр гына кузгалып, председатель бүлмәсеннән чыгып китте. Кабинеттагылар авызларына су капкандай карап калдылар. Габсаттарны юатып булмый, ул моңа мохтаҗ да түгел, үзенә, меңнәргә, илгә ябырылган дәһшәтнең төбен-тамырын ир акылы белән аңлый иде. Тимерче йөрәгендә ерткыч баскыннарга карата күтәрелгән үчне үлчәү мөмкин булмас шикелле, күңелендәге нәфрәт аңа бер генә киңәш бирә иде: «Үч ал, Габсаттар! Үч ал! Үчеңне кайтар!»

Хатыны Әсмагөлне Гаффарның үлем хәбәре аяктан екты. Ул урын өстенә үк ятты, тамактан калды, йокысы качты.

Габсаттар белән Нурсария Әсмагөлнең бу хәлгә төшүеннән тәмам шомлана калдылар: акылына зыян кагыламы әллә дип курыктылар. Берүк язмыш шундый җәза гына бирмәсен! Кешенең акылына ак кыл кысылудан да яманы юк. Андый бәхетсезлек әҗәлдән дә битәр. Ана өйнең өрлеге, ансыз гаиләдә ни кылырсың?! Инде болай да өй шыксызланды, яме китте. Әүвәл күңелгә якты салган нарат стеналар гүя кайгыдан саргайдылар. Озак еллардан бирле түрдә эленеп торган зур күз-

ге дә хәсрәт ачысыннан тәмаланды кебек. Тәрәзә төбендәге гөлләр дә зәмһәрир салкын кагылганнан түгел, ә җан кыйналудан шиңгәннәрдер төсле.

Шулай да сызлаган җанга иң яхшы шифа—вакыт дип тикмәгә әйтмәгәннәрдер. Кеше, көннәр, атналар, айлар узу белән, «үлгән артыннан үлеп булмый» дигән фикергә килә, сыкрап-сыктап булса да, янә дөнья көтү мәшәкатьләренә чума. Дөрес, ата-ана бәгырен гүргә кергәнче чәнчеп торачак бер шырпы кала да кала инде. Анысын еллар да, дистә еллар да суырып чыгара алмый.

Октябрь бәйрәме узгач, Габсаттар, фронтка китү ниятеннән, военкомат белән авыл арасындагы юлны такырайта башлагач, Әсмагөл йөрәгендәге ул шырпының кадавына чыдар әмәлләр бетте.

— Алла хакына дип сорыйм, үрсәләнмәсәнә, сиңа әйтәм,—дип ялварды Габсаттарга хатыны.—Гаффарсыз калдык, инде үзең дә җәһәннәм утына керим дип кыбырсыйсың... Карурманда качып ятмыйсың бит, хода бәндәсе!

Ире аны кызмый-дөрләми генә юатты. Аңлатты, төшендерде, ил язмышы хәл кылынган чакта үз урынының яу кырында икәнлеген каткат әйтте: «Мин, әнкәләре, үзем дошманнан саклашып калган илдә гражданнар сугышыннан бирле иркен сулап яшәдем. Хәзер минем фронтка китүем кирәк тә кирәк. Сугыш беткәч, кеше күзенә туры каравы рәхәт булачак»,

Иренең уен да, теләген дә аңлый иде Әсмагөл. Аңлый иде, ләкин тормыш тәрәгеп, дөньяда иң якын, иң газиз кешесен ут эченә чыгарып җибәрәсе килми иде.

Иртәгә авылдан чыгып китәргә дигән көнне Әсмагөлнең өзгәләнүен әйтеп аңлатуы читен булды.

— Соңгы күрүләрем шулдыр... Кемнәргә таянырмын да, кемнәр күзенә тилмереп карармын?—дип, ул өзми дә, куймый да яшь түкте.

— Кирәкмәгәнне юрыйсы булма, әнкәләре. Мине яуда ятып калыр дип уеңа да китермә.—Габсаттар бу сүзләрне шул тикле ышандырырлык итеп әйтте, Әсмагөл елавыннан туктап, иренә томырылып карап торды.—Гражданскида ике үлемнән калдым, колхозлашканда өченчесен үткәздем. Өчәрләнгән өзелми, әнкәләре... Гитлерның башына җитеп кайтырбыз, менә күрерсең!

Әсмагөл иренең гражданнар сугышында ике кат яраланганын тәнендәге яраларыннан гына белә иде, өченче тапкыр әҗәл авызыннан котылып калуы Әсмагөл күңелендә гомергә уңалмаслык шикелле тора.

...Колхоз оешкан гына чак. Күмәк хуҗалыкка үз тимерчесе дә, тимерчелеге дә кирәк булды. Сука-сабанын төзәтергә, урак-чалгысын көйләргә, көпчәк кыршауларга, ат дагаларга, келәт-абзарга күшәндер-тоткадыр ясарга, чиләк төпләргә... Чуты бетәмени хуҗалыктагы мәшәкатьнең! Башта саман кирпеч суктылар. Шуннардан алачык өйделәр. Иркен итеп, тирә-юньдә бер димәле. Халыкны шаккатырганы тагын шул булды, бай йортларыннан да уздырып, алачыкның түбәсен калай белән яптылар. Нигъмәт кулак амбарлары башыннан каерып... Ут-күздән имин булыйк дип. Беренче председатель Баһаветдин Борһаны кушуы белән. Бик булган кеше. Хәзер дә исән әле, райүзәктә яши...

Габсаттар, әтидән калган һөнәр дип, тимерчелектә эшли башлады.

Уракка төшкән көннәр. Эшкә ярардай һәммә кеше басуда. Караңгы капкач кына кайталар, ризыкланалар да, егып салган кебек йокыга авалар. Таңнан торып янә басуга. Көзге чәчүгә төшәргә дә санаулы көннәр калды дип, Габсаттар атлы чәчкечне ремонтлап йөри. Анысы да Нигъмәт кулактан тартып алган чәчкеч. Кояш иңгән, караңгы төшеп бетмәгән әле. Шунда алачыкка икәү килеп кермәсеннәрме!

Габсаттар баштарак аларның кемлеген аңайламый торды, янына килеп, изүеннән умырып алгач, таныды: берсе Нигъмәт кулакның төпчек улы Ясәви, икенчесе Сәфәр Садриенең Фазылы. Ярлы ябагай инде югыйсә, һич кенә дә ике чабата бер кием дия торган түгел. Анысының сыйлаганга сөйрәлеп йөрүедер. Кәгеп алганнар, үзләреннән котырган сыер сөтенең исе аңкып тора.

Ясәви әтәчләнепме-әтәчләнә.

— Калай түбәле алачыкта эш майтарамсың, коммун калдыгы? — дип җикеренә.— Әткәй сиялкасы белән камфуз арышын чәчәргә җыенасызмыни? Барып чыкмас, хәзер йомычка итәбез без аны!.. (Колхозны «камфуз» дип хурламакчы...)

Габсаттар ак диярга дә өлгермәде, кара да димәде, гарьлегеннән җан ачулары кузгалып, Ясәвинең танавына берне кундырды. Теге мәтәлчек атып, сандал буена барып төште. Тимерче ишеккә ташланды, мәгәр чыгып өлгерә алмады. Сәфәр Фазылы аяк чалып екты да башына тимер белән ямады. Шуннан Габсаттарның кул-аягын тимер чыбыклар белән бәйләделәр, авызына киндер алъяпкыч сәләмәләре тутырдылар. Аннары аны онытып тордылар диярлек, күмерлеккә көрәк-көрәк күмер салдылар.

— Җаның җәһәннәмгә ычкынсын!—ди Ясәви.—Үрләт күмерне, өрдер күрекне, ыргытабыз шунда...

Нинди генә йөрәкле, гайрәтле булмасын, Габсаттарның да коты очты. Тәмуг шушы булыр, күрәсең, миңа диган уй тетрәндерде аны. Кем кулыннан үлә бит әле җитмәсә! Тимерченең бәхетенәдер инде, күрек сабын тоташтыра торган алканы алыштырыйм дип, алып аткан иде. Өрдерә генә алмадылар, утлары дөрләмәде генә... Әй кайнаштылар, әй маташтылар—юк кына...

Күпме вакыт узгандыр, Габсаттар моны чамаларлык хәлдә түгел иде инде. Агу йоткан бандитлар ниндидер тавыш ишетеп сискәнделәр. Ат аягы тавышы ишетелә иде. Ясәви тәрәзә буена йөгереп килде һәм башын тыгып тышка карады. Шунда аның чырае качты, үзен дерелдәү алды һәм ул елан ыжгыргандай:

— Мытыес Харисе!—диде.

Шул язда гына оешкан МТСның директор ярдәмчесе—замполит Харис икән. Габсаттар белән атын дагаларга сүз куешкан булганнар. Анысы соңыннан ачыкланды.

Юлы кисәлгәнен, койрыгына ут капканын бик ачык төшенгән Ясәви зәһәрлегеннән буылыр дәрәҗәгә житкән иде. Ул алачык тәрәзәсе буеннан очынып килде дә, күнитек балтырыннан хәнҗәр суырып алып, Габсаттарга кизәнде. Кул-аягын бәйләп салган Габсаттар шуннан соң ни булганнарын бөтенләй хәтерләми, һуштан язган, аңын җуйган иде.

Шул хәлләрне искә алганда, Габсаттар абзыйның әле дә булса кәефе чамасыз кырыла, йөзе караңгыланып кала һәм сүзсез утыра. Бераз вакыттан гына әйтеп куючан:

— Бүгенге үрләргә менеп житкәнче тир генә түгел, канны да бик күп түктек. Сынадык та, сыналдык та. Мин ни, мин—бәхетлеләрнең берсе, бүгенге көннәрне күрә алдым. Бүтәннәр бит бу рәхәтне хыялларында гына алып киттеләр...

Шунысы кызыклы: Габсаттар абзыйның гомере өзелә язып калган алачык урынында хәзер умарталык, зәңгәр умарталар рәте. Заманасында ул алачыкны Габсаттар алачыгы дип йөрткәннәр, алачыгы булмагач исеме дә онытылып бара инде. Агай үзе моны һич оныта алмый. Гомерендә дә чәчәкле-чуклы сөйли торган гадәте булмаса да, моннан илле елга якын элек булып узган шушы вакыйганы исенә төшергәндә: «Шунда борынлап чыккан чәчәкләрдә минем кан тамчылары да бардыр төсле, билләһи!» — ди.

Ул елны, күпме тырышсалар да, Нигъмәт Ясәвиен эләктерә алмаганнар. Фазылын утыртканнар. Ясәвие дә я дөмеккәндер инде, я картаеп бөкрәйгәндер. Мәгәр Габсаттар йөрәгендәге үч картаймый да, сүрелми дә, чүпрәдәге кебек, кабара гына тора. Кешегә игелектән һәм турылыктан бүтәнне белмәгән карт, сүз кулак ерткычларга килеп терелсә, болай диюдән гел тайчанмый:

— Әгәренки менә хәзер очратсаммы, беркемнең бер сүзен тыңламыйча, бугазын чәйнәр идем мин аның: җирдә безнең белән яшәү хәрам андыйларга!

Ул сүзләр гел мөлаем, шаян, миһербанлы Габсаттар абзый холкындагы бүтәнрәк сыйфатлар барлыгын да сөйли. Аларны фикер иләгеннән үткәзгәч, кеше күп кырлы асылташ дигәнгә янә бер иман китерәсең.

*
* *

Сугышны җиңүле тәмамлап, хәрби госпитальләр белән исәп-хисапны өзеп, Актуганга кайтып кергәндә, Габсаттарны үзе дә, күзе дә ышанмаслык яңалык көтә иде. Капка төбендә шатлык яшьләре түгеп каршылаган Әсмагөлен кочагыннан бик озак җибәрми торганнан соң өйгә керсәләр, түрдәге караватта ике яшен тутырып өчкә чыккан сабый бала уенчыклары белән әвәрәләнеп утыра иде. Күмердәй кара күзле, бөтерkәләнеп торган кара чәчле малай. Маңгае киң, колаклар тырпаешкан, борын төз, авыз ерык. Габсаттарны күрүе булды, тартыну-ятсынуны белми кулларын аңа сузды һәм «баба! баба!» дип такылдарга кереште. («Бабаң кайта, бабаң!» дигәнне мең дә бер ишеткән иде инде ул. Колагына элдеме—сабый тутый кош белән бер, кабатлый да тора.)

Шулай итеп, йорт башы сугышка чыгып киткәндә өйдә калган ике җан өчәү булырга өлгергәннәр иде.

Габсаттар әллә ничаклы ят чалымнар белән бергә, бу сабыйда кызы Нурсариянең дә йөз сызыкларын абайлап алды. Әнә шул сызыклар гөнаһсыз җан иясенә карата миһербанлы хис кузгатты шикелле. Ул аны кулына алды, шап-шоп китереп артыннан какты, аннары, тулы җавап алырына инанган шикелле, баладан сорап куйды:

— Я, кара күз, сине кем дип белик инде? Исемең ничек синең?

Малай исемен бик чиста әйтеп бирде.

— Мин—Фаяз!—диде.

Чамасыз каушап, ире авызыннан нинди генә сүзләр чыгар инде дип тетрәнеп торган Әсмагөл, ничарадан бичара хәленә төшеп, үзе дә сизмәстән такмакларга ябышты:

— Мин—синең оныгың, бабакаем, диген, улым. Тәти оныгың булам, диген...

Габсаттар күзләрендә яман очкын биешеп сүнде. Әмма, нинди сабырлыклары килгәндер, күтәрелеп бәрелмәде генә түгел, тавышын күтәреп авыр сүз дә әйтмәде.

— Алай, алай...—дип сөйләнде ул һәм биштәрен чишеп, малайга шикәр кисәге тоттырды. Фаяз бу күчтәнәчкә беравык карап торды да, юкка бирмәгәннәрдер дип уйлап алды бугай, тәмләп суыра башлады. Габсаттар исә эчендә ниндидер хәерсез өермә күтәреләсен тоеп, тизрәк юынырга чыгу ягын карады. Әсмагөл артыннан ияреп чыкмасынга: «Тузаннан арынып керим әле, берәр чиста күлмәк карый торсаңчы!»—дип куйды. Әсмагөлен бер генә минутка да яныннан җибәрмәстәй булып, күзләренә генә карап утырырдай булып кайткан иде дә соң, Европаны гизеп, фашист мордарларының сыртын сындырып кайтуына әнә ниндирәк бүләк хәстәрләп куйганнар бит! Нурсария үзе эштәдер инде... Менә сиңа онык, менә сиңа Фаяз дигән җан иясе. Онык бар, әнкәсе бар, әткәсе турында ләм-мим. Әүвәл заман булса, капканы кара дегеткә бу-

яп китәрләр иде, баланың күзен ачырмаслар, «зина бәрәне!» диюдән бүтәнне белмәсләр иде. Эх, дөньялар, дөньялар. Бүре нәселенә дә җилдән бала табу һөнәре килеп кердемени соң инде?! Олыгаеп барган көнемдә мин шуның гайбәтләрен дә җыярга тиешмени инде? Монысы нинди җәза тагын? Ниткән гөнаһларым, кайчан кылган языкларым өчен? Мактаулы кыз туйда тәһарәт боза диләр, аның Нурсариясе дә шулай арзанлыга әйләнде микәнни соң? Кызның исеме чәчәктә, аннан төшсә тизәктә дип бик белеп әйткәннәр шул. Бәбәккә терәп әйтмәсәләр дә, дус бар, дошман бар, мыек астыннан гына елмаеп сораучылар табылыр әле. Нихәл, Габсаттар? — диярләр. Оныгың имин-аман гына үсәме?—диярләр... Башыңа таш төшкәндәй калмас та иден шәт, бу хакта сыңар сүз дә язмадылар бит, сыңар сүз дә!.. Карында яралган баланы ашереп булмаганны, якты дөньяга килгән җан иясен телгә алмый гына бүтәннәрдән яшереп буламыни инде?

Әсмагөл дә кызның тезгенен тота алмаган булып чыга. Нурсария дә тыйнак, сабыр булыр дигән өметләрне җилгә очырды дигән сүз. Чибәр булып үсте шул, егет-җилән сарылырлык булып. Матурлык сынавын һәркем имин узалмый, чибәрләрнең башын тиз әйләндерәләр. Кызлар дигән кызыл авыз тасма телле ир-ат затының һәммә сүзен чынга алырга ашыга. Азак килеп, мә сиңа: дөньяга Фаязлар туа...

Озаклап юынды Габсаттар, артык озак. Әсмагөле күлмәк хәстәрләп куйгач та байтак көтте аны, йорт башы кермәде. Юынып сөртенгәч тә өйгә ашыкмады.

Ян бакчага чыгып, умарталарны карады. Биш-алтысын бергә тезеп куйганнар. Бушлар. Кортлар, оялары тузгып, һәлак булганнар. Бердәнбер умартада тормыш кайный. Анысы ныкка чыккан гаилә дигән сүз...

— Шулай, шулай...—дип үзалдына сөйләнде йорт башы. Илгә килгән афәт иргә тия дибез, кортларга да кагылмый калмаган... Мәгәр ыруын үчерә алмаган. Алмас та!

Бакчадан кергәч, Габсаттар чүгеп-чүмәшеп калган абзар-кураны карап йөргәндәй итте, бер якка янтайган кара мунчаны күздән кичерде. Түбә такталары черегән иде. Тәньягыннан шундый куе мүк сарган, чәчеп үстергәннәр диярсең. Өйнең үзенә дә, болай булса терәү кирәгә башлар. Яңасын җиткерүләр моннан карап күренми әле. Дәүләттән тиз генә урман өметләнергә урын юк. Гаепләп тә булмый. Яндырылган, хәрабәгә калган авылларны, калаларны үз күзе белән күреп кайтты. Аларны торгызырга казнаның малы җитмәс әле! Фашист безнең илгә салган казаны хисапларга кеше башы җитмәстер, мөгаен. Сугыш кисәве дөрләмәгән безнең якларда бары бергә, югы уртак дип, булган кадәресенә шөкер итебрәк яшәргә туры килер шул әле...

Мәгәр тормыш дигәнең үзенекен даулар инде ул. Төзекләндерәсе дә килер, матурландырасы да килер. Дөнья туктап тормый бит, яшьләре үсә... Габсаттарның уйлары ихтыярсыздан янә Нурсариянең баласына, Фаязга кайтып теләлде. Сабыйның ни гөнаһысы бар инде? Җан биргәннәр, дөньяга килгән. Атам кем дә, анам кем дип, алар чын кешеләрме, әллә җилкуарлар, тотнаксызлармы дип уйлап та, сайлап та тора алмый бит ул. Менә аңа гомер биргәннәр, нинди тормыш бирерләрен уйлап баш ватмаганнар, анысына вакытлары булмаган, эшләре ашыгыч килгән.

Җан биргәнгә юнь бирер дип кенә яшәп булмый бит. Ул бала хәзер Халитовлар иңенә гомерлеккә берекқән инде. Телисеңме-теләмисеңме, аны кеше итәргә кирәк...

Өс-баш алыштырганын да көтмичә, Фаяз бабасына сарылды. Шикәр тәме шул кадәр тиз ияләштердеме, малай үзе кеше җанлы идеме, өзеп кенә әйтә алмассың. Шул чаклы җан җылылы бу сабый, ничек

итеп кырын карарсың да, тел тибрәтеп чәнечкеле сүз әйтерсең. Шулай да йорт башының йөрәгендә олыларга — хатынына һәм кызына — ачу да, рәнҗү дә зур иде. Шуңа күрә ул Әсмагөлгә бирәсе сорауны да оныгы белән гәпләшкән булып кына теленнән чыгарды.

— Кем малае инде син, улым? Әтиең кем була?—диде. Бала, «әтиең» дигән сүз ычкынуга, теле ачылган чакта ук отып калган җавабын бирде.

— Әттә титте...—диде.

— Шулаймыни соң, улым? Кая китте? Бик ераккамы? Кайчан кайтыр икән ул? Кайтыр микән? Әллә кайтмас тамы?

Габсаттар сорауларын сабыйга тезүен онытып җибәрде бугай, аның тавышы көрәя, усаллана барды, соңга таба бөтенләй кычкыра башлаганга охшап калды. Шуннан соң инде Әсмагөл чыдамады, иренең янына килеп утырды, аның беләгенә ябышып, башын иренең җилкәсенә куйды һәм капка төбендә каршылагандагыдан да яманрак итеп елый башлады:

— Әй, Габсаттар гынам! Сиңа да сабырлык бирсен инде ходай. Күңеленә шәфкать сала күрсен, зиһенеңне чуалтмасын берүк. Хак тәгалә үзе шаһит дип беләм, Нурсария азып-тузып йөрмәде, мәхәббәте шулай итте, мәхәббәте...

Габсаттарга бу сүзләр кашыклап тоз каптыргандай тәэсир итте. Ул хатынының кулын беләгеннән ычкындырды һәм читкәрәк шуышып утырды.

— Мәхәббәте, имеш. Таптың сүз, таптың акланыр җай! Тәкате бетте диген ичмасам. Анысы сүзгә охшар... Мәхәббәт! Аның ише мәче мәхәббәтенең кемгә кирәге бар! Кызым намусын саклый алмады диген инде син. Мин кулда тота алмадым диген. Итәгенә бала салып кайткач, куып чыгара алмадым дип аклан бер дә булмаса. Балавыз сыкма. Язмыш кыйнаганнан түккән күз яшен дә байтак күреп кайттым мин, азмыш уйнаганнан түккән яшьләрне күрергә зарыгып тормыйм. Авыл халкы ни диде инде, мин ничек кеше күзенә күренермен? Бу хакта ике ятып бер төшегезгә кергәне булдымы?

Әсмагөл кызарып чыккан күз асларын туздырып бәйләгән яулык чите белән сөртә-сөртә, елавыннан туктый алмыйча, аңлатмак булып маташты.

— Авылдашлар әллә ни гаепкә сукмадылар сугуын. Нурсариянең Мирхәйдәр белән чын-чынлап сөешеп йөргәнен белмәгән кеше юк иде бит инде, әтиләре... Тәмсез сүзгә урын да юк иде инде...

Дөрес чамалаган булып чыкты Габсаттар. Фаязны күрүгә, каршы күрше егете Мирхәйдәргә охшаткан иде ул. Ул егетнең үсмер чакта Нурсария тирәсендә әйләнгәләвен дә белми түгел иде.

— Баласын кулына алганы булдымы соң атасының? Мирхәйдәрнең дим?

— Андый бәхетләр насыйп булмады шул, Габсаттар гынам, насыйп булмады. Фаяз бит әтисе сугышка киткәч туды, Мирхәйдәр хәбәрсез югалды. Бизвисти дигән язуы килде.

Габсаттар иренен бүлтәйтеп, тешен кыскан килеш, сүзсез генә баш селкеп утырды да, эчен-тышын ут ялмаганын сиздереп әйтте:

— Җирдә бер ятим артсын дип ашкынуы булган икән егетнең! Болай азрак иде шул... Алар аһ-зарыннан ил сыкрап тора бит инде...

Шулай диде, ә Фаязны итәгенә күтәребрәк утыртты да зур учы белән башыннан сыйпаштыргалый башлады.

— Тумас борын ятим мени соң инде син, балам? Сыңар канат мени инде, ә?

Ул тагын сүзсез торды. Бугаз төененең арлы-бирле селкенүеннән

генә тамагына килеп утырган төернең эреп китә алмавын чамаларга мөмкин иде.

— Нурсария үзе кайда соң безнең? Габсаттарның тавышы янаулы чыкты.—Фермада эшли дип язган идегез, һәмишә шундамы?

Әсмагөл бу сорау кайчанрак, ни рәвешлерәк бирелер дип күптән көтә иде инде, җавабын ничек тә иренең күңелен табарлык итәргә тырышты.

— Каенлыкка киткән иде әле ул. Өчне кунды инде. Сеңелең авырып тора бит, Маһисәрвәр. Фермадан китәргәрәк тә нияте. Районга май заводына эшкә керимме әллә диебрәк тә тора. Торырга бер бүлмә бирәселәр, ди. Фаязга ясле дә булыр төсле икән. Әткәй кайткач хәл кылырбыз дип тора иде инде.

Габсаттарга тылмач-тәрҗемәче дә, аңлату-шәрехләү дә кирәкми иде. Һәммәсен төшенде. Маһисәрвәр сырхап торадыр, сүз юк. Яшьтән саулыгы бөтен булмады сеңелесенең. Мәгәр өч-дүрт көн, бер атна булышу белән генә аны сырхавыннан арындырмалы түгел иде. Хикмәт бүтәндә. Әткәй кайтканда күз алдында булмыйм дигән бу бала. Май заводына эшкә китү дигәне дә сынап карау булмагае. Юк инде, кылган кыланмышлары өчен аркасыннан сөймәсәм дә, өйдән куып булмас. Өйләреннән-илләреннән куылганнар сугыш аркасында да бихисап булды. Шулай карар кылгач, Әсмагөленә эндәште.

— Каенлыкка баручы булмый калмас, әйттер, әткәсе кайтты, диген. Аякка баскан булса, Маһисәрвәр дә килеп китсен... Ничек соң, Җәмилә кергәлиме? Караганы бармы соң баласының баласына күз сирпеп?

Бу сорау Әсмагөлгә житә калды. Бая әйтеп житкермәгәннәрен түгәрәкләп куярга мач килде. Аның сула төшкән, әмма чибәр йөзенә нур төшкәндәй булды. Зур соры күзләре җанланып китте, мәрҗән булып тезелгән ак тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды хәтта.

— Кодагыймы? Керәме дип, урам аша сукмакка тузан төшергәне юк. Фаяз дип сулый һәммә сулышын. Бала да аны үз итә. Әйтәм ич, ил күзендә рисвай итмәделәр алар. Кода да, туфрагы җиңел булсын, кодагый да Нурсарияне бульнистан үзләре барып алдылар да! Туп-туры үзләренә алып кайттылар. Мирхәйдәрнең гозере шулай булган...

— Алаймы? — Габсаттар чыраена да таң яктысы сирпелдемени?! — Ата-анасы белән мәслихәтләшкән икән алайса?..

— Шулай, шулай...—Әсмагөл ирен тынычландырырга дип җан атты.—Шулай булмыйни?!

Аннары ул аш өлгертте, чәй житкерде. (Габсаттар үена да китермәгән хәл өстенә кайтып кермәсә, күптән өстәл тирәли утырышкан булырлар иде инде.) Крестьян өстәленә солдат паеклары кучте. Поход кухняларында, госпитальь ашханәләрендә ашаган ризыклардан соң үз өең түрендә кинәнеп сыйланудан зур хозурны әзлисе дә юктыр ул. Шушы көнне көтеп, шушы сәгатьләргә дип саклап торган бодай онынн пешерелгән токмач дөньяның бер генә илендәге бер генә ашка да алыштыргысыз иде.

Ашап-эчеп, өстәл җыештырганда, сугышның утлы-күмерле юлларын урап кайткан солдат янына туган-тумача, күрше-күлән керә башлады. Габсаттар алар белән сагынып, тәмләп, җәелеп китеп сөйләште. Кемнәрне генә телгә алмадылар, кемнәрне генә хәтерләмәделәр. Ике йөз чамасы йорты булган Актуганнан өч йөзгә якын кеше яу кырыннан кайтмаган булып чыкты. Имгәнеп кайтканнары иллегә тула яза. Хәбәрсез югалды дигәннәре берничәү...

Бөреләнеп тә чәчәк атмаган, чәчәк атса да җимеш бирмәгән һәм бирмәячәк язмышлар турында фикер йөртте Габсаттар абзый. Туган көнендә үк атасыз калган бала, кавышкач ел да үтмәгән килеш тол калган кызының язмышы аны тирәнтен борчый, сыкрандыра иде. Ял-

гыз калса. Нурсария үзен генә кайгыртыр иде, хәзер аның иңендә сабый тормышы. Ятим бала киләчәге. Әлбәттә, заманы ятимне дә кагып-сугып йөртә торган заман түгел инде дә... Бездә кеше атадан-анадан ятим калса да, Ватан-анадан ятим калмый. «Ятим бала дип кимсетмә, бәхете булса, ир булыр» дигәне дә бар сүзнең...

Әсмагөл өстәл артъягында тын гына утыра бирде, Габсаттарның уйларын бүлдерергә кыймады. Йорт башы хатынына түгел, үзалдына әйтеп куйды:

— Оныкны ятим итмәбез анысы, итмәбез... Кактырмабыз да, суктырмабыз да. Үзе дә бик махы биреп торучылардан булмас. Туган үсәр, бездә кеше югалмый, суга артын борган тиле генә булмаса, югала да алмый... Югалсалар, ким-хур булсалар, гражданнар сугышы вакытындагы беспризорныйлар югалып калган булырлар иде! Кемнәр генә чыкмады алар арасыннан. Фаязның әле анасы бар, әбисе-бабасы бар, нибуч...

Бу минутлар Габсаттарның Фаяз язмышын үз җилкәсенә алган чак иде булса кирәк. Шул көннән оныгы аның өчен күздә-каштә булды. Төчеләнде, йомшагыннан гына кагып торды, бар тәмлене аңа каптырды, бала сүзен генә дөрескә чыгарып азындырды, үсендерде дип уйлый күрмәгез ләкин. Һич юк. Габсаттардан андый кәнфитләүү көтү мөмкин түгел эш иде. Ир итәргә тырышты ул аны. Аягында тупырдап йөри башлагач ук, кул арасына кертергә тырышты, олылар сүзенең закон икәнлегенә өйрәтте. Иркәгә, назга артыгын юмартланмады, сөясе килгән чакларында да Фаяз йоклап киткәч кенә үбә торган иде. Нурсариягә дә әмер шундый булды. Хәер, бу йортта Габсаттар сүзеннән узган кеше юк иде. Әмма үзе сүзен әйтер алдыннан кат-кат үлчәр иде. Кайчакларда җиде үлчәп тә бер дә кисми калдырганы да булды. Адәм баласы түгел, дүрт аяклы ат та абына, дип уйлый иде ул.

Шулай да оныгына килеп кагылышлы бер хәлдә җиде түгел, ике дә уйлап тормыйча зур күңелсезлеккә, хәтта бәлагә тара язып калды Габсаттар.

Болай булды.

Габсаттар Халитов гаиләсенең кырык бишенче ел өчен ит налогы түләнеп җитмәгән икән. Мондый хәлнең бик ямьсез исеме бар иде—недоимка.

Шул биреп житкермәгәнлекне юллап, сентябрь кичендә, көтү кайткач, уполминзаг[1] агенты белән авыл Советы башкарма комитеты секретаре Ризатдин Таҗиев килеп керделәр. Габсаттар ике атнадан бирле колхоз тимерчелегендә эшли иде инде. Эштән кайтып, тамак ялгарга йөргән чагы.

Ризатдин — авылдаш кеше, әллә ни батыраеп сөйләшми, кушканга килдем инде дигән төслерәк кенә торды. Мәгәр районнан килгән иптәш бик төксе күренә иде. Кыстаганны,' урындык тәкъдим иткәнне дә көтеп тормады, түр өстәл буена килеп утырды да, папкасыннан зур кенәгә чыгарып, кирәкле битен ачты. «Халитов Габсаттармы?» дип сорады.

— Шул дип белегез.—Габсаттар болай һавалы сөйләшүне көтмәгән иде, аңа ят тоелды сүзне болай башлау.

— Тәк, тәк,—диде агент.—Бәрәңге түләнгән сезнең. Түләнгән. Сөт буенча да норма. Түләнгән. Йон шулай ук түләнгән. Йомырка... Анысы да түләнгән. Ит белән эшегез мөшкел. Артыгын көтеп торыр җай юк, кем, иптәш Халитов. Аңлашыламы?

— Аңлашыла.—Габсаттар тыныч-сабыр гына җавап кайтарды.

— Артыгын көтмибез дигәне аңлашыламы? — дим мин сезгә, иптәш Халитов.

[1] Хәзерләүләр министрлыгы вәкиле

— Шунысы аңлашыла дип торам мин дә.—Йорт башы тавышына суык керде.—Уйлашырбыз, чарасына керешербез, түләрбез. Моңа тикле бурычлы булып калган юк иде әле.
— Бүген үк түләргә кирәк.
— Ягъни ничек итеп? — Габсаттарның күзләре зуррак ачылды, тавышы янгыравыграк чыга башлады. Ачуы кабарганы ачык иде.
— Син кем, иптәш уполминзаг, үгез булмагае чурт булсын, хатыныма сөт булсын дигән дивана кебегрәк сөйләшәсең бит әле. Таштан юкә суйдырмак буласың. Алай гына барып чыкмый ул. Әйтеп торам, озаклатмабыз, түләрбез. Безнең өчен кеше кашынмас...
Агент ике сөйләшергә яратмый иде булса кирәк, кырт кисте.
— Сарыгыгызны алып чыгабыз!
— Чыкмый торыгыз!.. Патша заманы түгел бу! Совет чоры диләр безнең заманны. Мин шул Совет властен яклап ике сугышта кан койган солдат. Кайтканыма ай тулыр-тулмас кына...
Уполминзаг агентына Габсаттарның аяк терәп сөйләшүе бөтенләй ошамады. Ул күн папкасын әле бер кулына, әле икенчесенә күчерде, зәңгәр пыялалы күзлеген бер салды, бер киде. Гарьлегеннән төкрегенә тыгыла язды.
— Син генә сугыштыңмы әллә бу дөньяда? Әйдә, Таҗиев, тотып бәйлә бәрәнне!
Кыш башында ук туган бәрән турында сүз кузгалуга, әбисенә сыланып, бармагын авызына кабып торган Фаяз җан өзгеч тавыш белән елап җибәрде.
— Бабам, бирмә минем бәрәнне! Минеке ул бәрән...
Бәрәнне, чыннан да, Фаязга атаганнар иде.
— Бирмим, улым, елама,—диде Габсаттар һәм җил-җил ишегалдына чыгып баручы агент белән Ризатдинга кычкырды:
— Туктагыз әле, тыңлагыз. Сарыкка да, бәрәнгә дә кагылмыйсыз. Әйтү шул. Янә дә кабатлыйм, шушы арада түлим. Менә мылтыгым.— Габсаттар чөйдәге ау мылтыгын болдырга тотып чыкты,—бүре чүкеп алам да, колхоз миңа сарык бирәчәк. Шул ит налогына китәр...
Габсаттарның соңгы сүзләрен уполминзагтан килгән кеше ишетмәде бугай инде. Ул, папкасын култык астына кыстырып, күзлеген кулына тотып, капкага йөгерде. Кәлиткәне дә япмыйча, авыл Советына чапты. Телефоннан хәбәр салырга ашыгуы иде.
— Галләм абый, Галләм абый! Хаталанма, сиңа атарга җыенган кеше юк...—Секретарь Ризатдин аның артыннан куш бугазга кычкырып калды, мәгәр уполминзаг Галләменнән җилләр искән иде инде.
Авыл советындагылар, колхоз идарәсендәгеләр аптырый калдылар.
— Булмаганны! Юк сүз! Габсаттар абзый кешегә ата димени?! Бүрене кыра инде менә,— диде председатель Һиммәтбану.
— Кеше ышанмасны хак булса да сөйләмә дигәннәр...
Шулай да: «Белмәссең!—диючесе дә табылды.—Әллә ничә ранный булган, эченә ят кан җибәргәннәр, может холкы бозылып кайткандыр...»
Участковый милиционер килде. Габсаттардан озак итеп сорау алды. Дөресрәге, тимерчене шактый озак тоткарлады, кат-кат төпченде. Фронтовикның сүзе бер булды:
— Кешегә мылтык төбәү уема ялгышып та кергәне юк. Әйттем, менә мылтыгым, дидем. Бүре атып, сарык түлим, мәйтәм. Шул гына. Инде дә кара ниятем булса, ул иптәшкә минем йодрык та хәттин ашкан бит... Шунысын әйтим, ятим оныгыма аталган малга ягылырга ирек бирми идем. Сабыйларның фашист аркасында түккән күз яшьләрен күреп тә йөрәк әрнегәне җиткән!

— Галләм иптәш—власть вәкиле, аңа җикеренүнең ярамаганын аңламыйсызмыни?—диде участковый.

— Без барыбыз да Совет власте вәкилләре, участковый иптәш.— Габсаттар команда бирелгәндәй торып басты һәм кырт кистереп әйтте.—Ярты Европаны солдат итеге киеп уздым мин. Мактана димәгез, ике Дан орденым бар, биш медалем. Иптәш Сталиннан өч благодарностем бар... Чебеннән фил ясап маташмасын уполминзагыгыз.

— Тыйнаклык кирәк, Халитов, тыйнаклык. Барыбыз да күкрәк суга башласа, дәүләт кешеләрен йортыннан сөреп чыгарырга тотынса...

Габсаттар, һәр вакыттагыча, нахакка чыдый алмады. Күкрәк суга мени әле ул? Расны әйтә ләбаса! Участковый менә ана акыл өйрәтә.

— Артыгын сөйлисең, энем,—диде тимерче, ниһаять, милиционерга.—Фәрештәгә парашют, балыкка су асты көймәсе өләшәсең. Болай да үз җанымны үзем киледә төеп торган көннәрем. Тыйнаклыкның ни икәнен белмәгән баш түгел.

Өендәгеләр куркыша калганнар иде Габсаттарның. Әсмагөл белән Нурсария кара кайгыга төштеләр. Олыларның кәефсезлеген чамалаган Фаяз да әбисенең итәгенә ябышып йөрүчән булып китте. Кичләрен, көтү кергәч, үз бәрәнен абзарга чыгып барламый калмый иде ул.

Ил-көн бәхетенә, дөньяның акыллылары күбрәк бит: гауга басылды, Габсаттарны бүтән борчымадылар. Ә ул сүзендә торды.

Янгын сараеннан ат алып, күптән колхозның сарык көтүен сискәндереп йөргән бүреләрне эзәрлекләргә чыкты.

Кояш күтәрелер-күтәрелмәстән үк көтү сарык абзарларыннан ярты чакрымнар булыр кыр ышыклау урманы янына килеп житкән иде.

— Өч көн падрәт бимазаладылар, Габсаттар абзый,—диделәр аңа көтүчеләр.—Атып алырлык түгел, якын үк килмиләр, акырган-бакырганга исләре китми, беравыкка куак арасына шылып торалар да, тагын килеп чыгалар.

— Гомерләре бетәсе юк икән, әнә берәүсе төшеп килә түгелме тимер юл ягыннан?—Кырык икенче елның башында үк сул кулын өздереп кайткан Сафиулла, укый-язарга дигәндә күзлексез күрмәсә дә, еракtан әллә ниеңне шәйли иде.

Габсаттар куак арасына бәйләгән атына карап алды да, бармак очларын төкреклән, кулын өскә күтәрде. Талгын гына искән җилнең юнәлешен тәгаен ачыкламакчы иде. Наратбашы ягыннан исә. Казыктеш-ачкүз ат исен дә, мылтык-дары исен дә тиз генә абайламаячак.

Тимерче ялгышмады. Соры баскынчы салмак кына атлап якыная барды. Бер мәл килде дә туктап торды, бөтен гәүдәсе белән диярлек борылып артына карап алды, узган юл ягы иминме, янәсе. Аннары тагын тәпиләде. Куакларга сыенып-сыланып диярлек килә иде.

— Шау-шу күтәрми торыгыз!—Габсаттар Кара турыны тезгененнән тотып урман полосасының аръягына алып чыкты да, сикереп ияргә менде. Баштарак бөтенләй кире якка юыртты, аннары гына атын чуен юл ягына борып, бүренең артына кисеп төште. Ләкин... куаклыктан ат өстендә килеп чыккан аучыны бүре абайлап өлгергән иде инде. Ул таш урынына томырылып фермалар ягына чапты. Кара туры аның артыннан элдертте. Ара шактый якынайды дигәндә генә ерткыч сул тарафка борылды һәм атлыны шактый калдырды. Сынатырга ярамый иде, тагын ике-өч минуттан бүре әрәмәлеккә кереп югалачак... Габсаттар күндәм чаптарын үз иркенә куйды һәм аңа тезген очы белән кагылып алды. Кара туры сөлек булып сузылды һәм уктай очты.

Беренче ату бүрегә зыян салмады, ул әҗәл дәһшәтеннән үз-үзен белештерми йөгерә башлады. Әмма куш көпшәдән бөркелгән икенче ут көлтәсе үзенекен итте, бүре баш аркылы мәтәлеп, бөгәрләнеп барып төште. Тик шунда ук аякланырга, качарга әрсезләнде, мәгәр аның

хәле-егәре калмаган иде инде, янә җиргә ауды. Габсаттар атыннан төшеп, аның янына килгәндә, ерткыч күзендә тормыш сүнеп бара иде.

— Ат өстеннән дә алалмасаң, гел килешмәгән эш буласы иде,— дип сөйләнде аучы үз-үзенә.—Аннары бүре өере бөтенләй азына.

Бу — аның сугыштан соң аткан беренче бүресе иде.

*
* *

Студент елларында ялга авылга кайткач, Габсаттар абзый белән озак итеп гәпләшкән чакларым булды. Ул инде миңа күркәдән талатып торучы малай итеп түгел, гыйлем эстәүче, мөстәкыйль тормышка басарга аяк киенүче егет итеп карый, кайбер мәсьәләләрдә хәтта киңәшләшә дә иде.

Сугыш яралары сиздерми булмады, яше дә үзенекен итте. Алтмышкача тимерчелектә эшләде, үз һөнәренә берничә егетне өйрәтте дә (бүген газеталарда язганыбызча, остаз булды да), колхоз умарталыгына күчте. Гомер-гомергә бал кортлары белән мәш килгән кешегә бу һөнәре дә юаныч булды. Ник дигәндә, ике кулы бер эшсез калмады (пенсия дигәнне һич өни алмый иде), беләк көче җитәрлек шөгыле, сулу алырлык вакыты бар иде.

Тимерче чагында онытылганда бер генә кагылгалый торган тальянын да Габсаттар абзый умартачы өенә алып килгән иде.

Август урталары. Кичке як. Иртәгә дә көн аяз буласын хәбәр итеп кояш баеды. Шәфәкъ алсулыгы карап кына тормалы иде.

Габсаттар абзый гармунын итәгенә алып, тузып беткән каешын җилкәсенә киеп куйды да, буынтыкланып торган калын бармакларын тальян телләре өстендә йөртеп алды. Аннары «Олы юлның тузаны»н сыздырып җибәрде. Көйнең тәмен белеп, һәр бормасын-борылышын җиренә җиткереп уйнады. Беравыктан ул үз бармаклары арасыннан ачылган моңга шул тикле бирелеп китте, тоныкрак калын тавыш белән җырлап та җибәрде. Артистланмый, кайбер мәҗлесләрдәге бер ише кешеләр сыман тырышмый иде ул, гүя янәшәсендә утыручыга салмак кына итеп башыннан кичкәннәрне сөйли иде.

Олы юлның тузаны ла,
Үзем күрдем тузганын...
Белми калдым, сизми калдым
Яшь гомернең узганын...

Мин дә авыз эчемнән генә аңа кушылдым.

Җырлап туктагач, Габсаттар абзый гармунын урындыкка куйды. Аннары гадәтенчә учы белән башын сыпыргалап торгач, сөйләп китте.

— Олы юл дигәне ошый бу җырның миңа. Ә яшьлекне сизми калмадык, юк! Әмма да ләкин байтакны күрдек инде. Сөенечен дә, көенечен дә. Чәчәген-гөлен дә, утын-күмерен дә... Фаҗигале шатлыкларын да...

Инде югалды-бетте дигән Мирхәйдәрдән кырык бишнең ноябрь азагында хат килеп төшмәсенме! Хатыны Нурсария исеменә язылган хат. Әлеге көтелмәгән хәл күпне күргән Гаспсаттар абзыйны да, карчыгы Әсмагөлне дә өнсез калдырды. Нурсарияне әйткән дә юк. Ул, бичара, конвертын да ача алмады, сихер зәхмәте йоккан бөти сыман тоелган хатны әтисенә күтәреп килде.

— Әткәй! Бу ни булыр бу? Кульъязуы Мирхәйдәрнеке! Дөньяларда бар микәнни ул? Газиз башкайлары кайда икән?

— Сабыр, кызым, сабыр!—Телен йоткандай торган ата Нурсариянең гайре табигый хәләтен күреп телгә килде.—Кил, утыр. Хәзер белербез. Хәерле хәбәр генә була күрсен берүк...

Хат ачылды. Хәерле идеме соң бу хәбәр?

«Мин бу хатны язарга да, язмаска да белмиенчә айлар уздырдым, еллар тилмердем. Бер уйласам, шул минутта ук хәбәр салырга тиеш таптым, икенчеләй уй йөртеп баккач, хат-хәбәр бирмәүне дөрескә чутладым. Инде дә тәвәккәлләдем һәм барысын язасы иттем.

Бәхетсезлек Польша җирен азат итә башлаганда килде. Суғышларның берсендә мин бик авыр яраландым. Яраландым дип хәзер әйтә алам. Ул чагында мине үлгәнгә чутлаучылар да булган. Якында гына авыр снаряд ярылуы байтак иптәшләрне шундук үтергән, берничәбез яраланган. Башта кыр госпиталенә озатканнар, анда гына рәт чыкмасын күргәч, самолет белән илгә җибәргәннәр. Контузия белән яралану икесе бергә булгандыр, мин унике көн буена аңга да килә алмаганмын. Һушымны җыйганда, мин Саратов госпиталендә идем инде.

Гаепләмәгез, дөресен язам, мин авылга кайтмаска, дөньяда икәнемне сезгә белдермәскә карар иткән идем. Таш бәгырьле икәнсең, вәгъдәләр-антлар биргән хатының бар, балаң үскәнен уйларга тиеш идең, газиз анаң синең өчен ут йотканы исеңә кереп чыкмадымы әллә, диярсез. Шулай битәрләсәгез дә, сез хаклы булачаксыз. Тик минем хәлләр чамадан ашкан яманга калган иде. Хәзер бәгырь ите янып күмергә әйләнде бугай инде, үзем күнектем шикелле, тик бүтәннәр минем хәлгә күнегә алмаслар. Күрсәгез, мине таный да алмассыз. Минем тез тиңентен аякларым юк, сул кулым терсәктән өзек. Снаряд кыйпылчыгы иякне сөяген җимереп киткән булган, аны бик озак дәваладылар. Азак чутта анда бүтән тире үстерә алдылар. Уң күз бөтенләй күрмәс кебек булган иде. Анысы әйбәтләнде. Сулы шикелле үк булмаса да, күрә.

Мин, Нурсария, җан асрау өчен хәсрәт чикмим. Менә тиздән инвалидлар интернатына урнаштырачаклар. Тамак тук, өс бөтен булыр. Берәр һөнәр өйрәнми калмам. Әйтергә теләгәнем шул: безнең ил үз солдатын ким-хур итми. Тормышның икенче ягы йөрәкне телгәли. Шушы хәлемдә миң сиңа кирәкме? Әллә, күпме генә авыр булмасын, без бер-беребез юлына таш булып ятмаска, кул-аякларыбызны чишүле итәргә тиешме? Кайсы як хәерлерәк буласын уйлауны, аннан килеп хәл итүне сиңа калдырам. Нинди уйга килсәң дә, хат язып сал. Мине кире кагар булсаң да, турысын әйтәм, рәнҗемәм...»

Хат укылгач, Габсаттар өендә кабер тынлыгы булып торды. Анналары елаш башланды. Чәч йолкымадылар, күрше ишетерлек аваз салмадылар, татар хатыннары тыенкы елыйлар. Мәгәр Нурсария белән Әсмагөлнең үксүен карап торулары үзе бер җәза иде. Габсаттар да диваналанып калгандай булды, башына күсәк белән ордылар диярсең. Әшнең асылына чын-чынлап төшенә алмаган Фаяз гына әле бабасы янында, әле әбисе белән әнисе янында нишләргә белми аптырады.

Хатын-кыз елап аргач, йорт башы әйтте:

— Кияү янына барырга кирәк булыр. Алып кайтырга тиешле без аны!—диде.—Тик Җ-ж-җәмилә кодагыйга бу х-х-хәбәрне б-б-бик җайлап, иплән кенә әйтергә кирәк.—Габсаттарның тотлыгу өянәге кузгалды.

— Мин керимме икән?—Әсмагөл җыена башлады. Габсаттар аны капылт туктатты.

— Син түгел, хәзер түгел... Бу кыяфәттә кешенең котын алырга мөмкин. Беләсең Җәмиләнең йөрәген... Тынычлансын, чырай керсен дә, Нурсария үзе сөйләшер.

Нурсария ире хакындагы хәбәрне сәгате-минуты белән кереп әйтерлек көч табар иде, анысына ул шикләнмәде. Дәһшәтле икеләнү эчендә калуы аның тынын буды, күз алларын караңгыландырды, фикерләрен чуалтты. Ул тирән куркуга төште, Мирхәйдәрнең исәнлек хәбәре аны жылытмады шикелле. Бәхеткәйләре шул чаклы да китекмени соң аның? Сугыш аның бер дигәнен соңгы чиккә җиткереп рисвай иттемени соң? Ике аяксыз, сыңар кулсыз, битендә әллә ниткән ямаулар белән янәшәсендә басып торачак гарипне үз итә алуына шикләнеп калды. Тездән аяксыз булгач, Нурсариянең бил турынтын гынадыр инде ул... Егетләр солтаны дип дан алган тракторчы Мирхәйдәр шул хәлгә калсын әле! Таянычым диярдәй ир буламы соң инде ул?

Ата-ана йөрәген алдар хәл юк, алар үз балаларының ни уйлаганнарын күңелләренең әллә кайсы җепселләре белән тоялар, сизәләр. Өлкәннәр Нурсариянең куркынып-икеләнеп калуын шундук чамаладылар. Әсмагөл җаен китереп сөйләшерен исәпли башлаган гына иде, Габсаттар ашыгып төшми генә үзенең карарын янә бер кабатлады.

— Алып кайтырга тиешле без аны! Исән калуына сөенергә тиешле без. Сиңа, Нурсария, гомер юлдашы, балага—ата...

Нурсария бу сүзләрдән соң да ак та димәде, кара дип тә җавап кайтармады. Шуннан ары ата кеше җиллерәк эндәшүне дә артыкка санамады.

— Син ни дип авызыңа су каптың әле, кызым? Әллә булмаса шүрли калдыңмы? Тузга язмаган уйларыңны җилгә тарат! Иреңнең башы исән-сау булганына шөкер ит. Башы сау чакта күздән төшәсе егет түгел ул.

Багучыга бармасалар да, төгәл сизенгәннәр икән, Мирхәйдәрнең исән хәбәрен ишетүгә, Җәмилә кодагыйлары йөрәген тотып, ятакка ауды. Әсмагөл аның янында утырырга мәҗбүр булды. Шул ятуыннан алып йөрәк чиреннән арына алмады, Мирхәйдәр кайтуга ярты ел дигәндә дөнья куйды.

Хәзер инде барысы да гомер-гомергә шулай булгандыр кебек: бухгалтерлар курсын бетереп кайткан Мирхәйдәр дистә еллар идарәдә эшли, колхоздагы исәп-хисап эшләренең төп хуҗасына әйләнгән.

Бүген дисә, бүген ялга китәргә хакы бар аның. Алай итми, кеше арасында, эш уртасында буласы килә.

*

* *

Лашчы станциясеннән җәяүләп кенә төштем. Яздан бирле яуган яңгырлар гарык иткән иде, көн аяз булганга сөенеп атладым. Туп-туры Габсаттар абзый янына киттем. Мин умартачы йортына килеп кергәндә, Габсаттар абзый тәрәзә пәрдәләрен ачып куеп, алдына җәеп салган газетаны укып маташа иде. «Маташа» диюем шуннан: калын кара ырмаулы күзлеген сала да кулына лупа пыяласын ала, аннары тагын күзлеген киеп укый башлый.

Мине күргәч, кәефе килгәндәй булды, бик ачык, бик илгәзәк каршылады. Газетасын бер читкә этәрде, лупасын аның өстенә куйды, күзлеген салып, пыялаларын сөрткәләде.

— Күзнең рәте-чираты китеп тора әле, улым. Ни нәрсә булгандыр, төшенә алмыйм. Шушы яшьтән үк начарлангач, тора-бара нишләр инде ул?—дип шаяртырга кереште.—Я, үзеңдә ни хәлләр бар? Нинди җилләр алып кайтты?

— Сине күрергә кайттым, Габсаттар абзый,— дидем мин.— Сагындырдың.

— Күр алайса, рәхим ит!—Карт торып басты, ишекле-түрле атлап китте, җилкәләрен сикертеп алды һәм гадәтенчә бик килешле көлеп

куйды.—Үсәм, Харрас улым, үсәм. Бер генә дә «чүгәм!», «үчәм!» дия-се килми, әй!..

— Авырмыйсыңмы, Габсаттар абзый?—дидем мин.—Эшләрең әй-бәт барамы?

— Тәгәри,—диде ул, мине үз янына утыртып.—Кортлар тырышса, минем эшләр ал да гөл. Тик быел аларга да бик читен. Яңгыр да яң-гыр, җилли дә җилли. Бүген әле менә яумый узды. Әй, очтылар инде бичараларым! Сокланып карап йөрдем, пуля урынына атылып торды-лар. Кереп гәзит караштыруым иде. Хәзер каравылчы килеп җитәр, кичке чәйне чәйләргә безгә кайтырбыз.

Дөресен әйтергә кирәк, минем дә гостиницага барасым килеп тор-мый иде (әби үлгәннән бирле, Актуганга юлым төшкән саен колхоз ку-накханәсендә туктала идем). Габсаттар абзыйлар өчәү генә яшиләр, кеше саен бер өй диярлек. Нурсария апа белән Мирхәйдәр абый бер якта, Габсаттар абзыйның үз ягы. Фаязның исә алардан бер йорт аша гына үз хуҗалыгы...

Ул кичне без, нидер сизенгән төсле, бик озак сөйләштек. Кешеләр белән әңгәмә корганда кәгазь-карандаш чыгарудан бик сакланучан булсам да, бу юлы шунсыз котыла алмадым. Хәер, агайга туп-туры әйттем дә. «Габсаттар абзый, чү, язып алыйм әле, хикмәтле сүзләр сөйлисең бит»,—дидем. Ул көлде генә.

— Мин бит сиңа караганда ничә дистә телем ипине артыграк аша-ган кеше,—диде.

Абзый минем яныма диванга утырды, тезен тезгә атландырып, зур учларын аслы-өсле итеп тез өстенә куйды. Аннары, тыгызламасын әле дигән шикелле, күлмәгенең туры яка төймәсен ычкындырды да, ашык-мый гына сөйләп торды. Кайчак сүзе өзелеп калды. Нәрсәнедер хәтер-ләгән кебек булды, ничегрәк әйтим икән дигән сыман, кирәкле сүзлә-рен эзләштергәләде. Сүзләрне исә бик белеп, сайлап тезә иде ул. Хә-зерге алфавит белән укырга-язарга да заманында үзлегеннән генә өй-рәнгән, тел фәне нечкәлекләренә гомерендә дикъкать итмәгән карт ди-мәссең.

— Адәм баласына, Харрас,—диде Габсаттар абый,—озын гомер кирәк...—Карт сүз басымын «гомер» сүзенә төшерде.—Гомер кирәк. Дөньяга килү бәхетенә ирешкән икән инде, кеше озын гомерле була күрсен, әйеме? Еллар, дистәләгән еллар аңа ниятләрен, уйлаганнарын гамәлгә кую өчен кирәк. Алдына куйган максатына ирешү өчен. Шу-ларга ирешкән затны җирләгәннең иртәгесен үк онытмыйлар... Яшә-гәндә инде, Харрас, үз иңенә күтәрәсене үзең күтәрү тиеш. Бу дөньяда авыр хисапны үзең чишмәүдән дә җиңелрәк нәрсә юк. Кеше дәфтә-реннән күчергән малай кебек... Яшьлек тә уза, сөйкемлелек тә бетә, дәрт тә сүрелә. Уй, фикер исән кала. Фикерле яшәгән кеше бәхетле. Ике җилкәсендә бер башы, башында фикере булган кеше.

Шуннан килеп, сәламәтлек белән җан тынычлыгы бик кирәк ке-шегә. Җан тынычлыгы! Семьяңда да, хезмәтеңдә дә. Шул булмаса, күзгә ак-кара күренми. Һич!

— Шулай, Габсаттар абзый.

— Шулай шул менәтерә. Җилнең дә вакытында исеп, яңгырның да вакытында явуы бик кирәк.

— Син үзеңне бәхетле саныйсыңмы, Габсаттар абзый?

— Зарлану—гөнаһ булыр иде. Гомеремнең бик күп елларын ти-мер чүкедем, кешеләргә файдага гына булды. Бал кортлары белән әвәрәләнүем дә шулай. Кулымнан килгәнне кызганмадым, шуның белән бай мин, Харрас. Шул булса кирәк, шөкерана итәм, ил-көн күзеннән төшермәде. Монысы инде, ай-һай, кыйммәтле... Сау-сәламәт булырга мөмкин, акча эшләү җаен төшенеп алырга мөмкин, бай яшәргә, власть-

лы булырга мөмкин, әмма гомереңне абруйсыз очлавың бар. Хурлык суы белән юынудан да авыры юктыр. Шул көнгә калмас өчен, кеше, минемчә, берничә сынауны кичәрлек көчкә ия булырга тиештер шикелле. Нинди сынаулар димсең? Әйтим. Аларның беренчесе дәрәҗә һәм пост белән сыналу. Аннары—байлык белән. Тагын да матурлык-чибәрлек белән сыналу бар. Янә дә бер авыр сынау бар, ул да булса тормыш кешене дан белән сыный. Дан белән!.. Әлеге имтиханны тотканда, Харрас, әллә кемнәрнең дә муен сындыруы гаҗәп түгел. Монда бер генә дару бар, ул—үз-үзеңә читтән торып карый алу, үз чамаңа тәнкыйть белән күз ташлау. Шул гап-гади нәрсәкәй күпме бәлаләрдән йолып кала, үсенмәскә, һаваланмаска ярдәм итә, кеше кадерен белергә булыша. Менә шулай, Харрас. Бер йолдызның җиде канаты дигәндәй, шуларга ирешсәң, «бәхет телим» дип аерып әйтмәскә дә була, минем исәбемчә. Болар барысы бергә шул бәхет дигәннең үзе була инде.

Иртәгесен колхоз идарәсе, партоешма җитәкчеләре белән сөйләштем. Редакциягә хат язган кешеләр белән очраштым. Махсус «сораулар — җаваплар сеансы» булмады булуын, шулай да сүз җае чыккан саен Габсаттар абзый хакында фикерләрен сорамый калмадым. Тимерче-умартачының кордашы — аръяктагы Сираҗетдин бабай Актуган кешеләре фикерен бер төенгә төйнәп бирде шикелле.

— Барыбыз да картайдык. Кулдан килгәннең барысын кылып олыгайдык. Иллә Габсаттар кордаш ил агасы булып картайды ул, — диде.

Актуганнан мин—район үзәгенә, аннан Казанга киттем. Габсаттар абзый турында очерк язу уе белән канатланып кайттым. Әйтер сүзем барын тоеп тордым. Күңелдә һич август түгел, май ае иде. Нур өстенә нур өстәп, кайтуыма өч көн дигәндә, Мирхәйдәр абыйдан хат килеп төште.

«Зур куанычыбызны уртаклашабыз, Харрас,—диелгән иде анда.— Ни гомерләр үткәч, бабайны тагын бер Дан ордены—беренче дәрәҗәлесе — эзләп тапты. Теге чакта, Берлинда яраланып, госпитальгә эләгүе бүләкнең иясенә ирешү юлларын бутаган булса кирәк. Тик Ватан үз уллары каршында һичкайчан бурычлы булып калмый бит ул. Эзләгәннәр, таптылар. Шулай итеп, Габсаттар солдат полный кавалер хәзер!..»

Язасы очергыма мондый да матур деталь өстәләсен хыялыма да китермәгән идем. Дулкынланып, кулга каләм алдым.

1978—1979. Казан.

# БАБУР

*Тимерләнкнең бишенче буын оныгы Заһретдин Мөхәммәд Бабур 1483 елның 17 февралендә, Фәрганә шәһәрендә туа. Анасы ягыннан ул Чыңгыз ханга барып тоташа, 11 яшендә тәхеткә менә. Ләкин, Шейбанилар белән көрәштә пай-тәхете Фәрганәдә кала алмаячагын аңлап, Кабул вилаятен яулап ала. Аннан Һиндстан солтаны Ибраһимны җиңеп, шунда өч гасыр буена дәвам иткән Бөек Моголлар династиясенә нигез сала.*

*Бабур 1530 елда үлә һәм Кабул шәһәрендә аның кабере әле дә саклана.*

*Бабур тарихта полководец һәм дәүләт җитәкчесе булып танылу белән бергә, дөнья әдәбиятында «Бабурнамә» исемле биографик әсәре һәм лирик шигырьләре белән мәшһүр. Чит илдә солтан булса да, шигырьләрендә үз илен — Үзбәкстанны сагынып җырлый Бабур. Аның шигърияттән метрика, рифма турындагы хезмәтләре, музыка теориясе һәм хәрби белем буенча кулланмалары булган. Ләкин, кызганычка каршы, алар сакланмаган.*

*Бу санда без шагыйрь Бабурның газәлләре һәм робагыйларыннан кайбер үрнәкләр бирәбез. Әсәрләр Ташкентта «Укитувчы» нәшриятында, «Мәктәп китапханәсе» сериясендә 1976 елда басылып чыккан сайланмадан алынды.*

## Газәлләр

●

Җиһаннан тынгы тапты тик тәнем үлем йокысында.
Сагынганда килерсез инде, дусларым минем, шунда.

Ни язмыш булса шул булыр, анык бел ки хакыйкать бер:
Орыш-кырылыш, газап-рәнҗеш, кыен чикмәк кенә монда.

Үзеңне шат хис ит, кайгырма һич дөнья диеп, зинһар,
Ки бер дә гамь йотуга тормый бу иске — черек койма.

Минем төсле авырлыклар кичергән бер генә углан
Табылмас эзләсәң дә бу фани җирдә, гөман кылма[1].

Җирем дә дәүләтем дип тынмадың гомереңдә бер, Бабур,
Фәкать тынгы табарсың бу җиһанда тик куеп дөнья.

[1] Гөман кылма — уйлама.

●

Тәкъвалык[1] китте вә кәрәм[2] кылды,
Мәхәббәт килде — мөхтәрәм кылды.

Әлиф кебек төз, ай йөзле сылу
Галәмдә мине бер әләм кылды.

Ләкин аерды гүзәлдән фәләк[3], —
Юк итте мине — хур, әрәм кылды.

Күңелем кабынды сагыш утыннан, —
Җил өреп аны гел дәвам кылды.

Гамь тырнагыннан котылмас Бабур,
Аһ-зарлар аны чын яран кылды.

●

Гел күңелне шат вә көр тотмак кирәк,
Оныталармы? — Без дә онытмак кирәк.

Бул көләч, гөлләр-чәчәкләргә су сип,
Гамь үләнен мәңге корытмак кирәк.

Юкка сыкранма, яшә кәефең корып,
Борчуларны гел җиңеп чыкмак кирәк.

Шәп габидлектән[4] җанының көрлеге,
Саф гыйшыкта җанны яктыртмак кирәк.

Эй, Бабур, күңелең төшермә кайгырып,
Рухны иркен һәм азат тотмак кирәк.

●

Дөньяның мин күрмәгән җәбере-җәфасы калдымы,
Хәстә күңелем чикмәгән зәхмәт-ярасы калдымы?

Үстереп мине хур итте, кылды бер чын дәгъвачы,
Ким-ятимнәр дип яшәүдән тыш хафасы калдымы?

Ул кояш борчу-сагышларда һәлак итте мине,
Инде тергезмәк өчен рәхим-вафасы калдымы?

Мин үлем таптым үземә, бик гашыйк булдым да, дус,
Инде аннан куркуның зәррә чамасы калдымы?

И күңел, Бабурны юкка син гаепли күрмә тик —
Ул галәм тели, галәмнең соң сафасы калдымы?

---

[1] Тәкъвалык — бу урында һавалылык, масаю.
[2] Кәрәм — яхшы күңеллелек, юмартлык.
[3] Фәләк — күк.
[4] Габидлек — табыну, гыйбадәт кылу.

●

Гыйшкы аһыннан зифа бу сәрви[1] наз бөгелмәсен,
Гамь җиленнән гамбәр[2] исле чәчләре түгелмәсен.

Төрле яманнар тиеп рәнҗетмәсен нечкә җанын,
Саф-нәфис күңелен бирәү дә кайгы-гамьгә төрмәсен.

Аерылышкач күп сагышларны кичердем, әй кояш,
Сәрвиең тик шәүләсен һаман да ким күндермәсен.

Бар галәм халкы арасында идең син максатым, —
Заты пакьтан булмаса кеше галәмдә йөрмәсен.

Я, башың биек икән, әй, таң җиле, әйт син аңа,
Кырда һәр корган үләнне сәрви дус дип белмәсен.

Гәрчә гыйшык язмышы бетсә дә еш хурлык белән,
Гыйшкы юлында Бабур күк ул да хурлык күрмәсен.

●

Әгәр дә булмасаң син, әй, ярым, күңел ачу мөшкел,
Шулай ук бергә булсак сөйләшү һәм аңлашу мөшкел.

Синең нечкә күңел, ә мин исә тупас дивана бер,
Сиңа, әй, пәри зат, минем хәлемне аңлату мөшкел.

Йокымсырап тора бәхетем, ә өстендә аның аһ-зар,
Бу өннәр ярдәмендә ай-һай аны уйгату мөшкел.

Миңа бер ни түгел әгәр дә булса дошманым йөз мең,
Тик, әй, күңелем, җиһанда бер яр алдында калу мөшкел.

Күреп назларга ярыңны теләр булсаң әгәр, Бабур,
Галәм багында, бел, чәнечкесез гөлне табу мөшкел.

●

Күпмегә бу гамь дә хәсрәтләр миңа гел хас икән,
Кашки үлсәмче, шулардан бер тынып булмас микән?

Нинди үкенеч! — җырларым, тик гамьнәрем сердәш миңа,
Мондый чакта мәйле-сыйлы туйларың бик хас микән?

Аһ, сынык булса күңел сез ят күреп җик күрмәгез,
Бу бәладән бер котылгы ник табып булмас икән?

Мин дивана, аңым-акылымны җуеп булдым гашыйк,
Белмәдем андый чибәргә бар күңелләр мас икән.

Күп сылуларны күреп кан төште Бабур бәгыренә,
Һич югы күз-яшь түгеп бер уч алып булмас микән?!.

---

[1] Сәрви — кипарис.
[2] Гамбәр — хуш исле амбра.

•

Җилкетә бит күңелне гүзәл кыз, ай чырайлы,
Белмимен көндез тынгы, ә төнлә йокыларны.

Кайда гына омтылмыйм янымда була михнәт,
Кайда гына юнәлмим җаныма тула кайгы.

Йөз җәбер-җәфа күргән, мең михнәт-хафа күргән,
Тынычлыкны белмәгән миндәй ир тагын бармы?!.

Әй, кояш йөзле бәндә, аерылу синнән бәла,
Күңелемне яктың утта, судай эреттең җанны...

Һәр ни булса хаклыдыр, тик ятларга сөйләмә,
Күз яшьләрең, әй, Бабур, күпләргә көлке бары.

## Робагыйлар

•

Бәхет табалмадым, борчу гел тапты мине.
Бурычлы калдым, эшләрем гел китте кире.
Туган илдән олактым мин Һиндстаннарга,
Сагышымнан, күр, дегеттәй каралдым инде...

•

Онытыла шул китеп ятлар ягына кеше,
Үз-үзен тик кызгануга салына кеше.
Гиздем илләр, бер кайчан да шатлык күрмәдем, —
Газиз туган илен мәңге сагына кеше.

•

Күпкә бармас, бик аз күкрәк киерер дошманың, —
Җиңү җамы эчеп өч көн йөрер дошманың.
Әйдә: «Башым күккә тиде!» дисен, кайгырма, —
Түбән җан ул, тиз җир-зәбәр килер дошманың.

•

Ни чара бәла-каза килсә башка, Бабур,
Гайбәтләр, хыянәтләр хәттән ашса, Бабур?
«Бабурнамә»мне укыган аңлар барын да, —
Күпме михнәт чикте шагыйрь һәм патша Бабур.

Борынгы үзбәкчәдән
**НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.**

## Габдрахман Әпсәләмов

# КАРТ МУКШЫ

хикәя

Ниләр, ниләр генә чыкмый гомер таулары артыннан! Бер вакыт шулай гомер мәгарәләре арасыннан мукшы патшасының кызы алтын чәчле гүзәл Нарчатка күренеп, каш сикерткәч, үзем дә шаккаттым.

Мин, гадәтемчә, балконда утыра идем. Күзләремне йомып, йөземне кояш җылысына куеп еллар йомгагын сүтә башладым. Йомгакны кузгатып җибәрергә генә кирәк, аннары, кем әйтмешли, китә ул, тәгәри дә тәгәри.

Әйзү тыкрыгында, мәһабәт өрәңге төбендә карт мукшы Михайла бабай безгә бик күп әкиятләр сөйләде. Әйтергә кирәк, әкиятне ул нәкъ татар карты кебек тәмен белеп, кулларын бутамыйча, бары тик тавышын я аз гына күтәреп, я бөтенләй әкренәйтеп сөйли иде. Минем күңелемдә ниндидер моңлы музыка чыңлаган кебек сеңеп калган. Мин инде аның сүзләрен хәзер тулысынча хәтерләмим, ул, әлбәттә, татарча сөйли, тик барысын да үзенчәрәк итеп сөйли. Без, аның әйләнәсенә аяк бөкләп утырган малай-шалай, карт кешедән көлмибез, киресенчә, авызларыбызны чак кына ачып онытылып тыңлыйбыз. Аның әкиятләре үтә кызык, сулыш алырга онытып, бу минутта кайда икәнеңне дә белмисең. Баш түбәбездә ялгыз өрәңге кәүсәсе генә булса да, безгә карурманда утырабыз кебек тоела. Михайла бабай күбрәк батыр аучылар турында сөйли, бигрәк тә аю аулаучы азамат егетләр безне сокландыра. Алар аюны мукшыларча аулыйлар. Уң кулларына, иңбашларына кадәр, юкә кабыгы белән чи каеш урыйлар да пычак тоталар, ә сул кулларында балта була. Балта белән аюның алгы тәпиләренә сугалар, уң кулларын аюның ыржайган авызына тыгалар. Аю башын чайкарга да өлгерми, үткен пычак аның бугазын ярып ташлый. Безнең күзләребез атылып чыгардай була, йөрәкләребез ярсып тибә, әллә кайдан бугазы ярылган аюның соңгы ыңгырашуы ишетелә кебек.

Мукшы алласы Кирәмәт турында тыңлаганда да без тып-тын утырабыз. Караңгы төшә, һәм безгә Кирәмәт шушы өрәңге артында гына басып торадыр кебек тоела, я күпер астыннан чыгып буа янындагы юан талга сөялгән дә кемнедер сагалый шикелле. Су анасы, йорт анасы, төрле җен-пәриләр турында әкиятләрне көн саен

ишетеп торганга, Кирәмәткә дә ышанабыз. Куркабыз, калтырыйбыз, шулай да китмибез, тыңлыйбыз. Аның каравы, Михайла бабай карурман уртасында шикәр кебек ап-ак йортта яшәүче мукшы патшасының кызы алтын чәчле гүзәл Нарчатка турында сөйли башласа, без җиңел сулап куябыз, тирә-ягыбыз яктырып киткәндәй була, курку-калтырауларыбыз онытыла, күзләребездә соклану, иреннәребездә ваемсыз елмаю барлыкка килә. Ә инде гүзәл Нарчаткага бер-бер куркыныч яный башласа, без, сикереп торып, ярдәмгә ташланырга әзер.

Күп мәртәбәләр тыңладым мин сылу Нарчатка турындагы гүзәл әкиятне, ләкин аның йөзен ачык кына күз алдыма китерә алмый идем. Ул, Зөһрә матур кебек, әле бер төскә, әле икенче төскә керә. Тик чәче, татар кызларыныкы кебек, кара яки коңгырт түгел, ә алтын сары, күзләре җәйге таң кебек зәңгәрсу. Башында татар кызлары кия торган энҗеле калфак түгел, ә мукшы калфагы — челтәр такыя, ак күлмәге кызыл чигүле, аякларында тамбур читек урынына кунычы сырлы (гармошкалы) күн итек.

Патша кызын гомердә күрмәсәм дә, мукшы кызларын — безнең авыл аркылы үтеп киткәннәрен дә, ерак кырыбыз читендәге мукшы йөнәсенә кагылганда да, тирә-юньдәге ярминкәләргә барганда да күргәләгәнем бар. Мукшылар күбрәк чүлмәк, кисмәк саталар. Ярминкә вакытларында балчыктан, агачтан ясалган, матур итеп буялган төрле уенчыклар да алып киләләр. Безгә, балаларга, үзе сызгыра, үзе шакылдый яки төрле кош булып сайрый торган уенчыклар кирәк тә инде. Ярминкәне яңгыратып, сызгырып, шакылдатып, сайратып йөрибез. Уенчыклар безгә келиндердән дә кадерлерәк.

Кайчагында шундый уенчыкларны сатар өчен мукшылар йөкләре янына бик матур кызларын да бастыралар. Болары инде яшь-җилкенчәкләрне үз яннарына тартып китерер өчен. Өсләрендә җәй-көз булса изүләре, җиң һәм итәк очлары чигүле киндер күлмәк, аякларында бик матур үрелгән мукшы чабатасы, чолгаулары калын, тезләренә җиткән, чабата бауларын да тезгә кадәр урыйлар. Татар хатын-кызлары чабатаны йон яки тула оек белән кия, рус хатын-кызларының чабаталары да күзгә ташланмый, ә мукшы кызларыныкы көлеп тора, әйтерсең, ак кунычлы күн итек; үзләренә күрә көязләр дә, матурлар да. Башларында челтәр такыя. Бу аларның маңгайларын биек, йөзләрен ачык һәм нурлы, көләч итә.

Шулай да, миңа калса, болар гади мукшы кызлары, алар арасында әкияттәге Нарчатка юк иде. Әллә инде мин генә күрмим. Билгеле, кызлар арасында чибәрләре, сылулары аз түгел, ләкин, мин малай уенча, Нарчаткага гади чабата, гади киндер күлмәк киертеп булмыйдыр төсле тоела иде. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, ниһаять, ярминкәләрнең берсендә гүзәл Нарчатканы күрдем шикелле. Дөрес, ул дип өздереп кенә әйтә алмый, әмма мондый матур кыз бөтен ярминкәдә бер генә иде. Ул киеме, ул такыясы, ул зәңгәр күзләре, алсу битләренең берсендә ай, икенчесендә кояш иде. Ә аякларында сырлы (гармошкалы) нәфис күн итек.

Ахрысы, авызымны ачып, озаграк карап торганмын. Нарчатка сөйкемле генә елмаеп нидер әйтте, күз явын алырлык уенчыкларга кулы белән күрсәтте, беләзеге, ачык муенындагы кырганәйләре (мәрҗәннәре) ялтырап китеп, күземне чагылдырды. Шунда башына ялтыр козыреклы карасу зәңгәр картуз, өстенә кызыл күлмәк кигән, билен тимерле нечкә камәр белән буган мукшы егете авызындагы келәләнгечен җиргә төкерде дә, арбадан сикереп төште, учындагы көнбагышын битемә атты, аннары кулбашыма төртеп:

— Пошел отсюдева! — диде. Күрәсең, бу малай берәр уенчыкны чәлдерергә чамалый, дип уйлагандыр. Кызый аңа нәрсәдер әйтте,

егет артына да борылмады, яңадан арбага сикереп утырды, яңадан көнбагыш чиртә башлады.

— Нарчатканың сакчысы усал икән, — дип уйладым арба яныннан киткәндә. Бу егеткә минем нигәдер артык ачуым килмәде, ләкин безнең авыл аркылы үтсә, таш яки карга йомыркасы җибәрермен әле үзенә, дип ниятләдем. Малай кеше үч кайтармый калмый инде ул.

Шуннан соң ярминкәләргә, базарларга баргаласам да гүзәл Нарчатканы нигәдер бер дә күрмәдем. Карурманына, ак йортына киткәндер дип уйладым. Кыш көне аннан чыга алмас шул, тирән кар бөтен юлларны баса, урманда аюлар, бүреләр дә күп. Менә җәй җитсен, аннары Нарчатка сагындырган иреккә чыгар. Ләкин кыш бик әкрен үтә, көн-төн күз ачкысыз буран котыра, авыл очындагы өйләрнең тәрәзәләре дә күренми, кайбер йортларны кар шул хәтле күмеп китә, күршеләре килеп казымаса, чыга да алмыйлар. Күптән инде капкалардан түгел, капкалар башыннан йөри башладылар.

Шулай да бер вакытны ямьле яз ишек кага, кар утыра, челтәрләнә, ачыла башлый, без, малай-шалай, иреккә ыргылабыз, кар сулары агыза башлыйбыз, аннары куйларны (бездә нигәдер сарык димиләр, күбрәк куй дип сөйлиләр) инеш аръягындагы чалуга, ягъни болынга алып чыгабыз; бу вакытта инде терлек азыгы такы-токы гына калган була. Көтүче әле юк, сарыкларны без, малайлар, үзебез саклыйбыз. Билгеле, безнең башта маллар кайгысы түгел, күбрәк төрле уеннар була. Аннары бер ун көннән ташу кузгала, болынга безнең юл киселә. Без инде ташу карарга йөрибез, кызыл йомырка көннәрендә[1] буй җиткән кызлар туп тәгәрәтеп уйныйлар, безне,ваграк малайларны, катнаштырмыйлар, без алар тирәсендә чуалабыз гына...

Юллар ачылып инде бөтен бакча, болын, урамнардагы үләннәр чәчәк аткан көннәрдә Гөлгенә абызларга — алар бездән ерак тормый иде — тагын Михайла бабай килде. Без аны ярата идек, аның килүен һәрвакыт көтә идек. Килсә, шунда ук бер-беребезгә хәбәр итәбез, өрәңге төбенә җыелабыз. Көз көне булса, ул безгә дуля, шалкан бирә, хәзер тәмле чын көпшә алып килгәндер әле.

Гөлгенә абызларның тәрәзәсеннән өрәңге бик яхшы күренә. Михайла бабай озакламыйча безнең янга чыга.

— Һай, минем оныклар җыелган да инде, ә Кирәмәт Тәкай урманы яныннан үткәндә минем кесәгә дуля белән шалкан салырга оныткан, — дип, ерактан ук сөйләнә-сөйләнә килә ул, үзе кесәләрен капшый. — Пай, бер ни юк бит. Вәт, рәхмәтле Кирәмәт!

Без чәчрәп көләбез.

— Кирәмәт онытмый ул, дибез. Ул кесәңдә түгел, бу кесәңдә, Михайла бабай! — дибез бер тавыштан, чөнки аның нидер тутырылган кесәсе кабарып тора. Безнең күзләр үткен, барысын күрәләр.

— Пошто монда салган, рәхмәтле Кирәмәт. Сезнеке белә, минеке белми. Ә ни салган, хәзер бит дуля белән шалкан җитмәгән әле. Ә-ә! Пай, үлән!

Без бик тәмләп кузгалак, чын көпшә үләннәрен кетер-кетер ашыйбыз. Татарлар нигәдер тәмле үләннәр җыймыйлар, аларны яхшы гына белмиләр дә бугай. Алма, дуля, кишер, шалкан, кыяр кебек нәрсәләрне дә күпләп утыртмыйлар, урыс-мукшы эше ул дип акланган булалар. Ә безгә, балаларга, болар бик тансык. Зур авылда, берәм-сәрәм кешеләрнең бакчаларында болар аз-маз үстерелә. Без, малай халкы, ул бакчаларга төннәрен керергә дә маташабыз. Ләкин күп вакытта юлыбыз уңмый, эләктерә калсалар, хуҗалар яшь кычыткан белән шәплән сыйлыйлар, күз яше белән тәүбә иттергәнче ычкындырмыйлар. Билгеле, болар барысы тукран тәүбәсе, шулай да... Ә Михайла

[1] Кызыл йомырка көннәре — руслардагы пасха бәйрәме.

бабай булганын үзе бирә, тагын килгәндә алмасын да, дулясын да, шалканын да китерермен дип вәгъдә итә. Ул онытмый, Кирәмәт оныттырмый аңар.

— Пай, шустригым, — ди ул миңа, аркамнан кагып, — бу юлы син бигрәк үскәнсең. Мин тагы килгәнче тал биеклеге булырсың инде.

Михайла бабай татарча ару гына сөйләшә, ә аның телендә һәрвакыт ишетелеп торган «пай», «пөштә», «шустрик» кебек сүзләргә без шул хәтле күнегеп беткәнбез, хәтта аларның татарныкымы, мукшыныкымы икәнен дә белмибез. Әлбәттә, без, балаларга хас кызыксыну белән, аңардан безне мукшыча сөйләргә өйрәтүен үтенгән булабыз. Ул өйрәтә дә, ләкин Михайла бабай хәзер безнең авылда тормагач, Гөлгенә абызларга икенче тапкыр килгәнче онытып та бетерәбез. Әвкә, кофты, колы, мите, вите дип санарга өйрәтүләре генә ничектер хәтердә сакланып тора иде.

Күптән инде, яшьлегендә, Михайла бабай Гөлгенә абызларда ялчы булып торган. Аннары Гөлгенә абызның ире Низүк абзый вафат булгач, Михайла бабай алардан киткән, атны сатканнар, сарыкларын берәм-берәм суеп бетергәннәр. Бер ала-кола сыер гына калган. Өлкәннәрнең әйтүенә караганда, бу моннан күп еллар элек, мин дөньяга туганчы ук булган.

Гөлгенә абызларның үз балалары булмаган. Аны туйлап алмаганнар да — урлаганнар. Күрәсең, бирнә түләргә Низүкнең хәленнән килмәгән. Кайчак Гөлгенә абыз шул хәлләрне искә төшереп безгә сөйли торган иде. Икенде ахшам арасында ул салмага камыр баса торган булган. Ян тәрәзәдән караса, арт капка ачык, казлар чыгып бара. Гөлгенә абыз аны-моны уйламыйча, камырлы кулларын да рәтләп сөртмичә, капканы ябарга йөгереп чыга. Капка янында аның башына чаршау ябалар, аннары әзер атлар очыртып алып китәләр...

Безгә бу үтә кызык, хәзер кыз урлаулар ишетелми инде. Гөлгенә абыз да моны нигәдер әрнеп, өзгәләнеп сөйләми, күрәсең, еллар үтү белән үз язмышына күнеккән. Тик сөйләгән чагында кара күзләре тагын да карала төшә иде. Әмма ирен әрләгәнне хәтерләмим. Ирне әрләмиләр, чөнки ул ир, хуҗа. Язмышым шундый булган, дип кенә җибәрә иде Гөлгенә абыз. Ә язмышны без, балалар, аңлап җиткерми идек, ул янәсе алла эше. Ә аллалар, Михайла бабай әйтмешли, үзара нидер бүлешә алмый, шуңа күрә берләре урысларны, икенчеләре мукшыларны, өченчеләре татарларны тинтерәтәләр. Тик моны Михайла бабай Гөлгенә абыз алдында сөйләми иде.

— Гөгола, — ди иде ул, Гөлгенә абызны үзенчә атап, — моны бик яратмый, ул татар алласын гына белә. Аныңча, татар алласы иң яхшысы. Чынында, шустрикларым, белмим кайсы яхшыдыр. Күргәнем юк.

— Ә Кирәмәтне күрәсең ич! Ул синең кесәгә дуля, шалкан сала,— диде безнең бер малай.

— Юк, дусларым, Кирәмәт күзгә күренми ул. Дуляларны, шалканнарны мин йоклаганда кесәмә тутыра.

Болар, билгеле, безгә, балаларга, аңлашылып җитми иде. Дөньяда аңлашылмаган нәрсәләр күп ул. Гөнаһлы булып алар турында уйлама диләр иде безгә өлкәннәр.

Гөлгенә абызның ире үзелчы, аннары приказчик булган, күбрәк читтә йөргән. Гөлгенә абызларда апасының кызлары алмаш-тилмәш торганнар. Алар кияүгә чыккач, минем абый торган. Ул дүрт-биш яшендә үлеп киткәч, мин торгалый башладым. Гөлгенә абыз буш өйдә ялгыз кунарга курка, төнлә пирләр ишегемне кагалар, тәрәзәне шакылдаталар әмән, дип әйтә икән. Ә минем белән, бик бәләкәй булсам да, курыкмый, чөнки пирләр ир кеше бар өйгә килмиләр, ди. Бу

сүзләрнең мәгънәсен төшенә башлагач, башымны күтәрә төштем, бу пир дигәне буе биш карышлы камыр батыр, имеш. Шулай да горурланасың, чөнки пирләр курыккач, ни дә булса торасың инде!

Михайла бабай бу йортка ияләшкән булган, ахрысы, чөнки утыз еллап вакыт үтсә дә, ул һаман Гөлгенә абызның килеп хәлен белгәли, я ауган зәмәтен күтәрә, я ишек тупсаларын төзәтә, я башка вак-төякләрне караштыра. Ир-ат булмагач, хуҗалыкның рәте китә икән, иске кием кебек аннан ертыла, моннан сүтелә.

— И Кирәмәт, йорт багу хатыннар эшемени, вәт сарай түбәсе дә ишелә башлаган, хәзәин булмагач, терәк куючы да юк...

Михайла бабай, пеләшләнә башлаган башын хәсрәтле генә селкеп, батып барган кызыл кояшка карап тора, картның йөзе моңсу, ә уйлары әллә кайда булса кирәк. Патшаны да менә төшерделәр, ә ерак авылларда барысы да искечә калды кебек. Рәсәйнең ярлы керәстиян тормышы тиз генә үзгәрмәс шул. Михайла бабай үзенең йөрәк түрендәге уйларын миңа әйтеп карый, әмма безнең башта кузна уены яки экиятләр генә, ә картларның экияттән башка да уйлары җитәрлек.

— Казлар да калмаган, Карач та үлгән. Яхшы эт иде, пай. Мине күрсә, күкрәгемә сикерә иде, кулымны ялый иде. Ну бигрәк тә Гөголаның гусагы отчайный иде. Йортка бер чит кеше җибәрмәс, шундый кычкыра, шундый разбой сала, үлеп йоклаган җиреңнән уята. Инде латы астында күгәрченнәр дә калмаган. Ә бит Гөголаның бүрекле күгәрченнәре дә, заморский күгәрченнәре дә бар иде. Минем кебек аякчулылары да. Хәзер кругом буш. Эх, тормыш, тормыш!

Михайла бабай кулындагы балтасы белән кыйшайган казыкларны турайтып кага, каерылып төшкән такталарны рәтли, тирләгән маңгаен җиң очы белән сөртеп ала.

— Вәт мин дә тузам, башта чәч калмады, сакал агарды, арка бөкрәйде, күзләр чепиләнә. Яшь чакта гомер бер дә үтмәс кебек тоелган иде, менә бераз эшлим дә алаша алам, байыйм дип хыялландым. Алаша алдым, ну баеп булмады, Кирәмәт нигәдер булышмады. Гомер үтте. Тройкада үткән кебек тиз үтте. Инде заманнар да үзгәрде, тора-бара бәлки тормышлар да рәтләнә төшәр, тик аларны без инде күрмәбез, сез генә күрсәгез күрерсез.

Соңгы килүендә дә Михайла бабай безгә, балаларга, дуля белән шалкан китерде, әкият тә сөйләп алды, Гөлгенә абызның ишегалдында анысын-монысын төзәткәләде. Шул чакта болдырга Гөлгенә абыз чыкты. Ул уртача буйлы, әле дә тыгыз гәүдәле иде. Билгеле, еллар үзләренекен иткәннәр — алар мәрхәмәт белми — битләргә җыерчыклар да кунган, гәүдә дә бөкрәя төшкән, ләкин тәмам бирешмәгән иде. Башында һәрвакыттагыча француз яулык, өстендә озын һәм киң күлмәк, билендә кызыл бөрчекле алъяпкыч. Җиңнәрен терсәкләренә кадәр сызганган. Беләкләре әллә кояшта янып, әллә картлыктан кибеп, юкә кайрысы кебек, кара-көрән төскә кергән. Мин һәрвакыт Гөлгенә абызның шул кулларына карый идем. Йөзе алай ук карасу түгел шикелле. Нигә беләкләре шулай каралган, әллә бик күп эшләгәнгәме. Гөлгенә абыз бер дә тик тормый иде шул. Яшь чакта ул бик үткен булган, кара күзләре янып торган дип сөйлиләр, шуңа күрә аны урлаганнар да, имеш, югыйсә аңа баерак башкодалар күп йөргән, ә эти-әнисе аларны һаман кире борган. Хәзер инде күзләре әүвәлге кайнарлыкларын җуйган, төсләрен дә вакыт бераз үзгәрткән. Әмма холкы һич үзгәрмәгән шикелле. Һаман сабыр, юкка-барга пошынмас, аптырамас. Авыл кешеләреннән берәрсе фаҗигагә юлыкса, кул-аягын имгәтсә, ат типсә, үгез сөзсә — тиз генә Гөлгенә абызны килеп чакыралар. Башка хатыннарның кан күрсә котлары оча, Гөлгенә абыз каннан аз гына да курыкмый, яраларын юып бәйли. Аның ак чүпрәкләре, әллә нинди шифалы үлән-

нәре һәрвакыт булып тора. Әнкәсеннән өйрәнеп калган дип сөйлиләр иде авылда. Мин аның чормасына менгәләгәнем бар. Кыш көннәрендә дә анда әллә нинди болын исләре аңкып тора иде.

Мин бер генә тапкыр Гөлгенә абызның тәрәзә янына басып елап торганын күрдем. Гомердә еламас карчыкның буш өйдә берүзе күзеннән яшь агызып торуын күрү миңа, малай кешегә, бик сәер тоелды.

— Гөлгенә абыз, ни булды, башың авыртамы? — дип сорадым. Аның башы еш кына авырта иде.

Ул дәшмәгәч, мин тәрәзә янына килдем. Аннан авылның еракка-еракка сузылып киткән урамы күренеп тора. Урам уртасыннан унлап кеше җеназа күтәреп баралар. Җеназаның чаршавы юк, димәк, ир кеше. Хатыннар җеназасы өстендә генә чаршау була. Җеназа алдыннан, кырык адым саен туктый-туктый: «Яхшы кеше иде, яхшы кеше иде», дип кычкыра-кычкыра ун яшьләрдәге ике малай бара.

— Низүк абзаңны да шулай алып киттеләр, мескенне,— диде Гөлгенә абыз, яшен сөртеп.

Шактый артка калып, койрыгын салындырып, бер эт бара.

— И, ходаем, эт булса да хуҗасы артыннан калмый,— диде Гөлгенә абыз.— Безнең Карач та Низүк артыннан зыяратка кадәр барган дип сөйләгәннәр иде...

Шул көннән соң мин Гөлгенә абызга ничектер башкачарак карый башладым. Кеше күңелендә бик зур кайгылар да була икән, тик алар аны адым саен башкаларга күрсәтеп йөрмиләр. Йөрәктә асраган кайгы тирәнрәк була торгандыр инде.

Бүтән мин Гөлгенә абызның елаганын һичкайчан күрмәдем. Ул чәчрәп көләргә яратмаса да, болай ачык чырайлы, кеше җанлы хатын иде.

— Михайла, чәй эчәргә кер,— дип кычкырды Гөлгенә абыз, мине дә чакырды.— Бик тәмле итеп ералма куырдым.

— Пай, эле яңарак кына эчкән идек бит.

— Әй, бахыр, нинди яңарак кына булсын, кояшка кара.

— Пошто шул кадәр вакыт үткән. Вәт, Кирәмәт!

Мин Гөлгенә абызның чиләтә куырган бәрәңгесен үлеп ярата идем. Ул аны ничектер үзенчә итеп куыра, бүтән беркемнеке дә аныкыча тәмле булмый, ашаганда телеңне йотарсың. Гомумән, Гөлгенә абыз аш-суга бик оста, аның нигъмәтләрен һәркем мактап туймый.

Без болдыр янындагы баганага беркетелгән комганнан кулларыбызны яхшылап юдык та өйгә кердек. Гөлгенә абызның ишегалдында кайчандыр кечкенә генә кара өе дә булган, анда, мич башында, Михайла йоклаган. Хәзер ул өй юк инде, утынга сүткәннәр.

— Кулларыгызны юдыгызмы?— дип сорады Гөлгенә абыз.

— Пошто аны онытырга.

Өстәлгә тирән таба белән бәрәңге китереп куелгач, мин агач кашыкның зурысын алдым. Мине өлкәннәр ач күз булырга ярамый дип күпме генә өйрәтмәсеннәр, Гөлгенә абызның бәрәңгесен күргәч, түзә алмый идем.

Тәмле бәрәңгене ашап, чәйләр эчкәч, урамга ашыктым, анда малайлар кузна уйный иде. Өлкәннәр чәй эчә калды. Бер ун-унбиш минуттан кире өйгә атылып кердем.

— Нарчатка, Нарчатка!— дип кычкырдым һәм Михайла бабайны йолыккалап ашыктыра башладым.

— Пай, нәрсә булды? — диде карт.

— Әйдә, тизрәк, Нарчатка!

— Чү, тиле, Михайла дәдәң чәен эчсен.

— Аннары китә ул.

— Кая китә, кем китә?

— Нарчатка дим ич. Әйдә тизрәк, Михайла бабай!

Безнең якларда Наровчат исемле зур гына базарлы авыл да бар. Аннан безнең авылга алма, дуля, кишер, кыяр, шалкан сатучылар да килгәли иде. Шуларның берсе килгәндер дип уйладылар, ахрысы, өлкәннәр, мин аңлатып тормадым, Михайла бабайның кулыннан тоттым да урамга җилтерәтеп алып чыктым.

Күпергә таба төшеп барган сөзәк таудан, кулга кул тотынышып, шәһәрчә киенгән ике кыз атлый иде. Үзләре чыркылдап-чыркылдап көләләр. Берсенең башында калфак, ике толымы аркасында тирбәлә, аягында биек үкчәле тамбур читек, икенчесенең башында биек челтәр такыя, чәче алтын сары, күлмәге чигүле, аягында сырлы куныччы күн итек.

Күпергә җиткәч кызлар, култыксага таянып, суга карап тора башладылар. Күпер каршында буа бар, шуңа күрә су тирән күренә.

— Әнә патша кызы гүзәл Нарчатка! — дидем шыпырт кына, тавышымны кызлар ишетүдән куркып.

Михайла бабай әле һаман сүз нәрсә яки кем турында барганын аңламый иде.

— Һай, пошто...

— Патша кызы дим ич, әллә танымыйсыңмы? Үзең сөйләгән идең бит.

Ниһаять, Михайла бабай барысын төшенде.

— Пай, шустригым, пошто бу патша кызы Нарчатка!

Кызлар кузгалдылар һәм Хәйрүш тыкрыгына таба китеп күздән югалдылар.

— Киттеләр, күрми дә калдык, — дидем мин әрнеп.

Михайла бабай мине аңлады бугай, кытыршы кулы белән башымнан сыйпады.

— Бусы патша кызының дусты гына. Нарчатка хәзер карурманда ак йорт каршында гөлләр үстерә, чыгып йөрергә вакыты юк. Әгәр ул булса, аның матурлыгыннан урам болай гына балкымас иде. Нарчатка чыкса, күктә нәкъ салават күпере була!

Михайла бабайның бу сүзләре мине канәгатьләндереп бетермәде. Юк, карт яхшылап күрмәгәндер, бу — ул, Нарчатка! Мин бит аны икенче тапкыр күрәм. Дөрес, ярминкәдә уенчыклар сатканда күргәнемдә әле шикләнсәм дә — аның турында берәүгә дә сөйләмәгән идем — бусында нигәдер һич шикләнми идем. Шуңа күрә бик хөрмәт итсәм дә Михайла бабайның сүзләренә ышанмадым. Дөрес, күктә салават күпере юк иде югын да, урам нинди якты иде бит, ә хәзер, күр, ничек һава тоныклана бара.

Карт мине кызганды, ахрысы, иңбашымнан кочты.

— Пошто күңелсезләнергә ярый, шустригым. Мин сине Наровчат базарына алып барырмын — Ильин көндә Нарчатка базарга чыга, диләр. Вәт күрербез. Бәлки чайнига алып кереп келиндер белән чәй эчертер. Кирәмәт рөхсәт итсә, ул юлаучыларга бик шәфкатьле була.

Мукшыларның Ильин көне кайчан була торгандыр тагы, аннары Кирәмәтләре дә татар малаен өнәп бетермәстер. Шулай да зәңгәр томан артында өметең булсын, диләр бит.

Әкияте, чыны белән аралашкан балалык истәлекләре! Барысы хәтердә, тик Нарчатканың йөзе генә күңелдә ачык уелып калмаган иде. Нигәдер ул һаман томанлы, һаман алмашына иде. Ә бүген гомерем мәгарәләре арасыннан шундый ачык балкып чыкты, зәп-зәңгәр күктә, Михайла бабай әйткәнчә, аллы-гөлле салават күпере хасил булды кебек. Әгәр балконда утырган булмасам, чын-чынлап могҗиза күрдем дип әйтер идем, гүя малай чагыма кайтып төштем.

1977 ел.

**Хисам Камалов**

# КУЯН КҮЗЕ НИГӘ КЫЗЫЛ?

хикәя



Бер көн Әлфис этисеннән шул хакта сораган иде. Тик канәгатьләнерлек җавап ала алмады. Этисе әллә белмәгәннән, әллә болай гына авыз әченнән нидер мыгырданды да бетерде.

Бүген этисе өйалдындагы агач караватта ята. Кичә читлектән качкан куяннарны бәрәңге бакчасында куып тотканда аягын авырттырган иде. Әллә үкчә тамыры сузылган инде, иртәнгә тубыгы шактый нык шешеп чыккан.

Әлфис ишектә күренүгә, этисе кыймылдап куйды, аягы авыртканнан ухылдады. Аннары башын борып:

— Куяннарга люцерна чабып салдыңмы? — диде. Бәрәңге бакчасының аргы башына шул үләнне махсус чәчкән иде Гаптелмән. Куяннарны бик шәп үстерә люцерна. Итләре дә тәмле була.

— Ашамыйлар, маемлаганнар. — Әлфис үлән сүле белән яшелләнгән учларын караштырды.

— Алайса, Бикәнәйдән сарут чабып кайт.

Иләк тоткан, керфекләренә он кунган әнисенең келәттән кереше иде, Гаптелмән сүзләрен ишетеп туктап калды.

— Җитәр, шул куяннар дип, баланың җелеген киптермә, — диде. Аның бөрешкән иреннәреннән ачуланганы күренеп тора иде. Гаптелмәннең бер кашы маңгаена таба җыерылды, ике коймак кебек бер-берсенә ябышып торган юка иреннәре ачылды.

— Эшкә таяк тыкма әле!

— Куяннарың бәрәңге җирен ат аунаган кебек иткәннәр!

— Иллә дә барышны аңламаган кеше булырсың икән, — дип кыза башлады Гаптелмән. — Бар керем шулардан түгелмени?

— Колхозда эйбәтрәк эшләсәң... кереме дә булыр иде.

— Ишеткән инде! Өйдә дә агитация белән теңкәгә тимә! Эшлим бит, ә нәрсә төшә?

— Каравылда йокы симертеп ятып сиңа... Әнә, атлы эшкә кер...

— Атлар белән чиләнәсем генә калды! Куяннарым исән булсын!

— Ялкауның сәбәбе мең була ди.

— Ялкау, имеш! Узган атнада куян балаларын тапшырырга баргач, нәчәлник үзе чакырып алды. Әгәр урын алып бирсәк, шәһәргә күчәргә риза булырсыңмы, ди. Киңәш итеп әйтүе. Әнә кая сикерергә тора эшләр! Ә син! Кешегә чыгара күрмә!

— Һаман шул һавадагы торнага алданып йөрисең! — диде хатыны төрттереп һәм тырт кына өйгә кереп китте. Әлфис ишек төбендәге эскәмиядә утырып тора иде.

— Әниең шулай ул, бер саплам җеп озынлыгы гына уй йөртә ала. Уйны аны еракка төбәргә кирәк. Ярар, бар, Әлфис.

Улы чыгып киткәч, Гаптелмәннең уйлары еракка йөгереп китте. Өйне Әлмәткә алып барып утыртсаң җайлы булыр иде булуын. Урынны иске Әлмәттән, Зәй буе тирәсеннән сорарга кирәк. Болыны, әрәмәсе якын. Бураны күчерергә үзләре машина бирерләр анысы. Ә шәһәргә бер төпләнсәм, куянны үрчетеп карар идем каравын! Анда, лабораториядә куяннар җитмәгәнлектән, эшсез утыралар икән...

Монысы артыннан Гаптелмәнгә тагы да татлырак уйлар килде... Авылдан ычкынсам бригадир Шәфәгатьнең борынына чиертәм инде. Килә дә, үзеңне бик саклыйсың, авыр эштән качасың, дип җанны тукый башлый. Әй, аның кукраеп, үзен әллә кемгә куеп сөйләнүен күрсәң. Тирес өстендәге әтәчмени! Үзенең миңа баш булудан рәхәт чиккәне йөзенә бәреп чыга. Әле кайчан гына киндер ыштан киеп мәктәпкә чаба иде. Армиягә китеп кенә кеше рәтенә кереп кайтты. Аның мине ничек тә авыр эшкә җигәсе килә. Бер көн шулай: әйдә, фермага тирес ташырга бар, ди. Мин аңа врач белешмәләрен чыгарып салдым. Тагы ярамый. Хәйләкәр син, ди. Һаман кеше ышыгында гына яшәргә яратасың дип, авыз ера. Куяннарга ымлап, өч тиенлек куян, ун тиенлек зыян, дигән була. Көнләшә. Минем өй дә, лапас та ак шифр белән ябылган. Ә аның өе түл, абзары салам сыртлы. Яңгыр үтеп ята. Шуңа җене чыга, көнчелегеннән нишләргә белми. Мин Әлмәткә күчеп китсәм, шартлар иде бер...

Шәһәрдә малайга да әйбәт булыр иде ансы. Армиягә киткәнче русчага да өйрәнер. Ә өйне шәһәрчә итебрәк салырга туры килер, тегe якка тагы бер тәрәзә уймыйча булмас. Барысы да әнә Әлфиска каласы. Әллә мин үзем өчен тырышаммы? Әнә шул Шәфәгатьнең үзен миннән өстен куеп йөрүләрен күрмәсәм иде.

Әлфис болыннан сарут чабып, ике капчыкка тутырган, шуны бәләкәй арба белән алып кайтып килә. Иң сусыл кыяклы сарутны кырый читлектәге куяннарга бирәчәк ул. Анда иң акыллы куяннар. Аталы-аналылар иде, хәзер сигез булдылар. Ана куян читлеккә алгы тәпиләре белән ябыша да артына утырып каршы ала Әлфисне. Печәнне таптап йөргән балаларын борыны белән этеп җәбәрә. Ике баласын этидән сорап алам, үзем читлек үреп, үзем тәрбияли башлыйм. Бигрәк матурлар үзләре. Ак кар йомарламы кебек тәгәрәп кенә йөриләр. Ә аналарының күзләре бик моңсу. Нилектән икән? Ун көнлек булгач та эти балаларын лабораториягә илтеп тапшыра. Бәлки шуңадыр. Әле имидән дә аерылмаган балаларын алар бик юксыналардыр?

Ә лабораториядә куян балаларының канын алалар икән. Шул каннан малларга укол салыр өчен нindидер дару ясыйлар, ди. Ул вакцина бик кирәкле дип сөйләде этисе. Әлфиснең үзенең дә күргәне бар: һәр яз саен, көтүгә чыгар алдыннан, сыерларны югары урамга тезеп бәйлиләр. Районнан килгән мал врачы һәр сыерның муенына укол кадап чыга. Әнә шул укол өчен даруны ун көнлек куян каныннан ясыйлар, ди. Укол салганнан соң өч-дүрт сәгать үткәч, врач сыерларның күзләрен карап йөри. Кайсы сыерның күзе эренле булса, шунысы чирле, үпкә авырулы. Аның сөтен эчәргә яра-

мый. Чахотка элэгүе ихтимал. Сыерны яраксызга чыгаралар, көтүгэ дэ җибэрергэ рөхсэт ителми. Бөгелмэгэ, бойнийга озатырга гына кала. Шулай итеп, куян балаларының каны бик кирэкле эшкэ китэ икэн. Тик... Әлфис учка сикереп төшэргэ торган ап-ак йомгакларны бик жэлли шул. Бик җанлы алар, тиктормаслар, үзлэре гаҗэп акыллылар. Ирекне яраталар. Ана куян тимер челтэрне кимерэ. Ябылуда ятканга бер дэ чыдый алмый. «Аристаннар кебек», дип бер көнне энисе дэ жэллэп куйды.

Әлфис кайтып кергэндэ, этисе таякка таянып читлеклэр янында тора иде.

— Эти, кырый читлектэге балаларны илтмэ эле,— диде Әлфис, печэнле капчыгын җиргэ утыртып.

— Нигэ алай дисең, улым? — Гаптелмэн күтэрелеп карамыйча гына алюмин чыбыкларны ишэ-ишэ читлек ишеген рэтлэде.

— Мин аларны жэллим. Бүген төшемэ дэ шулар керде. Эти!

Гаптелмэн эшеннэн туктады.

— Ничек инде жэллисең? — диде.— Аларны илтмэсэм, сиңа велосипедлык акча да булмый.

— Булмасын, җэяү дэ эйбэт йөрим.

— Соң, велосипед дип тэңкэгэ тиясең бит?

— Хэзер булмаса да ярый. Шул бэлэкэйлэр хисабына... кирэкми!

— Нэрсэ, энисең кебек мэгънэсез сүзлэр сөйлисең тагы?

— Мин аларны үзем үстерер идем.

— Тукта эле, хэзер лабораториянең иң кытлык чагы, һэр куян баласын икешэр сумнан да ким бирмим.

— Алар бигрэк риясызлар, матурлар.

— Матурлыгы нэрсэгэ аның? Эллэ син теге...— Гаптелмэн чигэсенэ төртеп күрсэтте.— Э куян бэлешен, ай-ай, шэп сыпыртасың, э?

— Эни тэмле итеп пешерэ.

— Юк, куян ите тэмле ул. Жэллэсэң, суймаска кирэк, суймасаң, куян итен ашап булмый,— дип Гаптелмэн учына тагын бер карап алды да капчыктагы печэннэрне учлап-учлап читлек эченэ ташларга тотынды. Әлфис этисенең сүзлэренэ җавап таба алмады, куян ите салып пешерелгэн бэлешне бик ярата иде шул.

— Син куян балаларын кызганма,—диде Гаптелмэн, бушап калган капчыкны җилкэсенэ ташлап. Аның бу минутта улына акыл бирэсе килде.— Жэллэү үзеңэ генэ зыян ул. Э куяннар үз балаларын бар дип тэ белмилэр. Тудыра да оныта.

— Кая! Энэ бит ничек ярата! Борыны белэн баласының колак төбен кашып тора.

— Эч пошканнан гына ул.

— Балаларын гел алганга күрэ аналарының күзлэре моңсу, боек.

— Ирекка чыгасылары килэ шилмаларның, — дип Гаптелмэн куяннарга карап көлемсерэде. Әлфис исэ этисенең елмаюын йомшаруга юрады һэм тагы баягы соравын кабатлады.

— Куян дип мэлҗерэмэсэнэ,— диде Гаптелмэн кинэт җитдилэнеп.— Энэ нэчэлник сиздереп куйды. Шул куян аркасында Әлмэткэ күчеп куюыбыз бар. Юлэр!

Әлфиснең күзлэре читлектэге куян күзлэре кебек моңсулык белэн тулды. Китек иреннэрен эле болайга, эле тегелэйгэ борып мелтмелт итеп торган, зур колаклары яшь эрекмэн яфрагыдай тибрэнгэн куян балаларын ул һаман да жэлли иде.

Икенче көнне этисенең аягындагы шеш тагы да ныграк кабарган булып чыкты. Э бүген нэкъ куян балаларын илтэсе көн. Гаптелмэн шешкэн тубыгына карап торды, юк, үзем бара алмам, ахры, дип уй-

лады. Йөзе чытылды, маңгаена җыерчык юллары сызылды. Ни кыларга белмичә баш ватып торды ул. Аннары гына эчтән үкенеп булса да бу эшне Әлфискә кушарга булды. Бүтән чара юк иде. Нигә, ике кулына ике кәрзин, авыр булмас, шәт? Ул аягына киез итекләр киеп, куян читлекләре янына чыкты. Үзенең шул эштә йөртә торган кәрзиннәрен алды һәм оялардан ун көнлек куян балаларын шунда тутыра башлады. Кәрзин саен уникешәр булды. Аннары кәрзиннәрне кулларына тотып, «үлчәп» карады. Юк, авыр түгелләр. Ишегалдында калайдан ук башы ясап маташучы Әлфисне чакырып китерде. Ике кулына ике кәрзин тоттырды.

— Я, күтәреп бак әле, авырмы? — дип, малаена көлемсерәп текәлде.

— Юк, очкын гына,— диде Әлфис ниндидер күтәренкелек белән.

— Алайса, бар яхшылап киен, Әлмәткә үзең илтеп кайтырсың.

— Ничек?— Әлфиснең күзләре чикләвек кебек түгәрәкләнде, йөзенә аптырау чыкты.

Әтисе дәшмәде, үзенең авырткан аягына карады. Димәк, әтисе бу эшне чынлап аңа ышанып тапшыра икән. Әтисенең ышануы Әлфиснең күңелен үсендерде. Үзенең җебегән түгеллеген күрсәтәсе дә килде аның. Хәер, әллә ни ис китәрлек эш тә түгел. Әтисенә ияреп баргалады ич ул анда. Азнакайдан Әлмәткә бара торган автобуска утырасың да базар янында төшәсең. Бер квартал үргә таба менә торган юлдан барасың, ветлаборатория шунда гына.

Кара чалбар, шакмаклы кызгылт күлмәк, коңгырт төстәге ботинка кигән, ике кулына ике кәрзин күтәргән малаеның җил-җил атлап барганын Гаптелмән бик кәефләнеп карап калды. Яшь әле, акча төмен белми, дип уйлады ул. Менә үзе шулай йөргәли башласа, тизрәк татыр.

Әлфис куян балаларын бик җайлы илтеп җиткерде. Лабораториядә бик көтеп торалар иде, аны чак кына күтәреп алмадылар. Барысы да ак халат кигән, чәчләрен малайларча йөрткән яшь кенә апалар шунда ук кәрзиннәргә ябырылдылар.

— Күрдеңме, минем юрау дөрес чыкты, Зилә,— дип шырк-шырк көлде берсе.

— Бер — нуль, синең файдага, — диде икенчесе, кәрзин эченә кулын төшереп. Алар куян балаларын учларына тоткан килеш көлешә-көлешә эшкә керештеләр.

— Болай булгач премия дә тәти инде.

— Алдан кычкырган күкенең...үзең беләсең.

— ДК да бүген дә танцы икән бит.

— Аһ, кичә туфләмнең үкчәсе купкан иде.

— Шул чаклы каты биемиләр аны.

— Партнерым шундый иде. Культура институтын тәмамлап кайткан, — дип чөкердәшә-чөкердәшә апалар китеп барды. Икенчеләре килде, кәрзингә кулларын төшереп куян балаларын алды. Бер түгәрәк битлесе куянны күкрәгенә кысты да бала урынына ярата, үбә башлады.

— И, җаныкаем, нигә болай колакларың шәлперәйде?— диде.— Әллә әнкәңне сагындыңмы?

— Куяннар балаларын бик тиз оныталар икән,— дип куйды икенче апа.

Кәрзин бушагач, Әлфис күтәрелеп карады. Шау-шу тынган, һәркем үз өстәле артына утырып, эшкә керешкән иде. Һәрберсенең өстәлендә кечкенә челтәр-читлек, рәт-рәт тезелеп торган приборлар, шприцлар. Әлфис үзе янындагы апаның нишләвен күзәтә башлады. Теге иң элек куян баласына йомшак кына бәйләвечләр кигезде. Бәй-

ләвечнең бер очын өстәл тартмасына кыстырып куйды. Куян бер җиргә дә кымшанырлык түгел хәзер. Аннары кулына юан энәле шприц алды. Икенче кулы белән куянның арт ботын йоннан аралады, бармагы кан тамырын эзләп тапты һәм... шул төшкә шприц кадады. Аннан шприцның пешкәген өскә таба иплән кенә тарта башлады. Пешкәк астында кызыл сызык барлыкка килде. Ул сызык калыная барып, пешкәк астына мул булып кан җыела иде. Куян баласы кечерәя, өстәлгә сеңә барган кебек булды. Кайчы шикелле тырпайган колаклары авып төште. Китек иреннәрен өстәлгә төртеп-төртеп ала. Шприц колбасы кызыл багана булып тулганда, куян баласы хәлсезләнеп бер якка янтайды, сузылды да күзләрен йомды. Аның эче генә бер күтәрелеп, бер төшеп торды. Ул шулай сулыш ала иде. Апа тиз генә шприцны тартып алды, ахак кызыл канны бер колбага бушатты һәм холодильникка куйды. Аннары икенче шприц белән куян баласына ниндидер укол ясады. Бер минуттан тегенең колаклары кыймылдады, турыланып утырды, иреннәрен бик җәһәт селкеткәләргә тотынды. Әлфис бугазына ниндидер төер килеп утырганын сизде. Шуны йота алмый азапланды. Куянны тагы нишләтерләр инде дип көтте ул. Шунда гына үзенә төбәлгән тавышны ишетеп, уянып киткәндәй булды.

— Ә син, хуҗа малае, алып килдеңмени, кая? — диде ишектән кергән абый һәм елмая-елмая кәрзиннәрне карарга тотынды. Кәрзиннәрнең буш икәнен күреп, бер Әлфискә, бер эшләп утыручы кызларга карады һәм барысын да аңлап:

— Бәяләре килешенмәс борын алып бетергәнсез бит, кычыткан чыпчыклары! — дип, үкенечле тавыш белән әйтеп куйды. Йөзендәге көләч ягымлылык кинәт сүнде.

— Ә син Маша орбитасында озаграк әйләндең. Аның тылсымнары бетмәс-төкәнмәс! — диде әлеге Әлфис күзәтеп торган кыз.

— Әй, телең, телеңдә — безең! — дип завхоз кулын селтәде һәм, Әлфиснең җиңенә кагылып, үз артыннан ияреpгә ымлады. Алар коридор аша үтеп, ян бүлмәгә керделәр. Әлфис һаман теге куян баласыннан кан алгандагы тәэсирдән айнып җитмәгән иде. Завхоз, куян балаларын куүпмедән бирәсең дип, аңа текәлеп карады. Әтисе аңа төгәл хакны колагына тукып җибәргән иде. Әлфис көчкә аек акылына кайта башлап:

— Эти икедән дә ким бирмәскә кушты, — диде һәм авызында, әрем сабагы эләккән шикелле, ниндидер ачы тойды. Завхоз биргән акчаларны тизрәк кесәсенә тыкты, буш кәрзиннәрен кулына алды.

Юлда да Әлфиснең күз алдыннан һаман теге юаш куян баласы китмәде. Укол кадаганда дерт итеп калтыранып китүе, китек иреннәре арасыннан телен чыгаруы, колбадагы канның күз явын алырлык кызыл төсе. Ни гаебе бар инде ул мәхлукның дип уйлады малай.

Өйгә бик боегып, җилкәләре салынып кайтып керде ул. Кара төк баскан битле әтисе, киез итектән килеш, тавыкларга җим болгатып маташа иде. Кәрзиннәрнең буш булуын шунда ук шәйләп алды ул. Күз кырыйларында җылы сызыклар пәйда булды. Малай кәрзиннәрне баскыч кырыена ташлады да күтәрмәгә килеп утырды. Бер сүз эндәшмичә, әтисеннән йөзен читкә борды.

— Әллә акчаңны югалттыңмы? — диде Гаптелмән, пошына башлап. Күз кырыена чыккан нурлар кинәт бетте. Малай башын ике кулы белән кочаклап утыра, һаман дәшми. Гаптелмәннең эченә салкын йөгергән кебек булды. Кызыл борыны кырыенда дәһшәт сызыклары пәйда булды. Әлфис әтисенең аңа төбәлүен сизде, башын күтәрде. Пинжәк кесәсенә кулын тыкты да, кәгазь акчаларны алып, әтисенең

сузылган учына салды. Үзе аңа күз дә салмыйча өйгә кереп китте. Тәрәзә янында басып торганда әтисенең акча санавы күзенә чалынды. Әтисе, җимле бармакларын теленә тигезеп ала-ала, тезенә куеп акча саный. Бер саный да башын селкеп куя. Аннары тагын бармакларын теленә тигезеп ала, гүя акчаның тәмен татып карый иде. Ниһаять, берничә кабат санаганнан соң, әтисенең йөзенә нур галәмәте чыкты.

— Шулай диген аны, уңгыры, — дип кычкырып куйды ул. — Котны ала яздың бит! — Шунда ниндидер рәхәтлек белән кесәсеннән каешланып беткән портмонет чыгарды һәм акчаларны салып куйды. Аның кыяфәтендә ниндидер җиңү һәм үзен бүтәннәрдән акыллырак итеп сизү чалымнары чагылды. Әлфис үзенең эчендә ниндидер ачу кузгалып куйганын сизде. Әтисенең шулай акча санавы аның күңелен кинәт кырысландырды. Ул хәзер акчаларның кайдан, ни рәвешле килгәнен үз күзләре белән күреп кайтты бит.

Әлфис төне буе саташа-саташа йоклады. Төшендә муенына куян каны агып төшә, имеш. Куяннарның күзләрен дә шул кызыл кан баскан, имеш... Әлфис уянып китсә, башына сыртын куеп мәче яткан икән. Чыкта йөреп йоны дымланып беткән. Шул чак тагы Әлфиснең йөрәген куян балаларын җәлләү тырнап үтте. Йокысы качты. Ул урыныннан торып, ишегалдына чыкты һәм куяннар янына лапаска керде. Нәрсә эшләгәнен үзе дә аңлап бетермәстән, лапасның бакчага чыга торган капкасын киң итеп каерып куйды. Аннары ниндидер кинәнү һәм үчегү хисе белән читлек ишекләрен ачып чыкты. Куяннар шыбырдашып җиргә коелдылар, бер мәл аяк асты кар яугандай ап-ак булып торды.

Ниндидер авыр йөктән арынган сыман җиңеләеп, Әлфис өйалдындагы караватына кереп ятты. Шунда ук йоклап та китте. Каты йокы белән йоклады.

— Харап булдык! — дигән ачынулы тавышка уянып китте ул. Карлыккан хәлсез тавыш белән әтисе кычкыра иде.

— Шул калай әтәч Шәфәгать эше бу! — Ул зарлана-каргана, аягы авыртуын да онытып, куяннар артыннан чаба-чаба тәмам хәлдән тайган. Өйалды басмасына килеп ауган да Әлфискә дәшә иде.

## БӨЕК РУС ЯЗУЧЫСЫ АНТОН ПАВЛОВИЧ ЧЕХОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

### А. П. Чехов

# АТА

хикәя



Дөресен генә әйткәндә, салмыш мин... Эссе булгач, үтеп барышлый сыраханәгә кереп ике шешә сыра эчкән ием. Гаеп итмә инде, эссе бит, туганкай! — Мусатов карт, кесәсеннән ниндидер бер чүпрәк тартып чыгарды да, күп эчүдән күгәренгән йөзен сөртеп алды.

— Бик мөһим эш белән бер генә минутка керүем ие синең янга, Боренька, — дип, улына карамыйча гына сүзен дәвам итте ул. — Гаеп итмә инде, бәлкем комачаулаганмындыр да. Сишәмбегә хәтле генә ун сумың булмас микән диган ием. Беләсеңме, фатирга кичә үк түлисе ием, акча юк... Хет суй менә!

Яшь Мусатов, дәшми-тынмый гына күрше бүлмәгә чыгып, дача хуҗасы һәм дачада бергә яшәүче хезмәттәш иптәшләре белән пышылдашып алды. Ике-өч минут үтүгә ул кире әйләнеп керде, бер сүз дә әйтмичә әтисенә унлык сузды. Әтисе, карап та тормыйча, акчаны илтифатсыз гына алып кесәсенә тыкты.

— Мерси, — диде ул. — Йә соң, ничек яшисең? Күрешмәгәнгә дә күптән бит инде.

— Әйе шул. Бәйрәмнән бирле.

— Дүрт-биш мәртәбә җыенганмындыр яныңа килергә. Һаман җитешеп булмый. Әле бер эш чыга, әле икенчесе... аптыраган инде! Хәер, юк ла, алдашам... Барысы да ялган. Ышанма син миңа, Боренька. Унлыгыңны сишәмбе көнне кайтарып бирәм дидем — анысына да ышанма. Бер сүземә дә ышанма син минем, эшем дә юк минем. Ялкаулык та исереклек кенә баскан мине, аннары мондый өс-баш белән кеше арасына чыгарга да оят бит. Гаеп итә күрмә инде, Боренька. Мин әле сиңа акча сорап ике-өч мәртәбә бер кызыйны да җибәргән ием, кызгандырырлык итеп хатлар да язган ием. Акчаң өчен рәхмәт анысы, ә хатларыма ышанма — алдаштым. Һаман саен теләнеп сиңа килү оят бит инде; үзеңнең дә ничек кирәк алай очын-оч-

ка ялгап барганыңны, ачлы-туклы яшәгәнеңне беләм бит, югыйсә, шулай да әрсезлегем җиңә, әрсезнең дә әрсезе бит мин! Нарасый йөзеңә тыныч кына карый алмыйм, шуңа күрә сиңа дөресен сөйлим.

Берәр минут тын тордылар. Аннары карт тирән итеп көрсенеп:

— Сыра белән сыйлар идең, бәлки?.. — дип куйды.

Улы дәшми-тынмый гына бүлмәдән чыкты, ишек артында тагын пышылдашкан тавышлар ишетелде. Берникадәр вакыттан соң сыра алып керделәр, шешәләрне күрүгә карт җанланып китте, аның сөйләшү тоны ук үзгәрде.

— Шушы араларда гына ат чабышына барганыем, — дип сөйли башлады ул, күзләрен куркыныч йөртеп. — Өчәү идек без. Җитез исемле атка тотализатордан өч тәңкәлек бер билет алдык. Рәхмәт инде ул Җитезгә. Шул бер тәңкәгә утыз икешәр сум бирделәр безгә. Ат чабышына йөрми булдыра алмыйм шул, туганкай. Асыл затлар рәхәте бит ул! Шунда йөргән өчен минем хатын кирәкне бирә-бирүен, шулай да — йөрим. Нишләмәк кирәк — яратам!

Борис — сүрән кыяфәтле, караңгы чырайлы егет, — әкрен генә ишекле-түрле йөренеп, эндәшмичә генә тыңлады. Ютәлләп алырга дип, карт сөйләвеннән туктагач, улы аның янына килеп болай диде:

— Әткәй, әле күптән түгел генә штиблет сатып алган идем, кечерәк булып чыкты, аягымны кыса. Шуны син алмассың микән? Мин аны сиңа арзанрак хакка бирер идем.

Карт чыраен сытып кына:

— Ярар соң, — диде, — тик үз хакына алырмын, киметмичә.

— Яхшы, мин аны сиңа көтәргә бирермен.

Борис карават астыннан яңа штиблетын тартып чыгарды. Әтисе аягындагы шыксыз кәрән күн итеген салды да (анысы да үзенеке түгел иде бугай), яңа штиблетны киеп карады.

— Таман гына икән! — диде ул. — Ярар, миңа булыр. Акчасын сишәмбе көнне, пенсия алгач җибәрермен. Хәер, алдашам, — диде ул кинәт кенә әлеге дә баягы еламсыраган тавыш белән. — Тотализатор турында да, пенсия турында да алдашам. Син дә мине алдыйсың, Боренька... Игелекле булуыңны сиздермәскә тырышканыңны тоеп торам бит мин синең. Үтәдән-үтә күреп, аңлап торам бит мин сине. Күңелең киң булганга штиблетың кысан булып чыккан бит синең. Их, Боря, Боря! Барысын да аңлыйм, барысын да сизәм бит мин!

Улының сүзне икенчегә борасы килде.

— Яңа фатирга күчкәнсез икән, — дип бүлдерде ул әткәсенең сүзен.

— Әйе, күчтек, туган. Ай саен күченәм мин. Хатын кәмәле холыксыз бит минем, бер җирдә дә тыныша алмый.

— Мин сезнең элекке фатирыгызда булган идем бит, үзебезнең дачага чакырсам дигән идем. Сәламәтлегегез начар бит, бераз саф һавада яшәп алсагыз әйбәт булыр диюем иде.

— Юк! — дип, кул гына селтәде карт. — Хатын да җибәрмәс, үземнең дә барасы килми. Йөз генә тапкыр маташмадыгыз бит инде сез мине чокырдан тартып алырга, үзем дә тырышып карадым — пычагым да барып чыкмады. Ташла! Шул чокырда дөмегергә язгандыр инде миңа. Менә хәзер дә синең нурлы йөзеңә карап утырам, ә үземнең өйгә, шул базга кайтасым килә. Язмыш шундыйдыр инде минем. Тирес кортын роза чәчкәсенә кундырып булмый, күрәсең. Юктыр, булмыйдыр. Алай да, караңгы төшеп килә, кайтырга вакыт.

— Ярар алайса, озатып куйыйм, бүген миңа барыбер шәһәргә кайтырга кирәк.

Алар өсләренә пальтоларын киделәр дә чыгып киттеләр. Берникадәр вакыттан соң, алар извозчикка утырып китеп барганда, тышта караңгы төшкән, тәрәзәләрдә утлар җемелдәшә иде инде.

— Таладым инде мин сине, Боренька, — дип сөйләнде ата кеше. — Бичара балакайларым! Шушындый атагыз булу коточкыч бәхетсезлектер инде ул сезгә! Боренькам, сөеклем, сине күрсәм алдаша да алмыйм. Гаепләмә инде... Оятсызлыкның аръягына чыктым бит мин, ходаем! Менә хәзер дә мин синең акчаңны да алдым, сәрхүш кыяфәтем белән оятка да калдырдым үзеңне, абыйларыңны да талыйм, минем аркада хурлыкка да калалар, кичәге кыланышымны гына күрсәң ие син минем! Яшерә алмыйм инде, Боренька! Кичәгенәк минем хатын янына күршеләр, җыен юк-бар кеше җыелганые, шулар белән эчеп исердем дә тотындым үз балакайларымны сүгәргә! Сүктем дә соң сезне шунда, ташлап киттеләр дип зарландым да үзегездән. Исерек хатыннардан кызгандырам үземне, бәхетсез ата итеп күрсәтәм, янәсе. Гадәтем шундый инде: әшәкелегемне яшерергә теләдемме, бөтен гаепне бер гөнаһсыз балаларым өстенә өя башлыйм. Ялганлый да алмыйм шул мин сиңа, Боренькам, синнән бернәрсә дә яшерә дә алмыйм. Яныңа барганда әллә кем булып этәчләнеп барганыем югыйсә, яныңа барып сабырлыгыңны, мәрхәмәтлелегеңне күрүгә телем аңкавыма ябышты, вөҗданыма көч килде.

— Ярар, эткәй, әйдәгез бүтән берәр нәрсә турында сөйләшик.

— Йа раббем, балаларымны гына күрегез әле! — дип дәвам итте карт, улының сүзен тыңламыйча. — Ходай тәгалә миңа әнә нинди хәзинә биргән бит! Мондый балалар мин юньсезгә түгел, эчендә җаны булган, ярата белгән берәр чын кешегә туры килгән булсын иде! Төс түгел алар миңа!

Карт төймәле бәләкәй картузын салды да берничә кат чукынып алды.

— И ходаем, рәхмәтеңнән ташлама! — дип көрсенде ул, үзе, изге сурәт эзләгәндәй, як-ягына каранды. — Бигрәк әйбәт балалар шул! Өч улымның өчесе тиң менә дигән. Аек башлы, сабыр табигатьле, эшлекле, акыллы үзләре! Извозчик, ишетәсеңме? Бер Григорийның акылы гына ун кешегә җитәрлек. Сөйләвен генә күрсәңие син аның, французча дисеңме, немецчәме — адвокатларың бер якта торсын, дөньяларыңны онытып тыңлыйсың... Балакайларым! Шундый балаларның үземнеке булуына ышанмыйм да мин! Ышанмыйм шул! Бигрәк җәфалыйм инде мин сине, Боренькам! Бөлдереп бетерәм бит инде... Син миңа һаман бирәсең дә бирәсең, биргән акчаңның юньлегә китмәгәнен дә беләсең, югыйсә. Шушы араларда гына мин сиңа кызгандыргыч хат җибәргәнием, чирем турында язганыем, анда да алдаштым бит: акча миңа ром алырга кирәк ие. Кире каксам рәнҗетермен дип куркып бирәсең бит син миңа. Мин барысын да белеп торам ич. Гришаны кара инде тагы — җәфалана. Беләсеңме, пәнҗешәмбе көнне, исерек килеш, пычранып беткән йолкыш бер кыяфәттә киттем мин моның эшләгән җиренә... Үземнән аракы мичкәсеннән килгән сыман сасы ис килә. Шундый кыяфәтем белән килеп керәм мин моның янына туп-туры, теләсә нинди кабәхәт сүзләр әйтәм, эшенә тылкышам, аның янында — иптәшләре, башлыклары, үтенеч белән килгән кешеләр. Мәңгегә хур иттем инде мин аны. Шунда да бит ул әз генә дә караңгы чырай күрсәтмәде ичмасам, бераз төсе качты качуын, ә үзе берни булмагандай елмаеп яныма килде, җитмәсә әле иптәшләре белән таныштырды. Аннары өйгә хәтле озатып куйды, үзе шунда шелтәләп ник бер сүз әйтсен! Аны инде мин сиңа караганда да ныграк талыйм. Хәзер менә абыең Сашаны алыйк, аны да җәфалыйм ич инде мин. Ул аристократ нәселеннән полковник кызына өйләнде бит, придан алды... Анда минем кайгы булмаска тиеш ие югыйсә. Юк шул менә, өйләнгән уңайга ук, яшь кәләшен ияртеп, туйдан соң беренче визит белән миңа... минем зинданыма килде... Валлаһи менә!

Карт сулкылдап куйды да шундук көлеп тә җибәрде.

— Ул чакта алар, үч иткәндәй, квас белән ачы торма әзерләгән чакка, балык кыздырган чакка туры килделәр, өйгә чыдап булмаслык сасы ис чыккан ие. Мин исереп ятам. Хатын кып-кызыл йөзен чекрәйтеп яшьләр каршына йөгереп чыккан... Кыскасы, моннан да ары юньсезлек булмас инде. Саша шуларның барысына да түзде.

— Әйбәт кеше шул безнең Саша,— диде Борис.

— Гаҗәп инде! Барыгыз да алтын бәясе кешеләр бит сез минем: син дә, Гриша да, Саша да, Соня да. Газаплыйм инде мин сезне, аптыратам, оятка калдырып бетерәм, акчагызны талыйм, ә үзем гомер буена бер кырын күз белән караганыгызны хәтерләмим, бер кәлимә авыр сүзегезне ишеткәнем юк. Үзем юньле кеше булсам бер хәл иде, кем соң инде мин — тьфү бит югыйсә! Явызлыктан башка нәрсә күргәнегез юк бит сезнең миннән. Юньсезнең юньсезе бит мин, юлдан язган бәндә... Хәзер әле ярый, аллага шөкер, басыла төштем, элек бит, сез бәләкәй чакларда, бөтенләй чыгырдан чыккан холыксыз бер җан ием. Нәрсә эшләсәм дә, ни сөйләсәм дә, барысы да шулай булырга тиеш сыман тоеладыры миңа. Кайчакларда шулай төннәрен клубтан исереп кайтырыем да тотынырыем мәрхүм әниегезне таларга, акчаны күп тоткансың дип битәрләргә. Төннәр буе талап чыгарыем бичараны, ә үзем нәкъ менә шулай булырга тиеш дип уйларыем; иртән торырыегыз дә сез гимназиягә китәриегез, ә мин әле һаман да аңа үземнең кем икәнлегемне күрсәтергә тырышырыем. Урыны җәннәттә булгыры, бичараны талап кына үтердем инде мин аны! Гимназиядән кайтырыегыз укып, ә мин әле һаман йокыда, шунда тамагызга да ашамыйдырыегыз бит сез мин тормыйча. Ашарга утыргач, яңадан шул ук музыка башланырые. Хәтерендәдер, шәт. Ходай берәүгә дә мондый ата бирмәсен. Сезне сынар өчен җибәргәндер ул ходай мин юньсезне. Әйе шул, сынар өчендер! Беткәнче түзегез инде, балакайларым. Атаңны олыласаң, озын гомерле булырсың диелгән бит изге китапта. Сабырлыгыгыз, чыдамлыгыгыз хакына әлләә ходай тәгалә сезгә чыннан да озын гомер бирер. Извозчик, туктат!

Карт, пролеткадан сикереп төште дә, йөгереп сыраханәгә кереп китте. Ярты сәгатьләр үтүгә чыкты да, исерекләрчә тамак кырып, улы янына менеп утырды.

— Соня кайда хәзер? Һаман да пансиондамы?— дип сорады ул.

— Юк, майда укып бетерде, хәзер Сашаның әбисендә тора.

— Менә бит!— диде карт, шаккатып.— Булдырган бит кызый, димәк, абыйларына охшаган. Их, Боренька, әниегез юк шул, сөенер кеше юк. Карале, Боренька, ул... ул минем ничек яшәгәнне беләме соң?

Борис ни дип тә җавап бирмәде. Тирән тынлык берничә минутларга сузылды. Карт сулкылдап алды, чүпрәген чыгарып битен-күзен сөртте.

— Яратам шул мин аны, Боренька! Бердәнбер кызым бит, картлык көнендә кыз баладан да кадерлерәк юаныч юк икән ул. Күрешәсе ие бит. Булыр микән, Боренька?

— Әлбәттә, кайчан теләсәгез, шунда күрешә аласыз.

— Валлаһимы? Ә соң ул каршы булмасмы?..

— Юкны сөйләмәгез! Күрешәсе килеп ул үзе сезне эзләгән иде.

— Валлаһимы? Менә ичмасам балалар! Ишетәсеңме, извозчик? Күрештер әле, зинһар өчен, Боренька! Ул бит инде хәзер туташ, деликатес, консули һәм башка шуның ише зыялылар рәтендә, шулай булгач, минем аңа мондый әшәке кыяфәттә күренәсем килми. Бу хикмәтләрне без менә болайрак оештырыйк, Боренька. Эчүдән күбе-

неп беткән йөзем бераз рәткә керсен өчен ике-өч көн хәмер капмыйчарак торырмын, аннары синең янына килермен дә, син миңа бирәр костюмыңны биреп торырсың; сакал-мыегымны кырырмын, чәчләремне кистерермен, аннары син аны барып алып килерсең. Яме?

— Ярар.

— Извозчик, туктат!

Карт яңадан да пролеткадан сикереп төшеп сыраханәгә йөгерде. Фатирына кайтып җиткәнче ул әле шулай тагын бер-ике мәртәбә төшеп менде, улы аны «эһ» тә димичә, сабыр гына көтеп утырды. Извозчиктан төшеп, озын, пычрак ишек алды буйлап фатирга кереп барган чакта карт бик уңайсызланды, үзен гаепле кеше сыман тотты, кыяр-кыймас кына тамак кыргалады, авызын чапылдатты.

— Боренька,— диде ул ялагай тавыш белән,— әгәр дә мәгәр минем хатын кисәге сиңа тегенди-мондыйрак берәр нәрсә әйтә башласа, син аңа игътибар итмә... ничек тә йомшаграк булырга тырыш инде. Тәрбиясез дә, дорфа да ул, шулай да үзе әйбәт хатын. Кайнар йөрәкле, миһербанлы кеше.

Озын ишегалдын үтеп, караңгы өйалдына барып керделәр. Чыгырлы ишек шыгырдап куйды, кухня исе, самавар төтене исе килде, зәһәр тавышлар ишетелде. Өйалдыннан кереп кухня аша үткәндә, куе төтен эчендә Борисның күзенә бауга эленгән керләр дә алтынсу очкыннар чәчрәп торган тишек самовар торбасы гына күренде.

— Менә шушы була инде минем хөҗрә,— диде карт, тәбәнәк түшәмле бәләкәй бүлмәгә бөкрәеп керә-керә. Кухня белән янәшә булганлыктан, бүлмәнең һавасы чыдап булмаслык тынчу иде.

Табын янында ниндидер өч хатын сыйланып утыра иде, арадан берсе, күрәмсең, шул хатын кисәге дигәне:

— Булдымы?— дип сорады.

— Булды, булды,— диде карт.

— Йә, Борис, рәхим ит әйдә, утыр. Бездә хәлләр менә шушылай, туган, гади генә яшибез без... үзебезчә генә.

Ул ничектер гел кирәксезгә ыгы-зыгы килә башлады. Улыннан оят иде аңа, шул ук вакытта хатыннар алдында да үзен һәрвакыттагыча көяз итеп тә, балалары ташлаган бәхетсез ата итеп тә тотасы килә иде, күрәсең.

— Әйе, туганкай, гади генә, кырланмый-сырланмый гына яшибез без,— дип сөйләнде ул.— Гади кешеләр без, егеткәем... Сезнең ише түгел, күзгә төтен җибәрергә яратмыйбыз. Шулайрак менә... Аракы эчеп җибәрәбезме әллә?

Хатыннарның берсе (чит кеше алдында эчәргә уңайсызлана иде ул) көрсенеп куйды:

— Гөмбә булгач тагын эчәм инде... Гөмбәсенең тәмлелеген күрсәң менә, эчмәс җиреңнән эчәрсең. Иван Герасимыч, кунакны да чакырыгыз, бәлки ул да эчәр.

— Эчеп җибәр әйдә!— диде карт, улына карамыйча гына.— Ширбәттер, ликердыр ише нәрсәләр юк, бездә гадие генә.

— Бездә ошамый аңа,— дип көрсенеп куйды хуҗа хатын.

— Эчә ул, эчә!

Әтисенең хәтерен калдырмас өчен Борис рюмканы алды да сүзсез генә эчеп куйды. Самаварны керткәч, шулай ук сүзсез генә, меланхолик кыяфәт белән картка ярарга тырышып, ике чынаяк күңел болгаткыч тәмсез чәй эчте, хуҗа хатынның бу дөньяда ата-анасын ташлый торган игелексез һәм имансыз балалар булуына ишарәләп сөйләгән сүзләрен дә эндәшмичә генә тыңлады.

— Мин синең хәзер ни уйлаганыңны беләм бит!— дип сөйләнде сәрхүшләнгән карт, гадәттәге исерек, ярсыган халәтенә кайтып.— Син инде минем турыда түбәнлеккә төшкән бу, юкка чыккан, кызганыч бу, дип уйлыйсың, ә минемчә, егеткәем, мондый тормыш синекенә караганда әйбәтрәк ул. Берәүне дә хаҗәтсенмим дә мин, һичкем алдында үземне кимсетергә дә теләмим... Нинди дә булса малайшалайның миңа кызганып каравын җенем сөйми.

Чәйдән соң карт селедка чистартты, селедка өстенә тураган суган сипте, күңеле үтә дә нечкәреп, күзләренә яшь килде. Ул яңадан да тотализатор турында, отышлар, панама саламыннан үрелгән ниндидер эшләпәләр турында сөйләнде. Үзе, аракы эчкәннән соң селедкасын ничек тәмле итеп ашаса, шундый ук ләззәт белән алдашты. Улы дәшми-тынмый гына берәр сәгать утырды да хушлаша башлады.

— Көчләп тота алмыйм инде, — дип куйды карт, һавалы гына итеп,— сез теләгәнчә яшәмәгәнем өчен гафу итәсез, егеткәй!

Ул үзенчә гайрәт чәчте, ирәйгән сыман итеп пырхылдап көлде, хатыннарга күз кыскалады.

— Хушыгыз, егеткәй!— диде улын өйалдына озата чыгышлый.— Атанде!

Өйалдына караңгыга чыккач ул кинәт кенә улының беләгенә сыенып сулкылдап куйды.

— Сонюшкамны күрергә ие бит! — дип пышылдады ул.—Күрештер инде син безне, Боренька! Сакал-мыегымны кырырмын мин, синең костюмыңны киярмен... Җүнле кыяфәткә керермен... Аның алдында бер сүз дә сөйләшмәм. Билләһи менә эндәшмәм.

Ул хатыннар тавышы ишетелеп торган ишеккә таба кыюсыз гына борылып карады, аннары, үксүен тыеп:

— Хушыгыз, егеткәй! Атанде!— дип кычкырып куйды.

**САИМӘ ИБРАҺИМОВА**
**тәрҗемәсе**




# БАҺАДИРЛАР ЮЛЫ

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ

Ерак, матур бер сәфәрдән кайтып төштем. Сокланып, дулкынланып кайттым. Юл мәшәкатьләре онытылды, ә хисләр яңара гына барган кебек.

БАМда булдым, Байкал—Амур тимер юлы магистрале. XX гасырның иң зур төзелешләреннән берсе. Партиябезнең XXV съездында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежнев бу төзелешкә зур бәя бирде.

Ул — иң кыска срокта эшләнә торган төзелеш.

Төзелеш белән бөтен дөнья кызыксынып тора. Һәр көнне диярлек Советлар Союзының төрле шәһәрләреннән, шулай ук чит илләрдән язучылар, журналистлар, композиторлар, рәссамнар, артистлар һәм скульпторлар килә. Алар төзелеш белән танышалар, алдынгы эшчеләр турында китаплар язалар, рәсемнәр ясыйлар, аларның сыннарын коялар, яңа җырлар иҗат итәләр.

БАМда безнең якташларыбыз — данлы Татарстан кешеләре дә күп. Гомумән, татар егетләре һәм кызларының илебездәге бөек төзелешләрдә катнашуы гүзәл бер традиция рәвешендә буыннан-буынга күчә килә. Шанлы Днепрогэста, Магниткада, бөтен дөньяны таң калдырып, бетон салу рекордлары куйган улларыбыз һәм кызларыбыз, Братск каһарманнары һәм, табигый, КамАЗ... Чыдамлылык, хезмәт сөючәнлек, намус сафлыгы — аларның холык-фигыльләрендәге бу гүзәл сыйфатлар һәркайда сокландыргыч чагылыш таба.

Шуларның берсе — шофер Рифкать Сәмигуллин. Төзелештә 1972 елдан бирле. Совет Армиясендә хезмәт иткәннән соң, туп-туры шушында килгән. Башта, билгеле, кыен була. Кышын 60 ар градуска җиткән салкынлыкта, җәен озынборынлы, черкиле юешлектә эшләргә күнегү җиңел түгел. Әкренләп кырыс Себер табигатенә җайлаша, авырлыкларны җиңә бара. Хәзер БАМда хөрмәтле кеше. Аның турында КПССның Тын-

да шәһәр комитеты секретаре Юрий Афанасьевич Есаулков та, төзелеш җитәкчеләре дә бик яхшы фикердә. Рәсеме Тында шәһәренең Почет тактасында тора. Хезмәттә зур уңышларга ирешкәне өчен коммунист Сәмигуллин «БАМның алдынгы төзүчесе» дигән медаль белән бүләкләнде. Күптән түгел БАМ төзелешендә эшләүчеләрне Мәскәү телевидениесеннән күрсәттеләр. Трассада эшләүче иң яхшы шоферлардан якташыбыз Рәфкать Сәмигуллин исемен ишетеп шатландык.

Германия Демократик Республикасыннан килгән язучы Карл Зигмунд якташыбыз Рәфкать турында немец теленда очерк язып чыкты.

Тимер юл төзелешендә мастер булып эшләүче Зәки Кирәев тә күпләргә үрнәк. Ул тимер юл төзүдә ике дистә елга якын эшли. Башкортстанның Кушнаренко районындагы Рәсмәкәй авылыннан комсомол юлламасы белән килә, 1973 елдан бирле эшли.

Зәки бала вакытта уйнап үскән авылын, ат саклаган болыннарын, челтерәп аккан чишмәләрне сагынып искә ала. Ул Агыйдел, Дим, Әй елгалары буенда нефть разведкасында эшләгән вакытларын телгә алды.

— Киң бит ул безнең Башкортстан җирләре! Салават батыр кылыч айкаган далалар, алтын бодай үстерә торган кырлар, нефть бирүче таулар һәм үзәннәр, очы-кырые күренмәгән котү йөри торган болыннар кемнәрне генә үзенә сокландырмый да кемнәрне генә үзенә тартмый! — Ул, тальян гармонен алып, «Дим буе»н уйнап җибәрә.

Аларның бригадасындагы сигез милләт уллары һәм кызлары бердәм, тату гаиләдәй эшли. БАМда иң алдынгы бригада бу. Җитәкчесе — тәҗрибәле эшче Иван Варшавский милләте белән украин. Тырышлыгы өчен әле күптән түгел генә «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде.

Тимер юл магистралендә җир асты юлы — тоннель эшләү иң катлаулы хезмәт. Бу эш мәңгелек туңлыкта аерата авыр. Әмма тоннель төзүчеләр табигатьнең мондый кырыслыгын күп мәртәбәләр җиңеп чыккан кешеләр. Аларны хезмәт каһарманнары дип тикмәгә генә әйтмиләр. 50—60 градус салкында да, 32 градус эсселектә дә алар үз эшләрен дәвам итәләр.

Тоннель төзүче бригада җитәкчесе Рәсим Исхаков — башкаларга үрнәк егет. Ул Совет Армиясендә хезмәт итеп кайтканнан соң Братск ГЭСы төзелешендә, аннан соң Красноярск ГЭСы төзелешендә эшли. Туган якларын — Бөгелмә шәһәрен искә ала. Әтисе Әнәс сугышка кадәр үк Себер якларында төзелештә була. Бөек Ватан сугышы башлану белән, фронтка китә, Харьков янындагы сугышларда батырлык күрсәткәне өчен орден белән бүләкләнә. Сугыш бетәр алдыннан гына һәлак була. Гөлфанасы кулында алты баласы кала...

Рәсим, атасы кебек, Себер төзелешенә үзе теләп килә. Төзелеш җитәкчеләре, аның тырышлыгын күреп, тоннель төзү бригадасына бригадир итеп билгелиләр. Биредә ул партиягә керә.

Байкал—Амур магистрале төзелешендә фидакарь хезмәтләре белән танылган яшьләр һәм комсомоллар, Мәскәүгә барып, Җиңү байрагы янында фоторәсемгә төшү бәхетенә ирешәләр. Бу хокук бары тик иң алдынгы кешеләргә, коммунистик хезмәт ударникларына гына бирелә. Менә шул Җиңү байрагы янында якташыбыз Рәсим Исхаков та фоторәсемгә төшкән.

Мине тагын бер гүзәл кеше белән таныштырдылар: Мәдинә Талипова — юл төзү мастеры. Шул эштә 1972 елдан бирле. Түбән өлкәсенең Тобол шәһәреннән. Курыкмый атлый Мәдинә! Хезмәтләре өчен ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены алуга лаек булды.

БАМ төзелешендә эшләп Ленин ордены белән бүләкләнгән Кәрим Гәраев — Амур өлкәсендә генә түгел, Якутия АССРда да алдынгыларның берсе. Татарстаннан. Айлык йөкләмәсен 200—300 процентка үти, яшьләр белән эш тәҗрибәсен уртаклаша.

— Бала чагымда паровозлар ясап уйный идем. Тимер юл салучы булып китүемә шул да әйдәгәндер, — ди Кәрим абый.

Татарстан хезмәт ияләре Байкал — Амур тимер юл магистрале эшчеләре белән тыгыз элемтәдә торалар. Без «Бамстройпуть» идарәсендә якташларга карата бик җылы сүзләр ишеттек. Советлар Союзының төрле якларыннан килгән ядкарьләр арасында Татарстаннан җибәрелгәннәре дә бар. Казан педагогия училищесы укучылары җибәргән сувенирлар аерата игътибарга лаеклы. Алар «Татарстан», «Казан», «КамАЗ» альбомнары бүләк иткәннәр һәм анда йөрәк түреннән чыккан иң җылы сүзләр язылган.

Тында, Нерюнгри шәһәрләрендә, Беркакит, Могота, Улькан, Лапри, Золотинко, Нагорный, Чульман поселоклары магазиннарында «Татарстан» дигән ислемайларны, «Спартак» фабрикасы эшчеләре эшләгән аяк киемнәрен, Х. Ямашев исемендәге мех берләшмәсе коллективы хәзерләгән туннарны, Чистай заводы эшчеләре эшләгән сәгатьләрне күрдек. Татарстан пионерлары һәм укучылары БАМ төзү өчен тимер-томыр өзерләп тапшырганнар.

Арча районының «Игенче» колхозы кешеләре дә «БАМстройпуть» идарәсе белән тыгыз элемтәдә тора. Бу эшкә колхоз председателе, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Әдһәм Сәмигуллин һәм партком секретаре Мөбарәк Галиев зур игътибар күрсәткән.

«БАМстройпуть» идарәсенең комсомол комитеты секретаре Виктор Муконин:

— Бөек Ватан сугышында тиңсез батырлык күрсәткән геройларны без мәңге йөрәк түрендә саклыйбыз. Шулар арасында күренекле татар совет шагыйре, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил безнең барыбызга да үрнәк.

БАМ төзелешенең Якутия АССР территориясендә Беркакит дигән яңа поселок бар. Монда һәр көнне яңа йортлар үсеп чыга, яңа урамнар барлыкка килә. Аларның берсенә Муса Җәлил исеме бирелде. Бу турыда «Правда» һәм «Известия» газеталарында язып чыктылар. Якутлар каһарман шагыйрь батырлыклары белән рухланып эшлиләр. «Якутия комсомолы» дигән комсомол-яшьләр бригадасы Муса Җәлил исемен яулап алу өчен көрәшүче бригада белән ярышып эшли.

Эшчеләр поселогында бу бригада инде ике ел рәттән Муса Җәлил исемен яулап алу өчен көрәшә. Алар кеше аягы басмаган тайгага беренчеләр булып аяк басканнар һәм, урман кисеп, беренче йортларны салганнар. Кыргый тайгада ике-өч ел эчендә Беркакит дигән поселок һәм зур станция үсеп чыкты, андагы үзәк урамнарның берсе Муса Җәлил исемендә. Аны ачу тантанасында балта осталары бригадасы бригадиры Василий Кударь болай диде:

— Дуслар белеп торсыннар: без Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемен горур йөртәчәкбез. Муса Җәлил — совет халкының бөек шагыйре — безгә БАМ төзешә!

Муса Җәлил исемен алу өчен көрәшүче бригадада 23 кеше: 6 милләт уллары һәм кызлары. Алар кичке мәктәпләрдә укыйлар, үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөриләр, семьяда, эштә һәм җәмәгать урыннарында үрнәк булып торалар, артта калучы бригадаларга ярдәм итәләр, ял көннәрен күңелле һәм файдалы итеп үткәрәләр. Россиядән, Украинадан, Белоруссиядән, Татарстаннан, Молдавиядән, Башкортстаннан килгәннәр.

Вагон-клуб «Без Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемен алу өчен көрәшәбез!», «Атаклы шагыйрь безнең сафта БАМ төзи!», «Бригада членнары! Батыр шагыйрь Муса Җәлилдән үрнәк алыгыз!» дигән өндәмәләр белән бизәлгән. Стенада М. Җәлилнең зур портреты, өстәлдә бюсты, шүрлектә татарча, русча, украинча һәм башка телләрдәге китаплары, «Муса Җәлил» альбомы, татар язучыларының китаплары. Шушындый ук китаплар һәм М. Җәлил бюсты Беркакит поселогындагы китапханәдә дә бар. Китапханәнең түрендә — М. Җәлил портреты, «Җырларым» шигыреннән бер өзек.

Китапханәдә төзүчеләр күп була. Алар Муса Җәлил шигырьләрен яратып укыйлар, батырлыгына сокланалар, эштә үрнәк алырга тырышалар. БАМ төзелешендә Эстония ССРдан килгән бригада тырыш хезмәтләре белән танылa. Шул бригада җитәкчесе һәм эстонча чыга торган журналның корреспонденты Энн Лейссон Муса Җәлил хакында болай диде:

«Правда»дан БАМдагы бер бригаданың Муса Җәлил исемен алу өчен көрәшүен укып белдек. Безнең бригада членнары, бу мәкаләне укыгач, миңа шундый тәкъдим әйттеләр: без дә үзебезнең эстон кызы, Советлар Союзы Герое Мельникайте исемен алу өчен көрәшик!»

Энн Лейссон бригадасы да Муса Җәлилнең эстон телендә басылган «Моабит дәфтәре» китабын тота.

Тындада «БАМстройпуть» идарәсе начальнигы Юрий Алексеевич Чупринко һәм партком секретаре Виктор Павлович Калаганский белән очрашып сөйләштек. Алар Татарстаннан килгән төзүчеләр эшчәнлегенә зур бәя бирделәр.

Чульман эшчеләр поселогында якташыбыз баш геолог, Социалистик Хезмәт Герое Саимә Кәримова белән очраштык. Карап торуга бик гадәти хатын, ә исеме бөтен җир шарына таралган! Аның турында рус, якут, бурят, немец, инглиз, венгр һәм башка телләрдә язып чыкканнар, документаль фильмнар эшләгәннәр. Үскән җире — гади татар авылы. Саимәнең атасы Сафа абзый, анасы Галия апа кызларын эш сөючән итеп тәрбияләгәннәр. Ул Буа шәһәрендәге урта мәктәптән соң В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының геология факультетын тәмамлый. 1954 елның июнендә өлкән геолог булып Якутия АССРга килә һәм, экспедиция җитәкчесе буларак, тайгада ару-талуны белмичә яңа казылма байлыклар эзли. Геологлар арасында хатын-кызларга гына түгел, кайбер ирләргә дә авыр. Саимәдә чыдамлык бала чактан тәрбияләнгән. Ниһаять, зур шатлык! Нерюнгри янындагы урманда ул ташкүмер ятмалары таба. Аңа РСФСРның атказанган геологы исеме бирелә, ә 1976 нчы елның мартында Саимә Кәримова Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ул тапкан ташкүмер запасы илебезнең промышленностен күтәрүгә ярдәм итә. БАМның Тында — Беркакит тимер юлы шул ташкүмерне илебезнең төрле шәһәрләренә, промышленность үзәкләренә һәм завод-фабрикаларга җибәрү өчен эшләнде.

БАМ төзелешендә күперләр күп салына. Якташыбыз Зыя Ягъфәров Тында — Беркакит тимер юлы күперен төзүдә катнаша. Ул комсомол-яшьләр бригадасын җитәкли. Хезмәте зур һәм мактаулы! Тимер юл күпере төзү — тоннель казу кебек үк авыр, катлаулы һәм җаваплы хезмәт. Шул эшне Зыя Ягъфәров бригадасы срогыннан алда үти.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежнев белән очрашу БАМ төзүчеләре күңелендә якты бер сәхифә булып саклана.

— Сезгә, иптәшләр, — диде Л. И. Брежнев, — кыен бурычларны хәл итәргә туры киләчәк. Мин ышанам, сез, комсомол чакыруы белән шушы бөек төзелешкә килгән егетләрнең һәм кызларның батыр коллективлары, аларны җиңеп чыгарсыз!

Л. И. Брежневның бу сүзләре төзүчеләрне яңа җиңүләргә рухландыра.

... Кичен БАМ төзелешендә меңләгән утлар балкый. Монда көндез генә түгел, төннәрен дә кызу эш бара.

САМАТ ШАКИР.

**Мәгъсүм Гәрәев**

# ШАМИЛ БАТЫР

ОЧЕРК

**Искиткеч көчле кешеләр.**
**Аларның исеме — көрәшче, һәм**
**Шуның белән бөтенесе әйтелгән.**

**Эрнест Хемингуэй.**



Тренерлар советы ике сәгатьтән артык киңәшә инде. СССР җыелма командасына кандидатларның һәммәсенә аерым тукталалар, аларның халыкара аренада ирешкән уңышлары турында сөйлиләр. Рөстәм Казаков, Валерий Резанцев, Анатолий Рощин, Николай Яковенко, Анатолий Назаренко, Җамал Мегрелишвили исемнәре аталуга, атлетларның бөтен спорт биографияләре күз алдына килеп баса. Икешәр-өчәр мәртәбә Европа һәм дөнья чемпионнары, Мехико Олимпиадасында катнашканнар. Тренерлары аларның Мюнхенда сынатмаячагына ышандыра.

Шамилнең тренеры Николай Николаевич Пархоменконың әллә ни әйтер сүзе юк.

— Хисаметдинов 21 яшендә, ике тапкыр СССР чемпионы. Халыкара ярышларда катнашканы юк.

Олимпиада йөге авырлыгын үз җилкәләрендә татыган тәҗрибәле тренерлар сагаеп кала. Бәхәс башлана.

— Бик яшь. Келәм батырларын күрүгә коелып төшәр.

— Мехикода безнең командада бердәнбер алтын медаль откан Роман Руруаны да онытмаска кирәк.

Шамил дә, Роман да бер категориядә — 68 килограммга кадәр үлчәүдә чыгыш ясый. Романның күкрәге Европа һәм дөнья чемпионатлары алтын медальләре белән тулы. Шундый данлы спортчыны калдырып, дөнья пәһлеваннарын бөтенләй күрмәгән Шамилне алырга ярыймы соң? Сөйләшә, бәхәсләшә торгач, көрәшчеләрне келәмгә чакыралар. Шамил бер ай чамасы гына элек Роман белән Ульяновскида СССР чемпионатында көрәшә. Ул очрашуның нәтиҗәсе илебез беренчелегенең алтын медале язмышын хәл итә. Зур бүләкне баллар исәбе белән Хисаметдинов ала.

Бу юлы келәмгә чыгуның характеры бөтенләй башка: судьялар ролендә — тренерлар советы членнары, залда тамашачылар юк. Келәмнең бер ягында — бай тәҗрибә,

икенчесендә — яшьлек. Шамил дүрт тапкыр дөнья чемпионы, Токио Олимпиадасының — көмеш, Мехиконың алтын призеры белән бил алыша. Ни әйтсәң дә, Роман бик көчле, классик көрәш алымнарын ашыкмыйча, кабаланмыйча гына куллана. Хисаметдинов та чын холкын, бөтен осталыгын, ихтыяр көчен күрсәтә. Титуллы көндәшен баллар исәбе белән тренерларның барысын да ышандырып ота. Икеләнергә урын калмый. Мюнхен Олимпиадасына путевканы аңа бирәләр.

Бу XX Олимпия уеннарының беренче һәм иң кечкенә имтиханы гына әле. Алда яшь көрәшчене драматизм һәм сенсацияләр белән тулы Олимпиада турниры көтә.

Зәп-зәңгәр спорт костюмнарына СССР Дәүләт гербы төшерелгән совет олимпиячеләре Мюнхенга уеннар башланырга бер атна калганда килә. Олимпиада авылы рухына күнегергә кирәк. Шамил чит илдә беренче генә тапкыр. Бавария башкаласының XX Олимпиада үзәге итеп сайлануы миллионнарча кешеләрнең күңелендә каршылыклар дулкыны уятуын Шамил яхшы белә. Мюнхен — сыраханәләр белән тулы шәһәр. Аның «Пена» дип аталган сыраханәсенең залы берьюлы 5 мең кеше сыйдыра. Янында шау-шу.

Җир шарының төрле якларыннан җыелган олимпиячеләрне мондый арзан күңел ачулар кызыксындырмый. Олимпиаданы халыклар арасында дуслык уеннарына әверелдерергә килгән төрле илләр яшьләре мондый «сарайларны» читләтеп үтәләр. Мюнхен — алар өчен эшчеләр шәһәре, пролетариатның данлы традицияләре булган шәһәр.

1919 елда, революцион бәрелешләр чорында, Мюнхенда Бавария совет республикасы игълан ителә. Озак та үтми, кораллы реакция аны тар-мар итеп ташлый.

Хәзер монда реакцион Штраус партиясе — христиан-социалистлар союзы хакимлек итә. Мюнхен промышленностеның хуҗалары илнең төп реакцион көчләрен тәшкил итә. Штраус партиясе Баварияне ультралар, реваншистлар һәм неонацистлардан торган реакциянең сыену урынына әверелдергән.

Әлбәттә, вакыт үтү белән чор үзгәрә бара. Бу көчләр, 50 нче һәм 60 нчы еллар башындагы кебек, Көнбатыш Германия политикасында беренче скрипка ролен үтәмиләр инде. Шулай да аларның чыгышлары, таләпләре һәм пропагандалары Бавария башкаласы тарихындагы кара сәхифәләрне искә төшерергә мәҗбүр итә.

Моның шулай икәнен Шамил үз күзләре белән күрә.

XX Олимпиада иле һәм башкаласы белән якыннанрак танышырга омтылу бик табигый иде. Хисаметдинов, көрәшчеләр командасының комсоргы буларак, Мюнхенда В. И. Ленин исеме белән бәйле урыннарга барырга тәкъдим итә. Ләкин совет олимпиячеләренә тапшырылган юллар белешмәсе китабында Мюнхенда Владимир Ильич яшәгән һәм революцион эш алып барган йорт та, аның урамы да күрсәтелмәгән. Көрәшчеләр Бавария башкаласы үзәгендә олимпиячеләргә хезмәт күрсәтү өчен оештырылган сорау-белешү бюросына киләләр. Монда да истәлекле йортның кайдалыгын әйтә алмыйлар. Безнең делегациягә Мюнхенның эшче-ветераннары ярдәм итә. Алар В. И. Ленин яшәгән йортның төгәл адресын атыйлар: Кайзерштрассе, 46.

Шамил, командадашлары кебек үк, тарихи йорт янына горурлык хисләре белән бара һәм күп нәрсә белеп китә. Прогрессив җәмәгатьчелекнең зур тырышлыгы белән 1968 елның 29 апрелендә 46 нчы йорт янына Мюнхенның йөзләрчә эшчеләре җыелган. Анда Ленин барельефы төшерелгән мемориаль такта ачуга багышланган митинг үткәрелә. Мәрмәр тактаны ясау өчен акчаны эшчеләр җыя. Аның авторы — танылган скульптор Карл Опенридер. Хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы барельефы астына рус һәм немец телләрендә болай дип язылa: «Бу йортта 1900 ел сентябреннән 1901 ел апреленә кадәр Совет дәүләтенә нигез салучы Владимир Ильич Ленин-Ульянов торды.» Шул истәлекле көннән соң монда һәрвакыт кызыл канәфер чәчәкләре балкып тора.

Ләкин хәзер Кайзерштрассedaгы 46 нчы йортта мемориаль такта юк. 1970 елның 9 нчы декабрь таңында фашист элементлары йорт янында бомба шартлаталар...

Истәлекле йорт янына совет олимпиячеләренең килүен белгәч, бирегә эшчеләр җыела. Алар мемориаль тактаны яңадан булдыру өчен Мюнхен властьлары алдына таләп куюларын сөйлиләр...

Тантаналы төстә XX Олимпия уеннары ачыла. Олимпия паркында биш божра үреп төшерелгән ак, яшел һәм зәңгәр флаглар җилферди.

Зарыгып көткән минутлар. Мең тапкыр көчәйтелгән динамиклардан тантананың



*Шамил (сулда) Олимпиада келәмендә.*

башлануы турындагы сигнал яңгырый. Стадион уртасыннан «Альп мөгезе» дип аталган алтышар метрлы агач уен кoралларында уйнап, музыкантлар үтә.

Күптәнге гадәт белән стадионга беренче булып Олимпия уеннары иле вәкилләре— Эллада командасы чыга. Аннан соң латин алфавиты тәртибендә колонна артыннан колонна агыла. Капкадан Советлар иленең зур кызыл флагы күренүгә, тамашачылар СССР олимпиячеләрен алкышларга күмә. Илебезнең иң көчле, иң җитез һәм иң оста егетләре һәм кызлары арасында спорттагы язмышларын Татарстанда башлаган көрәшчеләр Шамил Хисаметдинов һәм Виталий Кузнецов, футболчылар Виктор Колотов һәм Геннадий Еврюжихин да бар.

...«Рингер-Халл» залындагы дүрт келәмдә классик көрәшнең Олимпия турниры гаять кайнар башланып китә. Әле Шамилгә чират җитмәгән. Ярым җиңел үлчәүдә көрәшүче татар егете Рөстәм Казаков беренче очрашуына әзерләнә. Ул дөнья беренчелегенә ике ярышта ике алтын медаль алды, чемпионатның иң оста көрәшчесе дип танылды. Әфганстаннан Алам Мирны Рөстәм уенчык кебек кенә йөртә. Ә алтын медальгә кайвакыт бер мизгел җитеп бетми. Рөстәм булып Рөстәм дә чемпион исеменнән колак кага язды. Болгар Христо Трайков белән очрашуда соңгы ун секундта бер балл оттырды, Трайков җиңде. Калган очрашуларда Рөстәм келәмдә ут уйнатты. Поляк Юзеф Липенны һәм грек Отон Мосхидисны аркаларына салды. Япон Икуа Ямамота һәм венгр Янош Варгны баллар белән отты. Ә Шамил күзәтә дә күзәтә. Рөстәм финалда үзен ничек тотар? Көндәше Германия Федератив Республикасыннан Ханс-Юрген Вайльне трибуналардагы меңләгән ватандашы яклап тора. Тик Вайль келәмдә аркасы белән ятып кала.

Рөстәм Казаков — Олимпиада чемпионы!

Тагын биш минуттан Шамилне келәмгә Олимпиададагы беренче очрашуына чакырачаклар. Ул тренеры Пархоменко белән чишенү бүлмәсенә үтә. Икесе дә борчыла, дулкынлана. Николай Николаевич моны шәкертенә белдерергә теләми, аны тынычландырып:

— Үзеңне тыныч тот. Сак бул, — ди.

Шамил тренерның зәгыйфь тавышыннан һәм бераз калтыранган кулыннан моны үзен тынычландыру өчен әйтүен аңлый.

Шамил үзәк келәмгә атлый. Аягына зәңгәр тасма бәйләр алдыннан ул остазына карады.

— Борчылмагыз, Николай Николаевич.

Күңелендә бер уй: тренерлар, иптәшләр, спорт данын саклауны ышанып тапшырган Ватан алдындагы җаваплылык.

Төрек Сәет Хисирли белән көрәшә башлавының беренче минутларыннан ук Хисаметдинов кабаланмый гына баллар җыя, сабыр гына йөри. Тактика. Беренче әйләнеш— сынау гына. Баллары унсигезгә җитә — бәхәссез өстенлек.

Тамашачылар безнең атлетны ошата, аның келәмгә чыгуын түземсезлек белән көтеп ала. Спортчының елмаюы, тынычлыгы, ачык холкы, көрәш алымнары һәм көче били аларны.

Беренче җиңү егеткә көч һәм рух өсти. Башка очрашуларга ул күтәренке күңел, тагын да күбрәк җаваплылык хисе тоеп чыга. Алтын медальгә төп кандидатларның берсе дөньяның экс-чемпионы румын Симьон Попескуга тын алырга да ирек бирми безнең атлет. Судьялар Румыния спортчысына әкрен көрәшкәне өчен оттырыш яза. Аны җиңү вакытыннан элек яулана. Совет баһадирының көндәшләре сагая төшә: Хисаметдиновны җиңү — авыр эш. Ул бер генә юлны сайлый — алга, һаман алга, һөҗүмгә! Егет шул һөҗүме белән калган җиңүләргә дә ачкыч таба. Мисыр көрәшчесе Габер Мөхәммәтне Хисаметдинов алты минут ярым дигәндә аркасына сала, поляк Анджей Супрон белән очрашуда саф җиңүгә ирешә.

Олимпиадада бишенче очрашуы иң авыр һәм кыен очрашуларның берсе була. Болгар Стоян Апостолов, Шамил кебек, келәмгә бер штраф очко белән чыга. Апостолов, беренче чиратта Хисаметдиновны үзе аша ыргытып, кыйммәтле балл ала. Пархоменконың төсе китеп кала.

— Шүрләп куйдым. Салкын тир бәреп чыкты, — дип искә ала ул минутларны Николай Николаевич. — Шамил борчылуымны сизенде шикелле. Келәм уртасына атылып чыкты да, Апостолов алымын кабатлап, балларны тигезләде.

Хисаметдинов бу очрашу турында үзе болай сөйли:

— Апостолов — кыю көрәшче, техникасы әйбәт. Гонг тавышы яңгырарга минут ярым калгач, алга чыктым. Көчем беткән иде инде: томан эчендә йөргән төсле. Һөҗүмгә ташландым. Күкрәккә күкрәк терәлдек. Ахырда икебез дә егылдык, келәмдә ятабыз. Стоянны күтәреп алып киттеләр, мин ял бүлмәсенә көч-хәл белән генә чыгып җиттем.

Җиңү тренерларның күңелен күтәреп җибәрә. Соңгы очрашуга чыгар алдыннан зур тәҗрибәле Пархоменко:

— Кабынып китәсе түгел. Күп көч түкмә, синңа балларда отыш та җитә, — дип киңәш итә.

Ә Шамил беренче тапкыр остазы белән килешмәскә була.

— Юк, мин итальян Джан-Маттео Ранцины аркасына салырга тиеш. Олимпиадага очраклы рәвештә генә барды дип уйламасыннар...

Һәм Шамил сүзендә тора — Ранцины җиңә.

Мюнхенга җыелган көрәш «йолдызларыннан» 23 кеше арасында Хисаметдинов үз үлчәвендә «дөньяның җыелма командасын» җиңеп, ленинградлы Анатолий Рощин кебек, финалда көрәшмичә үк XX Олимпия уеннары чемпионы дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ш. Хисаметдинов илебез җыелма командасы составына зур җиңүләрсез һәм зур титулларсыз гына, данга күмелмәгән билгесез көрәшче буларак кергән иде. Мюнхендагы уңышыннан соң яшь чемпион коллективта нык һәм хаклы урын ала. Мәскәү өлкәсе спартакчысы 1973 елда бер генә халыкара турнирдан да читтә калмый. Олимпиада бүләге янына Европа чемпионаты, бөтендөнья универсиадасы һәм, ниһаять, дөнья беренчелеге алтын медальләрен өсти. 22 яшендә көрәшчеләрнең дөнья күләмендәге ярышларында Шамил алмаган иң югары бүләк калмый инде.

Җыелма команда ветераны, авыр үлчәүдә Олимпия уеннарының кырык яшьлек чемпионы Анатолий Рощин, келәм белән саубуллашкач, тренерлар уйга калалар: коллективны яңа җиңүләргә кем туплар, остазларның ышанычлы ярдәмчесе кем булыр? Иптәшләре лидерлык роленә иң яшь чемпион Хисаметдиновны тәкъдим итәләр. Көрәшчеләр комсоргы Шамил Валерий Резанцев һәм Рөстәм Казаков белән бергә

ветераннар советы тɵзи. Бу абруйлы совет яшь атлетларга җыелма команданың данлы традицияләрен өйрәнүгә, тәртипне ныгытуга ярдәм итә.

Җыелма команданың баш тренеры В. М. Игуменов:

— Хисаметдинов һәркемгә карата таләпчән һәм гадел. Иптәшләрен беркайчан кыен ситуациядә калдырмас. 1975 елгы дөнья чемпионаты алдыннан ул җәрәхәтләрен дәвалый иде. Ярышларга бара алмады. Үзе урынына Нельсон Давидянны тәкъдим итте. Дөрес күрә белгән. Давидян Польшадан алтын медаль белән кайтты.

Ш. Хисаметдинов, авыру сәбәпле, XXI Олимпия уеннарына бара алмый калды. Әмма тренерлар һәм көрәшчеләр ерак Монреальдә аның ярдәмен тоеп яшәделәр. Олимпиада командасын әзерләгәндә комсорг турыдан-туры катнашкан иде. Безнең классик көрәш осталарыбызның унысы да Канададан Олимпиада бүләкләре белән кайтты. Алексей Шумаков, Виталий Константинов, Сурен Налбандян, Анатолий Быков, Валерий Резанцев, Николай Балбошин, Александр Колчинский — алтын, Владимир Чебоксаров һәм Нельсон Давидян — көмеш, Фәрхәт Мостафин бронза медаль алды. Шамил җыелма командага тәкъдим иткән Нельсон Олимпиадада бер очрашуны да оттырмады. Тик поляк Казимеж Липенның бер штраф очкосы ким булу нәтиҗәсендә Давидян чемпион исемен ала алмады.

Спортта буыннар алышынган кебек, җыелма командада тренерлар да гомергә тормый. Монреальдән соң безнең классик стильдә көрәшүчеләребез халыкара аренада яулаган урыннарын югалта төштеләр. Командага заман рухы кертергә кирәк иде. Бу яңа тренер билгеләү белән эшләнә. Шундый кыен чорда 26 яшьлек Ш. Хисаметдиновка классик көрәшнең СССР җыелма командасы баш тренеры урынын тәкъдим итәләр. Илнең җыелма командасы дилбегәсен гадәттә яшен яшәгән, дөнья күргән аксакалга бирәләр. Өч дистә дә тутырмаган Шамил иң атаклы, үзеннән өч-дүрт яшькә олырак көрәшчеләрнең остазы була алырмы? СССРның зур спорт тарихында мондый яшь баш тренерның булганы юк иде. Команданы туплый алырмы? Хисаметдинов алдына тагын әллә никадәр сорау килеп баса. Атаклы хоккейчылар — Евгений һәм Борис Майоровлар, Вячеслав Старшинов үзләре чыгыш ясаган «Спартак»та уенны җайга сала алмадылар. Өлкән тренер булудан баш тарттылар. Икеләнеп торды-торды да — тәвәккәлләде Шамил. Әмма аның эшләре дә ал да гөл китмәде. 1977 елда, баш тренер булып эшли башлавының беренче елында, совет көрәшчеләре Ослода Европа чемпионатында оттыралар, командалар арасында чемпион исемен ала алмыйлар.

Хисаметдинов үзе сайлаган юлдан, сынаулар юлыннан читкә китәргә ярамавын, көрәшчеләр дружинасына яңа яшь көчләр тартырга кирәклеген яхшы аңлый. Мәскәү Олимпиадасына әзерлек барышының дөреслеген тормышта сынау зарури. Осло чемпионаты тәмамлангач, безнең тренер янына Швециядән, Болгариядән, Румыниядән, Чехословакиядән коллегалары килә. Алар аптырашта калган. «Классик көрәшне хәзер ничек оештырырга? Кая тәгәри ул? Кемнән үрнәк алырга?» Хисаметдиновка шундый сораулар ява. Чыннан да, Ослода сәер хәл хөкем сөрә: 260 очрашуның 107 сендә судьялар, пассивлык күрсәткән өчен, берәр көрәшчене ярышта сызып ташлыйлар. Классик көрәш көч һәм алымнарсыз була бара. Әмма илебез җыелма командасы тренеры үз позициясеннән чигенми, көрәш техникасын камилләштерү өстендә эшли. Бер ел дигәндә моның уңай нәтиҗәләре Мехикода дөнья чемпионатында ачык күренә. 1978 елның августында Ш. Хисаметдинов шәкертләренең унысы да Мексика башкаласында почет пьедесталына күтәрелә. Аларга алты алтын, бер көмеш һәм өч бронза медаль тапшырыла. Жюри баш тренер Шамил Хисаметдиновны да пьедесталга чакыра. Аның кулына команда беренчелегендә откан өчен көрәшчеләрнең бронзадан коелган фигуралары сурәтләнгән гаять зур приз тоттыралар. Шул тантаналы минутларда журналистларга биргән интервьюсында Шамил болай ди:

— Европа чемпионатында оттыргач, өметне өзмәдек. Без ялгышларыбызны искә алдык, дөнья беренчелегенә әзерлекне элек төзегән план нигезендә дәвам иттек. Җиңү — сайлаган юлыбызның дөреслеген раслаучы дәлил.

Мәскәү Олимпиадасы киләменә чыгачак совет олимпиячеләренең рухы бай, көчле булырга тиеш. Ш. Хисаметдиновка бу хакыйкать бик яхшы билгеле. Ул җыелма командага ярдәмчеләре итеп Мюнхен Олимпиадасындагы дуслары Рөстәм Казаков, Николай Яковенко һәм Анатолий Назаренконы чакыра. Көрәшчеләр сайлаганда

элекке олимпиячеләрнең фикерләре тәңгәл килә. Ш. Хисаметдинов җитәкчелегендә тренерлар командага үзләре кебек көчле ихтыярлы атлетларны сайларга тырышалар.

Алма-Атадан Шамил Сериков, Ростовтан Борис Краморенко һәм көрәш биографиясен Бакуда башлаган Гариф Нифтулаев та — Хисаметдинов ачышлары. Аларның өчесен дә урта кул көрәшчеләр рәтендә йөртәләр. Баш тренер һич икеләнмичә егетләргә Мехикода дөнья чемпионатында көчләрен сынарга, сәләтләрен һәм характерларын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Ялгышмый. Өчесе дә остазларын чемпион исеменә лаек булып куандыралар. Өстәвенә Гариф дөнья чемпионатының иң техникалы көрәшчесенә билгеләнгән махсус призга ия була.

Тренерны туры сүзле, гадел булуы өчен яраталар. Быел март аенда Минскида Иван Поддубный турниры була. Бу ярышларны классик көрәш буенча дөньяның рәсми булмаган чемпионаты дип йөртәләр. Чөнки анда планетаның иң көчле атлетлары җыела. Мәскәү Олимпиадасына әзерлекнең чираттагы этабы булган бу турнирга безнең атаклы көрәшчеләребез дә, яшьләр дә чакырыла. Арада Казаннан Европа беренчелегенең көмеш призеры халыкара класслы мастер Анатолий Бозин да бар иде. Шамил якташының чыгышын җентекләп күзәтә. Толя Минскида призерлар сафына чыкмаса да, белгечләрдә әйбәт тәэсир калдыра.

— Бозин үлчәвендә (48 килограмм) командада лидер юк, — дип сөйли соңыннан атказанган спорт мастеры Хисаметдинов. — Без Казан егетенә ышаныч баглыйбыз, Европа чемпионатына да алып бардык. Континент беренчелегенә ярышларга тагын барачак. Толя, хәзер Олимпиада-80 командасына кандидат буларак, кара эшне гаять зур күләмдә башкара. Аңа әлегә тизлек, һөҗүмнәрнең кискенлеге җитеп бетми. Хәзер аның белән җыелма командадагы минем ярдәмчеләремнең берсе — атказанган спорт мастеры Владимир Зубков шөгыльләнә. Олимпия уеннарына кадәр Толяга үзен күрсәтү өчен вакыт та, халыкара турнирлар да җитәрлек. Аны Болгариядә, Германия Федератив Республикасында һәм Финляндиядә үтәчәк ярышларда үз үлчәвендә беренче номер итеп куябыз.

Хисаметдиновның ялкауларны җене сөйми. Ул үзе яшьтән үк җиңүнең гаять зур физик көч, хезмәт кую нәтиҗәсендә генә яулануын аңлап үсә. Көрәш талантының айлар, еллар буе келәмгә ябышып ятканда гына тулысынча ачылуын яхшы белә иде. Шуның нәтиҗәсендә үзен, тренерын, совет спортын данга күмде.

— һөҗүм, һөҗүм һәм җиңү, тик җиңү генә! Көрәшчеләр күп, ә алтын медаль бер генә, — дия иде ул ярышларга керешкәнче.

Иван Поддубный мемориалы тәмамлангач, баш тренер ярышларга йомгак ясый. Ул элек үзе чыгыш ясаган үлчәүдә Монреаль Олимпиадасы чемпионы Сурен Налбандяннан һич канәгать түгел. Шамил, Мюнхенда алтын медаль алганнан соң, келәмдә бер мәртәбә дә җиңелүне белмәде. Алтын медальләрнең барысын да алып бетерде. Суренга нәрсә булган соң? Элекке дан белән алдырмакчы була. Көндәшләр йоклап ятмый, һаман көрәшә, өйрәнә тора.

— Налбандян талантлы атлетны югары класслы көрәшче дәрәҗәсенә зур хезмәт кенә күтәрүен оныткан. Болай булса, аңа җыелма командада да урын юк, — ди Хисаметдинов.

Бу Сурен өчен ачы сабак була. Ул хәзер көне-төне келәмдә. Бөтен көчен куеп, үз үлчәвендә элекке данын, лидерлык ролен кайтару өчен тырыша.

— Менә шундый киң күңелле, туры сүзле ул безнең якташыбыз — Чүпрәле районының Каракитә авылында туган Шамил батыр — чемпион, тренер. Якташыбыз кешеләр йөрәгенә үтеп керә, ачкыч таба белә. Келәмгә чыгучы шәкертләренә аның теләге бер генә һәм ул бик изге: бер вакытта да үзеңне көндәшләреңнән түбән куйма, көчеңә ышан! Шул чакта гына бәхәссез җиңүгә ирешерсең. Аның бүгенге яшь шәкертләре, шушы киңәшне күңел түренә салып, Олимпиада-80 гә яңа көч белән, осталыкларына һәм мөмкинлекләренә тулы ышанган хәлдә әзерләнәләр. Баш тренер Шамил Хисаметдинов классик көрәш баһадирларыбызның Мәскәү келәмендә совет спортын яңа баскычка күтәрүдә һәм данга күмүдә көчләрен кызганмаячакларына тулысынча ышана.

Нияз Акмалов

# ӘГӘР ЫШАНСАГЫЗ...

хикәя



*Туган елым — 1954. Туган ягым — Сарман районының Каран авылы.*
*1971—76 елларда Казан университетында укыдым. Аннан соң Балык Бистәсе районында радиотапшырулар редакторы булып эшләдем. Хәзер Казанда яшим.*



Ул ялгызы өстәл янында утыра. Иңенә салган юка мамык шәле каядыр кырыйга, урындыкка шуып төшкән. Талчыккан йөзендә тетрәнү, газап катыш аңлашылмас бер шатлык сизелә... Алдында — әле генә ачылган хат. Ул инде аны укыган, ул аны кат-кат укый...

«...Мин хәзер уйлыйм-уйлыйм да, искә төшеп әрним. Беркайчан да мондый халәттә калганым юк иде. Бу беренче тапкыр. Сез бәлки күп нәрсәне оныткансыздыр... Юк, юк, Хәлимә апа, онытмагансыз. Мин беләм. Тик минем бүген сез белмәгәннәрне генә түгел, сезгә билгеле булганнарны да язасым килә. Әйтәм бит, миндә беркайчан да мондый теләк туганы юк иде... Хәтерлисезме, мине башта ук «бур» дип атап йөрттеләр. Мине беркем дә яратмады, күрәлмыйлар иде мине. Сез хәтерлисездер, Сәриянең буяу карандашларын миннән табып алгач, класста минем белән әллә никадәр сөйләшми йөрделәр. Бу бит бишенчедә укыганда иде. Сез ул чакта мине оялтырга тырышкан идегез. Ә миңа нәрсә, мин ул чакта борын очына да элмәдем. Ә хәзер менә уйлыйм да, гаҗәпкә калам. Нигә соң шулай булган икән? Каян килгән ул гадәт? Әти-

дән көчкәнме, дисәм... Бәләкәй чакта аңа ияреп эшкә йөри идем. Ат ярата идем бит мин. Фермадан кайтканда, әз-мәз генә силосын да, печәнен дә әләктергәли идек... Урлашу түгел иде ул. Болай гына... Атлы эштә йөргәннәрнең гадәтенә кергән... Белмим, Хәлимә апа. Хуҗасыз әйбер күрсәм, кулым кычыта башлый иде. Алдың — кесәгә салдың...

Ә җиденчедә укыганда, химия кабинетыннан микроскоп югалгач, мине педсоветта тикшерделәр. Хәтерлисезме, безнең класста Нәгыйм исемле бер малай бар иде. Микроскопның кемдә икәнен шул җиткерде бит. Ул чакта мине хезмәт белән төзәтү колониясенә җибәргә уйладылар. Бөтенесе сүкте, тиргәде. Әллә кайчан булган хәлләрне казып чыгарып миңа мәктәптә урын юк икәнне кабатладылар. Ачу килде ул вакытта. Җитмәсә, шул ук кичне әти дә тотып ярды. Җибәрсәләр, бик әйбәт, дигән идем. Барысына да әзер идем. Тик ул вакытта сез мине алып калгансыз, мәктәптә калдыруларын сорагансыз. Ә беләсезме, Хәлимә апа, сез үзегез турында кайгыртып, класс җитәкчесе буларак үз абруегызны саклап калу өчен тырышкансыз дип уйладым мин ул вакытта. Шуңа күрә, дәрестән соң сөйләшкән чакларыгызда да, башны иеп, эчтән генә: «Хәтәр инде, яклаучы кеше табылган, имеш...» — дип көлеп утыра идем...»

Хәлимә ханым, ниндидер бик тә әһәмиятле сүзне төшереп калдырудан курыккандай, хатның һәр җөмләсен җентекләп-җентекләп, кат-кат укыды. Әйтерсең ул кайчандыр үзе укыткан баланың дәфтәрен тикшерә, хәреф хаталарын барлый... Юк, юк, бүген аның күзләре кәгазьдәге хәреф хаталарына түгел, ә бәлки шушы хат артында торган кешегә төбәлгән. Әйтерсең ул бүген, кайчандыр үзенә бик таныш булган бер нәрсәне озак вакытлар күрми торганнан соң кулына алган да, андагы таныш чаткыларны тагын бер кат барлый, өйрәнә; әйтерсең ул күптән инде көткән, эзләгән, барлыгына ышанган, әмма моңарчы, никтер, һич кенә дә очратмаган сыйфатларны тапкан.

Хат юлларына текәлгән күзләргә, акрынлап-акрынлап, кайнар яшь тулды. Бу яшь тамчылары, нәкъ моннан алты ел элек булгандагы кебек, ачы, әрнүле, җан түреннән иде.

...Ул көнне педсовет утырышында аны принципсызлыкта гаепләделәр. Ә ул «мәктәп йөзенә пычрак яккан каракның», «ата хулиганның» кыланышларын бик дөрес фаш иткән укытучылар янында тыныч булырга, бирешмәскә тырышып, һаман үз фикерендә кала бирде. Аңлатты, ышандырды да кебек. Хәер, барысын да түгел, билгеле. Мәктәпкә күптән түгел генә килгән яшь завуч, һич килешмичә, кызып-кызып:

— Сез нәрсәгә ышанасыз, Хәлимә Камаловна? Ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән кертмәкче буласызмы? Хәзер заманы бүтән, аңлыйсызмы, бүтән. Ә сездә балаларга карата искергән фикер, ниндидер урынсыз фанатизм бар! Әллә шундый ук хәл кабатланмас дип ышанасызмы?!.— дигән иде.

Хәлимә ханым ни дип тә җавап бирергә белмәде. Нәрсә дисен? Юк, фикерем искермәгән дисенме? Алтынчы дистәгә якынлашып барган кеше, бәлки, чыннан да, искергәндер?! Шул фикердән аның тыны кысылды. Күкрәгене, каяндыр эчтән, тирәннән, ниндидер бер бик тә каты әйбер басты. Бар хәлен, көчен җыеп:

— Юк, юк!.. Мин тагын бер кат үтенәм... Фәнилне минем шәхси җаваплылыкка калдырыгыз...— диде һәм бүлмәдән чыгып ук китте. Инде күптән бушап калган класска кергәч, көчкә-көчкә тыеп түзгән күз яшьләренә ирек куйды. Өстәлгә капланып, хәлсез иңнәре белән сулкылдаган вакытта ялгыз, бик тә ялгыз тойды ул үзен. Әй шунда ире — Хәбире исән булса... Аның куллары ирексездән, өстәл өстендәге китаплар арасыннан капшап, Хәбирнең бүләген — аның төсе итеп

сакланган сәгатьне эзләде... Ләкин сәгать юк иде. Ул кинәт сискәнеп китте. Сулкылдаудан туктады. Кесәләрен капшады, өстәлне кат-кат актарды — сәгать юк иде. Яшь төере, тагын да зуррак бер әрнү белән, тамагына утырды. Ачы иде, бик тә ачы иде ул яшь...

Хәлимә ханым, тынычланырга теләп, хатны читкәрәк этте, күзләрен сөртте; шуып төшкән шәлен иңенә ябып, урыныннан торды. Тар бүлмәдә куера барган караңгылыктан тәрәз каршына килде. Тышта яңгыр иртәдән бирле сибәли иде. Нәкъ менә шундый салкын, яңгырлы көндә, пычрак ерып, Фәнилгә посылка салырга дип, почтага барган иде ул. Нәкъ шундый көндә. Һәм нәкъ шундый ук көндә аңа Фәнил Хаҗиевның төрмәгә эләгүе турында әйттеләр. Һәркем, мәгънәле елмаеп, аны үчекли кебек иде. «Котлыйм, Хәлимә Камаловна, җимешегез оҗмахка кергән!» — мәктәп завучының сүзләре шул көнне җан түрендә ятып калды. Нәкъ менә шундый яңгырлы көндә.

Ул тәрәзәдән күзләрен алды; нәрсәнедер онытып калдырган шикелле, ашыгып-ашыгып өстәл янына килде. Әлеге хат ниндидер аңлашылмас бер көч белән аны үзенә тарта иде.

«...ә теге сәгатегезне юри кесәгә салып киттем. Сез аны, китаплар белән бергә, өстәл өстендә калдырган идегез. Соңыннан гына сезнең өчен аның нинди кадерле истәлек икәнен ишеттем мин. Ләкин кире бирергә курыктым. Дөресрәге, оялдым. Мин аны кая куярга белмәдем. Аннан буага ташладым. Сәгатьне мин алганны сизгән идегез бугай. Тик ул турыда үземә дә, бүтәннәргә дә бер сүз әйтмәдегез. Мине колониягә җибәрүләреннән курыктыгыз, дип уйладым мин.

Сигезенче класстан мине, үзегез дә беләсез, этеп-төртеп чыгардылар. Әллә ни юньләп укыганым да булмады. Хәер, алай дисәң, сез мине урта белем алырга, тугызынчы класска барырга үгетләп тә караган идегез. Шул чакны: «Безнең кебек малайлар кайда да югалмый ул!» — дип кенә җавап биргән идем. Шуннан тоттым да шәһәргә эшкә киттем. Өйдән чыгып югаласы килде. Туйдырганнар иде алар: әтинең — эчмәгән көне, әнинең тиргәүдән башка эше юк...

...Ә төрмәгә ни өчен утырганны беләсез инде. Ул турыда кабатлап та торасы килми. Бер караганда гел юк өчен утырдым кебек. Әни каргап хат язды: «Бүтән син минем балам түгел, син миңа әни дип дәшәсе булма!» — дигән. Хәер, аның шулай дип язуына гаҗәпләнмәдем дә. Ә менә сездән хат килгәч... гаҗәпләндем, Хәлимә апа. Сез анда хәлемне сорашып: «Ни кирәк, ни җибәрим? Түз, ничек тә үтәр, иреккә чыккач ныклап уйларсың, кешелегеңне югалтма!» —дип язган идегез. Тик ул чакта, Хәлимә апа, миңа барыбер иде. Сезнең сүзләрегезне дә: «Әһә, барып эләктеңме, әйткән сүзләрем дөрескә чыктымы?» — дип әйтүегез итеп аңладым. Шуңа күрә язган хатларыгызга да, җибәргән посылкаларыгызга да җавап бирмәдем.

Мине әйбәт эшләгән, тәртипле яшәгән өчен сроктан алда чыгардылар. Эш урыны тәкъдим иттеләр. Эшкә урнаштым да, авылга кайтып килер өчен ял бирүләрен сорадым. Әти-әнине, башкаларны күрәсе килүдән түгел, авылны күрәсе килде. Авылны бик сагынган идем.

Әти белән әни үзләре дә әллә ни якты чырай белән каршыламады. Әллә ничек чит идек, ят идек без. Элекке яшьтәшләр дә ачылып сөйләшмәде. Хәер, үземнең дә авылда кеше күзенә күренеп йөрисем килмәде. Ә менә сез миңа гел көтмәгәндә очрадыгыз бит, Хәлимә апа! Башны иеп, күрмәмешкә салышып үтәргә дә уйлаган идем, үзегез туктаттыгыз. Туктаттыгыз, кочаклап алдыгыз сез мине. Хәзер дә аңламыйм: ни өчен шулай якын иттегез, ни өчен башкалар кебек йөз чөермәдегез?! Сезгә нинди яхшылыгым тиде, кем идем, кем идем мин сезнең өчен, Хәлимә апа? Кочаклап алып, өегезгә чакырдыгыз. Әллә ничек булып китте миңа. Керергә дә, кермәскә дә белмәдем. Сез мине җитәкләп алып киттегез.

Бергәләп сездә чәй эчкән идек. Гел үткәннәрне искә төшердегез, классташлар турында сөйләдегез. Сез укыткан балаларның рәсемнәрен туплаган альбомны карадык. Ә анда минем дә, минем дә рәсемем бар иде бит! Күпләр үз хәтереннән сызып ташлаган бер вакытта, сез мине ничек үз укучыларыгыз исемлегеннән сызмадыгыз, Хәлимә апа?!. Сез безнең һәрберебезне хәтердә саклагансыз, артыннан күзәтеп торгансыз. Кемнең кайда яшәвен, кем булып эшләвен — барысын да беләсез. Әлеге альбомда һәр рәсем астына исемнәре, кайда, кем булып эшләүләре язылган иде. Ә беләсезме, Хәлимә апа, мин үз рәсемем астында шундый язуның юклыгын күрдем. Авыр булып китте миңа. Аңлыйм: сез бит анда минем турыда «төрмәдә» дип язып куя алмагансыз... Сез безне хәтердә саклагансыз, һәрберебезне күзәтеп торгансыз. Кем идек, кем идек без сезнең өчен, Хәлимә апа?!.

Гармунда уйнавымны да онытмагансыз! Сез бит ул чакта: «Уйна әле бер, Фәнил! Күптән тыңлаганым юк», — дип, ирегездән калган гармунны кулыма тоттырдыгыз. Мин, үзем уйныйм, үзем сезгә карыйм, Хәлимә апа. Шушы биш-алты ел эчендә шактый картайган икәнсез. Үзем уйнадым ул чакта, Хәлимә апа, тамак төбендә төер иде. Күздән яшьләрем тәгәрәп төшәр кебек иде.

Тизрәк китәргә ашыктым. Авыр иде миңа. Рәхмәт әйтергә дә онытып, артымнан кемдер куып килгәндәй, бәрелеп-томырылып чыгып йөгердем. Сезнең яннан киткәч, бәрәңге бакчасына кайтып егылдым да, туйганчы бер үксеп еладым, Хәлимә апа!..

Сез мине аңларсыз, сез мине аңлыйсыз. Мин үземдә гомер булмаганча бер яңарыш сизәм. Беренче тапкыр тоям мин мондый хәлне... Авылдан киткәч, үз-үземне белештермичә йөрдем. Тик эштә мин чын күңелдән тырыштым. Сез миңа ышангансыз, ышанып яшәгәнсез. Минем сезнең ышанычыгызны аклыйсым килә, ышанычыгыз дөрес булуын башкаларга исбатлыйсым килә!

Бик күп яздым, Хәлимә апа, беркайчан да болай озын язганым юк иде. Минем сезгә барысын да сөйлисем килгән иде. Юньләп аңлата да алмадым бугай инде... Юк, бу минем сездән гафу үтенүем түгел, кичерегез дип тә әйтә алмыйм мин сезгә. Тик шуны гына әйтәм: бүген беренче хезмәт хакын алдым, шушы хат белән бергә җибәргән сәгатьне бернинди карышусыз кабул итеп алыгыз, Хәлимә апа!?. Мин үтенәм, алыгыз: бу минем сезгә бүләгем, бары тик бүләгем.

Тагын шуны сорыйм: теге альбомда минем рәсем астына «Фәнил Хаҗиев, төзүче» дип язып куегыз, әгәр ышансагыз, әгәр миңа ышансагыз, шулай дип язып куегыз, Хәлимә апа?!. Мин сүзне бары тик сезгә генә бирергә телим... мин аклармын...»

Күзлек пыялалары, яңгырга чыланган тәрәзә кебек, юешләнде. Дулкынланудан калтыранган куллары белән Хәлимә ханым күзлеген салды, аннан, үрелеп, каршыдагы китап шүрлегеннән калын альбомнарның берсен алды. Кабалана-кабалана, альбомның битләрен актарып, Фәнилнең рәсемен эзләп тапты.

Фәрваз Миңнуллин

# ЯШЬЛЕКНЕ САГЫНУ

*М. Мәһдиевнең иҗат портретына эскизлар*

Без Мөхәммәт белән күп еллар буе аерылмас дуслар булып яшәдек. Табыннар һәм танышлар уртак иде, серләр уртак булды. Миңа аның бөтен тормышы таныш, туганнары, нәсел-нәсәбе таныш. Ничек әдәбиятка килгәне билгеле. Күпчелек әсәрләренең нинди шартларда язылганын беләм, ул әсәрләрдәге геройларның тормыштагы өлгеләрен, аерым эпизодларын, ситуацияләрен беләм.

Әмма иң кирәклесен, иң әһәмиятлесен белмим: әнә шул миңа таныш, мин белгән материалдан ул ничек итеп тормышның үзеннән дә чынрак әсәрләр яза ала? Язучы буларак, Мөхәммәт Мәһдиев талантының сере нәрсәдә? Аның иҗатының әсәрдән-әсәргә күчеп килгән төп хасияте, төп үзенчәлеге нидән гыйбарәт?.. Шул сорауларга җавап табарга, ачыклык кертергә тырышып, әсәрләрен кат-кат укып караганым бар. Тик рәтле-башлы җавап кына таба алганым юк. Күрәсең, әдәби талант шундый серле нәрсәдер инде. Күрәсең, аның сере еллар буе, гомер буе ачыла барырга тиештер...

*
* *

Язучыларны без шартлы рәвештә төрле буыннарга бүлеп йөртәбез. Өлкән буын, урта буын дибез, яшьләр дибез. Әлеге бүленеш буенча М. Мәһдиев урта буынга керә. Ул — яшьлекләре авыр сугыш елларына туры килгән буынның, 11—12 яшьтән тырма тырмалап, сука сукалап үскән буынның, әдәбиятка тормышның үзеннән килгән буынның бер вәкиле. Күпчелек замандашлары кебек, ул да күбрәк сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы колхоз тормышы, авыл кешеләре турында яза. Ләкин замандашларының берсенә дә охшамаган, берсенә дә иярми, берсен дә кабатламый.

Алардан аермалы буларак, әдәбият мәйданына ул соңгарак калып, алтмышынчы елларның ахырларында гына килде. Аның каравы, «Без — кырык беренче ел балалары» исемле беренче әсәре белән үк үзен өлгергән язучы итеп танытты.

Хәтерлисездер, повестьта Ватан сугышы елларындагы педучилище тормышы сурәтләнә. Авыл малайларының дөньяга күзләре ачыла баруы турында ул әсәр. Бер тын алуда, бер сулыш белән укыла торган бу җыйнак повестьны мин җиргә сибелгән бер уч энҗе белән чагыштырыр идем. Әсәр берсеннән-берсе кызыклы эпизодлары, бик тә үзенчәлекле геройлары белән хәтергә сеңеп кала.

Менә кайчан гына колхоз басуларында көлтә керткән, бәрәңге ташыган авыл малайлары. Җәй буе борчак, яңа бәрәңге, төтен тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп, тәннәре ныгып беткән — бүген шул көчне кая куярга белмиләр. Кичә кичен генә мунча кергәнне сылтау итеп, бүген битен дә юмаган унбиш-уналты яшьлек малайлар педучилище коридорында колхоз тузанын кагалар. Менә коридорның бу почмагында Түбән Кенә малайлары.



Барысы да чиста ыштырдан, яңа чабатадан. Менә зәңгәр сырмалар кигән Карадуган малайлары — һәммәсе кишер ашый. Мөрәле малайлары кесәләрен әйләндереп бер төрерлек тәмәке эзлиләр, шул арада ду килеп бәргәләшеп алалар. Чабыш атлары кебек барысының да борын тишекләре киңәйгән... Менә «натуралист» Әркәшәләр, «шовинист» Әлтафилар. Менә шул юньсез малайларга «ребятки» дип үз итеп, яратып дәшүче Хәлил Фәтхиевичлар, хуш исле тәмәке өчен үлә торган география укытучылары, ата кара тараканның кан әйләнешен сөйләтеп, балаларның җелегенә төшә торган зоология укытучылары...

Бер кайчан да истән чыкмый торган мондый эпизодларны, бер кайчан да онытылмый торган мондый геройларны күп санарга була. Кызыклы ситуация һәм көлке эпизодлар эзләп табу, колоритлы образлар иҗат итү — М. Мәһдиев талантының бер үзенчәлеге дияргә була.

Бер уйласаң, «Без — кырык беренче ел балалары» повестенда язучы көлке артыннан куу, кызыклы ситуацияләр эзләү белән мавыга кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай тоела. Әсәрнең ахыры якынлашкан саен, вакыйгалар кискенләшә, драматик төс ала, ниндидер сагыш, моңсулык, якты моң көчәя бара. «Телеграф чыбыклары сызгыралар...» дигән соңгы бүлекчәдә ул үзенең иң югары ноктасына күтәрелә. Ихтыярсыздан кабат алда сөйләнгән вакыйгаларга әйләнеп кайтасың. Вакыйгалар да, геройлар да, өрфия шәл белән төренгәндәй, моңсулык пәрдәсе белән өртеләләр. Язучы үзенең һәм яшьтәшләренең авыр елларга туры килгән, әмма мәгънәле узган яшьлеген сагына. «Без — кырык беренче ел балалары» — яшь аралаш көлеп язылган, көлке белән фаҗига чиратлашып килгән әсәр, үзгә бер сагыш, якты моң белән сугарылган әсәр. Мин аны яшьлекне сагыну җыры дип атар идем.

Яшьлекне сагыну... Сагыну, сөену, өмет... Бу сыйфат Мөхәммәт Мәһдиевнең барлык әсәрләренә хас диярлек. Хикәяләренә дә, «Каз канатлары» белән «Ут чәчәге»нә дә, «Кеше китә — җыры кала» повестена да һәм, һичшиксез, «Фронтовиклар» романына да. Ихтимал, шунсыз чын әсәр язылмыйдыр да.

«Фронтовиклар» — киң колачлы, күп планлы роман. Әсәрне укыганда без Акбалык мәктәбенең укучылары, укытучылары белән танышабыз. Безнең алда мәктәп тормышы, андагы кешеләр ачыла, аларның шатлык-кайгылары, борчу-мәшәкатьләре, җаннары ачыла. Роман торган саен киңәя, тармаклана бара. Мәктәп тормышыннан авыл, колхоз хәлләренә күчәбез. Бераздан әсәргә район, республика күләмендәге вакыйгалар, ахырга таба бөтен ил күләмендәге вакыйгалар килеп керә. Вакыйгаларның кысалары киңәйгән саен, кешеләр арта, хәл итәргә тиешле мәсьәләләр күбәя... Бу романга авторның гомер буе җыйган күзәтүләре, аз-азлап туплаган ачышлары кергән. Монда аның тормыш, кеше гомеренең мәгънәсе турындагы уйланулары, теләк-омтылышлары, идеаллары, яшьлекне сагынуы...

Тыштан караганда әсәрдә буйдан-буйга сузылып килгән тоташ конфликт та, андагы геройларны һәм вакыйгаларны, эреле-ваклы мәсьәләләрне үз тирәсенә җыйнап торырлык үзәк ситуация дә юк кебек. Ләкин күзгә күренми торган ниндидер җепләр, ниндидер бер хис әсәрне тотып тора, андагы вакыйгаларны бер төенгә бәйли,

Ниндидер бер эчке көч безне гел киеренкелектә тота. Әлеге киеренкелек һаман үсә, көчәя бара. Нинди хис ул, нинди җепләр алар? Бер сүз белән әйтүе бик кыен...

Ләкин ул хис бар. Әсәрне бөтен итә торган, аны сәнгать әсәре итә торган шул хис булмаса, роман таркала башлар, кызыклы эпизодлар җыелмасына әйләнеп калыр иде. «Каз канатлары»н укыганда шундый хиснең җитәрлек булмавы урыны-урыны белән үзен шактый нык сиздерә...

Язучы иҗатының «Без — кырык беренче ел балалары» повестенда ук күзгә ташланган сыйфатлары «Фронтовиклар» романында тагын да үсә, тагын да камилләшә төшкән. Автор геройдан-геройга, темадан-темага, чордан-чорга, бер төрле хистән икенче төрле хискә, бер настроениедән икенче настроениегә бик җиңел, бик табигый күчә. Кырыс реализм юмор белән, лиризм сатира белән чиратлаша, ул да түгел, патетик тасвир алгы планга чыга. Стильдәге шушы күп төслелек, күп тавышлылык романга үзгә бер ямь, үзенчәлекле яңгыраш бирә. Музыкадагы, сынлы сәнгать әсәрендәге кебек.

М. Мәһдиев үзенчәлекле бер деталь, бер-ике отышлы эпизод аша геройның тулы характерын, бөтен тормышын күз алдына бастыра ала. Ул бер битлек, бит ярымлык мәйданга зур бер хикәялек материал сыйдыра.

«Рушадның әнисе мәктәптә егерме биш ел чамасы укытты. Рушад кечкенәдән ишетеп үсте: әллә нинди тәҗрибәле укытучылар да дәресләренә чит бер кеше кереп утырса каушыйлар, ди. Инспектор да булмасын, хет берәр баланың ата-анасы гына кереп утырсын. Гомумән, дәресеңә кереп утырам дигән кешене укытучы халкы бер дә яратмый. Бер төрлесе дәрестә катыша, укучыга сораулар бирә — укытучыны тәмам эштән чыгара. Икенче бер төрлесе берөзлексез язып утыра. Нәрсә яза икән? Тагын нинди сүзне ялгыш әйттем икән? Бер төрле инспектор дәрестән чыккач синең дәресеңә озаклап анализ ясап үзеңә үтә. Менә син фәлән сүзне әйтеп күрсәткәндә тавышың болайрак булды, алай түгел, менә болай ул, ди. Кыскасы, җаныңны каһәрли. Укытучы укытып картаймый, инспекторның дәрескә керүеннән картая».

**Укытучы укытып картаймый, инспекторның дәрескә керүеннән картая...** Шушы бер җөмләдә укытучы хезмәтенең асылы, бөтен авырлыгы ачып бирелгән. М. Мәһдиев гел шулай яза. Тормыштагы берәр гыйбрәтле хәл турында сөйләп килә-килә дә, ахырдан афоризм булып китәрлек йомгак ясап, нәтиҗә чыгарып куя.

Клубта шау-шулы җыелыш бара. Сабир Ишмуратович белән Бибисара күпме генә тырышып карамасыннар, колхозчыларны күндерә алмыйлар — халык Сәмигуллинны укырга җибәрергә теләми. Председатель булырга лаек кеше түгел, салырга ярата, хатын-кыз белән чуала диләр. Берсе дә белеп әйтелгән сүз түгел, югыйсә. Нишлисең, үз итмиләр, өнәмиләр...

Иптәш Сәмигуллин әнә шул хәлгә хурланып, алай гына түгел, җәберсенеп үк өенә кайтып китә.

«Сәмигуллин өенә арт урамнан бата-чума кайтты. Күптәннән авызга алмаган нәрсә аның эчәгеләрен лезвие белән турагандай итә иде.

Баскычта кар шыгырдауга хатыны аңа ишек ачты. Ичмасам, биләмгә дә чыгып китмәгән! **Начар кәеф белән кайтып кергәндә яратмаган хатыны ишектә каршылаган ирдән дә бәхетсез ир юктыр».**

Бу соңгысы бер Сәмигуллинга гына карамый, аның кебек үк бәхетсез барлык ирләргә карый. М. Мәһдиев әсәрләре тагы әнә шундый соң чиккәчә гомумиләштерелгән нәтиҗә — резюмелары белән истә кала.

Образлар иҗат иткәндә дә шундыйрак хәл күзәтелә. Кызыклы бер-ике эпизод, үзенчәлекле бер деталь — синең карашыңда инде тотып, капшап карарлык дәрәҗәдә тере, җанлы образ басып тора. «Каз канатлары»н искә төшерегез. Шул өсәрдән ат җене кагылган Шәйдулланы — матур солдат формасын, хром итекләрен һәм ак перчаткаларын күрсәтер өчен, кышкы салкында егерме чакрым араны ялан өс кайткан Шәйдулланы алыгыз, колхозга килгән олы кунакларны гына чәйгә дәшә торган һәм һәр кунакны: «Эчеп җибәрегез, сездә юк ул», дип сыйлый торган Галләмгали абзыйны, я булмаса шул ук Галләмгали абзыйның «эштие суынган» Зәмзәмбикәсенә өйләнгәненә хурланып, җанын кая куярга белмичә бәргәләнгән Миңнулланы алыгыз...

Андый образлар «Фронтовиклар» романында да күп: «Иптәшләр, бу — минем

гаеп», дип мәктәптәге бөтен җитешсезлекләрне үз өстенә алып килә торган акыллы һәм хәйләкәр директор Сабир Ишмуратович; аның матур итеп авырый, «грандиозно» итеп егыла белә торган хатыны — тавышы дөньядагы бер генә гармунга туры килмәсә дә, җырчы данын күтәреп йөргән чибәр Гөлчирә; ике сүзнең берендә «бәлки, мин ялгышамдыр...» дип кабатларга ярата торган надан Хушият; мут күзле Мәсрүрә; акыллы һәм әдәпле Бәлкыйс; нәзакәтле Нәркис; моңлы Мостафа...

Мин аларга тукталып тормыйм. Бары Рушад белән Гата образы турында гына берничә сүз әйтәсем килә. Әсәрдә аларга күп урын бирелгән өчен дә, алар романның төп геройлары булганы өчен дә түгел. Алар — фронтовиклар. Беренче чиратта шуның өчен.

*
* *

Фронтовиклар, хәрби тема, колхоз авылы кебек үк, М. Мәһдиев иҗатында зур урын алып тора. Моңа ышану өчен, авторның «Без — кырык беренче ел балалары», «Кеше китә — җыры кала» һәм хәзергә әле дөньяга чыгып өлгермәгән «Ут чәчәге» кебек әсәрләрен искә алу да җитә. Бу әсәрләрнең һәр кайсында диярлек ул сугыш китергән корбаннар, яралар турында сөйли, халыкның психикасында, рухи дөньясында сугыш тудырган үзгәрешләр турында уйлана. Аның әсәрләрендә Ватан сугышы тормышны ике чорга, ике дәвергә бүлгән зур фаҗига буларак сурәтләнә.

Солдат, фронтовик — М. Мәһдиев өчен иң кадерле кеше. Кешенең дәрәҗәсен, кадерен, бәясен ул аның сугышта булу-булмавыннан чыгып бәяли. Аның әсәрләрендә фронтовик булу этик һәм эстетик категория дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Фронтовик икән, димәк ул — иң гадел, иң принципиаль кеше, нык иманлы, олы җанлы, горур кеше дигән сүз. Сугыш аларның бөтен тормышына тирән эз салган. Кырыс сугыш чынбарлыгы аларны үз язмышларын ил язмышы белән бәйләп карарга, намуслы булырга, тормышның вак-төягеннән өстен булырга өйрәткән. Тыныч тормышта да алар фронтовиклар булып калалар. Дөньяга караштa, кешегә мөнәсәбәттә, семьяда, хезмәттә, мәхәббәттә. Иң кыен чакларда чит җирләрдә үлеп калган фронтташ дусларын искә төшерәләр, күңелләреннән алар белән киңәшләр. «Кеше китә — җыры кала» повестендагы Тимерханнар, «Ут чәчәге»ндәге Асаф Раимовлар, «Фронтовиклар»дагы Рушад һәм Гаталар — әнә шундыйлар.

*
* *

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, М. Мәһдиевнең тирәнтен белеп, яратып сурәтли торган тагын бер өлкәсе, дөресрәге, төп өлкәсе—сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы колхоз тормышы, авыл кешеләре. Шул темага караган әсәрләренең иң уңышлысы — күптән язылып та, күптән түгел генә дөнья күргән «Кеше китә — җыры кала» исемле повесть.

«Кеше китә — җыры кала» — киң колачлы вакыйгаларны, драматик эпизодларны үз эченә алган, олы һәм катлаулы язмышлы характерларга, кызыклы образларга бай булган, гаҗәеп дәрәҗәдә халыкчан рухлы, олы хисле, зур яңгырашлы әсәр, әдәбиятыбызның казанышы булып саналырлык әсәр. Композицион яктан да төзек, җыйнак һәм бөтен әсәр. Ул тагын әнә шул сыйфатлары белән дә аерылып тора.

Бу әсәрне укыганда авторның әдәби таланты тагын да ныгый, чарлана төшкәнен күрәсең. Сугыш башланган. Кара Чыршы авылы үзенең иң асыл ирләрен фронтка, ут эченә озатырга тиеш.

«... Таң атты, кояш чыкты. Ат абзарлары тирәсендә тимер ходлы арбаларны көйли башладылар, дугаларга кыңгыраулар тактылар. Авыл ыгы-зыгы килде. Әле берәү дә еламый, берәү дә шауламый. Бары тик йөгерешәләр генә. Мунча кергән, кырынган, кызмача ирләр бер-берсенә йөгерешеп керәләр, кызу-кызу тәмәке суыралар. Кайдандыр гармун тарткан тавыш ишетелә. Бу мәшәкать сәгать уннарга хәтле шулай барды. Повесткада «сәгать сигездә Ташлытауда булырга» диелгән иде. Сәгать ун тулды, кемнеңдер өмере булгандай, капка төпләрендәге өсәрешкән атлар башларын

селки-селки урамга борылдылар. Халык Ташлытауга чыгып китә торган юл чатына агылды. Күперне чыккач, бер арба ирләр җыр башлады:

Ал кисәргә, гөл кисәргә
Үтмәс кайчыларыбыз,
Киләсе ел бу вакытта
Булмас кайсыларыбыз.

Капка асларында койрыкларын кәкрәйтеп йөргән этләр күккә карап елаштылар, Тальян, шөлдер тавышына эт заты чыдый алмый... Койрыкларын җиргә терәп утыралар да капка төбеннән китмичә генә күккә карап елыйлар. Бу тавыш күңелләргә шом сала. Нәрсәдер бар, дөньяның кай төшендәдер гаделсезлек бар... Эт күңеле сизгер, ул әрәгә генә алай шыңшымый. Хәер, этләр генә түгел. Шөлдер, гармун тавышына атлар да борчыла. Әсәренгән атлар борын тишекләрен киңәйтеп, башларын чайкый-чайкый, басу капкасына таба атладылар. Түбән очтан да шундый бер йөк ирләр күренде. Басу капкасы төбендә чуптарларын түбән иеп ялгыз каен тора. Юлга чыгасы атлар шул каен төбенә җыелдылар. Ике-өч гармун тавышы бергә кушылды. Болар өчесе дә төрле көйгә уйныйлар иде. Мондый буталган көйләр күңелләргә тагын шом салды. Чыннан да, бу сугыш дигәннәре әллә нинди куркыныч нәрсә икән! Хатын-кыз елаша башлады, атлар тыпырчынды...»

Шомлы тантана, коточкыч кара бәйрәм!.. Моны Г. Ибраһимов белән М. Галәү генә һәм М. Мәһдиев кенә шулай яза ала.

Асыл егетләр, гаярь ирләр ут эченә китә. Тыл тормышының бөтен авырлыгы хатын-кыз, карт-коры, бала-чага җилкәсенә төшеп кала. Шәяхмәт һәм Шәйхи картларга, Васфикамалларга. Әсәр асылда шулар турында, аларның тормышы, язмышы турында. Образ буларак, һәр кайсы ифрат көчле эшләнгән, һәр кайсы хәтердә кала. Шәяхмәт белән Шәйхи, Васфикамал белән Улибаева — ачыш дәрәҗәсендәге образлар.

Һәрберсенең үз характеры, үз кайгысы, үз бәхетсезлеге. Аннан да бигрәк, һәрберсенең өстендә уртак кайгы — ил кайгысы. Әмма кайгыга да сыгылып төшмиләр, шатлыкка да сикереп чыкмыйлар болар. Һәммәсе төптә, тирәндә. Шундый кешеләребез күп булганга, без сугыш чорының кыенлыкларын җиңдек, мәкерле һәм көчле дошманны тар-мар иттек. «Кеше китә — җыры кала» повесте белән М. Мәһдиев тагын бер тапкыр шул хакыйкатьне раслый. Әсәрнең төп кыйммәте әнә шунда.

Без Мөхәммәт Мәһдиев иҗат иткән иң уңышлы әсәрләрне күздән кичердек. Шул әсәрләр мисалында аның сюжет-композиция төзү, образлар иҗат итү өлкәсендәге үзенчәлекләренә туктадык, тормышның ул аеруча яратып сурәтли торган өлкәләрен атадык. Бер сүз белән әйткәндә, язучы иҗатының кайбер характерлы якларын ачыкларга тырышып карадык. Нәтиҗә ясап нәрсә әйтергә мөмкин? Мөхәммәт Мәһдиев безнең әдәбиятны тагын бер адым реаль чынбарлыкка, кешегә якынайтты дипме?.. Ихтимал, шулай дип әйтергә кирәктер. Һәр язучы әдәбиятны кешегә, тормышка якынайтырга тиеш. Бу — һәр язучының төп миссиясе.

Равил Кукушкин

# ЯҢА ШИГЪРИ АЧКЫЧ ЭЗЛӘП

Бүгенге көн татар совет балалар поэзиясен күзаллаганда ирексездән Г. Тукайның 1910 елда язган сүзләре искә төшә:

«Әдәбиятымызның иң гүзәл кыйтгаларын гына сайлап яки сайларга тырышып та вә, гүзәл булып та, балалар рухына килешмәслекләрен калдыра торып ,..шушы «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» кеби олугъ бер китап мәйданга куярга мөмкин икәнен күргәч, яшь әдәбиятымызның байлыгына вә киңлегенә хәйрат иттем вә шатландым.

Татарда тел юк, әдәбият юк диюче мөтәгассыйбларны (бөтен мәгънәсе илән) кызгандым. Әйе, бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият!»[1]

Инде бүген, бу сүзләр язылганга җитмеш ел үткәннән соң, социалистик җәмгыять шартларында яңа рухи биеклекләр яулаган татар балалар әдәбияты байлыгын күздән кичерәбез икән, табигый, милли мәдәниятебез өчен булган горурлык хисе тагын да арта төшә. Совет чоры балалар поэзиясенең төп үсеш юлын билгеләгән Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, Ш. Маннур, Ә. Исхак, Ә. Бикчәнтәева, Җ. Тәрҗеманов, Б. Рәхмәт, З. Нури, Ш. Галиев иҗатлары — моңа ачык дәлил.

Сүз дә юк, татар балалар поэзиясенең бөтен байлыгын һәм төрлелеген бу шагыйрьләр иҗаты гына билгеләми. Әлеге исемлекне тулыландырган очракта, безгә тагын байтак кына исем атарга туры килер иде.

Татар совет балалар поэзиясе әнә шундый бай поэтик мираска: фольклор, Тукай, аның чордашлары, шулай ук яңа революцион заман тудырган шигъри традициягә таянып эш итә һәм бүгенге көндә ул зур үзгәрешләр кичерә.

Эш шунда, үткән еллар шигърияте безгә традицияләрнең уңаен гына түгел, ә бәлки тискәресен дә — әле бүгенге көндә дә поэтик үсешкә зур тоткарлык ясап торганнарын да бергә кушып тәкъдим итте. Чын поэзия белән бернинди уртаклыгы булмаган шигырь такмакларының дистәләрчә ел матбугат битләреннән төшә алмый тартышуын без бүген, беренче чиратта, әнә шул үткән еллар тудырган шаукым итеп күзаллыйбыз. Бу агым бер тармак булып балалар поэзиясенә дә килеп керде. Һәм бирегә тагын да киңрәк үсеш алды. Тематик яктан балаларныкы булып күренгән һәрбер шома такмак балалар шигыре битлеге астында әдәбиятыбыз мәйданында үзенә аулак сыенып урын тапты. Бүген кайбер авторларның еллар тузанында бик хаклы төстә күмелеп калган дистәләрчә китапларын актарганда, шуңа ышанасың: вакыт тән-

[1] Г. Тукай, Әсәрләр, 4 томда. Казан, 1977, IV том, 99 бит.

кыйтьчеләр һәм бөтен әдәби җәмәгатьчелек эшли алмаган чистарту-барлау эшен тә-гәл башкарган... Ләкин бүгенге көндә дә процессны үзагымына куярга безнең хакыбыз юк. Чөнки әлеге шигырь такмакларының китергән зыяны бер нәни балалар өстенә генә төшми. Аларның тискәре йогынтысы гомуми иҗат психологиясе, гомуми иҗат атмосферасына да үтеп керә. Беркемгә дә сер түгел, соңгы елларга кадәр безнең иҗат кешеләре арасында балалар әдәбиятына берникадәр үгисетебрәк карау яшәп килде. Балаларга язу алар өчен художниклык дәрәҗәсен төшерү, җитди булмаган бер эш белән шөгыльләнү булып тоелды. Иҗатларын балалар шигъриятеннән башлаган талантлы авторларыбыз да тизрәк олылар поэзиясенә — олырак, җитдирәк проблемалар хәл итәргә китү ягын карадылар. Татар балалар поэзиясе озак еллар буена талантлы һәм ахыргача үзенеке булып калырлык үз шагыйрен көтеп яшәде. Илленче елларда чын балаларча гадилек һәм самимилек белән сугарылган Б. Рәхмәт шигырьләренең ни өчен шундый зур күтәренкелек һәм соклану белән каршы алынуы бүген безгә бик ачык аңлашыла.

Аңардан соң олы-җитди проблемаларны чишүдә нәниләр поэзиясенең ким түгеллеген, еш кына олылар шигъриятендә ачып бетереп булмаганны да биредә шактый җиңел әйтеп бирү мөмкинлеген Шәүкәт Галиев күрсәтә алды. Аны бөтенсоюз балалар әдәбиятының гүзәл үрнәкләре булырлык дәрәҗәгә күтәрә алды.

Бер тапкыр олылар дөньясыннан бала чагына әйләнеп кайткан шагыйрьне сабыйлыгын яңадан оныттыр димә. Шигъриятгә бар да киресенчә: сабыйлыктан картлыкка юл юк! Балалар әдәбиятының көче һәм өстенлеге дә әнә шунда, күрәсең... Шагыйрьләребезнең балалар поэзиясенә, үзләренең сабыйлык дөньяларына әйләнеп кайтуы да инде билгеле бер күләмдә традициягә кереп бара. Мин биредә олылар поэзиясендә уңышлы гына эшләп килгән һәм соңгы елларда балалар шигъриятендә җитди эзләнүләр алып барган шагыйрьләрнең берничәсен: Рөстәм Мингалимовны, Равил Фәйзуллинны, Роберт Миңнуллинны, Роберт Әхмәтҗановны истә тотам.

Әлбәттә, бу авторларның балалар өчен иҗат итә башлаулары очраклы түгел.

Беренчедән, моны шагыйрьнең эчкерсез сабыйлыгын сагынуы итеп карарга?дыр.

Шулай ук, балалар поэзиясендә шигъри уен, поэтик фантазиянең тагын да ачыла төшүе, шигъриятнең биредә салават күпере кебек ачык һәм төрле төсләр белән балкып яшәве дә шагыйрьләрне үзенә битараф калдыра алмый, күрәсең.

Балалыкка кайтуны шагыйрьнең сүз художнигы һәм шәхес буларак үсүе, җитлегүе, кешелекнең киләчәге булган яшь буынга әйтер сүзе барлыкка килү дип тә аңларга кирәктер. һәм, әлбәттә, бу кайтуның төп сәбәбе авторларның талантлы шагыйрь, ягъни дөньяны художестволы фикерләү аша үзләштерүгә сәләтле кешеләр булуындадыр. Ә, белгәнебезчә, художестволы фикерләүнең нигезендә балаларча конкрет, җанлы, эмоциональ уйлый белү ята. Димәк, чын шагыйрьнең балалар әдәбиятына килүе дә бик табигый. Некрасов, Маяковский, Толстой, Горький исемнәрен алыйк, үзебезнең Тукаебызны, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларны алыйк. «Бәләкәй гениялар» белән теләсә кем сөйләшә һәм уртак тел таба алмый. Иң элек талант кирәк. Инде шуннан соң гына аның балаларныкымы-юкмы икәнлеген һәм ни дәрәҗәдә икәнлеген ачыклый башларга мөмкин. Балалар шагыйрен әнә шундый икеләтә сыналу көтә.

Р. Мингалимов, Р. Фәйзуллин, Р. Миңнуллин, Роберт Әхмәтҗанов, минемчә, бу таләпне бик яхшы аңлап килделәр. Бу — аларның әдәбиятта сыеныр урын эзләүләре түгел, бәлки үз мөмкинлекләрен тагын да тулырак чагылдыруга булган бер омтылыш. Алар, татар балалар поэзиясенең иң гүзәл үрнәкләренә таянган хәлдә, шома такмак урынына балалар поэзиясенә художестволы фикерләү, бала булып кыланган беркатлы ташкурчак урынына замана баласының катлаулы кичерешләрен, психологик эчке нюансларын алып килделәр.

Роберт Әхмәтҗанов исеме поэзия сөючеләргә күптәннән таныш. Ә менә балалар шигъриятендә әле ул үзенең беренче адымнарын гына ясый. Әйтергә кирәк, беренче китабы («Балалар хоры», 1978) белән үк ул үзен әлеге өлкәдә дә уңышлы гына эшләргә сәләтле автор итеп күрсәтте.

Р. Әхмәтҗанов балалар шигъриятендә дә уйчан-лирик. Балалар күңеленә ул художестволы фикерләү, дөньяны поэтик күрү аша якын килә:

Йолдызлар кабызды төн.
Ай елмаеп карый күктән.
Тәрәз каршында кар кызы
Челтәр бәйли
Көмеш җептән...
Өй түрендә топольләрнең
Башлары ак йомгак кебек.
Әллә кар кызы бәйлиме
Шул йомгакның җебен сүтеп!..

Автор әнә шундый бер бөтен шигъри картина ясап куйганнан соң, баланы үзе белән уйлар, кичерешләр, хыяллар дөньясына алып кереп китә: тәрәзәгә кар кызы абагалар, иген кырларын чигеп куйган... Туган ягын шулай сагынуымы?

Җәйне каян белсен икән!
Яшь ич ул кышын гына...
Тик хыялын чигәдер ул,
Я сөйлидер
Төшен генә...

Авторның «Хыял», «Сабый», «Хыяллар» исемле шигырьләрендә дә балалар поэзиясе өчен төп үзлек — хыялый шартлылык, шигъри конкретлык, образлылык бар. Алар чынбарлыкны тематик үзләштерүдән бигрәк, балалар дөньясын ачуга юнәлдерелгән шигъри фикерләү буларак чагылыш табалар. Бу шигырьләрнең заманчалыгы һәм төп уңышы әнә шунда!

Шул ук вакытта, Р. Әхмәтҗанов бу шигырьләрендә балалар дөньясының кайбер нечкәлекләрен исәпкә алып бетерми әле. Әйтик, аның иң характерлы кимчелекләреннән берсе — әсәркүләм шигъри механизмның бер бөтен эчке логикага — балалар логикасына буйсынмавы, бер бөтен шигъри чишелешнең табылмавы, төрле якка таркалу үзен нык сиздерә. Бу уңайдан «Алтын көз» шигыренә конкрет тукталып үтик:

Җил йөри ылыслар эчендә,
Усаклар калтырый: «Алтын көз!»
Кояш исеменә берәмләп —
Берәмләп коела алтын сүз.

Биредә строфаның тематик яктан азмы-күпме берләшкән өч мөстәкыйль җөмлә, өч мөстәкыйль тасвир-образдан торуын күрәбез. Бу — авторның олылар поэзиясендәге художестволы фикерләү үзенчәлеге. Әмма бала аны бер бөтен итеп җыеп күзаллый алмас. Чөнки аларда гомуми настроениене эчке яктан бәйләп торган конкрет бала җаны юк. Бу деталь-образларның һәрберсен аерым-аерым алып мөстәкыйль үстерергә мөмкин. Бигрәк тә беренче юлдагы гаҗәп матур табылган балаларча деталь — җилнең чәнечкеле ылыслар эчендә йөрүе — үзе үк үстерелүне сорый сыман.

Әлеге «олыларча» таркаулык, бер бөтенлекнең табылмавы шигырьнең икенче — соңгы строфасында да күренә:

Салкын борынлы гөмбәләр
утыра аланда чүгәләп.
Менә бу «Әбиләр чуагы!» —
Октябрь, —
Урманда — күбәләк!

Биредә дә «салкын борынлы гөмбәләр» кебек матур шигъри табыш ахыргача үстерелмичә, шигырьдә «чүгәләп» кала сыман. Шигырьнең потенциаль мөмкинлеге, әнә шул рәвешчә, ачылмыйча кала. Бу кимчелек «Гомер кыры», «Җыр агачы», «Кояшлы кырлар» һ. б. шигырьләрдә дә сизелә. Детальләр генә түгел, аларның композицион оештырылышы да балалар психологиясе үзенчәлекләреннән чыгып эшләнергә тиеш. Балалар шигыре ахыргача аларныкы булсын!

Роберт Миңнуллин чынбарлыкны юмористик аспектта, баланың шаянлык, җорлык сыйфатлары җирлегендә үзләштерүгә омтыла. Дөрес, гадәттә, аның шигырьләрендә нәни герой үзе җитди, эшлекле кыяфәттә бирелә. Ә менә аның кылган гамәле, уй-

фикерләве, ягъни психологик үзенчәлеге, тәҗрибәсезлеге объектив дөнья белән каршылыкка кереп юмор тууга сәбәпче була:

**И сызланам! Әмма миндә**
**Берәүнең дә эше юк.**
**Кычкырып елар идем дә —**
**Янымда бер кеше юк.**

**(«Кеше карап тормагач».)**

«Урман аша үткәндә» шигырендә без баланың хыялый дөньясы белән очрашабыз. Каршысына Шүрәле килеп чыкканда, нишләячәген ул болай күз алдына китерә:

**Шүрәлегә: — Мин Былтырның**
**Энесе, — дияр идем.**
**— Шулаймыни!**
**Исәнме! — дип,**
**Ул башын ияр иде.**

Батыр булу әйбәт. Әмма Шүрәленең хыялда гына калуы тагын да шәбрәк:

**Күренмәгәч, сөенечтән**
**Карап куйдым тагы бер.**

Бала күңелен үсеш-үзгәрештә күрсәтү өчен автор биредә аның үз психологиясенә мөрәҗәгать иткән.

Кайчакта гади генә тормыш күренеше дә бала күңелендә шартлы үзгәреш алып, шигъри детальгә әверелеп китәргә мөмкин. Әнә һаман-һаман йорттан чыгып качкан кәҗәләре турында уйланып, бала түбәндәге нәтиҗәгә килә: ул кәҗә ялан кырда бүре очраса да куркып калмас. Чөнки:

**Сөзешергә хәтта әзер,**
**Кыр кәҗәсе бит ул хәзер.**

**(«Кыр кәҗәсе».)**

«Елмаючы бүреләр» шигыре дә бала уены, аның хыялый шаяруы буларак истә кала.

Бу урында Р. Миңнуллинның сүз уйнату, каламбурлык осталыгын да әйтеп үтми булмый. «Без нәрсәләр яздык» шигырендә ул әнә татар телендәге омоним сүзләрдән файдалана. «Автобуста» шигыренең нигезенә дә поэтик образ буларак сүз уйнату алынган:

**Ишек ачылып киткәчтен**
**Мин кем керә дип торам,**
**Малайларны да уздырып**
**Килеп керде ак буран.**

**Җәяүле буран да хәзер**
**Алдатмый, ай-яй оста.**
**Безнең кебек рәхәтләнеп**
**Йөри ул автобуста.**

Күргәнебезчә, сүз уйнату — каламбурлык, шигъри уен буларак, бала табигатенә һич кенә дә ят түгел. Киресенчә, ул аларның үзләре кебек үк шаян, тапкыр, җор табигатьле. Шул ук вакытта ул туган телгә игътибарлы булырга, аны нечкәрәк тоемларга ярдәм итә.

Әлеге сүз уйнатулар еш кына үткен сатирага әверелеп, тәрбияви көч ала. Бу бигрәк тә шигырьгә пародия элементы килеп кергәндә ачык чагыла. «Төмле кычыткан» шигырендә әнә «Кычыткан да юашланган, тәмләнгән бит... пешергәч», дип малай тантана итә итүен... Ә шулай да биредә җиңүче — кычыткан: сүз тыңламаган өчен үзен тотып «пешергәнен» малай әле дә булса оныта алмый, үчләшеп аңардан көлгән була...

«Нишләрбез инде?» шигырендә әле маймылланып, әле кәҗәләнеп, әле әтәчләнеп төрле рәвеш алган Ләлә дә укучыда гыйбрәтле көлү тудыра. Бу яктан «Акбай шулай ди» шигыре дә кызыклы.

Р. Миңнуллинның җитди тонда язылган шигырьләре дә юк түгел. Шулай да ул юморда зуррак уңышка ирешә. Аның яңа эзләнү, яңа табышлары нәкъ менә шушы өлкәгә карый. «Мияулый торган ишек» шигыренә игътибар итик. Биредә ишек шыгырдавы мәче кычкыруы белән чагыштырыла:

Тавышлары әй әче,
Кычкыруы нәкъ мәче.
Ачкан саен, мияу, ди,
Мин һәрвакыт уяу, ди.

Әмма авторның әйтергә теләгәне моның белән генә чикләнми, ул әлеге тасвирга яңа детальләр кертеп җибәрә:

Май бирмиләр миңа-у, ди,
Мияулый да мияулый.

Мәче белән ишек ике уртак үзлекләре аша әнә шулай ныклы, табигый шигъри бөтенлек хасил итә. Авторның «Акбай цирк карый» циклын да иҗади эзләнүләр нәтиҗәсе итеп карарга кирәк.

Циркка бару, гомумән, балага үзе зур бәйрәм. Ә инде янында Акбай да булгач, биредә һәр номер чын тамашага әверелә. Әнә зебраны күргән Акбай аның артыннан чапмыйча чак түзеп утыра. Чабар иде дә (игътибар итегез, монысы баланың этка булган мөнәсәбәте)...

Мондый буйлы-буйлы атны
Күргәне юк шул аның,
Мондый атка бер тапкыр да
Өргәне юк шул аның.

Өрер дә иде... зебра әйләнеп тә карамый, кеше дә күп...

Цирк номерлары — төп тема әнә шулай икеле призма — Акбай һәм аны да, циркны да бердәй кызыксынып күзәткән нәни бала күңеле аша чагыла. Бу исә шигырьне мавыктыргыч итә, фикер, халәт бирелешен төрле нюанслар белән баетып, әсәрне яңа шигъри биеклеккә күтәрә.

Җитешсезлекләр Р. Миңнуллин шигырьләрендә дә юк түгел. Кайчак шигырьләргә олыларга гына хас абстракт тәгъбирләр, ясалма шигъри образлар килеп керә, Кайчак баланың сүзләре дә ышандырып бетерми («Шаккаттым», «Алмазның үтенече» һ. б.).

Шагыйрь юмор нигезенә, гадәттә, баланың беркатлылыгы, тәҗрибәсезлегеннән килеп чыккан каршылыкны ала. Бу исә аңа бала күңеле белән бер булып кушылып китүне шактый авырлаштыра. Еш кына ул балага өстәнрәк көлеп карап торган сыман тәэсир кала.

Вакыт-вакыт аның иҗатында Ш. Галиевтә чагылыш тапкан кайбер шигъри элементлар очрап куя. «Мактанмыйм» шигырендә, мәсәлән, мактанмыйм дип мактанган малайны күрсәтү бурыч итеп куелган. Ә бит Ш. Галиевнең «Мин» исемле — «Шәвәли» циклының кереше булган шигыре дә нәкъ әнә шул ачкычта чишелеш тапкан иде. Бу очракта Р. Миңнуллинның шигыре әлеге әсәрнең йомшаграк бер варианты гына булып кала.

Р. Миңнуллинга юмор өлкәсендә 20 ел эшләгән Ш. Галиевтән соң иҗат итүе җиңел дә, авыр да... Әлеге шагыйрьнең иҗат тәҗрибәсе аның иҗатына берникадәр җиңеллек тудырса, моның кыенлыгы да шактый. Аның тәэсиренә бирелмичә, бу өлкәдә табылганнарны кабатламыйча, үз юлыңны тотып алга бару — шагыйрьдән зур көч сорый. Шулай да юморның Р. Миңнуллин иҗатына килеп керүе кимчелек кемгәдер нәрүдән түгел. Ул аның үз фикерләү үзенчәлеге, үз күңел ихтыяҗы.

Равил Фәйзуллин балалар өчен 1965 елда «Рәсем ясыйм» исемле китап чыгарган иде. Дистәдән артык елдан соң ул:

**... уянып киттем**
**үлән үскән тавышлардан...**

**(«Балачак... Болында төн куну»)**

кебек юллар белән бу өлкәгә кабат кайтты. Чынбарлыкны хыялый шартлылыкта масштаблы, конкрет, ачык итеп күзаллау бары тик балалар шигърияте дә генә мөмкиндер. Ә шагыйрьнең сабыйлыгы исә аның фикерләвенә, җанына күптән салынган:

**Көнбагыш чәчәге ясыйм,**
**Сары карандаш алдым.**
**Эшем бетте, исем китте:**
**Кояшны ясаганмын.**

**(«Рәсем».)**

Күрәбез, бу — баланың рәсем ясап уйнавы гына түгел. Бу — поэтик образның туу рәвешен чагылдырган, шагыйрьнең поэтик фикерләү үзенчәлеген күрсәткән шигъри иҗат этюды. Бу — конкретлыктан образлы фикерләүгә булган күчеш, һәртөрле шигъри метаморфозаларның башлангычы. Шагыйрьнең художестволы фикерләве үткән юлны нәни бала еш кына шулай уйнап-шаярып, тормышта үзе яшәп үтә. Балаларча конкрет, җанлы итеп уйлауның художестволы фикерләү белән уртаклыгы әнә шунда. Инде моннан соң баланың:

**Үрмәкүч үргән челтәр-бишектә**
**тибрәнә җәй!**

**(«Җәй».)**

— дип, я булмаса, кар баскан урман өстендә уйнаклаган кызылтүшне:

**Карлы дугалар өстендә**
**Кызыл кыңгырау!**
**Кышкы урман уртасында**
**Язгы яңгырау!**

**(«Кызылтүш».)**

— дип, шигъри күрүе гаҗәп түгел. Әнә, бала йоклаганда, «ай да башын салган болытларның өстенә» («Йокы әкияте»), «Кояш исә болытларның читен ачып, җиде төрле буй сөлгесен иңгә асып», яңгырдан соң саф һавага чыккан («Яңгырдан соң»), тал песиләре, ташулар ярга менгәч, рәхәтләнеп су коена («Быелгы яз»), телефон чыбыгына кунган чыпчыклар исә малай әнисенең кызык сүзен ишетеп, «чырык-чырык итәләр» («Чыпчыклар»).

Әлеге образ-детальләр артында уй-хисләре, кичерешләре — бөтен барлыгы белән бала үзе тора. Аның үткен күзе, конкрет фикерләве, бай фантазиясе берга кушылып җанлы сурәткә әверелә.

Әнә ул — көчсез, тәҗрибәсез табигать баласы:

**Барырга кая дип,**
**Торганда уйланып,**
**Беткәнбез чыланып...**

**(«Яңгырда».)**

Ә бал корты исә аптырап калмаган, үлән-яфрак астына кереп поскан; әнә ул — Идел кебек җәелгән инешләргә карап «бәлки быел безнең якка аккошлар да килерләр» («Быелгы яз») дип, татлы, яшерен хыялый өметкә бирелгән: әнә ул — ата-ананың шаян, бәхетле улы:

**Шулай да җиләкләр**
**Күбрәк табыла**
**Әтием янында,**
**Әнием янында.**

**(«Җиләк кайда күп».)**

Балалар логикасын тасвирлаганда шагыйрьнең нәниләрчә фикер йөртә белүе, шигъри гомумиләштерүдәге кыюлыгы тагын да ачыграк күренә:

Карталарда безнең илне
Буяганнар алсуга.
Чөнки кояш иртүк торып,
Алсу утлы шардай булып,
Иң башта бездә чыга.
(«Безнең ил».)

Мондый «чикләнгән» логикалы дәлил — балаларга хас фикерләү шигъри гомумиләштерүләр генә алып килми, ул еш кына әсәрнең настроениесен дә билгели. Авторның юмористик рухлы шигырьләренең күбесе шул үзенчәлеккә корылган:

Курчагымның битен юам,
Пычрак, шапшак йөрмәсен.
Ә сабынны бик аз сөртәм,
Күзенә керә күрмәсен.
(«Курчакны юындырганда».)

Ләкин бала беркатлы гына түгел, гаҗәп хәйләкәр дә. «Тамчысы ни хак тора?» шигырендә ул ширбәт сатучы апага әнә шундый сорау бирә һәм «ни хак торсын, берни тормый» дигән җавапны алгач, «алайса тамчылап бер стакан агызыгыз», дип куя.

«Паласны кем кагар?», «Ни җитмәгән?» һ. б. шигырьләрендә юмор-көлү актив тәрбия чарасына әверелә.

Р. Фәйзуллинның шигъри осталыгы деталь-образларда гына түгел. Шигырьнең композицион оештырылышында да аның кызыклы гына үз табышлары бар. Шул ук «Ни җитмәгән?» шигырен алыйк. Ул өч буыннан тора.

1. Искәндәрнең кулында таплар бетмәгән. Сәбәбе — юынганда су җитмәгән.

2. Мунчада сулар ләгәнләп. Искәндәрнең бите корымлы чыга, — ахрысы, су җитмәгән...

3. Искәндәр Иделдә су керә — борыны һаман кара. Әллә инде аңа Иделдә су җитмәгән?..

Шулай итеп, беренче очракта сәбәп булган — «су җитмәү» икенче һәм өченче тапкырында, үсә барып, шартлы төс алып, абсурд дәрәҗәгә җиткерелә. Искәндәрнең шапшаклыгы әнә шундый сатира утына алына: су җиткән, кул җитмәгән!

«Каймаклы чия» һәм «Кызыл кар» шигырьләренең дә төзелеше үзенчәлекле һәм кызыклы.

Шулай да әле Р. Фәйзуллинга кайбер шигырьләренең композицион оештырылышы, аларның бала психологиясе белән ни дәрәҗәдә бәйләнүе турында нык лап уйланасы бар. Таркаулык кайчакта матур табылган детальләрне дә күмеп китә, аларга салынган потенциаль көч, шигъри матурлык нәни укучыга тулысынча барып җитми кала.

Рөстәм Мингалимов үз иҗатының башында ук (аның «Әйт, кояшым!» исемле беренче балалар китабы 1966 елда чыккан иде) дөньяны шигъри күзаллауга үзенчәлекле һәм кыю омтылыш ясады:

Күк — кара такта,
Ә яшен
Яза да яза гына,
Нокталар да куеп тормый
Сүзләрнең азагына...
(«Яңгырлы кичтә», 1963.)

Чынбарлыкны шигъри үзләштерүгә булган омтылышны без Р. Мингалимовның соңгы елларда язган шигырьләрендә дә күрәбез.

Җемелдәшә дулкыннарда
Акчарлак бишекләре.

Яисә: **Малайлар атта киләләр,**
**Тояклар җирне кага.**
**Көчле малайлар үскәнне**
**Хәбәр итеп дөньяга**
**Тояклар җирне кага.**

Р. Мингалимовның турыдан-туры бала психологиясен тасвирлауга корылган шигырьләре дә шактый:

**Әни миңа әйткән иде:**
**— Тамчы ташны тишә, — диеп.**
**Минем учны тишә алмый...**
**(«Тамчы тотам».)**

Бала логикасы (ул реаль җирлеккә таяна) биредә сүзнең күчерелмә мәгънәсе белән каршылыкка кереп, аны инкарь итә һәм үзе дә художестволы фикерләүнең бер төренә әверелә.

«Ә сәгать келт-келт итә» шигырендә дә самими бала күңеле белән очрашабыз:

**Көн уза да кич була,**
**Өй эче йоклап китә,**
. . . . . . . . . . .
**Күрсәтә ул вакытны,**
**Соңгармаска икәнне,**
**Кунакларга күрсәтә**
**Китәр вакыт җиткәнне.**

Бер-берсеннән шактый еракта торган сәгать һәм кунак төшенчәләре бала аңында әнә шундый бәйләнештә чагылыш таба.

Соңгы елларда бала психологиясен бирү ягыннан Р. Мингалимов үз иҗатында шактый зур борылыш ясады: бала психологиясе нюансларының шигырьдә ул турыдан-туры үсеш-үзгәрешен, хәрәкәтен күрсәтергә кереште. Балалар поэзиясе алдына әлеге максатны кую — Р. Мингалимовның үз иҗаты өчен генә түгел, бөтен татар балалар поэзиясе өчен дә яңа үсеш югарылыгына күтәрелү дигән сүз.

Дөрес, хәрәкәт ул, гомумән, балалар поэзиясенең нигезендә яткан хасиятләрнең берсе. Шуңа да балалар шигъриятенең осталары балалар спецификасының бу ягына һәрвакыт зур әһәмият биреп килделәр. Шулай да хәрәкәт күпчелек очракта вакыйгалар хәрәкәте, картина-детальләр хәрәкәтенә кайтып калды. Баланың эчке күңел үсеше дә еш кына шушы тышкы чынбарлык хәрәкәтенә бәйле булып чыкты. Шигырьгә алынган реаль дөнья бәйләнеше, бер яктан, бала психологиясен ачуда ярдәм итсә, икенче яктан, аның иркле хәрәкәтен буып-тоткарлап торды. Шагыйрьләр бала халәтен билгеле бер кысага куеп, шуны фотога төшерү белән канәгатьләнделәр. Р. Мингалимов ул халәтне кирәксез фон — реаль дөнья бәйләнешләреннән арындырып, аңа билгеле бер юнәлештә хәрәкәт бирүне бурыч итеп куйды.

Дөньяны шигъри үзләштерүгә булган омтылышы шагыйрьне чынбарлык бәйләнешен җимереп, аның урынына үз субъектив дөнья бәйләнешен тәкъдим итүгә китерде. Әйтик, башлангыч иҗат чорында олылар өчен язган «Военкоматта» шигырендә үк ул реаль дөнья үлчәменә каршы килеп:

**Нигә бу егетләрне**
**үлчәп маташасыз**
**салкын, җансыз үлчәгечләр белән!**

— дип яза һәм моңа каршы үз шигъри үлчәмен тәкъдим итә:

**Алар, әтиләре сугышка киткәндә,**
**кайнар беләктә калдылар, —**
**тәгәл авырлыкларын**
**бары әниләре белә.**

Әйе, шагыйрь өчен теге яки бу предмет-күренешнең реаль үзлеген күрсәтү максат түгел. Аңа билгеле бер психологик халәтне бирү, шуны уздыру әһәмиятле. Реаль

дөнья бәйләнешенең җимерелүенә дә карамастан, психологик-сәнгати тормыш дөреслегенә ул әнә шулай ирешә. Шуңа да «Тормышның чын йөзе аның алдында һаман үзгәреп тора»:

**Косады ярында**
**чалбарымны чәйнәп торган**
**ала бозау булып**
**тормыш миңа килде...**
**Кесәмдә тиен дә юк чакта,**
**кибеткә кайткан яхшы костюм булып**
**тормыш миңа килде...** һ.б.
**(«Эзләр».)**

Ә индә менә хыялый бала күңелен, бала дөньясын әлеге шартлы реаль тормыш детальләре белән дә биру мөмкин түгел. Ни генә әйтсәң дә, җисми реальлек художестволы фикерләү көченең ахыргача ачылып бетүенә барыбер тоткарлык ясый. Шуңа да балалар өчен яза башлагач, Р. Мингалимов, иркенәеп, бу шартлы, әмма реаль метаморфозалардан китеп, әкияти-хыялый метаморфозаларга мөрәҗәгать итә.

Дөрес, Р. Мингалимов иҗатының башында ук әкиятләр язган иде. Тик алар — сюжетлы-вакыйгалы әкиятләр. Ә болары — эчке халәт үсешенә буйсынган әкияти шигырьләр, әкияти метаморфозалар.

Биредә мотоциклга утырып йөрүче һәм юл йөрү кагыйдәләрен бозган ике малайны акылга утыртучы ап-ак кәҗә тәкәсе дә, сары автомобильгә әверелгән сары тавык та, кармак белән малайлар тоткан балыкчы балык та бар. «Өч әтәч, бер агай» да исә иптәшләрен базарга алып барып бер сумга сатарга уйлаган ике әтәчне күрәбез. Нәни укучы тавык булып кытаклаган мәче, әтәч булып кычкырган эт, атка атланып җырлап баручы бака («Әйбәт авызлы бака»), әнисе аш бүлгәнче тау өстеннән болытларга сикереп менгән, кояш белән сөйләшеп, яшен белән куышып йөргән малай («Авылга яңгыр килә») белән дә очраша. Әлеге шигъри әкиятләр, һичшиксез, бала фантазиясе өчен шәп рухи азык. Алар фольклорыбыздагы һәртөрле алдавыч, такмаза, сүз уйнатуларның матур дәвамы булып тора. Шунысын да истән чыгармыйк, бу әсәрләр гади әкият кенә түгел. Биредә ике башлангыч — шигъри күрү һәм балалар психологиясе, бер бөтенгә әверелеп, әкияти-шартлы яшәеш ала. Август каеннарының «Күз кила!» дип кычкырулары («Кем кычкыра?»), баланың язны... кулына алып, яшел кош итеп очырырга әзерләнүе («Минем рәсем»), яфракларның җилгә ялгыш иярәп адашуы һәм үзен үстергән урманны эзләп йөрүе («Уйнап йөгерә, диләр»), «Алтын чәчләре тузгыган» яланбаш учак («Күлмәксез учак») һ. б. әнә шул кушылуның матур нәтиҗәсе.

Шунысы кызыклы, шигъри образ нигезендә яткан әкияти метаморфозаларның туу, үсү процессы еш кына, акрынайтылган кинокадрлар сыман, укучының үзенә, гадәттә, берәр вакыйга-сюжет аша тасвирланып күрсәтелә. «Дөньяда бер эт бар иде» шигырен алып карыйк:

**Дөньяда**
**Бер эт бар иде —**
**Кечкенә,**
**Йомшак кына,**
**Ак кына,**
**Тик маңгаенда**
**Кара тап бар чак кына.**

Менә шушы этне хуҗа малай бер көнне яратмый да, ашатмый да башлый, шәһәр эченә алып кереп адаштырып та калдыра. Ләкин эт, кызганыч булып, көн саен аның төшенә керә. Инде малай аны эзләп тә карый, тик эт кенә табылмый.

**Эзләмәсен малай этен,**
**Инде җирдә юк эт ул.**
**Кая киткән соң дисезме!**
**Төшкә әйләнде бит ул...**

Якын дусны югалту тойгысы безнең күз алдында әнә шулай ышандырырлык, тәэсирле чагылыш таба.

Бала психологиясенең хыялый үзенчәлеген файдалану авторга, гомумән, бала белән уртак тел табу, әсәргә балаларча шигъри ачкыч сайлауда зур мөмкинлекләр бирә. Моның матур үрнәкләрен без шагыйрьнең «Чәчең сыйпап җил исә», «Мин җиләккә килдем», «Җил исте дә», «Кунак», «Алтын таба», «Әкәмәтнең ике авызы» һ. б. шигырьләрендә күрәбез.

Р. Мингалимовның күп кенә шигырьләре балага тәрбия бирү максатыннан чыгып язылган. Әнә «Исәнмесез!» дип елмаеп кешеләр күңелендә шатлык тудыра белгән кыз. Олылар тукталып аның исемен сорый. Ул аларга үзенең бәхетле исемен әйтә («Бәхетле исем»). Аның «Учак эченнән алынган» зуррак күләмле «Яхшылык һәм яманлык», «Төнге әкият», «Аны шатлык җыры озата китәр» әкиятләре, шулай ук «Карт кәҗәнең ала бәрәне», «Онытткан», «Үсми калдым», «Бала балык», «Аңа ничек ярдәм итим икән?» шигырьләре дә гыйбрәтле һәм балалар игътибарын җәлеп итәрдәй кызыклы-мавыктыргыч.

Эчке халәтеңә игътибарлы булсаң, кайчакта үз-үзеңә дә гыйбрәтле буласың икән. «Быел миңа әллә нәрсә булды...» шигыренең герое әнә ничек үз күңел хәрәкәтен, үз характерындагы үзгәрешләрне бик ачык тоя:

**Сүз әйтергә авыз ачтым икән,**
**Мин сүземне әйтми калмый идем.**
**Әгәр кулга бер таш алдым икән,**
**Ул ташымны атмый калмый идем.**
**Аргы очның усал Алабае**
**Мине күрсә читкә кача иде...**

Мин үземне хәзер таный алмыйм, ди малай. Кызыл тайга таш тезәгән идем — мин үземне шул тай итеп тойдым... Фәрдискә «елак» димәкче идем, үземне ул дип тоеп, сүзләремне эчкә йоттым...

**Мин үземне таный алмыйм әле,**
**Быел миңа әллә нәрсә булды:**
**Аргы очның усал Алабае**
**Ялап тора хәзер минем кулны.**

Тирә-ягындагы кешеләргә, тереклеккә, табигатькә игътибарлы булу, кешелекле булу кебек иң кыйммәтле сыйфатларны тәрбияләүдә бу әсәрнең әһәмияте бәхәссез.

Р. Мингалимов бала тойгыларының гармоник үсешенә дә зур әһәмият бирә. Аның шигырьләрендә җылы юморны да, үткән сатираны да, лирик моңсулык, фәлсәфи җитдилекне дә очратасың. «Хәзердән үк батырларча йоклый белгән» Булат кебек малайлардан («Батыр Булат») әче итеп көлсә, «Гөрләвекләр озатып мин йөгердем» шигырендә ул уйчан-фәлсәфи.

**Елга ярына йөгерә гөрләвекләр,**
**Йөгерә алар гөрләп, уйнап-ярсып.**
**Гөрләвекләр озатып мин йөгердем,**
**Инде калам яр өстенә басып...**

Дөрес, автор әле кайбер җитешсезлекләрдән дә азат түгел. Иң элек аңа йөгәнсез хыялларга артык зур урын бирүен, укучыга реаль җирлеген һәм сәнгати чик-чамасын югалткан әсәрләр тәкъдим итү очракларын да онытырга ярамас. «Шулай чыга бит ул», «Иң кызыгы соңында», «Минем үрдәк, синең үрдәк...» һ. б. шигырьләр шуның ачык мисалы. Әлеге максаты ачык булмау шигъри детальләрдә дә сизелеп кала. Әйтик, «Туфлие сары табанлы» шигырендә бер оялчан кыз тасвирлана. Тик аны бал кортына охшату да (Бал корты ни дәрәҗәдә оялчандыр инде?..) туфли табанының сарылыгын ассызыклау да (бу турыда өч тапкыр әйтелә) әсәргә нинди мәгънә бирә икән?.. Р. Мингалимовны балалар шигъриятендә гаять зур роль уйнаган ритм мөмкинлекләреннән дә ахырынача файдалана дип әйтеп булмый әле.

Болар — хосусый кимчелекләр. Эзләнүләр дәвам итә. Шагыйрь беркемне дә кабатламаган, үзенә генә хас хыялый шигърияте белән балалар күңеленә һаман тирәнрәк үтеп керә бара.

Әлеге дүрт шагыйрь иҗатын гына күзаллау да бүгенге безнең татар балалар поэзиясенең төп үсеш юнәлешен билгеләргә ярдәм итә. Күп тавышлы, көчле рухлы, яңа заман биеклеге алган нәниләр поэзиясе балалар күңеленә үтеп керүнең яңадан-яңа шигъри ачкычларын эзли.

Фәридә Шәмсетдинова

# ТАТАР СИМФОНИК МУЗЫКАСЫ ҮСЕШ ЮЛЛАРЫ

Музыканың үсеше, объектив яшәеш кануннары буенча, вокаль жанрдан инструменталь жанрларга таба бара. Профессиональ милли музыка культураларының аякка басуында һәм төрле музыка жанрларын үзләштерүендә билгеле бер эзлеклелек бар. Алар музыкаль драмалардан операга, аннары программалы симфоник әсәрләрдән тулы канлы симфониягә киләләр. Симфоник музыканың милли культура чикләрендә җанланып үсә башлавын күпчелек тикшеренүчеләр теге яки бу милләтнең рухи культурасы үсеше дәрәҗәсен билгели торган баскыч дип саныйлар. Күренекле совет музыка белгече академик Б. Асафьев, мәсәлән, «ныклы үсеш алган симфония культурасы музыка сәнгатенең профессиональ нигезе нык икәнен күрсәтүче билге» дип яза.

Музыкаль фикерләү алымы буларак, музыка сәнгатенең башка өлкәләренә, опера, оратория, җыр һәм кече күләмле инструменталь әсәрләргә дә йогынты ясаучы, симфония, симфоник сюита һәм поэмалар, увертюра, концерт, вокаль-симфоник характердагы әсәрләр хәзер татар композиторлары иҗатында да елдан-ел зуррак урын ала һәм илнең башка төбәкләрендә дә таныла бара. Совет сәнгатенең тулаем үсеше белән аерылгысыз бәйләнгән бу уңышлар татар совет музыкасының ныклы профессиональ нигезгә корылганлыгы хакында сөйли.

Безнең музыкабыз үз үсешендә күп кенә мөһим баскычлар үтте. Шулар арасында егерменче, утызынчы елларны, Бөек Ватан сугышы чорын, сугыштан соңгы унъеллыкны, ниһаять, соңгы дәверне аерып алырга мөмкин. Бу этап-дәверләрнең һәрберсенә яңа темалар, сюжет-образларны үзләштерү, милли музыка телен формалаштыру, яңарту һәм үстерү хас.

Профессиональ музыка буларак һәркайсының үсеш нигезендә, мәгълүм булуынча, милли (халыкчан) һәм интернациональ (классик) башлангычларның синтезы ята. Халыкчан башлангыч дигәндә, шиксез ки, татар халык иҗаты, аның шигъри һәм музыкаль фольклоры, сурәтле фикерләү өлкәсендә гасырлар буе туплый килгән хәзинәсе, татар әдәбиятыннан алынган сюжетлар, халыкның социаль яшәеше тудырган темалар һәм образлар күз алдында тотыла. Болар барысы татар композиторларына халыкның милли характерына хас үзенчәлекләрне, рухи халәтендәге хасиятләрне, халыкның тормыш-көнкүреше, гадәт-йолалары, табигатькә мөнәсәбәтен, татар милләтенең үткәндәге һәм бүгенге эволюциясен танып белергә һәм иҗатларында гәүдәләндерергә ярдәм итә. Интернациональ, классик башлангыч исә совет сәнгате казанышларыннан, Көнбатыш Европа һәм рус классик музыкасы традицияләреннән иҗади файдалануда, бүгенге чор музыка чараларын куллана белүдә чагыла.

Татар халкы музыкаль иҗатының кайбер үзенчәлекле яклары симфоник музыка үсешендә мәгълүм кыенлыклар да тудырмады түгел. Борынгы традицион татар халык җыры монодик характерда булуы белән аерылып тора. Ул, кагыйдә буларак, ялгыз җырчы тарафыннан башкарыла. Мондый көйләрдә пентатоник ладка корылган интонацияләр өстенлек итә. Халык уен кораллары да егерменче йөз башында күп төрлелек белән аерылып тормый, күбесенчә гармун, скрипка, курай, кубыз кебек уен кораллары кулланыла. Күп тавышлы һәм бай аһәңле оркестрларны эшкә җигү, борынгы җырларны яңа чаралар ярдәмендә, моңарчы бик аз файдаланылып килгән музыка коралларында яңгырату, яңа интонацияләр табу, яңа форма һәм жанрларны барлыкка китерү һич тә ансат хәл ителә торган бурыч булмый.

Бүген исә без бик хаклы рәвештә татар совет музыкасы ифрат актив һәм бәрәкәтле үсеш юлы үтте дип раслый алабыз. Берничә дистә ел эчендә күп төрле му-

зыка жанрлары туды, музыкаль драмалар, опера һәм балетлар, симфоник әсәрләр — бер сүз белән әйткәндә, милли музыка классикасы барлыкка килде.

Татар симфоник музыкасының өлгереп җитүе Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорга туры килә. Композиторларыбызның байтагы бу чорда күләмле симфоник әсәрләр иҗат итүгә (поэма, увертюра, сюита, рапсодияләр, концертлар) керешә һәм алар милли симфоник музыка үрнәкләре булып танила. Ә симфонизм үсешендәге яңа дәвер алтмышынчы елларда башланды: әсәрләрне берничә буын авторлар иҗат итә, шул җөмләдән алтмышынчы елларда мәйданга чыккан яшь буын да актив катнаша; яңа тема һәм образлар, яңа жанрлар аеруча кыю үзләштерелә. Кыскасы, симфоник музыка бөтен татар совет музыкасы үсешен билгеләүче күренеш булып әверелә.

Бу казанышлар һич тә очраклы күренеш түгел иде. Ул татар совет музыкасы үсешенең элгәрге барча еллары белән тыгыз бәйләнгән. Музыкабызның яңа чорда профессиональләшү юнәлешендәге беренче адымнары, инструменталь традицияләренең эз сала башлавы 1905 елгы революциядән соңгы елларда башлана. Бу елларда, татар иҗтимагый тормышында барган үзгәрешләргә нисбәтле рәвештә, рухи хәзинәбездә, шәһәр көнкүрешендә музыка шактый зур урын били. Ул турыдан-туры иҗтимагый-культура тормышындагы яңару процессына хезмәт итә, әдәби кичәләр, төрле драма труппалары спектакльләрендә яңгырый. Тамашачылар массасы өчен ачык концертлар, әдәби-музыкаль кичәләр торган саен күбрәк оештырыла. Татар халык җырлары бу елларда үзенең яшәешендә яңа формалар ала, күп кенә сыйфат үзгәрешләре кичерә. Көйләрне музыка коралларында, ялгыз яисә музыкаль ансамбльләр тарафыннан башкару, шул максатка җайлаштырып эшкәртү гадәткә керә. Алдынгы татар әдипләре, җәмәгать эшлеклеләре симфоник оркестрлар булдыру хакында хыялланалар, инструменталь музыканы үстерүгә даими этәргеч биреп торалар. Музыка тормышында инструменталь башкаручылыкның нык таралып китүе, профессиональ дәрәҗәнең үсә баруы соңга табарак эре һәм кече музыкаль формалар, жанрлар тууына китерә.

Бөек Октябрьдан алып утызынчы еллар башына кадәр татар совет профессиональ музыкасы үсешендә сыйфаты һәм эчтәлеге җәһәтеннән яңа дәвер дәвам итә. Милли культураларны үстерү Советлар илендә дәүләт политикасына әверелә, яңа социалистик культураны барлыкка китерү, яшь иҗат көчләрен тәрбияләү хакында партия һәм совет хөкүмәте даими кайгырта. Бу елларда илебездә яшәүче күп халыкларның музыка тормышында зур үзгәрешләр, моңарчы күрелмәгән күтәрелеш башлана. Урта Азиядә, Казагыстанда, мәсәлән, профессиональ музыканы үстерү мәсьәләләре, халыкның иҗатын җыю, фәнни өйрәнү, эшкәртү белән тыгыз бәйләнештә карала. Татар совет музыкасында да шундый ук тенденция өстенлек итә, халык көйләренә нигезләнгән музыкаль драма, татар совет гавами җырлары алгы планга чыга. Милли музыка телен яңа табышлар, яңа ритм һәм аһәңнәр белән баету процессы шул чор татар көйләре үзенчәлекләрен иҗади үстерү, русның шәһәр җырлары үзенчәлекләрен файдалану, классик музыканың иң гади жанрлары һәм формаларын үзләштерү нигезендә бара.

Егерменче елларда ук инде татар инструменталь музыкасы өлкәсендә мөһим үзгәрешләр барлыкка килә, милли симфонизм элементлары ачык сиземләнә башлый. Татар халык көйләрен эшкәртү культурасы үсә, яңадан-яңа музыка чаралары, формалар үзләштерелә, мөстәкыйль симфоник әсәрләр иҗат итүдә беренче тәҗрибәләр ясала. Биредә В. Виноградов, А. Эйхенвальд кебек, татар профессиональ музыкасын үстерү юлындагы иҗади эзләнүләрдә турыдан-туры катнашкан рус композиторлары эшчәнлеге хакында әйтеп үтәргә кирәк. В. Виноградов, мәсәлән, «Татар сюитасы» (1921 ел), «Шихан» (1924 ел) музыкаль картинасында татар һәм башкорт халык көйләрен файдалана. Бу әсәрләрдә шулай ук Спендиаровның «Кырым эскизлары», Бородинның «Урта Азиядә», Римский-Корсаковның «Шәһрезадә»сы йогынтысы да сизелә. А. Эйхенвальд «Казан татарлары көйләре» дип исемләнгән сюитасына нигез итеп «Каз канаты», «Окоп көе», «Салкын чишмә», «Мөслимә», «Туган тел», «Газизәкәй балдыз» көйләрен ала һәм симфоник оркестр өчен эшкәртә. Мондый тәҗрибәләр татар совет музыкасының симфонизмга табан үсеш алуына билгеле күләмдә этәргеч бирә.

Әмма татар совет музыкасының бу еллардагы төп казанышлары, яңа чорга хас рухы, олы симфоник яңгырашка йөз тотуы, беренче чиратта, Салих Сәйдәшев исеме белән бәйләнгән.

С. Сәйдәшев иҗатында татар совет профессиональ музыка сәнгате ныклы эзгә төшеп, үзенең ышанычлы үсеш юлын таба. Гаять зур талантка, музыкада заман рухын гәүдәләндерү сәләтенә ия булган бу композитор яңа совет чынбарлыгын, Татарстанның якты киләчәген, тормыш һәм хезмәт героикасын җырлаганда, социалистик Ватан, Совет Армиясе, канатлы яшьлек, халыклар дуслыгы темаларын гәүдәләндергәндә халыкның элекке җыр иҗаты традицияләре белән генә чикләнеп кала алмый иде. С. Сәйдәшев иҗатында яңа үсеп килүче милли профессиональ музыка сәнгате өчен иң үткен, иң четерекле проблема — милли музыка телен булдыру проблемасы табигый чишелешен таба. Композиторның иҗади казанышы яңа чынбарлыкны чагылдырган калку, дәртле музыкаль образлар иҗат итүендә генә түгел, ә татар совет профессиональ музыка теленең нигезен салуында, музыканың халыкчан милли стилен, аһәңен тудыруында да иде.

С. Сәйдәшев милли музыка традицияләрен үзенчәлекле формада классик музыка традицияләренә ялгый. Биредә аңа бик сирәк очрый торган мелодик таланты ярдәмгә килә. Композиторның үзе иҗат иткән көйләре гади, әмма алар нурда коендыргандай якты рухлы, һәрберсеннән көч-дәрт ташып тора. Халыкның элекке традицион көйләре белән чагыштырганда, аларда яңа сыйфатлар барлыкка килә. Халык моңнары, татар халык көйләре традициясе рус халкының шәһәр җырлары традицияләре белән табигый рәвештә бергә кушыла бара. Композитор революцион заман рухы белән сугарылган яңа интонацияләр тудыра. Аның бүгенге көнне дә популяр булган җыр-маршлары, дәртле, гайрәтле көйләре турыдан-туры революцион җырлар, гавами совет җырлары тәэсирендә иҗат ителә.

К. Тинчурин, Т. Гыйззәт кебек драматурглар белән берлектә татар совет музыкасы тарихында беренче эре жанр — музыкаль драмалар иҗат итеп, С. Сәйдәшев музыка сәнгатен яңа баскычка күтәрде. Бу музыкаль драмалар өчен композитор бик күп арияләр, ялгыз яисә дуэт белән, шулай ук хор белән башкару өчен җырлар, бию көйләре, увертюралар яза. Музыка белгечләре һәм галимнәр бик хаклы күрсәтеп үткәнчә, С. Сәйдәшевнең музыкаль драмалары соңрак опера, балет кебек эре жанрлар, симфоник әсәрләр иҗат итүгә җирлек әзерли. «Сүнгән йолдызлар», «Галиябану», «Казан сөлгесе», «Наемщик», «Таһир-Зөһрә», «Кандыр буенда» драмаларына язылган увертюралар, бию көйләре чынлыкта милли симфонизмның юл башы иде. Күпләр аларны хәзер дә мөстәкыйль симфоник әсәрләр буларак кабул итәләр. Увертюраларында С. Сәйдәшев спектакльнең тулаем концепциясен бирә. Төрле характердагы темаларның (мәсәлән, актив һәм лирик башлангычларның) бер-берсенә каршы куелуында татар симфоник музыкасының соната төрендәге әсәрләре башлангычын күрми мөмкин түгел. Музыкаль драмаларның шушы инструменталь сәхифәләрендә халык тормыш-көнкүреше, бәйрәмнәре, хезмәт күренешләре гәүдәләнә. Боларда чын мәгънәсендә татар милли симфонизмының күп кенә мөһим сыйфатлары туплана. Милли музыка теле хасиятләрен композитор инструменталь музыка өлкәсенә күчерә. Иң әһәмиятлесе, ул милли характерга ия булган инструменталь тематизм нигезләрен сала, аны үстерү юлларын билгели, шуңа ярашлы инструменталь фактураны тудыра. «Галиябану» музыкаль драмасының увертюрасы моңа иң гади мисал була ала. Анда файдаланылган халык көе интонацияләре яңа инструменталь сыйфатлар ала. Шул ук вакытта әле монда халык уен кораллары ансамбльләреннән килә торган башкару традицияләре йогынтысы да сизелә. Шушында ук иң гади симфоник жанрларның берсе попурри принципларының тәэсиреннән әле азат булмаган сюита да формалаша, симфонизмның жанрлы-сурәтле төре туа. Кыскасы, С. Сәйдәшев иҗат иткән күп санлы увертюралар, бию көйләре, сюиталар милли симфонизмның киләчәге өчен нигез була.

Утызынчы еллар ахырын татар совет музыка сәнгате үсешендә яңа мөһим этап дип бәяләүчеләр бик хаклы. С. Сәйдәшевтән тыш, бу чорда яшь композиторлар Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, А. Ключарев, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллиннар кыю рәвештә һәм зур дәрт белән иҗат эшенә керешәләр. Музыка сәнгатебездә опера һәм балет жанры үзенә лаеклы урынны ала. Музыканың милли теле-аһәңе яңа сыйфатлар белән баетыла. Аның нигезен халык көе традицияләре, милли башлангыч белән рус классик музыкасы традицияләре, совет музыка культурасы казанышларының синтезы тәшкил итә. Егерменче елларда С. Сәйдәшев күбесенчә үз чорының көй-моңнарына, шуларның интонацион төзелешенә таянып иҗат итсә, утызынчы елларда әлеге җирлек шактый киңәйтелә. Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи һәм башкалар үз әсәрләрендә борынгы озын көйләр традицияләрен дә, кыска җыр, авыл көйләре, такмак, катлаулы көйләрнең жанр үзенчәлекләрен дә файдаланырга омтылалар. Мелодиканың маршны хәтерләтүче актив төре үсүен дәвам иттерә, шул ук вакытта романс тибындагы яңа көйләр барлыкка килә.

Әлеге чорда композиторларның классик музыканы киңрәк колач белән үзләштерергә керешүләрен әйтергә кирәк. С. Сәйдәшевнең егерменче еллар иҗатында без рус халкының шәһәр көнкүрешенә хас көйләреннән оста файдалануын күргән идек. Композитор күбесенчә классик музыканың садә формалары һәм жанрларына мөрәҗәгать иткән. Утызынчы елларда татар композиторларының профессиональ дәрәҗәсе тагын да үсә. Алар, рус классик музыкасының бай һәм өлгереп җиткән традицияләренә кыю таянып, инструменталь музыканың катлаулы формаларына, опера һәм балетлар иҗат итүгә алыналар. Профессиональ музыканың тека күтәрелеше, тематика һәм жанр төрлелеге милли симфонизмның төрле яссылыкларда күпьяклы булып формалашуына китерә.

Симфоник музыканың туу, өлгерү процессы бу чорда күп төрле жанрларда дәвам итә. Халык көйләрен эшкәртү фольклор серләрен аңлауны тирәнәйтергә һәм гармонияләштерү принципларын үзләштерүгә ярдәм итсә, композиторларның җыр иҗаты өлкәсендә эшләүләре совет симфонизмына хас булган җыр-көй башлангычын үстерүгә этәрә. Мәсәлән, А. Ключарев үзенең сюиталарына лирик-гражданчыл характердагы җыр иҗаты аша килә. Көйлелек—композитор тудырган симфоник әсәрләрнең иң күркәм сыйфатларыннан берсе. Аның музыка фольклоры өлкәсендәге эшчәнлеге дә киң мәгълүм. Халык көйләрен композитор даими җыя, өйрәнә, иҗатында файдалана. Аның симфоник әсәрләрендә еш кына нинди дә булса халык көен ишетәсең. Ул композитор әсәренең тукымасына кереп, органик рәвештә аңа береккән була. М. Мозаффаровның утызынчы елларда иҗат иткән җырларында исә (мәсәлән, «Җи-

ләк жыйганда», «Сайра, сандугач») ниндидер иркенлек, импровизация, поэмага якынлык сизелә. Ул җырларда композиторның киләчәк симфоник әсәрләренең стиль үзенчәлекләре калыплана. Композиторлар кече күләмле инструменталь әсәрләр иҗат итеп, инструменталь тематизмга ныграк ия була баралар, катлаулы инструменталь формаларның (соната, рондо, фуга) серләренә тирәнрәк төшенәләр. Төрле симфоник жанрларда да көчләрен сынап карыйлар (мәсәлән, Ф. Яруллин һәм Н. Җиһанов симфонияләре, А. Ключаревның «Галиябану» сюитасы, М. Мозаффаровның кече күләмле сюиталары һ. б.).

Милли симфонизмның формалашуында татар опера һәм балет әсәрләре зур роль уйный. Н. Җиһановның «Качкын», «Ирек», «Алтынчәч», «Түләк» опералары, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетында симфонизм төп башлангыч булып тора.

Нәкъ менә опера һәм балет кебек эре жанрларда зур тарихи-социаль, әхлакый-этик идеяләрне үсештә гәүдәләндерергә мөмкин. Н. Җиһанов операларында симфонизм үзен нык сиздерә, ул музыкаль темаларның спектакль барышында эзлекле төстә үсә килүендә чагыла. Композитор иҗатында опера жанрының зур урын тотуы, югары профессиональ осталык дәрәҗәсе аның симфоник музыка иҗаты өчен алшартлар тудыра. Н. Җиһанов операларында увертюралар, эпизод-күренешләр, бәрелеш күренешләре, сюита-биюләр еш очрый. «Качкын» операсының увертюрасы мөстәкыйль симфоник концепциясе белән аерылып тора. «Алтынчәч» операсыннан аерым сурәт-эпизодларны да милли симфонизмның үзенчәлекле үрнәкләре дип атарга мөмкин.

Милли музыка культурасы үсешендә «Шүрәле» балетының нинди зур әһәмияткә ия булуы һәркемгә мәгълүм. Аның музыкасы тирән халыкчанлык сыйфатларына ия булу белән бергә, югары симфонизм рухы белән сугарылган. Балеттагы бер-берсеннән аерылып торган өч образлы-интонацион сфера — фантастик (Шүрәле һәм урмандагы җен-пәриләр), лирик (Былтыр — Сөембикә линиясе), халык көнкүреше күренешләре, милли рухны саклаган килеш, классик музыка кануннарына да җавап бирә. Алар симфоник эзлеклелек белән әсәрнең буеннан-буена күп планлы үсеш баскычлары үтәләр.

Утызынчы еллар татар совет музыкасында симфоник башлангычны үстерү, аның иҗтимагый яңгырашын киңәйтү, мәгънәви эчтәлеген тирәнәйтү ягыннан зур бер этап була, татар симфоник культурасын тудыруга шартлар өлгереп җитә.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы ун ел татар симфоник музыкасының киң мәйданга чыккан чоры булды. Татар совет музыкасының өлгереп җитүе табигый рәвештә симфоник әсәрләр тудыруга китерде, профессиональ музыка яңа сыйфат баскычына күтәрелде. Шунысы аеруча характерлы, кыска бер чор эчендә симфоник поэмалар (Н. Җиһановның «Кырлай», М. Мозаффаровның «Г. Тукай истәлегенә», «М. Вахитов истәлегенә», А. Вәлиуллинның «Тынычлык сугышны җиңәр», «Яшьлек»), скрипка белән оркестр, фортепьяно белән оркестр өчен язылган беренче концертлар (М. Мозаффаров, Р. Яхин, А. Леман әсәрләре), симфоник сюиталар (А. Ключарев, Н. Җиһанов, А. Леман әсәрләре), беренче увертюралар һәм рапсодияләр иҗат ителә. Беренче татар симфонияләре дә (А. Ключаревның «Идел» симфониясе, А. Вәлиуллин симфонияләре) шушы ук чорда тудырыла. Шулай да әлеге чорда язылган татар симфоник әсәрләре арасында кече симфоник жанрлар өстенлек итә, авторлар әсәрнең программалылыгына юнәлеш тоталар, фольклорга таяналар. Шул ук вакытта рус классик симфонияләре традицияләреннән дә файдаланып иҗат итәләр, совет музыка сәнгатенең гомуми үсеш процесслары йогынтысын кичерәләр.

Татар симфоник музыкасы үсешенең беренче дәверендә фольклор элементы, халыкның музыкаль иҗатыннан файдалану зур урын тота. Беренче сюиталар, поэма, концерт, рапсодияләрдә һәркемгә яхшы таныш булган халык көйләрен ишетәсең, әсәрләргә алар еш кына хәтта тоташ килеш килеп керә. Бу хәл, бер яктан, композиторларның симфония чаралары мөмкинлек биргән тирәнлек һәм колач белән халык көйләренең киң мәгънәсен, төп хасиятләрен ачарга, халык тормыш-яшәешенең җанлы сурәтен бирергә омтылулары белән аңлатылса, икенче яктан, халык моңнарының, музыкаль уй-фикер йөртү алымы буларак, симфонизм элементларына ия булуына бәйләнгән. Дистәләрчә еллар, гасырлар буе халык күңелендә эшкәртелеп, мәгънәви баетылып килгән җырларның интонацияләре үсешендә камил логика һәм эзлеклелек бар. Симфонизм аларның гомумиләштерелгән лад-интонация корылышында, озын көйләрнең эзлекле мелодик үсеш-хәрәкәткә корылган булуында чагыла. Мәсәлән, «Зиләйлүк» көенең интонацияләре, чын-чыннан симфоник эзлеклелек белән үсә барып, дулкынландыргыч драматик кульминациягә китерә.

Димәк, татар симфоник музыкасының дөньяга килүе, формалашуы, музыка сәнгатебезнең профессиональ дәрәҗәсе өзлексез күтәрелүе иҗади тәҗрибәне даими рәвештә баета бару нәтиҗәсе булса, музыка фольклоры, көй-моңнарның эчке симфоник хасиятләре бу процессны тагын да тизләтергә ярдәм итә.

Татар симфонизмы үсешендә рус классик музыкасының да уңай йогынтысы аз түгел. Ул йогынты халыкчанлык, реализм принципларының ачыклыгында, әсәрләрнең гомумиләштерелгән программасы булуында да күренә. Татар композиторларының бу чорда иҗат иткән әсәрләре билгеле бер программага корылган. Симфоник әсәрләрнең исемнәре үк шуны белдереп тора. М. Мозаффаровның Г. Тукай, М. Вахитов истәлегенә багышланган поэмалары, А. Ключаревның «Идел» симфониясе, Н. Җиһановның әдәби әсәрләргә нигезләнеп язылган «Кырлай» симфоник поэмасы һәм «Нәфи-

сә» увертюрасы әнә шундыйлар рәтеннән. М. Мозаффаров музыка чаралары белән татар халкының сөекле шагыйре Г. Тукай, атаклы большевик-революционер М. Вахитов образларын гәүдәләндерә, алар яшәгән чорның атмосферасын тудырырга омтыла. А. Ключарев симфониясендә Идел буе халыкларының дуслыгы, фидакарь хезмәте тасвирлана.

Н. Җиһановның 1946 елда язылган «Кырлай» симфоник поэмасы шагыйрьнең бала чагын, табигать моңын, халык күңелендәге хис-тойгыларны хикәя итә. Глинка һәм Римский-Корсаковтан килә торган сурәтле симфонизм традициясен иҗади файдаланып һәм шул ук вакытта халыкчан стильне саклап, композитор бөек шагыйребезнең туган ягын, табигатенең, халкының эчке матурлыгын садә, йомшак аһәңле көйдә бирә алган.

Симфоник әсәрләрдәге халыкчан башлангыч композиторларның милли темалар, сюжет һәм образларга мөрәҗәгать итүләрендә дә чагыла. Татар әдәбияты әсәрләре, халык тарихының мөһим чорлары, халыкның тормыш-яшәеше татар симфонизмының төп темасына әверелә. Халыкның үз көйләре, борынгы һәм бүгенге заман җырлары белән бергә, композиторлар халык көйләренә якын торган, формасы һәм төзелеше буенча катлаулырак, гомумирәк темаларны да эшкәртәләр. Үзәккә алынган образларның милли характеры татар симфоник музыкасының милли стиль һәм яңгырашын тудыруга нигез бирә.

1950 елларда симфоник музыканың үзенчәлекле өлкәсе булган концерт жанрында күркәм уңышларга ирешелә. Әлеге жанрны үстерүгә М. Мозаффаров, Р. Яхин, А. Леман кебек композиторлар күп хезмәт куя. А. Леманның фортепьяно белән оркестр, скрипка белән оркестр өчен язылган концертлары кызыклы яңалык алып килә. Аларда классик музыкаль форма халыкның музыкаль традицияләре белән үрелеп бара. Р. Яхин да фортепьяно белән оркестр өчен язылган концертында Рахманинов концертларына якын торган классик формадан файдалана. Шул ук вакытта автор халкыбызның озын көй стихиясен дә нечкә тоя, әсәрендә үз импровизациясенә төрле халык мотивларын бик оста чигеп бара. Концерт, тыңлаучыларны шатлык хисләренә уратып, тормыш романтикасына алып кереп китә, яшәешкә мәхәббәтне раслый. Әсәрдәге драматик, лирик яисә элегия характерындагы темаларның логик эзлеклелек белән бер-берсен алыштырып торулары, шуларга актив, хәрәкәтчән мотивларның килеп кушылуы күңелне әсир итә.

М. Мозаффаров концертлары исә икенче бер үзенчәлеге — иркен, җиңел моңы, скрипканың шагыйранә тел белән күңел серләрен уртаклашуы, тыйнак, басынкы, тирән хисләр дөньясы белән үзенә тарта. Концертның буеннан-буена диярлек иркен поэтик импровизация өстенлек итә, көйләр бер-бер артлы туып, бер-берсен алыштыра-күмә барып, хис-тойгыларның өзлексез хәрәкәтен тудыралар.

Шушы ук елларда симфония жанрында да кызыклы үрнәкләр иҗат ителде. «Идел симфониясе»ндә (1955 ел) А. Ключарев, әйткәнебезчә, халыклар дуслыгы темасын күтәрә, аларның иҗади хезмәтен данлый. Автор монда татар һәм рус музыкасы интонацияләре, ритмнары синтезын барлыкка китергән. Әсәрдә көй-җыр башлангычы зур урын тота, лиро-эпик темалар бию көйләре, көнкүреш сәхифәләре белән оста үрелеп бара. Аның интонацияләр корылышы, темаларны үстерү ысулы композиторның җыр иҗаты үзенчәлекләрен хәтерләтә.

Сугыштан соңгы ун ел — татар симфоник музыкасы үсешендә аеруча әһәмиятле дәвер. Композиторларыбызның шактый өлеше симфоник әсәрләр язуда үзенең мөмкинлекләрен сынап карый, тәҗрибәләр ясый. һәм шулар арасында җитди уңыш казанганнары да аз түгел. Беренче симфонияләр һәм симфоник поэмалар гына түгел, увертюра, сюита, рапсодия, концертлар да иҗат ителде. Н. Җиһанов симфоник поэма, сюита һәм увертюра жанрларына нигез салуда зур хезмәт куйса, А. Ключарев беренче татар симфониясен тудыручылардан булды, шулай ук симфоник сюита жанрына да ул беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итте. М. Мозаффаров та симфоник поэмалары, скрипка һәм оркестр өчен концертлары белән татар симфонизмын үстерүгә зур өлеш кертте. А. Леман, Р. Яхин беренче булып концерт жанрына юл ачтылар. Симфоник сюиталары, рапсодиясе белән татар музыка сәнгатенең югары профессиональ культурасын үстерүгә өлеш керткән А. Леманның иҗат үрнәкләре дә игътибарга лаек. Симфоник жанрлар А. Вәлиуллин иҗатында төп урынны алды.

Ниһаять, симфоник жанрларның татар совет профессиональ музыка сәнгатен катлаулы инструменталь формалар белән баетуын әйтеп китәргә кирәк. Симфоник оркестр музыкабызга яңа төс-бизәкләр, бай аһәңнәр алып килде. Татар совет музыкасы бу чорда катлаулы инструменталь темаларны үстерүнең гомумиләштерелгән симфоник ысулларын үзләштерде, профессиональ музыкабыз, образлар драматургиясе серләренә ия булып, яңа сыйфат баскычына күтәрелде.

Илленче еллар ахыры, алтмышынчы еллар башында татар совет музыкасы үсешендә яңарыш дәвам итә.

Бу чорда татар композиторларының яңа буыны — М. Яруллин, Ф. Әхмәтов, Р. Билялов, Р. Еникеев, И. Якубов, Ш. Шәрифуллин кебек талантлы яшь композиторлар иҗат мәйданына чыга. Алар профессиональ музыкабызга заманга хас ритмнар, яңа сулыш алып киләләр. Шул ук вакытта өлкән һәм урта буын композиторлары Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, А. Леман, А. Монасыйпов, А. Вәлиуллиннар да зур дәрт һәм энергия белән иҗат эшләрен дәвам иттерәләр. Алтмышынчы ел-

ларда профессиональ музыка жанрларының эволюциясе дәвам итә, заман таләпләренә ярашлы рәвештә милли тел-стиль чаралары яңару кичерә, музыкаль фольклористика халык көйләренең моңарчы кузгатылмаган катламнарын күтәрә. Симфоник музыка һәм инструменталь-камера музыкасының эре һәм кече төрләре профессиональ музыканың үзәк жанрлары булып әверелә. Музыка теле чаралары киңәю белән бергә төрле музыкаль жанрларның чикләре хәрәкәткә килә, инструменталь әсәрләрдә вокаль музыка чаралары, хәтта театр, рәсем сәнгате, әдәбият, кино кебек мөстәкыйль сәнгать төрләренең сурәт алымнары кулланыла башлый, музыка сәнгатенең төрле форма һәм жанрлары арасында синтез процесслары нык көчәя. Композиторларның симфоник музыка өлкәсендәге иҗаты, төрле жанрларга мөнәсәбәте катлаулы төс ала. Алар бу өлкәдә инде үзләрен бик иркен хис итә, өлкән яшьтәгеләре генә түгел, яшь буын вәкилләре дә симфоник музыканың барлык төрләрендә диярлек кызыклы әсәрләр тудыралар.

Алтмышынчы еллардан башлап, татар профессиональ музыкасында халыкчан һәм интернациональ башлангычларның һәр икесе яңача трактовка ала. Татар музыка фольклорын өйрәнү эше көчәя, тармаклана, халык җырларының иң тирәндә яткан катламнары үзләштерелә бара. Композиторлар аларны яңача ишетә, бүгенге көн музыка чаралары ярдәмендә аларга заманча яңгыраш бирәләр. Халыктан җыйган музыка материалы белән хәзерге заман композиция ысуллары, гәүдәләндерү чаралары, форма тудыру алымнары бергә кушылып, үзенчәлекле, гаять кызыклы күренеш барлыкка китерә. Бу процесс бүгенге татар музыкасында шактый зур урын тота. Мисал өчен Р. Яхинның кайбер романсларын, Р. Биляловның фортепьяно өчен язылган әсәрләрен, Н. Җиһанов, М. Яруллин сюиталарын, А. Монасыйпов, Р. Еникеев, Ш. Шәрифуллин әсәрләрен әйтергә мөмкин.

Татар композиторларының алтмышынчы-җитмешенче елларда иҗат иткән симфоник әсәрләрендә халыкчан башлангыч заманга яраклы рәвештә бутәнчәрәк хәл ителә. Бүгенге көннең композиторлык техникасын тулы файдаланып, композиторлар халык көйләренең моңарчы билгеле булмаган хасиятләрен, фәлсәфи-лирик тирәнлеген ачарга омтылалар, көйләрне заманча «тоялар». Көйләр әсәрләрнең образ корылышына нисбәтле рәвештә үзгәртелә, аларның теге яки бу сыйфаты үстерелә. Икенчедән, композиторларыбыз совет музыкасы туплаган гаять зур рухи хәзинәдән, егерменче йөз музыкасы классиклары Шостакович, Прокофьев, Стравинский, Барток иҗатларында салынган традицияләрдән файдаланалар. Н. Җиһановның «Сабантуй» симфониясе, бөек Җиңүнең утыз еллыгына багышланган алтынчы симфониясе, А. Монасыйповның «М. Җәлил» поэма-симфониясе, Ф. Әхмәтовның «Фәрит Яруллин истәлегенә» исемле симфоник поэмасы заманыбызның олы темалары һәм образларына мөрәҗәгать итү, чор таләпләренә җавап бирерлек әсәрләр тудыруның күркәм үрнәкләре булып тора. Болар шулай ук музыка сәнгатенең иң югары формаларына ия булуны күрсәтә.

Бу чорда язылган симфоник әсәрләр характерлары белән бер-берсеннән нык аерыла. Н. Җиһанов симфонияләренә эпик колачлылык хас булса, А. Монасыйповның симфоник әсәрләре драматик симфонизм юнәлешен үстерүгә ярдәм итә. Аның һәр әсәре форма өлкәсендә нинди дә булса яңалык алып килә. Ф. Әхмәтовның «Фәрит Яруллин истәлегенә» поэмасы татар симфоник музыкасы үсешендә әһәмиятле вакыйга булды. Үзенчәлекле милли музыкаль фикерләү рәвеше, цикллар төзелешендәге төгәл эзлеклелек, бүгенге заман композиторлык техникасына тулысынча ия булу, мелодик материалның байлыгы — бу сыйфатлар Ф. Әхмәтовның симфоник музыка өлкәсендәге зур мөмкинлекләре хакында сөйли.

Әйткәнебезчә, татар симфоник музыкасының жанр диапазоны хәзер нык киңәйде, аларның үзара бәйләнешләре катлаулы төс алды. Сюита, увертюра, поэма, концерт жанрлары эчке хасиятләре, әсәрне бер бөтен итеп берләштерү һәм теманы үстерү алымнары ягыннан симфониягә тартылалар. Симфоник поэма һәм камера-вокаль цикллар белән ике арада соңгы елларда вокаль-симфоник әсәрләр туа башлады. Р. Еникеевнең «Карьят батыр», М. Яруллинның «Сандугач һәм чишмә», А. Монасыйповның «Тукай аһәңнәре» — нәкъ менә шундый әсәрләр. Болар шулай ук симфонизмның барлык музыка өлкәләренә һәм төрләренә көчле йогынты ясавын раслыйлар. Н. Җиһановның «Симфоник новелла»лары, Р. Биляловның концерт-симфониясе, А. Монасыйповның поэма-симфониясе, вокаль-симфоник әсәрләр, соңгы елларда мәйданга чыккан башка күп үзенчәлекле иҗат үрнәкләре, һичшиксез, әле махсус өйрәнүне, тирән фәнни анализлауны таләп итә. Әмма шунысы бәхәссез ки, татар симфонизмының бүгенгесе генә түгел, киләчәге дә өметле һәм якты. Симфоник әсәрләрнең күпчелегенә хас югары сәнгатьлелек хасиятләре, образларның тирән эшләнеше, милли характеры, югары композиторлык техникасы татар профессиональ музыкасының киләчәк уңышларына ныклы ышаныч уята.

СССР халыкларының профессиональ музыка өлкәсендәге казанышлары — законченлыклы һәм объектив күренеш. Совет сәнгатен, бердәм совет культурасын төзешүдә илебезнең барлык халыклары катнаша. Татар симфоник музыкасы татар совет музыкасы тарихы, бөтен совет сәнгатенең үсеш процессларына турыдан-туры һәм аерылгысыз бәйләнгән. Татар симфонизмы ирешкән биеклекләр — социалистик җәмгыятебезнең мөһим уртак казанышы.

Эльмира Бариева

# БӘЙЛӘНЕШ СЕРЛӘРЕН АЧКАНДА...

Һәр әдәби күренеш билгеле бер җәмгыять җирлегендә җитешә, аның материаль һәм социаль туфрагында тернәкләнә. Икенче төрле әйткәндә, иҗтимагый тормыш һәм аның барышы әдәбиятның үсеш хәрәкәтен җитәкләүче көч булып тора.

Әдәби үсеш серләрен ачыклау юнәлешендәге эзләнүләргә һәр заман үзеннән билгеле өлеш кертсә дә, әдәбият-сәнгать күренешләренең тарихи үсеш закончалыклары ахырынача ачылып бетмәгән әле. Бу—совет әдәбият гыйлеменең дә үзәгендә торган мәсьәлә. Дөрес, бүген әлеге юнәлештәге эзләнү-тикшеренүләр башка теоретик югарылыкта алып барыла, шуңа карамастан, мәсьәлә һаман көн тәртибендә кала бирә.

Хәзерге этапта әдәбиятның иҗтимагый роле артты, фән әдәбиятның социаль потенциалын һәрьяклап ачу максатына юнәлдерелгән яңа методологик проблемалар чишү эшенә кереште, буржуаз дөньяда киң җәелеш тапкан «массачыл культура» теориясенә, яңа модификацияләргә кергән вульгар социологизмга, әдәби үсешне техник прогресска гына бәйләп аңлатучы һәм шул рәвешле, әдәбиятның мөстәкыйль үсеш үзенчәлеген берьяклы күрсәтүче яисә бөтенләй инкарь итүче технократик концепцияләргә каршы көрәш көчәйде. Болар барысы бүген әдәбият социологиясе мәсьәләләренең кабат җанлануына китерде.

Социология—хәзерге тәнкыйть фронтында да актуаль мәсьәлә. Аның әһәмияте партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы 1972 елгы карарында да күрсәтелгән иде. «Сәнгать күренешләрен тормыш күренешләре белән чагыштырып алып барырга» дигән тезис астында әлеге карар нәкъ әдәбият социологиясе мәсьәләсен истә тотты һәм бүгенге эстетик-теоретик фикер үсешендә аның тагын да тирәнрәк өйрәнелергә тиешлегенә басым ясады.

Җитди методологик проблемалар анализлау зарурияте көннән-көн ачыграк расланый барган бүгенге эстетик проблематика һәм идеологик көрәш фактлары безне 20 нче еллар совет әдәби тәнкыйте тәҗрибәсенә алып кайта. Мәгълүм булганча, 20 нче елларда әдәби иҗатның иҗтимагый детерминациясе мәсьәләсе аерым игътибар үзәгенә куела. Татар тәнкыйте бу чорда, рус совет әдәбият белемендәге кебек үк, әдәбиятның асылы, аның җәмгыять белән катлаулы элемтәсе мәсьәләләрен фәнни-теоретик эшкәртү эшенә керешә.

Әдәбиятны җәмгыять үсеше закончалыклары белән бәйләп өйрәнү үрнәкләрен марксизм-ленинизм классиклары үз хезмәтләрендә даими күрсәтеп киләләр, әдәби күренешләргә бәя бирүдә методологик ачкыч булырлык тирән күрсәтмәләр калдыралар. Әмма 20 нче еллар тәнкыйть практикасында аларның конкрет кулланылышы авырлык белән бара. Әдәбият белгечләре әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен хәл итүдә революция раслаган рухны үткәрергә тырышып, һәртөрле буржуаз карашларга (безнең шартларда исә, буржуаз милләтчелеккә), сәнгатьнең сыйнфыйлыгын, иҗатның иҗтимагый мәгънәсен, аның социаль чынбарлыкка бәйләнешен кире каккан субъективизмга каршы көрәшкә күтәреләләр. Әдәби тәнкыйтьтә марксистик положениеләрнең тиешле тирәнлектә үзләштерелмәве, марксизмның бай әдәби концепциясеннән аз мәгълүматлы булу әлеге көрәш шартларында зур катлаулылыклар китереп чыгара, совет әдәбияты белемендә марксистик социологиянең ныклы урнашып китүенә җитди комачаулык ясый. Татар тәнкыйте әдәбият социологиясе проблемаларын хәл иткәндә, беренче чиратта, егерменче еллар рус совет әдәбият белеме казанышларына таяна, аның белән бер юнәлештә барырга тырыша. Шуңа күрә бу юнәлештәге җитди уңышлар да, һәртөрле хаталар да билгеле бер дәрәҗәдә рус әдәбият фәне тәҗрибәсе белән бәйләнгән.

Тәнкыйтькә тирән марксистик хәзерлек белән килгән әдәбиятчылар Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Сәгъди һәм башкалар әдәбиятны социаль-экономик шартлар, халык тарихы белән бәйләп аңлау һәм аңлатуда житди уңышларга ирешәләр, татар тәнкыйтендә марксистик әдәбият социологиясен урнаштыруга үзләреннән өлеш кертәләр. Әмма шуның белән бергә, аларда диалектик материализм принципларын әдәбиятка механик рәвештә күчерү кебек ялгыш тенденцияләргә ияру очраклары да күренә.

Шулай да, егерменче еллар тәнкыйтенең әдәбият социологиясе мәсьәләләре буенча тупланган мирасына тулаем вульгар социологизм мөһере сугу дөрес булмас иде. Иҗтимагый-тарихи үсеш һәм әдәбият арасындагы үзенчәлекле мөнәсәбәтләрне яктырту, идея-эстетик процессны аңлау бу чор тәнкыйть практикасында берьяклы янсә гел вульгарлаштырылып кына бармый. Бүген без шул чорның дөрес фәнни положениеләрен, уңай фикер һәм карашларын торгызып карарга, әдәбият социологиясе мәсьәләләренең прогрессив хәл ителү үрнәкләрен сайлап алырга, аларга үзебезнең бәябезне бирергә бурычлыбыз.

Билгеле, болай дию һич тә мәсьәләнең уңай ягын гына күрергә тырышу булып аңлашылмасын иде, без 20 нче еллар татар совет тәнкыйте практикасында булган ялгышларга да күз йомарга җыенмыйбыз. Вульгар социологизм—20 нче еллар тәнкыйтенең үсеш авыруы, ул иң авторитетлы, әдәби тәнкыйтьнең уртасыннан атлап баручы тәнкыйтьчеләрне дә читләтеп узмаган. Әдәби эрудициясе, фәнни фикерләве, марксистик хәзерлеге кинрәк, тирәнрәк булган саен, әдәби тәнкыйтьчеләр вульгар социологизм чиреннән шул кадәр кыюрак арыналар. Гомумән, марксистик-ленинчыл эстетика фәне үзе әнә шундый катлаулы көрәш шартларында формалаша.

Әдәбиятның җәмгыять белән бәйләнеше мәсьәләсенә игътибар татар тәнкыйтендә егерменче еллар башында ук көчәеп китә. Бу юнәлештә, беренче чиратта, Г. Ибраһимов мәкалә һәм хезмәтләренең әһәмиятен күрсәтеп узарга кирәк. «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» (1922), «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» (1922), «Татар әдәбиятын тикшерү юлында» (1923), «Пролетариат әдәбияты турында» (1924) кебек хезмәтләрендә ул әдәбият социологиясенең эчтәлеген күрсәтергә, фәнни социологияне ачарга омтыла.

«Татарстан» газетасы битләрендә Җ. Вәлиди белән алып барылган мәгълүм бәхәс вакытында ук, мәсәлән, Г. Ибраһимов әдәби күренешләргә бәя бирүдә Җ. Вәлидинең эстетизмы белән килешмәвен белдерә, әдәбиятны җәмгыять һәм сыйныфлар белән тыгыз мөнәсәбәттә карауны яклап чыга.

«Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән мәкаләсендә Г. Ибраһимов (ул аны Җ. Вәлиди белән бәхәс артыннан ук бастыра) әдәбиятны һәм аның тарихын социологик планда өйрәнү мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә куя. Бирелгәге гомумиләштерүләр һәм кайбер фәнни нәтиҗәләр, бер яктан, бәхәскә соңгы сүз төсен алса, икенче яктан, аларда әдәбият социологиясенең нигезенә ята торган әһәмиятле теоретик положениеләр дә формалаштырыла.

Әдәбият социологиясен ачу, Г. Ибраһимов фикеренчә, аны «иҗтимагый-сыйнфый нигезләре буенча тикшерү»дән гыйбарәт. Бу юнәлештә төп рольне язучы шәхесе яки башка тарихи факторлар белән чикләмичә, «мәмләкәтләр тарихындагы икътисади үзгәрешләрдән» эзләү файдалы нәтиҗәләргә китерәчәк, ди ул. «Әдәбиятлар, фәлсәфәләр, гыйльми ысуллар, диннәр, әхлаклар, кыскасы, бөтен идеология хезмәтләренең һичбере күктән яумаган кебек, нинди дә булса бер даһиның тик үз башыннан уйлап чыгаруы белән дөньяга килмиләр. Боларның фикерләре, рухлары, мөндәриҗәләре—һәммәсе тарихның мәгълүм бер матди, иҗтимагый катлаулары туфрагында үсеп чыга торган чәчәкләре генәдер»[1]. Бу факт исә әдәбиятны һәм әдәби күренешләрне үзләрен тудырган социаль-экономик җирлек белән тыгыз бәйләп өйрәнү зарурияты күрсәтеп тора. Әдәбият, әдәби күренеш һәм әдәби хәрәкәтләрне тикшерүдә мондый алымны Г. Ибраһимов «бердәнбер дөрес юл» дип бәяли.

Әлеге бәйләнешнең конкрет очракларда нинди рәвеш алуы һәм нинди формалар аша башкарылуы тегәл күрсәтелмәсә дә, Г. Ибраһимов тарафыннан тәкъдим ителгән социологик принцип заманы өчен гаять зур әһәмияткә ия. Ул татар әдәби тәнкыйтендә чын фәнни ачыш дип саналырга лаеклы. Татар тәнкыйтьчеләренең әдәбиятны халык тарихы һәм аерым социаль-экономик җирлек белән бәйләп өйрәнә башлауларында, һичшиксез, Г. Ибраһимовның роле зур.

Дөрес, Ибраһимов мәкаләләрендә «марксистлар өчен тарихның бөтен материалы—идеологиянең, әдәбиятның бөтен тармаклары һәммәсе дә тик үткән тормыштагы техниканың, иҗтимагый-икътисади эшләрнең өскә чыгарган җимешләре генәдер»[2] кебек бер яклырак фикерләр дә әйтелә. Әмма Г. Ибраһимов әдәбиятның социаль детерминациясен ачуны һич кенә дә үзмаксат итеп алмый. Иске методларга, «әдәбият әдәбият өчен генә, ул башка һичбер максуд юлында корал булырга тиеш түгел дигән груһлар»га, «әдәбиятны тикшергәндә «алладан», «тәкъдирдән» яки аерым та-

---

[1] «Безнең юл», 1922 ел, 2 сан.
[2] Ибраһимов Г. «Татар әдәбиятын тикшерү юлында», «Мәгариф» журналы, 1923 ел, 3—4 саннар.

ғантлардан сәбәп эзләүчеләргә» кискен отпор бирү өчен ул әдәбиятның иҗтимагый тормыш продукты булуы хакындагы марксистик положениене аерата көчле акцент белән күрсәтергә тиеш була. Г. Ибраһимов әдәбиятны тормыш күренешләрен үзгәрешсез-нисез генә күрсәтеп баручы, көзге кебек кенә чагылдыручы бер корылма итеп күз алдына китерми, әдәби әсәрдә тормышның «...әдәбият аркылы гәүдәләндерелгән якларын» эзли.

«Әдәбилек, тел, өслүп әдәби кыйммәт белән бер дәрәҗәдә менә шул ике ноктага (әдәбиятның иҗтимагый һәм сыйнфый табигатен күрсәтүгә — Э. Б.) тукталмаса, мәсьәлә бу эшне бушка бушатуга, сандугачның тавышы матур, төсе чуар икән, ул бик шәп кош икән дигән кебек нәрсәгә әйләнеп калачактыр» [1], — дип яза Г. Ибраһимов, бу инде әдәби тәнкыйтьтә социаль һәм эстетик анализ берлеген яклау дигән сүз. Автор әдәбият һәм сәнгатьнең үз хосусый үзенчәлекләренә генә таянып эш итүдән ерак торган кебек, әдәби тәнкыйтьтә иҗтимагый-сыйнфый анализ доминантасын да ялгыз гына күтәреп чыкмый. Ул аларның уртаклыгы, бер-беренә үзара керешеп, килешеп яшәүләре ягында була.

«Пролетариат әдәбияты турында»гы китабында Г. Ибраһимов әдәбиятның җәмгыять белән бәйләнеш мәсьәләләренә тагы да киңрәк туктала. Биредә автор әдәбиятның иҗтимагый тормыштагы урыны мәсьәләсенә аерым бер бүлек багышлый.

Әдәбият социологиясен һәрьяклы ачу максатыннан чыгып, Г. Ибраһимов эшне әдәбиятның асыл үзлекләрен, иҗтимагый функцияләрен тикшерүдән башлый. Ул әдәбиятны «саф югары» хакыйкатьләргә генә хезмәт иттерергә маташучы эстетлар, «кабинет галимнәре» карашы белән килешә алмый, әдәбиятны һәм, гомумән, сәнгатьне генетик яктан да, функциональ яктан да җәмгыять белән бәйли. Сәнгать үзеннән-үзе барлыкка килгән, үзенә үзе хезмәт итә торган автоном организм түгел, дип күрсәтә Г. Ибраһимов, сәнгатьнең социаль чыганаклары: кеше, хезмәт, материаль тормыш. Әдәбиятның вакыт һәм аралык белән чикләнмәгән абстракт билгеләнешен ул ярак-сыз дип таба һәм катгый рәвештә кире кага. Әдәбият һәм сәнгатьнең килеп чыгышын тикшерү бүгенге ноктадан караганда әһәмиятсез күренергә мөмкин, әмма әлеге алым егерменче еллар тәнкыйтендә әдәбиятның социаль табигатен тулырак күрсәтү максатыннан чыгып эшләнә.

Әдәбият кебек иҗтимагый күренешнең килеп чыгу сәбәпләрен объектив чынбарлык, хезмәт процессы белән бәйләп аңлату үзе үк — мәсьәләгә объектив социологик якын килүне дәлилләүче төп моментларның берсе.

Чыгышы, табигате, функцияләре белән сәнгать һәм аның бер формасы булган әдәбият «җәмгыять җимешләре», иҗтимагый күренешләр икән, «без аларның туулары, үзгәрешләрен, кичкән баскычларын аңларга теләсәк, һәр нәрсәдән элек боларны җитештергән иҗтимагый туфракка, тормышның икътисади-сәяси моментларына карарга, тамырны шуннан эзләргә тиеш булабыз» [2]. Шунда гына әдәбиятның бөтен элементларына, эстетика өлкәсендәге бөтен мөнәсәбәтләргә социологик якын килүне тәэмин итәргә мөмкин.

Әдәби үсешкә күп төрле тарихи факторларның тәэсире бар. Г. Ибраһимов шуларның кайберләренә—географик сәбәпләр һәм «чит тәэсирләргә» туктала. Авторның бик хаклы күрсәтүенчә, әдәбият социологиясен фәнни нигезләү өчен тарихи факторлар тәэсирен исәпкә алу гына җитми. Билгеле бер халыкның, илнең эчке тормышында, мәсәлән, иҗтимагый-экономик шартлар өлгермәгәндә, чит тәэсирләр аңа үтеп керә алмыйлар, «тамырсыз агач кебек тиз корыйлар», чөнки бу тәэсирләрнең нәтиҗәсе кабул итүче якның материаль һәм социаль нигезләренә дә бәйле. Г. Ибраһимов үз фикерен халкыбыз тарихының конкрет материаллары нигезендә дәлилли.

Әдәбият үсешен иҗтимагый-экономик шартлар белән бәйләнештә карап, Г. Ибраһимов яңа социологик гомумиләштерүләргә килә, ул Г. В. Плеханов концепциясендә танылган биш рәтле бәйләнеш схемасын тәзи (җитештерүче көчләр— җитештерү мөнәсәбәтләре — социаль мөнәсәбәтләр—иҗтимагый психология—әдәбият). Сәнгать эволюциясенең объектив социаль сәбәпләрен ачыклауга юнәлдерелгән бу социологик схема кызыклы һәм мәсьәләнең болай куелышы әдәбият үсешендәге күп проблемаларны аңлау мөмкинлеген вәгъдә итә. Бер үк вакытта Г. Ибраһимов әдәбиятның иҗтимагый тормыш белән бәйләнешен яктырткан әлеге схеманың бик гомуми булуын да искә ала, рәт члennарының үзара һәм әдәбият белән мөнәсәбәттә бәйләнешен җентекләп анализлау зарурлыгына чакыра, экономика белән әдәби иҗат арасындагы төп бәйләнешләрне ачу мөмкинлеген дә шунда күрә. Г. Ибраһимов схемасындагы мондый фәлсәфи ориентация—яңа сыйнфый-пролетар караш ноктасын кабул итүче беренче һәм бик дөрес адым. Әмма кайбер очракларда бу юнәлеш әдәбиятның материаль һәм сыйнфый җирлек белән бәйләнешен үтә схематик сурәтләүгә китерә. Әдәбият-сәнгать күренешләренең иҗтимагый-экономик тормыш шартлары белән бәйләнеше хакындагы материалистик положениенең әһәмиятен аңлаган хәлдә, тәнкыйтьчеләр әдәбият үсешен билгеләүче конкрет үзенчәлекләрне һәм конкрет тарихи факторларны исәпкә алып бетермиләр. Ялгышлардан котылуның бердәнбер дөрес юлы турыдан-туры марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләренә мө-

[1] Ибраһимов Г. «Татар әдәбиятын тикшерү юлында», «Мәгариф», 1923 ел, 3—4 саннар.
[2] Ибраһимов Г. Пролетариат әдәбияты турында, М., 1924, 16 бит.

рәҗәгать итү, шулардан өйрәнү була, билгеле. Ләкин биредә бер мөһим моментны искә төшерергә кирәк. 20 нче еллар ахырына кадәр совет әдәби тәнкыйтендә марксистик-ленинчыл эстетикага нигез салучылар итеп Маркс, Энгельс, Ленин түгел, ә Плеханов саналып килә. Плехановның әдәби эстетик концепциясе тәнкыйтьтән өстен тәгълимат дәрәҗәсендә кабул ителә. Әдәбият галимнәре Плеханов теориясендәге кайбер йомшак якларга да игътибар итмәстән, аңа сукырларча ияреләр. Заман сулышы белән яшәгән Галимҗан Ибраһимов та үз карашларында Г. В. Плехановка нигезләнә, тәнкыйтьче галимнең фикер нәтиҗәләре еш кына Плеханов хаталарына барып тоташа. Тәкъдим ителгән социологик схемасында, мәсәлән, аның Плеханов карашларыннан ары китә алмавы татар әдәбияты тарихын чорларга бүлүдә «тарихи конкретлылык, социологик төгәллек, методологик эзлеклелек» югалуга, идея-эстетик процессны вульгарлаштыруга китерә. Моны Ибраһимов иҗатын тирәнтен өйрәнгән галимнәр М. Хәсәнов һәм Гали ага Халит үз тикшеренүләрендә бик дөрес күрсәттеләр[1].

Ул гына да түгел, Плеханов фәнни тәнкыйтьне ике актка бүлеп, икенче актны — тикшерелә торган әсәрнең эстетик кыйммәтен бәяләүне беренчесеннән—социологик анализдан аерып куеп, аңа өстәмә, ярдәмче бер акция дип каравы белән, гомумән, тәнкыйтьтә вульгар социологизмның килеп чыгуына җирлек тудыра. Нәкъ шушы өйрәтмәгә таянып, татар әдәби тәнкыйтендә дә һәрбер әсәрдә социальлекне генә мишень ясау гадәткә керә башлый. Хата фикерләр рус әдәбият белемендә популярлык казанган В. Ф. Переверзев, М. В. Фриче һәм башкаларның вульгар-социологик концепцияләре нигезендә тагын да тирәнәя. Әдәби үсешне социаль-экономик һәм идеологик ситуацияләрнең туры чагылмасы итеп карау нәтиҗәсендә, теге яки бу иҗтимагый-экономик формациянең әдәби продукциясе бердәм агым дип кабул ителә, язучының дөньяга карашы белән иҗаты арасындагы катлаулы мөнәсәбәт тикшерелми.

Ниһаять, тәнкыйтьтә иҗат сферасын бары җитештерү ысулына гына бәйләп карау күренешләре күзгә чалына башлый. Нәкъ шушы нигездә галим һәм тәнкыйтьче Х. Вәли әдәби үсешне җәмгыятьнең экономик үсеше белән параллель куеп, әдәбиятның барлык закончалыкларын хезмәт процессы закончалыкларыннан чыгарырга омтылыш ясый. «Бер чорның экономический хәле ничек, ни рәвешле, ни дәрәҗәдә булса, аның әдәбияты да шундый һәм шул дәрәҗәдә була,—дип яза ул.—Шуңа күрә, һәр чорның әдәбиятын үлчәгәндә, аны тикшергәндә, чорының экономикасына туктарга, ул чор әдәбиятының дәрәҗәсен төгәл үтәр өчен экономикасының дәрәҗәсенә градусыбызны куеп карарга тиеш булабыз»[2]. Идеологиянең бөтен формаларын тәнкыйтьче экономикага мөнәсәбәттә бертигез дип исәпли һәм аныңча сәнгать, фән, политика, дин кебек төрле өскормә күренешләренең специфик асылы бер үк экономик базис үзенчәлеге белән каралырга тиеш булып килеп чыга. Билгеле, проблеманы болай гадиләштерү, берьяклы аңлату фәннилектән ерак була.

Ләкин мәсьәләгә сак килүче тәнкыйтьчеләр дә юк түгел. Татар тәнкыйтендә, мәсәлән, Г. Нигъмәти әдәбиятка социологик анализ ясауда вульгар социологик адашулар куркынычын да сизә. Галим «әдәбиятны фән һәм социология ягыннан тикшерүнең гаять авыр эш» икәнен аңлый. «Моның өчен бик күп нәрсәләр, материаллар белән танышырга, бик күп конкрет әдәби мисалларны тикшереп карарга, шуның соңында гына яхшы булган, танылган марксист һәм әдәбият теориясен моңача белүче кешеләрнең фикерләрен дә нык искә алып, саклык, бик җыйнаклык белән фикер йөртергә кирәк»[3], — дип яза. Әдәбият теориясенең бәхәсле проблемаларын чишүдә алдан әзерләп куелган схемалар белән эш итәргә ярамый. Г. Нигъмәтинең бу кисәтүе бик урынлы, вакытлы һәм бик дөрес була.

Әдәбият-сәнгать үсешенең социологик закончалыкларын билгеләүдә төп авырлык әдәби процесстагы төп тарихи тенденцияләрне дөрес формалаштыруда. Нәкъ шул тенденцияләрне аңлап җитә алмау күп тәнкыйтьчеләрнең социологик карашларында каршылык тудыра. Җәмгыять тормышының динамикасын тәшкил итүче көч — экономика, экономик мөнәсәбәтләр, производство мөнәсәбәтләре дигән хакыйкатькә таянып, тарихчы-галим Г. Сәгъди җәмгыять күренешләреннән тел һәм әдәбиятны турыдан-туры шуларга бәйли һәм ул хаклы була. Әмма шунда ук Г. Сәгъди «бергәлекләр (җәмгыятьләр—Э. Б.) икътисади нигезләрендә, нәрсә эшләп чыгару мөнәсәбәтләрендә никадәр зәгыйфь, ярлы булсалар, аларның тел, әдәбиятлары да шуңа яраклы булып, зәгыйфь, ярлы хәлдә туалар» дигән ялгыш фикер дә ычкындыра[4]. Мәгълүм булганча, бу «яраклашу» һәр очракта да үзен аклап бетерми. Җитештерү көчләренең үтә зәгыйфь һәм түбән чорларында да сәнгать шедеврлары тууына мисаллар кешелек тарихында аз түгел. Мәсәлән, антик сәнгать, Шекспир, рус критик реализмы һ. б. «Сәнгатькә карата шунысы билгеле, — дип өйрәткән иде К. Маркс, — аның чәчәк атуының мәгълүм чорлары һич тә җәмгыятьнең гомуми үсешенә һәм, димәк, шулай ук җәмгыять оешмасының скелетын тәшкил итә торган нәрсә — аның материаль нигезе үсешенә дә туры килмиләр»[5].

---

[1] Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1964, 207—210 битләр. Халит Г. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан, 1975, 298 бит.
[2] Вәли Х. «Әдәбият фронтында», «Кызыл Татарстан», 1925 ел, 252 сан, 10 ноябрь.
[3] Нигъмәти Г. «Соңгы җавап», «Безнең юл», 1928 ел, 1 сан.
[4] Сәгъди Г. «Татар әдәбиятын җәмгыятьне өйрәнү белән баглау мәсьәләсе», «Мәгариф», 1926 ел, 10 сан.

Г. Сәгъди «әдәбиятны бергәлек тормышының бер җимеше» дип карау белән бергә, аның «әйләнеп килеп тормышны төзү, оештыру юлында да үз тәэсирен нык күрсәтүен» таный. Әдәбият белән җәмгыять тормышы арасындагы ике яклы мөнәсәбәтне дөрес аңлап һәм бу карашын ачык теоретик формалаштырып, галим әдәбиятны чагылдыру позициясеннән генә караудан ары китә, әдәбиятны статик бер форма дип түгел, хәрәкәттәге көзге дип күрсәтә.

Г. Сәгъди әдәбиятның җәмгыять белән зарури бәйләнешен һич тә гади һәм җиңел бәйләнеш итеп күрсәтергә ашыкмый, «ничек багларга, нинди системада, нинди ысулда багларга, моның өчен материалларны ничек билгеләргә» кебек сораулар өстендә баш вата. Ләкин дөрес нәтиҗәгә килү буталулар аша бара.

Әдәби әсәр теге яки бу чорның тарихи закончалыкларына иллюстрация сыйфатында гына мәйданга килми, иҗтимагый үсеш спецификасын ачып салу белән бергә, ул үз үзенчәлекләрен дә эшкә җигә дигән позициясен Г. Сәгъди тикшеренү тәҗрибәсендә эзлекле үткәреп җиткерми. «Татар әдәбияты тарихы»нда (Казан, 1926), мәсәлән, тарихчы әдәби хәрәкәтне иҗтимагый-тарихи процесстан аерып карауга игътибарны аз бирә, әдәбият тарихының өченче кисәгендә исә вульгар социолог М. В. Фричега ияреп, эпоха стиле белән әдәбият стиле арасында туры сызыклы тиңдәшлек уздыра[1]. Сәнгатьне җәмгыять структурасы, иҗтимагый-экономик формация белән бәйләп карарга омтылу, бер яктан, сәнгать анализында күркәм күренеш буларак бәяләнсә, икенче яктан, мәсьәләне артык гадиләштерү, примитивлаштыру әлеге уңай күренешне мәгънәсез бер эшкә әвереләдерә. Әдәбият тарихы — стильләр тарихы, ә «һәр дәвернең әдәби өслүбе төбендә шул дәвернең икътисади төзелеш (общественно-экономическая формация) өслүбе һәм шуның тәэсирендә, шуның нәтиҗәсе булып туган идеяләр өслүбе белән шартлы» булып кала.

Г. Сәгъди бу хата карашларында катып калмый, алга таба әдәбиятның җәмгыять тормышы белән бәйләныш мәсьәләләрендәге катлаулы моментларны аңлау биеклегенә күтәрелә. «Шуны нык искә алып үтәргә тиешбез,— ди ул,— әдәби хадисәләр күп вакытта экономикага урау һәм кайчагында бик урау юллары белән барып багланалар»[2].

Әдәбият-сәнгать закончалыкларының, гомумән, иҗтимагый-экономик нигезләр белән бәйләнешен өйрәнү әдәбият-сәнгатьнең шул нигездә үсүен исбат итү — марксистик тәнкыйтьнең катлаулы мәсьәләсе. Моны тәнкыйтьче Г. Гали дә дөрес аңлый. Әдәбиятның үсеш динамикасын әйдәүче көчне, бу катлаулы структураның төрле элементларын хәрәкәткә китерүче төп моментны тормышның социаль-экономик шартлары җыелмасында күреп, Г. Гали әдәбиятның сәнгатьчә үзенчәлеген тикшерүгә игътибар итә башлый. «Әдәбият тарихының төп материалы, тикшерә торган нәрсәсе — матур әдәбият булырга тиеш. Әдәбият өчен генә махсус булган моментларны тикшерүдә, мәгълүм иҗтимагый-икътисади барышның матур әдәбиятка ничек тәэсир итүен тикшерүдә булырга тиеш»[3]. Ул чорда татар әдәбияты тарихы буенча язылган хезмәтләрнең төп җитешсезлеген Г. Гали культура тарихы белән әдәбият тарихын тәңгәлләштереп карауда, әдәбият үсешенең үзенчәлеген җитәрлек тикшермәүдә күрә. Дөрестән дә, әдәбиятка йогынты ясаучы факторлар белән генә мавыгу нәтиҗәсендә, гомумән, культура тарихын гына язу килеп чыгарга мөмкин. Әлеге очракта әдәбиятның спецификасы, аның үсешен идарә итүче гомуми закончалыклар игътибар үзәгеннән читтә кала. Шулай итеп, Г. Галиның әдәбиятны җәмгыять тормышына бәйле өйрәнү белән бергә, аны эчке үсеш кануннары да булган күренеш итеп карау хакындагы фикере заманы өчен шактый прогрессив булды.

Галимҗан Нигъмәти вульгар социологлар һәм формалистларның төп ялгышын әдәбиятның нәкъ шушы ике яклы үсеш үзенчәлеген аңлый алмауларында күрә. Нигъмәти фикеренчә, әдәбият социаль-экономик хәл һәм идеологик ситуацияләрнең гади автоматик чагылышы түгел, ә чагыштырмача мөстәкыйль иҗтимагый организм, аның «үзенә караган аерымлыклары да бар». Әдәбият-сәнгать турыдан-туры экономикага бәйләнмәгән, дип аңлата тәнкыйтьче, әдәби үсеш хәрәкәтендә идеология тармакларының йогынтысы да көчле. Өскорма күренешләренең бер-беренә үзара тәэсирен инкарь итү һәм үз чиратында аларның экономик җирлеккә тәэсирен исәпкә алмау хата һәм реакцион карашларга китерде һәм китерәчәк. Г. Нигъмәти «әдәбият — идеологиянең үзенә генә хас сыйфатларга ия булган тармагы», бер үк вакытта, әдәбият үз-үзенә йомылган, аерымланган, изоляцияләнгән организм да түгел, дип аңлата. «Әдәбиятны марксистча тикшерү аны идеологиянең башка тармакларына һич бәйләнмәгән, фәкать үзенә генә махсус кануннарга ия булган күренеш итеп, механик рәвештә аерып йөртүнең дә дөрес түгеллеген күрсәтә»,— ди ул. Шул рәвешле Г. Нигъмәти татар тәнкыйтендә марксистик әдәбият социологиясе принципларын кыю рәвештә формалаштырган, дип әйтергә мөмкин.

Күренгәнчә, 20 нче еллар татар совет тәнкыйтендә әдәбият-сәнгать һәм тормыш бәйләнешенең төрле аспектлары тикшерелә һәм аерым социологик нәтиҗәләр ясала. 20 нче еллар әдәбият социологиясен бөтенләе белән вульгар социологизм дип бәяләргә урын юк. Әдәбият галиме Гали Халитның бик хаклы күрсәтүенчә, бу чор татар әдәби тәнкыйте социологиясендә ныгу процессы бара, «әдәбият белемебезнең югалмас сәхифәләре» рәтенә керерлек хезмәтләр языла. 20 нче еллар татар әдәбияты социологиясен без әдәбиятның марксистик социологиясе формалашуда бер этап булды, дип бәялибез.

---

[1] Сәгъди Г. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты, Казан, 1930.
[2] Шунда ук, 37 бит.
[3] Гали Г. «Без әдәбият тарихын ничек аңлыйбыз», «Безнең юл», 1927 ел, 2 сан.

# ЯЗУЧЫНЫҢ ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК ФИКЕР ХӘЗИНӘСЕННӘН

Галимҗан Ибраһимов иҗат мирасының сигезтомлыгын бастыру дәвам итә. Бу фактның татар классик әдәбияты хәзинәсен барлауда һәм халыклаштыруда зур әһәмияткә ия булуы турында чыккан томнар уңае белән фикерләр әйтелде инде. Менә хәзер укучы кулына әдип әсәрләренең 5 нче томы бирелде [1]. Бу томга 1910—1933 еллар арасында әдәбият һәм сәнгать турында язылган мәкаләләр, хезмәтләр тупланган. Әүвәлге томнар шикелле үк, 5 нче том да СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты карамагында хәзерләнгән. Башта ук шуны әйтергә кирәк: бу томга Ибраһимовның әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрендә күренекле теоретик, тарихчы, тәнкыйтьче һәм рецензент булуын күрсәтә алырлык мирасы тупланган. Томга кергән әсәрләргә бай искәрмә-аңлатмалар һәм берничә йөз исемгә алфавит тәртибендә күрсәткеч бирелгән. Болар һәммәсе дә беренче мәртәбә башкарылган һәм төзүчеләрдән күп көч, тырышлык сораган эшләр итеп каралырга лаек. Аның өстәвенә филология фәннәре докторы, профессор М. Хәсәновның «Г. Ибраһимов тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме» дигән махсус мәкаләсе дә 5 нче томның эчтәлеген бәяләүгә бер ачкыч булып тора. Шулай итеп, беренче мәртәбә Г. Ибраһимов әдәби-эстетик карашларының шактый тулы тарихи үсешен һәм системасын күз алдына китерерлек мөмкинлек бирә торган әсәрләр җыелмасы, тиешле фәнни аппараты белән тәкъдим ителә. Әлбәттә, 5 нче том әдипнең бу темага караган барлык әсәрләрен дә бирүне максат итмәгән, ә билгеле күләмдә сайланмалык принцибын да сакларга тиеш табылган. Әсәрләр тарихи-хронологик принцип белән урнаштырылып, әдипнең шушы өлкәдәге чирек гасырлык эшчәнлеге үсешен, эволюциясен шактый төз, конкрет итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Бу үсешнең гаять катлаулы, киеренке эзләнүләр белән тулы ике иҗади чоры — социалистик революциягә кадәрге һәм аннан соңгы чорлары үзләренең төп тенденцияләре белән ачык булып тора.

Унынчы еллардан башлап гомеренең азагына кадәр Ибраһимов татар әдәбиятының барышына карата үзенең принципиаль фикерләрен әйтә килде. Әлбәттә, күп очракта ул фикерләр язучының үз иҗат тәҗрибәсеннән аерылгысыз булды. Шуңа күрә аларда билгеле дәрәҗәдә субъектив идея-эстетик ышанычларның, концепцияләрнең чагылышын да истән чыгарырга ярамый.

Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик мәсьәләләргә караган хезмәтләренең тематикасы шактый төрле һәм киң. Аның беренче мәкаләләрендә үк сәнгатьнең төрле өлкәләренә һәм жанрларына кагылышлы фикерләр кузгатыла. Тукайга тирән теләктәшлек белән, халык әдәбиятына — фольклорга югары бәя бирелә. Әдәбиятны халыкка һәм мәктәпкә җиткерү мәсьәләләре күтәрелә. Рус һәм Көнчыгыш әдәбиятларының татар культурасын, әдәбиятын үстерүдәге рольләренә бәйле әһәмиятле фикерләр әйтелә. Болар һәммәсе унынчы еллардагы татар әдәби-эстетик фикеренең үзәгендә торган мәсьәләләр. Г. Ибраһимов аларга үз мөнәсәбәтен, аларны үзенчә аңлавын күрсәтә алды, һәм бу мөнәсәбәт алдынгы демократик караш юнәлешендә үсә, ачыклана барды.

Әдипнең әдәби-эстетик карашларына бәя безнең әдәбият фәнендә теге я бу күләмдә бирелде инде. Бу очракта без 5 нче томда урын алган кайбер мәсьәләләргә, башлыча беренче мәртәбә басылган яки аеруча әһәмияткә ия булган әсәрләр уңае белән, кагылып китүне генә кирәкле санныйбыз. Шулардан беренчесе — Ибраһимов нинди әдәби юнәлешне, нинди иҗат методын яклаучы булып әдәби тәнкыйть мәйданына чыкты дигәндә, аның романтик рухта сүз йөртә башлавы шиксез иде. Аның беренче әдәби әсәрләре саналган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) һәм «Татар хатыны ниләр күрми» (1909) кебек хикәяләрендә үк инде көчле ихтыярга ия булган һәм шәхесне, кешене изгән тирәлек белән килешмәс конфликт-

[1] Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр, сигез томда. 5 т. Казан, 1978. Томга кергән әсәрләрнең текстларын һәм искәрмә-аңлатмаларны М. Хәсәнов белән Р. Гайнанов хәзерләгәннәр. Фәнни редакторы Н. Юзиев, нәшрият редакторы Р. Даутов.

ка кергән, ниһаять, шул тирәлекне ташлап китәргә батырчылык иткән герой алга куелды. Нәкъ шундый герой концепциясендә актив романтизмның бер әһәмиятле сыйфаты чагылды да инде. Бу әсәрләреннән соң күп тә үтмәде, Г. Ибраһимов татар әдәбиятында байтак дәверләр хөкем сөргән дидактизмга, үгет-нәсихәткә каршы көрәш ачып, әдәби образның тормышны һәм кешене сәнгатьле сурәтләү җирлегендә иҗат ителү зарурлыгын яклап, шушы урында әдәби әсәрнең аеруча эмоциональ-психологик акцент белән язылырга тиешлегенә басым ясады. Бу да башлыча романтизм эстетикасына хас таләп иде. Шушы моментларны истә тотканда, Ибраһимовның кайбер очракларда көтелмәгәнрәк, хәтта сирәк булып тоелган карашларының да сәбәбе, мәгънәсе тулырак аңлашылыр.

Әдипнең романтик концепцияләре 1912—1913 елларда тәмам формалашып, «Яшь йөрәкләр» романында һәм «Татар шагыйрьләре» дигән тәнкыйть очеркларында бай чагылыш тапты. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларын аңлау өчен бик кирәкле әсәр булган «Татар шагыйрьләре»нең социалистик революциядән соң беренче мәртәбә басылуын хупламыйча булмый. Бу әсәр авторның романтик карашларындагы күп кенә характерлы якларны һәм каршылыкларны чагылдыруы белән, һичшиксез, зур әһәмияткә ия. Бигрәк тә шушы әсәр үҗәе белән озак елларга сузылган «аңлашылмауларны» да истә тотканда, аны, бу хакта объектив хөкем йөртү өчен, укучының үз кулына бирүгә күптән вакыт җиткән иде инде.

«Татар шагыйрьләре»нә әдәби җәмәгатьчелекнең мөнәсәбәте тенденциоз төс алды. Моның төп сәбәбе, әлбәттә, Тукай иҗатына мөнәсәбәт булды. Чыннан да, «Татар шагыйрьләре»ндә С. Рәмиев белән Дәрдмәндне Тукайдан алда куеп сүз алып барудан ук тенденциозлык күзгә ташлана. 1910—1911 еллар тирәсендә Тукайны татар поэзиясенең беренче йолдызы дип мактаганнан соң («Татар матбугаты», 1910), Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре»ндә Тукайга мөнәсәбәте икенче төсмер алуы аның үрынсызга кизәнүе итеп аңлашылу да гаҗәп тоелмас. Ләкин хәзер инде бу әсәргә мондый караштан килеп бәя бирү артык берьяклылык булыр иде. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре»ндә тенденциозлыгы, барыннан да элек, аның романтик концепцияләренә бәйләнгән. Моның чагылышы Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатларына мөнәсәбәттә күренә. Нәкъ шул концепцияләреннән чыгып, ул аларны алгы планга куя да инде. Һәм бу ике шагыйрьнең романтик сыйфатларын шактый төгәл һәм дөрес билгеләгән күзәтүләр ясый.

Инде Тукай иҗатына килгәндә, Ибраһимов анда беренче ике шагыйрьдә булган субъектив оригинальлекне таба алмый. Үгет-нәсихәткә каршы көрәш белән мавыгып, Ибраһимов Тукай лирикасының чын шигърияткә, тирән психологизмга бай чорына игътибар итми диярлек. Дөрес, ул Тукайдагы сатираның ролена һәм халык иҗаты белән бәйләнешкә югары бәя бирә. Әмма Тукай реализмын тиешенчә аңламау сизелә иде. Шуның нәтиҗәсендә Тукай иҗатының заман чынбарлыгы һәм халык белән турыдан-туры бәйләнеше уңай бәяләнми. Мондый караш Тукай иҗатының иң югары сыйфатлары булган тормышчанлыкны һәм халыкчанлыкны кире кагу булып аңлашыла. Чынлыкта исә Ибраһимов әдәбияттагы тормышчанлыкны һәм халыкчанлыкны һич тә кире кагу юлына басмады, ә бу төшенчәләргә үзенчә, романтикларча, икенчерәк әдәби-эстетик мәгънә салырга теләде.

Ибраһимовның Тарас Шевченкога багышлап язылган «Каһарман шагыйрь» мәкаләсендә сүз кешене изгән җәмгыятьтәге художникның трагик язмышы, аның халык азатлыгы өчен көрәштәге роле һәм халык каршындагы җаваплылыгы турында бара. Аны унынчы елларда «Шагыйрь һәм халык» проблемасы тирәсендә кызган бәхәсләр, ягъни идея-эстетик көрәш белән бәйләп караганда, Ибраһимовның бу мәсьәләгә принципиаль җавап бирергә омтылуы күренер.

Татар әдәбиятындагы прогрессив, актив романтик юнәлешне җитәкләгән һәм үстергән хәлдә, Г. Ибраһимов, әйткәнебезчә, тормышчанлык һәм халыкчанлык принципларын яклау позициясендә ныгый барды. Бу инде реализмны яклаудан аерылгысыз иде. Ибраһимов идея-эстетик концепцияләренә прогрессив романтизм белән критик реализм арасындагы уртаклыкны, якынлыкны халыкчанлык һәм тормышчанлык җирлегендә аңларга омтылыш характерлы булып торды.

Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары халыкчан-демократик җирлектә катлаулана һәм киң колач ала барды. Бу яктан аның күптомлыгына беренче тапкыр кертелгән «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» (1915) һәм «Телләре башка булса да, күңелләре бер» (1916) кебек әсәрләре игътибарга лаек. Болар беренче империалистик сугыш елларында язучының әдәби-эстетик карашларында сизелерлек үзгәреш барлыкка килүне күрсәтә. Аларның беренчесендә сәнгать үзенең тумышыннан ук кешелеккә, яхшылыкка хезмәт итү максатын куйган бөек рухи казаныш дигән фикер раслана. Әлбәттә, сәнгатьнең җәмгыятьтәге роленә карашында Ибраһимов романтик идеализмнан азат түгел әле. Шуннан милли сәнгатьне, милли культураны идеаллаштыру килеп чыга. Әмма, әйтелгәнчә, «Альбом мөнәсәбәте белән...» мәкаләсендә гуманистик идея барысыннан да көчле. Шул идея яктылыгында «кешелек һәм сәнгать язмышы» дигән мәсьәләгә җавап бирү максаты куелган.

«Телләре башка булса да...» мәкаләсе — Ибраһимовның милли культура һәм тел мәсьәләләренә тарихи объективлык белән карый алуына ныклы дәлил була алырлык мисал. Ул елларда буржуаз милләтчелекнең котырынып китүен искә алганда, бу әсәрнең турыдан-туры шуңа каршы һәм милли мәстәкыйльлеккә омтылган халыкларны яклап язылуы аңлашылыр. Монда әдипнең тарихи барышны тирән төшенә

башлавы белән бәйле интернационалистик карашы гаять тулы чагылган.

Социалистик революция Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларында тирән үзгәреш тудырды. Аның «Дүртенче елга кергәндә» (1920) дигән мәкаләсендә шул үзгәрешнең шактый характерлы билгеләре теркәлгән.

Әдәби хәрәкәт барышына, аның революцион чынбарлык белән бәйле җанлы, өметле үрентеләренә нык игътибар биреп, Ибраһимов, татар әдәбият белемендә беренче буларак, татар әдәбияты тарихын марксизм тәгълиматы яктылыгында өйрәнү мәсьәләләрен күтәрде. 1922—1923 еллар дәвамында шул мәсьәләләргә күп кенә мәкаләләр багышлап, әдәбият тарихын дәверләргә бүлеп, бу дәверләрнең иҗтимагый-сыйнфый эчтәлеген билгеләдә. Г. Ибраһимовның бу чыгышлары татар әдәбияты тарихын, сыйнфый көрәш күзлегеннән карап, иҗтимагый хәрәкәтләр белән бәйләп аңлатуда һәм буржуаз милләтчелек карашларыннан арындыруда, һичшиксез, зур роль уйнады. Аның концепцияләренә таянып, татар әдәбият белгечләре әдәби мираска, милли культурага мөнәсәбәттә әһәмиятле фәнни тикшеренү эшләрен башкардылар, үз вакыты өчен бик кирәкле хезмәтләр яздылар (Г. Газиз, Г. Рәхим, Г. Сәгъди һ. б.). Дөрес, хәзерге караштан чыгып фикер йөрткәндә, ул хезмәтләрдә күп кенә искергән һәм кимчелекле яклар табылачак. Алар шулай ук Ибраһимов тикшеренүләрендә дә бар. Мәсәлән, әдәбият тарихын чорларга бүлүдә, һәр чорның әдәби-эстетик эчтәлегенә игътибар итмичә, социологик якка гына басым ясауда, халык белән бәйләнгән язучыларны буржуаз идеология лагерена бирүдә һ. б. кайбер моментларда шул чорда киң таралган вульгар социологизм карашлары сизелеп торды. Сәнгать белән иҗтимагый базис арасындагы мөнәсәбәт бер турылыкта, бер яссылыкта гына күз алдына китерелде. Шуның аркасында әдәби-эстетик процессның катлаулы һәм каршылыклы табигатенә игътибар җитәрлек булмады.

Ибраһимовның совет чорындагы әдәби-тәнкыйть мәкаләләре аның бу өлкәдә зур теоретик, эрудит булуын гына түгел, ә яңа әдәби хәрәкәтне җитәкләүче булуын да күрсәтәләр. Ул, яшь татар совет әдәбиятының уңыш һәм кимчелекләрен күреп, аның актив вәкилләре эшчәнлегенә объектив бәя бирде, аларның иҗади үсешенә булышу теләгән беренче планга куйды. Шуның бер гыйбрәтле үрнәген, мәсәлән, һ. Такташ иҗатына мөнәсәбәтендә табарга мөмкин (5 т., 412—413 бб.). Ибраһимов, гаять дәрәҗәдә сизгерлек белән Такташ талантының шигъри куәтен, үзенчәлеген тоеп, аның совет чынбарлыгы белән тагын да ныграк бәйләнештә иҗат итүен теләп, тиз арада зур шагыйрь булу мөмкинлегенә өмет белдерә: «һади Такташтан, шөбһәсез, пролетариат революциясе дәверенең алгы сафтагы шагыйрьләреннән зурысы чыгар», — ди. Чыннан да, күп тә үтмәде, Такташ бу теләкне, өметне аклады. Тагын да К. Насыйри, М. Гафури, Ш. Бабич, М. Фәйзи, М. Максуд һ. б. әдипләргә Ибраһимов биргән бәяләрдә бүген дә үзләренең кыйммәтен югалтмаган фикерләр байтак табылыр.

Егерменче еллар уртасында ук совет әдәбиятының үзәк юнәлешен билгеләү ноктасыннан зур гына теоретик әһәмияте булган хезмәтләр арасында Ибраһимовның «Пролетариат әдәбияты турында» (1924) дигән монографиясе, һичшиксез, мактаулы урында торырга лаек. Вульгар социологизмның кайбер догмаларыннан бөтенләй үк азат булмаса да, бу әсәр яңа әдәбиятның нигез ташларыннан саналган партиялелек, сыйнфыйлык, халыкчанлык, коллективизм һәм интернационализм кебек идея принципларын сугышчан рухта яктыртып, аларга каршы булган күренешләрне каты тәнкыйтьләп чыкты. Шул принциплар социалистик реализм юлыннан барган әдәбиятның төп юнәлешен билгеләделәр. Ибраһимов тәнкыйть мирасында социалистик реализмны катлаулы, киң колачлы иҗат методы итеп аңларга омтылыш ачыклана килде. Шуның бер мисалы — Уфа әдипләренә хат итеп язылган «Кайбер әдәби мәсьәләләр» (1933). Бу әсәрендә олы әдип социалистик реализмны догматик аңлауга каршы бик дәлилле фикерләр әйтә, социалистик реализмның тормыш каршылыкларын бөтен тирәнлеге, драматизмы, трагизмы белән чагылдырырга тиешле метод булуын раслый, чынбарлыкны ялтыратып, шомартып күрсәтүне кире кага. Бу максатка ирешүнең дөрес юлы — язучының һәрвакыт партиялелек принцибына тугры булуы күрсәтелә.

Без Г. Ибраһимов әдәби-эстетик мирасында урын алган мәсьәләләрнең кайберләренә генә басым ясап киттек. Әмма искә алынган кадәресе дә 5 нче том эчтәлегенең шактый бай булуын исбатлар дип уйлыйбыз.

Әлбәттә, бу томга кергән әсәрләрнең һәммәсе дә бер үк дәрәҗәдә кыйммәткә ия дигән мөһерне сугу да кирәк булмастыр. Алар арасында эчтәлеге белән берберсенә бик якын торган яки әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә турыдан-туры кагылышы аз булганнары да бар. Ибраһимовның теге я бу сәбәп, мотив белән кертелмәгән әсәрләреннән дә әдәбият, сәнгатькә бәйләнешле сайланма өлешләрен бу томга кертү артык булмас иде.

Орфография мәсьәләсендә дә кайбер төгәлсезлекләр бар. Гомумән соңгы елларда безнең классик әдәбият текстологиясен фәнни принципларга нигезләп барлауда зур гына уңышларга ирешелсә дә, ачыкланып бетмәгән, буталчык, каршылыклы моментлар, яшәмәктәге орфографик нормалардан ераклашу еш очрый әле. Бу томда да алар күзгә бәрелә. Мәсәлән, кушымчаларның калын-нечкәлегенә игътибар итмәү: «Асар», «Миръат», «Курсави», «дәгъва» кебек сүзләрдә нечкә, Берлин, Пекин кебекләрдә калын кушымча язу. Бу урында шуны да әйтеп узасы килә: гомумән акылга сыймаган күләмдә безнең матбугатта татарча кушымчаларның калынлык-нечкәлек закончалыгын бозу, сакламау күренешләре

кубәеп бара. Аның хакында ныклап уйлыйсы һәм чик куясы бар. 5 нче томда **Казакъстан, Дагъстан, Әзәрбәйҗан** дип язылыш та — шул орфографик тотрыксызлык күренеше. Минемчә, **Казагыстан, Дагыстан, Азәрбәйҗан** дип бирү төгәлрәк булыр иде. Иске орфографиягә буйсындырырга тырышып, **крестьян** сүзен **крәстиян** дип бирү дә үзен акламый, һәм алай язудан бертөрле отыш та юк. Совет чорында Г. Ибраһимов орфографиясендә сакланган кайбер традицион элементларны шул көенчә хәзерге язуга күчерү дә бик үк кирәк түгел (буңа, бундый, каюсы, уйгата һ. б.). Моңа охшаш һәм башка мисалларны тагын китереп булыр иде. Аска төшерелеп, аңлатма бирелергә тиешле сүзләр дә очраштыргалый (зәваллы — 107 б., хиҗаб ташлау — 343, гыйркы, гамил — 352, мантыйк — 353, дарелфөнүн — 357, муаффәкыятьле — 377 һ. б.).

Тулаем алганда исә, Г. Ибраһимов әсәрләренең 5 нче томы, югарыда әйткәнебезчә, классик әдәби мирасны бастырып чыгаруда, барыннан да элек, үзенең уңышлы яклары белән таләпчән укучыны канәгатьләндерерлек итеп эшләнгән.

**ГАЛИ ХАЛИТ,**
**филология фәннәре докторы.**

≈≈≈≈≈≈

# ОЗАК ЯШӘҮНЕҢ СЕРЕ

Табигать Шәүкәт Галиевкә берьюлы ике зур бүләк биргән: беренчесе шагыйрьлек булса, икенчесе — юмор хисе!

Юмор — тормышның иң четерекле, сикәлтәле урыннарында да үз канатларында күтәрә алган кодрәтле көч; бу «җиденче тойгы» кешеләргә шул кадәр юмарт итеп сирәк биреләдер. Шәүкәт Галиевнең «Шигырьләр, поэмалар»[1] җыентыгын һәм, гомумән, бу шагыйрьне, иң элек юморга юмартлык характерлый. Юморны шагыйрьнең бөтен иҗатына, шул исәптән лирик шигырьләренә дә нур биреп торучы, аның иҗат индивидуальлеген, талант үзенчәлеген билгеләүче аерылгысыз сыйфаты дияр идем мин.

Китап «Ут кабынгач» дип исемләнгән лирик шигырь белән башлана. Монтер егет авылдагы бер кызга гашыйк булган диган фикерне әйтү өчен шигырь язып кара әле син! Язуын язарсың да — укучы булмас. Ә Ш. Галиевнең җылы юмор белән өртелгән, шаян очкыннар чәчеп торган шигыре җыр булып китте. Янсә мөлаем күренешләре белән авылда туып-үскән һәркемнең йөрәгенә якын булган «Челләдә» шигыренә тукталыйк. «Казык башларында, авыз ачып тик торучы әлсерәгән итек», кызу кояш астында «каралтыга сөялеп салкын кышны искә төшерүче чана» — болар җәйге авыл пейзажын тулыландыручы детальләр генә түгел, эссе көндә исеп куйган җил кебек рәхәтлек бирүче, бала чак истәлекләренә чумып моңсулана башлаган кешене елмайтып җибәрүче «витамин»да.

«Әткәйгә хат» поэмасы кебек җитди әсәрендә дә шагыйрь бала психологиясен бирүдә нечкә юмор куллана. Әтисе сугышка китүнең ни икәнен аңламыйча «җылы сохарилар» кимереп утырган ваемсыз сабый тора-бара аны кинодагы кебек «гел безнекеләр җырлап алга бара, гел дошманнар гына егыла торган җир» итеп күз алдына китерә башлый. Аннан 12 яшьлек малайның фронт өчен бодай ташыганда тыгыз капчыклар өстенә утырып, бәрәңгене мактап ашауларын искә алыйк — үзалдыңа да елмаеп куймый мөмкин түгел.

Сугыш темасына, җитди-фәлсәфи темаларга язылган шигырьләрдә юмор булу мөмкин түгел кебек, әмма Ш. Галиев шигырьләрендә кычкырып торган юмор булмаганда да, киная, үткен итеп әйтә белү осталыгы бар. «Сапун гора — Сабын тавы икән» шигырендә:

...Җиргә сыенып алга үрмәләгән
Солдатларны гүя күрәм мин...
Алар моннан шуышып үткәнгә дә
Йөрим бүген аягүрә мин...

Шул ук вакытта, поэтик образ дәрәҗәсенә күтәрелгән үткен чагыштырулар, төгәл, көчле, тормышчан метафоралар шигырьләрдәге җитдилекне көчәйтә.

Борын заман гаҗәп тыныч булган —
Булса булган су һәм җил шавы.
Юллар озын...
Вакыт салмак аккан...
Галәмәт зур булган җир шары!
Хәзер — үзгә...
Шар да бик бәләкәй:
Бер хәл булса берәр ягында,
Орынмыйча һич тә үтә алмый,
Йөрәгеңә килеп кагыла.

Менә сиңа шаян шигырь! Тынычлык турындагы җанлы, йөгерек фәлсәфәдә шагыйрьнең күңел түрендәге иң якты уйлары бәреләнә. Шул ук темага багышланган тагы бер шигырьдән өзек китерми калу уңайсыз:

...Карточкага төшә хәзер монда
Башкалага килгән кунаклар.
Кеше тынгач, бу борынгы тупка
Күгәрченнәр килеп кунаклар.
Аяз көннәр нинди яктылар да,
**Тыныч сулар нинди тоныклар...**
**Атылмаган ракетаны шулай**
**Курсә иде безнең оныклар!**

[1] Шәүкәт Галиев. Шигырьләр, поэмалар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1978.

Шәүкәт Галиев татар телен, Тукай телен шул кадәр яхшы белә, һәр сүзнең музыкаль яңгырашына шул кадәр игътибар итә ки, шигырьләренең һәр юлы үзеннән-үзе җырлап тора, рифма, ритм уйнаклап бара, аерым сүзләр поэтик бизәккә әйләнә. Шагыйрь гади, халыкчан әйтемнәрне дә үз иҗатында бик мул файдалана һәм аларга үзенең наянлыгын, җорлыгын, осталыгын өстәп, кабат халык сөйләменә күчәрлек тәгъбирләр ясый. Тел Шәүкәтнең төп коралы: сүзләр сайлауда ул искиткеч талымчан, гаҗәеп осталык белән аларның үз урыннарын таба белә, алар шигырьнең эчтәлегенә, мәгънәсенә карап, геройның характерын искә алып, хәтта үзләренә рифма булырдай сүзләргә кул изәп, тиешле урыннарга килеп кенә яталар. Мәсәлән:

...Каз кебек канатланып,
Кайттым өйгә шатланып.
Әйтәм кера-керешкә:
— Хатын, чыгар көмешкә!
Хатын әйтә: — Кем эчкән?
Беткән монда көмешкәң!
...Хатын әйтә: — Җүләр, ди,
Әйтсәң кеше көләр, ди,
Сылтамый тор казга, ди,
Үзең йөрдең базда, ди.

Әгәр шагыйрь ихтыяҗ сизеп башка телгә мөрәҗәгать итә икән, анда да ул туган телебезгә кереп, инде көндәлек кулланышта шомара барган, рифмага ятышып торган сүзләрне генә сайлый. Әйтик:

Яшермичә фактны
Яздылар бит актны.

Яисә:

...Салып куян беретын,
Алып бирә билетын.

Шәүкәт тел белән виртуозларча эш итә, сүзләрне цирктагы жонглерлар кебек уйната. Аның сүзләргә булган талымчанлыгы балалар өчен язылган шигырьләрендә аеруча игътибарга лаек: карасана, «надан» сүзе кайсы яктан гына укысаң да надан була икән бит.

Яисә икенче бер шигырьне искә төшерик.

...Яз җитте, йокы качты,
Юкәләр күзен ачты.
Гаҗәпләнгән бөреләр
Ят бер җирне күрделәр.
Урамнар тап-тар кебек,
Машина таптар кебек...

Шәүкәт Галиев шигырьләре тел һәм әдәбият укытучылары өчен чын мәгънәсендә хәзинә. Класс сәгатьләрендә педагог-тәрбияче мисал итеп китерерлек фикерне ул ап-ачык кына яра да сала:

— Ник таптадың бәрәңгене,
Хәзер колагыңны борам.
— Белмәдем бит, абзыкаем,
Колхозныкы диеп торам.

Яисә сугышуның ахмаклык, надан әтәчләргә генә хас күренеш икәнен тасвирлаучы «Сугыш чукмары» шигыре. Кемнең шундый хурлыкка төшәсе килер? Бу инде мәктәпкә, беренче класска укырга йөри башлаган «зур кеше» өчен бөтенләй оят. Хезмәт тәрбиясе бирүне максат итеп язылган «Камырша», «Бикмулла», «Алтын куллар», «Җир тәмлеме» һ. б. шигырьләр дә уңышлы.

Табигатьне саклау темасы исә «Кеше урман кисә...», «Бер йортлы шәһәр», «Имән ни дигән?» «Көрәшәләр», «Керпе таптык» шигырьләрендә сабый күңелен сискәндерерлек һәм аның күңеленә кереп калырлык детальләр аша ачылган. Ә кечкенә генә лирик миниатюра — «Болында» шигырендә нинди нечкәлек һәм нәфислек белән кеше һәм табигать арасындагы бәйләнеш тасвирлана. Табигатькә карата шәфкатьле, игътибарлы булырга өйрәтү, гомумән, баланы нечкә күңелле, миһербанлы, кешелекле итеп тәрбияләү дигән сүз. Гомумән, шагыйрь — балалар өчен үзе бер тәрбия мәктәбе, ул аларны дөнья белән дә таныштыра, табигатьне яратырга да, эш сөяргә дә, гадел булырга да, әдәпле булырга да өйрәтә.

...Табада пешеп тора,
Табынга төшеп тора.
Кайнар! —
            ялан кул тотма.
Тәмле! —
            телеңне йотма.
Син телең йотсаң Нәбирә,
Кем рәхмәт әйтер әбигә?

Шәүкәт Галиев һаман шаярып кына тормый, әлбәттә. Тиешле урында бик җитди дә була белә. Аның шигырьләренә әледән-әле авыл темасы, җиргә, икмәккә, игенчегә мәхәббәт темасы килеп керә. Яңгырлар яумый торса, ул игеннәр өчен үзе сусый, өзелгән башак тузанда аунап ятканын күреп сызлана. Туган як күренешләрен, иген кырларын тасвирлаган юлларда моң сизелә. Басулар өстендә сагыну хисләре йөзә. Ул йөргән тузанлы юллар, көпчәк эзләре моң белән тулган. Әмма биредә дә Шәүкәт Шәүкәт булып кала, ул озаклап моңаерга, сагышларны сузарга яратмый — укучыны тиз генә яктыга, кояшка алып чыга — шигырьләрдә яңадан да оптимистик рух өстенлек ала. Сагыш, моң тулган иркен басулар кисәк кенә якты чыганакка әйләнә:

...Тургайлар сузган
Кылга кагылып
Җил үтә көйләп,
Җир очып чыгар
Кебек пырылдап
Арыштан кинәт.

Яисә:

...Чыгамын да да иртән басуларга
Шөкерана кылып йөримен —
Тургай өстендәге күк имин дә
Тургай астындагы җир имин.

Безнең халыкның борын-борынгыдан килгән күркәм сыйфатларының берсе ул — сабырлык һәм шөкерана хисләре. Бер генә строфа белән шушы олы, изге хисне (әйе, әйе, мул иген басуларына карап шөкерана

итү, җирнең, күкнең иминлеге өчен куану хисләре шулай аталырга хаклы) бирү осталык та, җитдилек тә таләп итә.

Ш. Галиев тормышның төрле өлкәләренә актив үтеп керә торган әдип. Ул әдәбият, шигърият, аларның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында да уйлана. Китапта аның элек бер җыр язып та халык күңеленә кереп калган «зур шагыйрьләр» булуы, ә хәзер йөзәр җыр язып та кеше күңелен тибрәндерә алмаган «вак шагыйрьләр» очраштыргалауга пошынуын тасвирлаган парчалар бар. Бу темага ул кабат-кабат кайта электән үк күңелдә берничә шигъри парчасы утырып калган:

Тәүге җырларымның туган җире
Басу юлы, арыш арасы.
Кайбер елның хәзер игенен дә,
Тургаен да күрми каласың...

— дип, бер офтанып ала да, «булмаса булган икән, бер миннән генә калмасын!» дигәндәй:

Күп кешеле юлга кушылдым мин,
Җырлар машинага утырды.
Туктап уйланырга вакыт та юк,
Мин оттыммы, җырмы оттырды?

— дип төгәлләп куя. Биредә дә шагыйрь, күңеленә төшкән пошаманны киметү өчен, гадәтенчә үзенең сыналган һәм тугрылыклы юлдашы — юморга мөрәҗәгать итә. Нинди генә темага язса да, кай тирәләрдә йөрсә дә, шул рәвешчә ул үз сукмагына, үз юлына килеп чыга. Чөнки юмор аның табигатендә, ул җай гына көтеп тора, һәр уңай очракта бәреп чыгарга әзер.

Ш. Галиев юморы тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә килеп кергәч үзен бигрәк тә иркен хис итә. Әйтик, гаилә тормышының гомер-гомергә килгән шактый четрекле мәсьәләсе — килен һәм каенана мөнәсәбәте. Өйдә тавыш чыга — мәхшәр куба: килен-каенана бер-берсенә «колак камашырлык» сүзләр әйтешәләр.

Каенананың улы да — мин,
Киленецең ире дә — мин.—
Нишли алам биредә — мин?!

Менә сиңа «ике ут арасында» калган ир хәле. Монда инде хет көл, хет ела! Әмма уйланыр нәрсә бар: әгәр ана улын җәлләсә, хатын ирен хөрмәт итсә, үзен өзелеп яратучы ике кеше тарафыннан ут газабына ташланган ир бәхетле булачак.

Юк, Ш. Галиев шигырьләрен юмор, лирика дип тә, олылар, балалар өчен дип тә кырт кисеп кенә аерып куеп булмый. Балалар өчен дип язылган шигырь олыларга ярап тора, олылар өчен язылганнары балаларга зарар итми. Лирика дип тотынсаң, юморга килеп чыгасың, көлке дип авыз ерып укый башласаң, тормышчан һәм җитди бер фикергә юлыгасың. Шәүкәт Галиев иҗаты бер бөтен, ул олы иҗат. Шагыйрьнең әйтер сүзен, күңелендәге уйларын, тормыштагы кайбер тискәре күренешләргә җаны әрнүен лирик әсәрләр генә сыйдырып бетерә алмый, ул юморга-сатирага мөрәҗәгать итә. Вакыйганың мәзәк һәм тискәре якларын бер фокуска җыеп яктыртып күрсәтә дә — акыл да сатмый, үгет-киңәш тә бирми — дустанә елмаю, күз яше аша көлү, яисә ирония белән чикләнеп кала. Ә нәтиҗә ясау, уйлану — укучының үз ихтыяры.

Көлү иң калын тиреле кешегә дә үтми калмас. Бигрәк тә кеше үзеннән көлгәнне яратмый — кеше үзен орышканга, кыйнаганга караганда да, адәм көлдерүдән күбрәк курка. Хикмәт шунда, көлү олы кешегә дә, бала психологиясенә дә бердәй тәэсир итә. Ә мәзәк, үткен сүз һәм киная белән әйтү бүгенге яшьләрне, бигрәк тә үсмерләрне, гомумән, әсир итә. Гомер-гомергә яшьләр арасында эшләгән кеше буларак, бүгенге яшь кеше юмор, тапкыр сүзгә мөкиббән китә дип авыз тутырып әйтә алам. Шуңа да урамда ишетеп отып алынган анекдотлар урынына алар шигырь-мәзәкләр укысалар, куен дәфтәрләренә шигырьләр, җырлар язып алсалар, файда, бәхәссез, күбрәк булыр иде. Ш. Галиев шигырьләрен иң күп укучы — балалар һәм яшьләр булу бик тә куанычлы. Сүз уңаенда Шәүкәт Галиев киләчәктә үсмерләр дөньясына да үтеп керсен, алар өчен дә язсын иде, дигән теләк белдерәсе килә. «Сөзгәк үгез» исән-аман торган булса, аның мөгезенә эләгер нәрсәләр дә табылачак яшүсмерләр арасында.

Кояшлы, витаминлы, тирән мәгънәле шигырьләр тупланган бу китапка шагыйрьнең үз сүзләре белән үк бәя бирергә мөмкин булыр иде, әйтик:

Кояш барда илһам якын йөри,
Илһам барда шагыйрь үлми ул!

Яисә:

Озак яшәүнең сере
Шаянлыкта, кәнишне!

Кыскасы, юморсыз Шәүкәт Шәүкәт була алмас иде. Мәкаләне күренекле шагыйребез Хәсән ага Туфанның: «Аның (Шәүкәт Галиевнең) уйчанлыгы — көләч, ә көләчлеге — уйчан», дигән сүзләре белән тәмамлыйсы килә.

*Ләлә ХӘЙДӘРОВА.*

# ГАЗЕТА ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДУСЛЫГЫ

Татар әдәбияты Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң киң колач белән тармакланып, яңадан-яңа үрләр яулады. Октябрьның беренче көннәрендә үк күпчелек татар әдипләре революция байрагы астында яшь совет республикасын яклап чыктылар. Аларның бер төркеме гражданнар сугышы фронтларында кулына корал алып акгвардиячеләргә һәм интервентларга каршы көрәште, икенчеләре редакцияләрдә эшләде, эшче һәм крестьян мәнфәгатен яклап мәкаләләр, очерклар, хикәяләр, соңга табарак повестьлар, романнар яздылар. Язучыларны һәм журналистларны Коммунистлар партиясе яңа иҗатка рухландырды, аларга юл күрсәтте.

Партия әдәбият һәм сәнгатьнең халыкка хезмәт итүен, коммунистик төзелеш интереслары хакына эшләвен өзлексез кайгыртра килде, матбугатны да шуңарга чакырды. Язучы һәм журналистларның шул юлдагы күп кырлы һәм бай эшчәнлеген өйрәнеп, тарих фәннәре кандидаты Ш. Хамматов яңа хезмәт язды һәм ул күптән түгел дөнья күрде[1]. Китапны кулга алу белән авторның нинди зур эш башкарганлыгына сокланып куясың. Автор кереш өлештә үк 1918 елның 12 мартында татар телендә «Эш» дигән газетаның чыга башлавын, бу газетаның соңга табарак исемнәре үзгәрүен һәм, ниһаять, «Социалистик Татарстан» газетасы исеме белән чыгуын, аның партиябезгә һәм халкыбызга инде 60 елдан артык хезмәт итүен, социализм төзүгә үзеннән лаеклы өлеш кертүен ассызыклап күрсәтә.

Китап дүрт бүлектән тора. «Партиядән көч алып» дигән беренче бүлектә татар әдипләренең матбугат белән, аерата «Эш» газетасы белән тыгыз элемтәдә эшләве, көн кадагына суга торган актуаль әсәрләр иҗат итүе, аларның газета битләрендә басылуы бәян ителә. Бу чорда совет властеның беренче декретлары, мөһим документлары, партия Үзәк Комитеты карарлары һәм мөрәҗәгатьләре халыкка системалы рәвештә җиткерелә. В. И. Ленин кул куйган документлар тәрҗемә итеп бирелә.

Бөек Октябрь социалистик революциясен хәзерләүдә актив катнашкан һәм революциянең беренче көннәреннән үк алгы сафта барган күренекле революционер һәм публицистлар Мулланур Вахитов, Камил Якуб, Хәсән Урмановлар татар совет вакытлы матбугатының беренче актив хәбәрчеләре булдылар. Бу елларда шулай ук Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Вәли Шәфигуллин, Садыйк Әхтәмов, Шәһит Әхмәдиев, Ибраһим Кули, Габдрахман Кәрам, Мостафа Сөбхи, Сәгыйть Сүнчәләй, Фатих Сәйфи-Казанлы, Мәхмүт Дулат-Али, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Сәгыйть Фәйзуллиннар да ялкынлы материаллар белән даими рәвештә чыгыш ясап киләләр. «Эш» газетасында яшь язучылар Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов, Бари Рәхмәт, Мансур Кырыймовның әсәрләре дә басыла. Бу чорда революционер һәм язучы Галимҗан Ибраһимов газета белән аеруча тыгыз элемтәдә тора. Кәрим Тинчурин 1919 елда ук «Якты көндә әүвәлгедән артыграк көч сарыф салырга, эшләргә кирәк... Татар театрының хәзерге дәвере — эшләр өчен иң күңелле бер дәвер. Татар театрының хәзерге барышы көткәннән артык файдалы нәтиҗәләр тудырачак. Бары эшләргә кирәк, эшләргә, эшләргә!» — дигән чакыру белән чыга. Галиәсгар Камал бу газетада бөтен көчен куеп эшли һәм үзенең сатирик шигырьләре белән актив чыгыш ясап килә.

1920 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылгач, «Эш» газетасы 2 июльдән «Татарстан хәбәрләре» исеме белән чыга башлый. Бу елларда күренекле революционер Сәхипгәрәй Сәетгалиев мәкаләләре басыла. 1922 елдан газета «Татарстан» исеме белән чыга башлый, ә 1924 елның маеннан «Кызыл Татарстан» исемен ала. 1951 елның 5 августында «Совет Татарстаны» дип үзгәртелә. 1960 елның 27 сентябрендә «Социалистик Татарстан» исеме белән чыга башлый.

Газетаның редакторы булып шактый вакытлар талантлы журналист һәм публицист Вәли Шәфигуллин эшли. Ул вакыттагы «Известия Тат. ЦИКа» газетасы (хәзер «Советская Татария») редакторы В. М. Бахметьев Вәли Шәфигуллин белән даими элемтәдә тора. Алар 1921 елның мартында РКП(б)ның X съездында катнашалар, Татарстан партия оешмасы делегациясе составында В. И. Ленин белән очрашалар. В. М. Бахметьев Вәли Шәфигуллинны Ленин белән таныштыра. Юлбашчы татар әдәбияты һәм журналистикасының үсеше, газеталарның тиражы, анда милли интеллигенциянең катнашуы, полиграфик базаның торышы белән кызыксына.

1921 елны «Татарстан хәбәрләре» газетасында редактор булып язучы-коммунист Фәтхи Бурнаш эшли башлый. Газета битләрендә әледән-әле аның мәкаләләре, шигырьләре басыла. Танылган каләм остасы Г. Ибраһимов газета битләрендә культура, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә караган мәкаләләр белән чыгыш ясый. Күренекле татар әдибе аларның берсендә болай дип яза: «... чыккан әсәрләрне белдерү, аларның телләре, мөндәриҗәләре, хаталары, яхшылыклары белән эшче-крестьян иптәшләрне таныштыра

[1] Шәмси Хамматов. Газета һәм әдәбият дуслыгы. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1979 ел, 184 бит.

башларга бик вакыт инде. Икенче төрле әйткәндә, газеталарда «Яңа әсәрләр» бүлеге ачарга кирәк. Гыйльми рәвештә тәнкыйть хезмәтен тиешле дәрәҗәсендә башларга кирәк».

Г. Ибраһимов Шәриф Камалны партиягә керүе белән котлап та чыгыш ясый, тарихи борылыш чорында язучыларның совет ягына чыгуын, аларның Коммунистлар партиясе тирәсенә туплануын чын күңелдән хуплый. Шул уңай белән Шәһит Әхмәдиев, Фатих Сәйфи, Сәгыйть Сүнчәләйнең җиң сызганып иҗади эшкә керешүләрен билгеләп үтә. Галиәсгар Камалга исә Г. Ибраһимов аерата җылы караштә була һәм аны «татар драма әдәбиятының атасы» ди.

Газета битләреннән Г. Ибраһимовның яшь шагыйрь һ. Такташка биргән бәясен укыганда өлкән әдип никадәр алдан күрә белгән икән дигән нәтиҗәгә киленә... «Татарстан» газетасының 1924 ел, 10 январь санында мондый юллар бар: «Әгәр тарихның шул яңа мәгънәсен камил үзләштереп җитсә, тормыш моңа булышлык кыйлса, һади Такташтан, шөбһәсез, пролетариат революциясе дәверенең алгы сафындагы шагыйрьләрнең зурысы чыгар».

Газетада 1926—1928 елларда Галимҗан Нигъмәти редактор була. Ул газетаның идея эчтәлеген баету, аның халык массалары белән элемтәсен ныгыту, яңа тормыш төзүдә матбугатның әһәмиятен тагы да күтәрү өстендә тырышып эшли. Г. Нигъмәти газета битләрендә әдәбият мәсьәләләрен яктырта, В. И. Ленинның әдәбиятка һәм сәнгатькә карашларын даими пропагандалый, татар укучыларын рус халкының зур әдипләре һәм культура эшлеклеләренең эшчәнлеге белән таныштыра бара.

Китапның икенче бүлеге «Бердәмлек байрагы астында» дип исемләнгән. Анда без утызынчы елларда «Кызыл Татарстан» газетасында дөнья күргән әсәрләр, актив катнашучы язучылар белән танышабыз. Автор язучылар иҗатын бәяли һәм анализлый, аларның иң актуаль чыгышларын билгеләп үтә.

Бу елларда сәнгать мәсьәләләренә газетада элеккечә киң урын бирелә. М. Гафури поэмасы нигезендә эшләнгән «Эшче» операсының сәхнәгә куелуы турында хәбәр ителә. Шагыйрь үзе дә «Эшче» операсы турында» дигән мәкалә белән чыга.

Бу елларда СССР язучыларының беренче съездына әзерлек һәм аны үткәрү турында газетада күп кенә материаллар басыла. Газета съезд алды трибунасына киң урын бирә, эшлекле мәкаләләр урнаштыра. Аларда совет язучысының җаваплылыгы, социалистик реализм мәсьәләләре, тема төрлелеге, художество осталыгы проблемалары яктыртыла. — Болар һәммәсе Ш. Хамматов тарафыннан документаль нигездә раслана.

Газета битләрендә шагыйрь һ. Такташның шигырьләре еш басылуын искә алып, автор талантлы татар совет шагыйренең иҗаты турында аеруча җылы итеп яза. Муса Җәлилнең күп кырлы таланты үсә баруны газетада басылган материаллар белән раслау да яңа хезмәтнең авторитетын күрсәтеп тора. Гомумән, автор татар совет әдәбияты корифейлары Такташ һәм Җәлилнең матбугат, шул исәптән «Кызыл Татарстан» газетасы белән өзелмәс элемтәдә булуларын бик күп конкрет фактлар белән раслый.

«Дәһшәтле еллар авазы» дип аталган өченче бүлек укучыны исеме белән үк үзенә җәлеп итә. Изге Ватаныбызга саранча кебек ябырылган немец-фашист илбасарларына каршы сугышка бөтен ил күтәрелде. Бу кыю көрәштә язучылар иң алгы сафта булдылар. Башка милләт язучылары кебек үк, татар язучылары да каләм белән генә түгел, штык белән дә дошманга каршы батырларча көрәштеләр. Аларның мәкаләләре ,очерклары һәм ялкынлы шигырьләре газета битләрендә еш басыла. «Кызыл Татарстан» газетасының һәр санында диярлек язучыларның һәм журналистларның әсәрләре набат булып яңгырый. Бу елларда М. Җәлил, К. Нәҗми, Ш. Маннур, Г. Кутуй, А. Шамов, Ф. Хөсни, Г. Бәширов, Ә. Исхак, С. Хәким, М. Садри, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис, Г. Насрый газетада актив катнашалар. Тора-бара газетаның тематикасы үзгәрә, әсәрләрдә конкрет сугыш вакыйгалары чагылыш таба. Шагыйрьләр алгы сызыктан — ут эченнән үзләре күргән сугыш батырлары турында яза башлыйлар. Фронт газеталарында М. Җәлил, Г. Кутуй, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Х. Госман, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, Н. Баян, И. Гази, Г. Бакиров, А. Шамов, Ә. Исхак, Г. Галиев, Г. Хуҗиев, Ш. Мөдәррис, Б. Корбанов, М. Мазунов, М. Шәйми һәм башкалар хезмәт итәләр һәм үзләренең әсәрләре белән «Кызыл Татарстан» газетасында актив катнашалар. Тылда эшләгән һәм иҗат иткән язучылардан Ш. Камал, М. Әмир, Г. Бәширов, К. Нәҗми, Г. Кашшаф, Ф. Хөсни, Н. Исәнбәт, Т. Гыйззәт, Г. Иделле һәм Х. Хәйриләрнең көн кадагына суга торган мәкалә, очерк, хикәяләре басыла.

Фронт һәм тылның нык элемтәдә булуы, фронт газеталары чыгу күп милләтле совет солдатларын Ватанга бирелгәнлек һәм совет патриотизмы рухында тәрбияли. Совет кешесенең тылда да, фронтта да тиңдәшсез батырлыклары турында газетада яңадан-яңа материаллар басылып тора.

Дүртенче бүлектә газетаның сугыштан соңгы чордагы эшчәнлеге яктыртыла.

Газетада публицистиканы үстерүгә, төрле милләт журналистларын бер-берсенә якынайту эшенә тугандаш рус әдипләре һәм журналистлары да зур өлеш кертә. Газетада даими рәвештә «Әдәбият һәм сәнгать» бите чыга башлый. Газетада тәнкыйть материаллары, ялкынлы шигырьләр, эчтәлекле очерклар, хикәяләр, җырлар белән бергә, зур әсәрләрдән өзекләр бирү гадәткә керде.

Әдипләрнең бөтен дөньяга шаулаган КамАЗ турындагы иң яхшы әсәрләре газетада киң урын алдылар. Түбән Кама химия комбинаты төзелеше игътибар үзәген-

дә булды. Республикабыз игенчеләре һәм терлекчеләре тормышы, хезмәт юлы да әдипләрнең әсәрләрендә даими яктыртылып килә. Газета Ленин һәм Татарстан юбилейларына багышлап ике елдан артык алып барылган «Шигъри сабантуй»да республикабызның һәм тугандаш халыклар шагыйрьләренең иң яхшы әсәрләрен үз укучыларына тәкъдим итте. «Октябрьда туган культура» дигән баш астында 1967 елның 26 октябрендә Идел һәм Уралдагы алты автономияле республика газеталарының берләштерелгән саны чыгарылды. Аны «Правда» газетасы да билгеләп үтте.

КПССның XXV съездында партия Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежнев, идеология оешмаларының, культура учреждениеләренең шефлыгына олы бәя биреп, болай диде: «Театрларыбызның, әдәби-нәфис журналларыбызның заводларга, колхозларга, БАМ һәм КамАЗ кебек төзелешләргә шефлык итүе киңәйгәннән-киңәя бара; моны хупларга гына мөмкин». Соңгы бишьеллыкларда совет кешесенең батыр көрәше, замандашларыбызның эшчәнлеге, чорыбызның һәртөрле вакыйгаларга, фактларга бай булуы бик күп язучыларны һәм журналистларны тагы да күләмлерәк әсәрләр язуга рухландырды. Газета чор тудырган әнә шул югары художестволы әсәрләрне үз битләрендә урнаштырып килә.

Язучы, журналист — иң актив профессия вәкилләре. Әдипләр белән газетаның элемтәсен конкрет эштә ныгытуга редакция зур әһәмият бирә. Язучының үткен һәм тылсымлы сүзе укучының йөрәгенә тирән кереп урнаша, аңа рух, дәрт бирә. «Социалистик Татарстан» газетасы үзенең битләрендә яшь һәм башлап язучыларның әсәрләренә дә киң урын биреп, әдәби алмаш үстерү буенча да зур эш алып бара.

Без кыскача эчтәлеген шәрехләп үткән хезмәттә газетаның күп кырлы эшчәнлеге шул рәвешчә тулысынча фактларда чагыла. Аны укыганда республикабызның зур үсеш чорлары барысы да күз алдыннан уза. Автор 60 елдан артык чыгып килгән газетаны инәсеннән-җебенә кадәр өйрәнгән, иң кирәкле материалларны язып алган, аларны тәртипкә китергән, анализлаган. Өлкән журналист Шәмси Хамматовның озак еллар буе дәвам иткән фәнни-практик хезмәте җимеше ул «Газета һәм әдәбият дуслыгы» дигән китап. Аның дөньяга чыгуын чын күңелдән хупларга кирәк. Бу — әдәбиятыбыз тарихы өчен генә түгел, укучылар массасы өчен дә игътибарга лаек вакыйга.

**ШАКИРОВ С.**

# АДЫМНАР

Җир өсте гел таулардан гына торса, күренеш бик ярлы, күңелсез булыр иде. Табигать андый бертөрлелекне яратмый, күрәсең. Ул җир өстенә таулар өйгән, чокырлар казыган. Анда үзәнлекләр бар, мәһабәт тигезлекләр... Үсемлек дөньясы да бертөрле генә түгел, җәнлек-җанварлар дөньясы да... Бу — система, бердәм яшәү системасы. Биредә һәр төрлелек, һәр аермалык берберсенең үзара яшәү шарты булып тора һәм барысы бергә бер бөтенне хасил итә.

Шигърият дөньясында да эш шулай тора: берәүләр юл ярып бара, икенчеләре юлга төбәп сукмак сала, өченчеләре иҗади эшкә бәя биреп тора. Билгеле, әлеге хезмәтләрнең һәркайсы үз урынында — зарури, үз урынында — әһәмиятле. Чөнки, шагыйрь Фатих Кәрим әйткәнчә:

> Һәрбер чәчәк матур үз урынында,
> Урманга ямь бирә һәр агач!

Әйе, иҗади хезмәтне, әдәби хуҗалыкны бер система итеп, төрле талантлар эшчәнлеген берләштерә торган берлек итеп карыйбыз икән, димәк, аның бер генә буыны да — зурмы ул, кечкенәме — әһәмиятсез була алмый.

Биредә шунысы бигрәк тә әһәмиятле: халыкның художество культурасы даими үссен, чәчәк атсын дисәк, системаның һәр буыны актив эшләп торырга тиеш. Бер генә талант та тукталып калмасын, алга барсын, иҗат итсен, үзенең үсеш юлын дәвам итсен.

Бүгенге татар совет шигърият мәйданында үзләренең иҗат эшчәнлеген даими раслап торучы шагыйрьләр аз түгел. Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Нәби Дәүли, С. Сөләйманова, Шәүкәт Галиев, Мәхмүт Хөсәен, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Р. Миңнуллин — менә аларның кайберләре. Бу исемлеккә тагын бер шагыйрьне өстәргә кирәк. Ул — Галимҗан Латыйп. Аның укучылар белән элемтәсе өзелеп тормый: ул яза, иҗат итә...

Мәгълүм булганча, Яңа Дөмбәй авылында ярлы Шакир ага гаиләсендә туып үскән Галимҗан үзенең беренче шигырен 1935 елда «Коммуна» (хәзер «Кызыл таң») газетасында бастыра. 1939 елда аның беренче китабы — «Юл буйлап» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Беренче китап — һәр автор тормышында зур вакыйга. Ул күңелне күтәреп җибәрә, хисләрне канатландыра, илһамны арттыра.

«Хезмәт иртәсе» исемле икенче китабында шагыйрь үзенең кайсы ягы белән киңрәк ачыла соң? Аңарда нинди үзенчәлек барлыкка килә? Әлеге китап турында «Татарстан яшьләре» газетасының 1951 ел, 28 февраль санында шагыйрь Зәки Нури болай язды: «Галимҗан Латыйп

үзенең «Хезмәт иртәсе» җыентыгына... сизелерлек үскән активлык һәм үзенчәлек белән килгән. Аның шигырьләрендә хезмәтнең гүзәллеге аерым фактларны һәм тышкы билгеләрне санап чыгу юлы белән түгел, бәлки теге яки бу геройның уйлары, хисләре, кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә».

Әлбәттә, иҗади үзенчәлеккә, кем әйтмешли, бер селтәнү белән ирешеп булмый. Чөнки сурәтле фикер үзенчәлеге күктән төшми, чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыру процессында формалаша. Сәнгатьчә чагылдыру исә иҗат кешесеннән осталык, камиллек сорый. Боларына инде талант, даими тырышлык, нәтиҗәле хезмәттән башка ирешеп булмый. Галимҗан Латыйп та сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеген алда тагын да камилләштерергә, аны яңа сыйфатлар белән баетырга омтыла — эзләнә, сыный, чагыштыра, өйрәнә, сабак ала. һәм бушка түгел. 1958 елда басылып чыккан «Кыр чәчәге» исемле шигырьләр җыентыгында авторның иҗат ысулына яңа сыйфатлар өстәлә һәм алар шунда ук үзләренә тәнкыйть игътибарын җәлеп итәләр.

Ниһаять, 1967 елда Г. Латыйпның «Адымнар» җыентыгы басыла. Шагыйрьнең үзенчәлеге тагын да тулылана төшә. Бу уңайдан шагыйрь, әдәбият белгече, хәзер инде профессор Гыйлемдар Рамазанов күзәтүләре игътибарга лаек. «Кызыл таң» газетасының 1968 ел, 79 санында басылган мәкаләсендә ул болай ди: «Галимҗан Латыйп иҗаты артык шаулы, күзгә нык ташланып баручан да түгел. Ләкин аны ихлас укыган һәркем шагыйрьнең чын күңелдән сөйләшүенә, иҗат ялкынына салкын карый алмый. Безнең якташыбыз — тирән хисләр, якты фикерләр, зур образлар белән эш итүче чын шагыйрь».

Мәкаләдә тагын бер үзенчәлек күрсәтелә: «Шагыйрьнең, — ди галим, — бик кыска, афористик шигырьләре — дүрт юллык, сигез юллык тирән философик мәгънәле әсәрләре дә бар. Аларны шунда ук күңелгә салып куясың».

Әйтергә кирәк, шагыйрьнең иҗат үзенчәлеге алдагы елларда да аерым бизәкләр хисабына тулылана барды, элек ирешкән сыйфатлар тагын да ныгый, ачыла төште. Бу үзгәрешләргә игътибар иткән белгечләрнең берсе Зәет Мәҗитов «Социалистик Татарстан» газетасының 1972 ел, 20 январь санында басылган мәкаләсендә Г. Латыйп «купшы бизәкләр белән, күзгә кереп торырлык тышкы формалар белән язарга яратмаучы шагыйрь», ди. һәм алга таба аның шигырьләренә тыйнак һәм сабыр агышлы ритм, гади һәм ачык тел хас булуны искәртеп уза.

Биредә китерелгән фикерләр, шөбһәсез, Галимҗан Латыйп иҗат портретын төсмерләргә, шагыйрьнең үзенчәлеген сиземләргә ярдәм итәләр. Ләкин иҗат үзенчәлеге турында сүз барганда, шагыйрь эшчәнлегенең тагын бер ягын истән чыгармаска кирәк. Галимҗан Латыйп — балалар язучысы да. Аның иҗатында балаларга багышланган шигырьләр зур урын алып тора. «Якты көннәр» (1952), «Яз башлана» (1953), «Кошлар килде» (1954), «Учак янында» (1955), «Аучы малае» (1959), «Җилферди лагерь байрагы» (1965), «Бәләкәй музыкант» (1970) «Крокодил елый» (1976) — болар барысы да балалар өчен язылган китаплар. Г. Латыйпның бу өлкәдәге эшчәнлеге дә тәнкыйтьтә уңай бәя алып килә. Әйтик, 1952 елда галим һәм тәнкыйтьче Нил Юзиев («Совет әдәбияты», 11 сан) «Галимҗан Латыйпның «Якты көннәр» китабын укыгач, шуны әйтәсе килә: автор үзенең нәни укучылары белән аларны кызыксындыра торган күп нәрсәләр турында чын күңелдән сөйләшә ала... Һәр шигырь балага коммунистик тәрбия бирү максатыннан чыгып язылган, һәр шигырьдә дидактика бар. Тик бу дидактика ялангач түгел, автор үз идеяләрен әдәби эшләнгән образлар аша, художестволы тел белән тормышка ашыра», — дип язган иде.

Шагыйрь Зыя Мансур исә болай язды: Г. Латыйпның «...аерым шигырьләрен тыныч кына укып килгән җиреңнән елмаеп җибәрәсең. Бу исә шагыйрьнең кирәк урында юмор элементларыннан файдалана белүе дигән сүз». («Яшь сталинчы», 1955, 28 авг.)

Шунысы куанычлы: соңгы елларда да Г. Латыйп иҗат портретына яңа буяулар өстәлә тора. Шагыйрь һаман актив, һаман иҗат итә. Аның 1978 елгы җыентыгы — әнә шул тынгысыз иҗат нәтиҗәсе [1].

«Карлыгачларым» — мәгънәле исем. Карлыгачлар — бик күпләргә билгеле гади һәм файдалы кошлар. Җыентыктагы шигырьләр дә, гүя шул кошлар кебек, кешегә дус һәм иптәш. Бу — чыннан да, шулай. Ул шигырьләрне кешегә нәрсә якын итә соң? Мәгънәле сүз, заман сулышы, сәламәт хис. Бу компонентларны Галимҗан Латыйп киң тормыш материалында чагылдыра. Мәсәлән, аның туган җиргә, туып-үскән авыл тормышына мәхәббәт шигырьләре күп. «Безнең яклар», «Ай үтә, еллар үтә дә», «Әйтелмәгән сүзләрем бар», «Суынмаган әле учакларың», «Казан арты», «Кырлар, кырлар», «Авылга кайта җырлар», «Базы бүе бөдрә тал» һ. б. — болар туган җирне, туган тиреләкне олылыйлар.

Аннары шагыйрьнең хис кайнарлыгын, фикер зирәклеген шулай ук даими биләп торган темалары бар. Алар — Ленин, Октябрь, Туган ил.

Дөньяның тынычлыгын бозарга маташучыларны авызлыкларга чакырган шигырьләр дә җыентыкта үзләренә лаеклы урын алганнар. Аларда шагыйрь табигатьне, тереклекне, матурлыкны саклау өчен кешенең җаваплы булуын ассызыклап күрсәтә.

Кем үз-үзен бераз хөрмәт итә,
Хөрмәт итә җирне, тормышны,
Тынычлыкны саклау, яклау өчен
Соңгы көненә кадәр бурычлы.

---

[1] Галимҗан Латыйп. Карлыгачларым. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1978.

Ләкин шагыйрь нинди генә тормыш материалын алмасын, аның игътибар үзәгендә торган төп объект — кеше.

Мин колы да, солдаты да
Түгелмен «аллалар»ның,
Кемгәдер таш аттырырга
Яраннар ялламадым.

Кем ул? Нинди кеше? Һәрхәлдә — җилбәзәк, тотнаксыз, бозык зат түгел. Ул — чын кеше. Аның намусы — пакь, зәвыклары — камил.

Вак җанлы адәмнәр белән
Итмәдем алыш-биреш.
Яраттым җирне, күкләрне
Саф килеш, аек килеш.

Шул ук вакытта ул курку белмәс батыр да, тәвәккәл дә:

Очраса юлда эт, бүре,
Юк, кире чигенмәдем.
Дошманым кылыч селти дип,
Булмады иелгәнем!

Аның башкаларга мөнәсәбәтен чын әхлаклылык билгели:

Юл биргәнгә юл бирәм,
Кул биргәнгә кул бирәм.
Тәкәбберге — мин тәкәббер,
Кулда корыч дилбегәм.

Ниһаять, менә бу кешенең рухи асылы:

Кешегә, Җиргә, Дөньяга
Изгелек кылганнарга
Табынам аллам итеп мин,
Кылычым — яманнарга!

Күренә ки, шигырь тормышта актив позицияле, кыйбласы ачык билгеләнгән кешене сурәтли. Җыеп әйткәндә, ул — җитлеккән социалистик җәмгыятьтә Коммунистлар партиясе тәрбияләгән яңа Кеше, җитмешенче еллар кешесе. Ул кирәк булган һәр минутта «Кече җир» баһадирларының каһарманлыгын, Муса Җәлил күрсәткән батырлыкны, рухи ныклыкны кабатларга әзер.

Г. Латыйп югары гражданлык хисләрен раслауда Муса Җәлил, Һади Такташ, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур һ. б. кебек остазлар салган юлдан бара. Шуңа күрә дә аның лирик герое — даһи Ленин белән горурланамы ул, хезмәткә мәдхия җырлыймы, әллә мәхәббәт хисләре кичерәме, туй ясыймы, ял иткәндә күңел ачамы — шигырьдә тәгъбир ителгән заманча рухы, күтәренке күңел пафосы белән терлекчегә һәм игенчегә дә, завод эшчесенә һәм космонавтка да, галимгә һәм студентка яки мәктәп баласына да бер үк дәрәҗәдә якын.

Укучы шигырьне беренче уку, беренче аңгырау белән ачык аңласын, үзләштерсен, үз итсен. Сурәтле фикер аны дулкынландырырлык, уйландырырлык, хәрәкәткә китерерлек актуаль булсын. Шушы караштан чыгып Г. Латыйп үзенең күпчелек шигырьләрендә кеше образын формалашу процессында түгел, бәлки аны тәрбиянең нәтиҗәсе буларак, өлгергән шәхес, җитлеккән характер итеп сурәтли.

Җыентыкта публицистик пафослы монолог формасында язылган шигырьләр күп. Алар турыдан-туры укучыга мөрәҗәгать итәләр, аны уйланырга, карар кабул итәргә, конкрет эш күрсәтергә чакыралар:

Чишмәләр тап, агач, чәчәк утырт,
Җаның яшәрт, яшәрт дөньяны.
Җәберләмә җирне, типкәләмә,
Футбол тубы түгел Җир шары!

Шагыйрь җыр текстлары иҗат итү өлкәсендә дә уңышлы гына эшләп килә.

Гел кояш балкысын күкләрдә,
Чыкмасын кап-кара болытлар.
Тынычта яшәсен Җир шары,
Елмаеп уянсын оныклар...

Безгә калса, бу юлларның үзләрендә үк музыка бар һәм аларны Хәснул Вәлиуллинның көйгә салуы, мөгаен, очраклы түгелдер.

Галимҗан Латыйп иҗаты, әйткәнебезчә, хәзерге татар совет шигърияте мәйданында биек тау булып калкып тормый. Ләкин ул, әдәби хуҗалыкның бердәм системасында әһәмиятле буыннарның берсе буларак, шул мәйданда инде мәһабәт булып күтәрелгән тауларны ачыграк төсмерләргә ярдәм итә:

Без бу җирдә гөлләр үстерәбез,
Ихтирамга лаек халкыбыз.
Планетаның күпме гомере булса,
Шуның кадәр яшәү хакыбыз!

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН.**

# ИЛ БЕЛӘН БЕРГӘ

*Мәхмүд Максудның тууына 80 ел*



*Мәхмүд Максуд — татар совет әдәбиятының нигез ташлары салыну чорында ук иҗат итә башлаган әдипләребезнең берсе. Татар демократик әдәбияты рухында тәрбияләнгән һәм рус классик әдәбияты белән дә таныш булган яшь язучының иҗаты баштан ук төрле юнәлешләрдә үсә. Ул шигырьләр, нәсер-хикәяләр белән бергә мәкаләләр дә яза, тәрҗемә өлкәсендә актив эшли.*

*М. Максудның иҗаты аның тормышы һәм иҗтимагый-политик эшчәнлеге белән аерылгысыз бәйләнгән. Гражданнар сугышы елларында ул үзе теләп Кызыл Армиягә языла һәм кулына корал алып Совет власте өчен көрәшләрдә катнаша. 1919 елда Коммунистлар партиясе сафына баса. Мәхмүд Максудның матбугат эшчәнлеге башлану да шушы елларга туры килә. 1918 елда ул Мәскәүдә Г. Ибраһимов редакторлыгында чыга торган «Чулпан» газетасында тәрҗемәче булып эшли башлый. Гражданнар сугышыннан кайткач, ВЛКСМ Үзәк Комитеты аны «Яшь эшче» газетасы редакциясенә эшкә җибәрә. Бөек Ватан сугышына кадәр М. Максуд төрле газета-журнал редакцияләрендә һәм нәшриятларда җаваплы эшләр башкара. Сугыш башлангач, ул, кулына корал һәм каләм алып, яу кырына китә, фронтта чыга торган «Совет сугышчысы» газетасында эшли.*

*Мәхмүд Максудның әдәби эшчәнлеге гаять күп кырлы — ул шагыйрь һәм прозаик та, тәнкыйтьче һәм ялкынлы очерклар авторы да. Әдип үзенең әсәрләрендә яңа тормыш төзүче совет кешеләренең тырыш хезмәтен, тугандаш халыкларның бердәм гаиләсендә чәчәк атучы республикабыздагы күркәм үзгәрешләрне тасвирлый. «Яңа шәһәр һәм аның кешеләре», «Безнең мехчылар» исемле очеркларында, мәсәлән, язучы ныклы адымнар белән алга баручы социалистик җәмгыятьнең кешеләрне дә үзгәртүе, үстерүе турында дулкынланып сөйли.*

*М. Максудның таланты әдәби тәрҗемә өлкәсендә аеруча үзенчәлекле яклары белән ачыла. Ул татар теленә В. И. Ленин хезмәтләрен, бөек «Коммунистлар партиясе Манифесты»н тәрҗемә итә. Без А. С. Пушкин, И. С. Тургенев, Л. Н. Толстой, А. М. Горький, шулай ук Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятлары классикларының күп кенә әсәрләрен аның тәрҗемәсендә укыйбыз.*

*Заман сулышы белән яшәү, халык идеалларына хезмәт итү — Мәхмүд Максуд иҗатына хас төп сыйфатлар әнә шундый.*

*Түбәндә әдипнең бертуган энесе Хак ага Максудның истәлекләре тәкъдим ителә.*

Туган авылыбыз Югары Кибәхуҗа тоташтан салам түбәле, тәбәнәк өйле авыл иде. Аның кайсы ягыннан килмә, беренче карашка, салам эскертләре арасына барган шикелле буласың. Түбәләрдән чыгып торган морҗалар эскертләр өстенә кунган козгыннарны хәтерләтәләр. Ике мәчет манарасы һәм такта түбәле берничә йорт кына авылга якынлашуыңны белдерә.

Авылның көнбатыш кыр капкасыннан чыгып ике чакрым чамасы җир китсәң, Максабаш авылына барып җитәсең. Бу авылның төньягындагы тау итәгеннән чыккан чишмәләрдән Макса елгасы башлана. Ул, өч Кибәхуҗаны һәм Казаклар авылын узып, Мишә суына барып кушыла.

Җәй көннәрендә Макса суы тездән узмаса да, аерым тугайларында балалар йөзәрлек була, язгы ташу вакытларында исә ул тегермән буаларын, күперләрне җимерерлек дәһшәтле агымга әйләнә иде. Авылыбызның тегермән буасы һәм Макса аркылы салынган күпер җимерелми калган елны хәтерләмим. Язгы ташу вакытында кичләрен авыл яшьләре зур-зур салам көлтәләренә ут төртеп, агып бара торган бозларга «утыртып» җибәрәләр. Кемнең көлтәсе ярдан ераграк аккан бозга эләгә һәм яктырак яна, шул кеше мактауга лаек була.

Су өсте, күз күреме арага, күчеп йөрүче учаклар белән каплана. Олы Кибәхуҗага җиткәндә аларның көле генә кала. Биредә дә егетләрнең йөрәгенә мүк үсмәгән, алар яңа учак ягалар.

Салам яндыручылар арасында Мәхмүд тә чуала. Кечкенә гәүдәле, көлтәсеннән ике тапкыр нечкәрәк Мәхмүднең көлтәсе кайчакта яр буенда ук кала.

— Әй, җебегән, алай итмиләр аны, — ди зуррак егетләрдән берәрсе һәм көлтәне озын саплы тимер ыргак белән эләктереп ала да, яңадан бозга ташлый...

Авылдашларыбыз җебегәнлекне яратмыйлар, үз тиңдәшләребездән калышсак, хәтта кимсетеп карыйлар иде. Шуның өчен берничек тә аерылып тормаска тырыштык. Урагын да урдык, көлтәсен дә керттек, кардан яңа гына ачылган тау битләүләрендә сарыклар да көттек. Тәмәке тартырга да, сүгенергә дә өйрәндек. Ләкин Мәхмүд абый тәмәке дә тартмады, сүгенә дә белмәде. Үсеп җиткәч тә аның иң начар сүзе «чорт»тан узмады. Әмма «чорт»ны нык басым ясап әйтә белә иде.

Хуҗалыгыбыз байдан булмаса да, йорт-җире белән салам түбәле тәбәнәк өйләрдән аерылып тора иде. Өч өйнең берсе «ак» дип атала, анда әтиебез яши. «Ак» өйгә керергә бездә зур теләк юк, чөнки әтиебез җитди һәм коры кеше иде. Мәхмүд абый аңа өч-дүрт сүз белән төгәл характеристика биргән: «Әтием аз һәм үзсүзле, эре һәм кире табигатьле кеше иде» («Кайбер истәлекләр»). Уку сезоны җиткәч кенә ул өйгә керәбез. 6 яшьтән 10 яшькә кадәр әти безне үзе укыта, аннары Кышкар мәдрәсәсенә илтеп куя иде.

«Мин бик кече яшьтән, 8—9 дан ук әдәбият укуга бирелдем...», — ди Мәхмүд абый үзенең «Кайбер истәлекләр»ендә. Шул вакыттан алып вакытлы матбугат һәм матур әдәбият әсәрләре белән танышып бару аның гадәтенә әйләнде. Барыбызга да мәгълүм Гази Кашшаф «Соңгы минутларда» исемле мәкаләсендә Мәхмүд абыйның Казанда чыга торган барлык матбугатны укып баруын әйтә.

*
* *

Югары Кибәхуҗаның төньяк басулары Симет авылы урманына барып терәлә. Бу урман безгә үтеп чыга алмаслык булып күренә.

Анда кура җиләге һәм чикләвек хисапсыз күп була иде. Авылыбызның карчыклары һәм бала-чагасы җиләк сезонында таң белән урманга баралар, туз чиләкләр җиләк белән тулгач кына өйгә кайталар иде. Мин башта күрше Хубҗамал әбигә ияреп, аннан Мәхмүд абый белән бергә җиләккә йөри башладым. Ул чакта иң авыры кояштан да алда тору иде. Бер әйтү белән тормасаң, ул көтми. Чыгып китсә, йөгереп тә артыннан җитә алмыйсың. Көннәрдән бер көнне җиде-сигез малай һәм кыз, Мәхмүд абыйга ияреп, җиләккә киттек. Элекке көннәрдә чиләкләр ике-өч сәгать эчендә тулган булса, бу юлы төпләре генә күмелгән. Мәхмүд абый кычкырып җырлый башлый:

**И җиләгем, җиләгем,**
**Тулмады ич чиләгем,**
**Мөхәммәди килеп чыкса**
**Бирер идем кирәген!**

Җыр тәмамлана гына, бер кыз әче тавыш белән:

— Әнә, Мөхәммәди килә! — дип кычкыра да, бөтен кәчүнә авыл ягына йөгерә, Без — аның артыннан. Урман сакчысы Мөхәммәди абзый җырны ишеттеме-юкмы, әйтеп булмый, бала-чага артыннан йөгереп вакланмады...

Көн саен өйгә кайту белән Мәхмүд абый җыйган җиләген чүп-чардан тазарта, урманга йөри алмаучыларга күчтәнәч өләшә, калганын изеп, шома такталарга җәя, киптерә. Шул рәвешчә мәдрәсәгә алып китәргә как хәзерли.

*
* *

Әтиебезнең ир балаларын дин хезмәтчесе итү теләге булуы табигый хәл. Ул үзе күп еллар укып Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган. Кышкар мәдрәсәсе исә фанатик мулла һәм мәзиннәр хәзерләү үзәге иде. Ләкин безнең 6 ир туганның берсе дә ул мәдрәсәне тәмамламады. Абыебыз Гаяз Кышкарны ташлап Буби мәдрәсәсенә киткән булса, Мәхмүд абый Малмыжга китте һәм анда Бөек Октябрь революциясен каршылады. Безне — энеләрен һәм сеңелләрен — яңа юлга бастыру чараларын күрде, 1923 елда ир туганнардан өчесе коммунист, икесе комсомолец иде.

1919 ел башында Мәхмүд абый Малмыждагы «Ярлылар тавышы» газетасы редакциясендә эшли башлый. Шул вакытта комсомолга керә, аның актив члены була, өяз комитетының члены итеп сайлана. Ләкин тыныч тормыш озакка бармый. Малмыж комсомолецлары үзләре теләп Колчакка каршы көрәш фронтына китәләр. Алар арасында Мәхмүд Максуд та була. Ул дошманга каршы мылтык һәм каләм белән көрәшә, фронтта чакта күп кенә шигырь һәм нәсерләр яза. Аның «Корал алам», «Бөек идеал өчен», «Изге максатка таба» исемле шигырьләре, «Кырылыш мәйданында», «Изге көрәшкә», «Каравылда», «Сагынам, сөям сине, туган илем» исемле нәсерләре фронтта язылганнар һәм шул вакытта Казан газеталарында басылганнар.

*
* *

... 1919 елның көзе иде. Өйгә чәчләре җилкәсенә төшкән, үтә ябык һәм чырайсыз бер солдат килеп керде. Аның шинеле чамасыз киң һәм озын. Барыбызның да күзләре аңар төбәлде, ләкин берәү дә сүз башламый.

— Әллә танымыйсызмы? — ди солдат.

Бу тавышны ишеткәч, әнинең йөзе ачыла, аның күзләреннән шатлык яшьләре тәгәри, «Мәхмүд, Мәхмүд, Мәхмүд», — дип кабатлый. Без дә солдат абыйны әйләндереп алабыз. 1922 елда язган «Әнигә хат» исемле нәсерендә Мәхмүд абый бу очрашуны болай исенә ала: «... Исеңдәдер, әнием, бервакыт мин фронттан авырып кайткан идем. Чәчем озын, чыраем ак, бөтен гәүдәм хәлсез иде. Син, ике кулың белән минем кулымны кысып, күз яшьләрең белән еладың...»

Мәхмүден озын чәчле көенчә әти күзенә күренүдән кисәтә*әни.

— Улым, әйдә, чәчеңне алыйм, атаң бу килеш ошатмас, — ди ул һәм чәч алу машинасын кулына ала (барыбызның да чәчен әниебез үзе ала иде).

— Мин бик арыдым һәм ачыктым әле, чәчне соңыннан алырсың, әти күрсә дә зарары юк, — ди Мәхмүд абый.

Өч елдан артык читтә йөргән Мәхмүд абый бөтенләй икенче кешегә әйләнгән, ашап-эчеп бетергәч дога кылмады, әнигә рәхмәт әйтте. Җомга җитте — намазга бармады. Мәсьәләгә соңрак төшендек: ул вакыттагы авыл советы председателе Исхак абзый «Мәхмүд коммунист булып кайткан» дигән хәбәр чыгарды.

Атна-ун көн ял иткәннән соң Мәхмүд абый Лаешка китеп барды. Үзе белән апабыз Галияне дә[1] алып китеп, аны Лаештагы укытучылар курсына урнаштырды. Әти моңа рөхсәт бирмәгән иде. Шуның өчен Мәхмүдкә дә, апабыз Галиягә дә бойкот белдерде, «кайтып күземә күренмәсеннәр», диде. Ул вакытта Нәҗиб[2] тә Малмыжга киткән иде.

Авылның хәлле кешеләре һәм куштаннары безне яратып бетермәсәләр дә, гади крестьяннар һәр вакыт теләктәшлек күрсәттеләр.

---

[1] Галия — күп еллар укытучы булып эшләде, хәзер пенсиядә, Казанда яши.
[2] Нәҗиб — хәзер персональ пенсионер. Казанда яши.

Бер көнне авылдашыбыз Җәләлетдин абзый:

— Габделхак, мин иртәгә Лаешка барам, Мәхмүдләргә йомышыгыз юкмы? — дип сорады.

Мин моны әнигә кайтып әйттем. Әни шул көнне күп итеп он иләде. Кичен капчыкка бер пот чамасы он һәм бер каз түшкәсе салып, Җәләлетдин абзыйларга илтеп бирүне миңа һәм кече энебез Хәкимгә[1] йөкләде. Моны әти белергә тиеш түгел иде, әлбәттә.

Без капчыкны кечкенә чанага чыгарып салдык та, аның өстенә Хәким менеп утырды. Мин чананы тартып капкадан йөгереп чыгып киттем. 1919—1920 еллар кышында бу «операция» өч-дүрт тапкыр кабатланды. Ләкин аны әтигә җиткерүче булмады.

Мәхмүд абыйның вакытлы матбугатта актив катнашуын без белми идек әле, чөнки аның әсәрләре басылган газета-журналлар авылыбызга килми иде. Шулай да «Әнигә хат» дигән нәсере, «Кызыл шәрык яшьләре» журналында чыгу белән, Югары Кибәхуҗа халкына барып җитә. Авылның надан куштаннары: «Мәхмүд чукынган», «Мәхмүд урыс диненә күчкән», — дип шау киләләр. Мәхмүд абый соңгы сулышына кадәр сугышчан атеист булып калды.

*

* *

Мәхмүд Максуд Бөек Ватан сугышының башыннан ахырынача фронтта булды. Сугыштан исән-сау кайткан майор Казан урамында бәхетсезлеккә очрап (аны машина бәреп ега), чукраклана. Ишетмәгән килеш шигырь дә, хикәя дә язарга, тәрҗемә дә ясарга мөмкин. Очерк язу өчен исә кешеләр белән нык аралашырга кирәк. Мәхмүд абый үзенең күләмле очеркларын чукрак килеш язды.

Көннәрдән бер көнне ул мехчылар тормышыннан әсәр язарга була да, мехкомбинатның парткомына барып теләген сөйли. Парткомдагы иптәшләр комбинатның кадрлар бүлегендә эшләүче Камал иптәш Гайнетдиновка әдипне таныштырып йөрү бурычын йөклиләр. Ул вакытларны Гайнетдинов[2] иптәш түбәндәгечә искә ала:

«Мәхмүд ага белән комбинатның барлык фабрикаларында, цехларында, бүлекләрендә булдык, кайбер эшчеләрнең өйләренә бардык. Кайда гына булсак та Мәхмүд ага үзенең кем булуын, нигә килгәнлеген әйтә дә, сорауларын бирә башлый. Мин җавапларны чәчми-түкми кәгазьгә терким. Ул язуымны күзәтеп тора һәм язып бетерүгә яңа соравын бирә... Теләгән җиренә алып бардым, сораганын җавапсыз калдырмадык. Атна-ун көн шулай йөргәннән соң, барлык кәгазьләрне папкасына салып, миңа рәхмәт әйтеп китте. Озакламый «Безнең мехчылар» исемле очерк журналда басыла башлады, соңыннан аерым китап булып чыкты. Без китапны яратып укыдык, Мәхмүд агага рәхмәт әйттек...»

*

* *

Мәхмүд абый каты һәм озак авырды. Ләкин үлем турында телгә алырга да яратмый иде. Эш турында сөйләде, эшне кайгыртты. 1961 елның май аенда ул Казан больницасында дәваланды. Мин баргач бакчага чыкты. Бераз барабыз да ял итәргә туктыйбыз. Бакча эскәмияләренә дә утырып торабыз. Шулай йөри торгач бер сәгать вакыт узды. Мәхмүт абый әле терелеп күп кенә эшләр башкарырга өметләрен сөйләде.

Хәйләкәр үлем аны эш турында, әдәбият турында икенче бер әдип белән фикер алышу вакытында егып салды. Гази Кашшаф әйткәнчә, М. Максуд атакага барганда пуля тиеп егылып калган солдат кебек, зур иҗат планнары белән илһамланып кулына каләм тоткан хәлдә, үз постында вафат булды.

**ХАК МАКСУД.**

---

[1] Хәким — Ватан сугышында һәлак булган энебез. — Х. М

[2] К. Гайнетдинов хәзер пенсиядә. Казанда яши

## Зәйнәп Хәйруллина

# ҖЫР БУЛЫП ЯҢГЫРАГАН ЯЗМЫШ

*Җәүдәт Фәйзинең тууына 70 ел*

Җәүдәт Фәйзинең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге — күп милләтле совет сәнгатенә фидакарь хезмәт итүнең гүзәл үрнәге. Аның иҗади мирасы музыкаль культурабызның алтын хәзинәсенә керде. Җ. Фәйзи төрле жанрларда иҗат иткән киң колачлы композитор, халкыбызның музыкаль иҗатын тирән өйрәнгән, бигрәк тә хәзерге заман халык көйләрен җыюга һәм эшкәртүгә күп көч куйган фольклорчы, музыка мәгърифәтчесе һәм актив җәмәгать эшлеклесе.

1932 елның декабренда Җ. Фәйзинең беренче җырларыннан «Урман кызы» киң җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителә. Күренекле композитор һәм педагог В. И. Виноградов аңа музыкаль иҗат белән җитди шөгыльләнергә киңәш бирә. Шулай итеп, Һади Такташ сүзләренә язылган үзенчәлекле интонацияләргә ия, ягымлы лирик җыр Җ. Фәйзинең тормыш юлына яңа юнәлеш бирә, аны гомерлеккә музыка дөньясына алып кереп китә. Казанда ул заманда яңа гына ачылган совет хокукы институтының гыйльми секретаре булып эшли башлаган юрист Җәүдәт Харис улы Фәйзуллин яңадан студентка әйләнә, Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә укырга керә, консерватория профессоры Г. И. Литинский һәм композитор Б. С. Шехтер классларында композиторлык серләрен өйрәнә.

Революцион рухлы массовый җырлары белән танылган композитор Б. С. Шехтерда уку елларында Җ. Фәйзи музыка фәнен үзләштерү белән бергә, иҗат эшенә дә чума. Заманга аваздаш җырлар яза. Җырларында ул гражданнар сугышының яшь батырларына соклана («Комсомолка Гөлсара»), Ватанны уяу сакларга өнди («Атым чайка башыңны»), туган җирнең гүзәллеге турында сөйли («Урман буенда»). Композиторның җыр жанрында эшләве кырык елдан артык дәвам итә. Ул халыкка 200 ләп җыр бүләк итә. Аларның күбесе илебездәге зур вакыйгалар, үзгәрешләр белән бәйләнгән һәм, иң әһәмиятлесе, берсе дә «бер көнлек» түгелләр, бүген дә художество кыйммәтләрен югалтмыйлар. Әйтик, 1935 елда язылган «Шауласын, гөрләсен безнең җыр» һ. б. дәртле, алга өндәүче җырлары бүген дә яшьләрне берләштереп, өлкәннәрне җилкендереп кырда да, табында да җырлана.

1941 елның көзендә совет халкы киеренке көннәр кичергәндә иҗат ителгән «Канга кан» җыры җиңү көненә кадәр дошманнарга нәфрәт, хак эшебезгә ышаныч булып яңгырады. Без аны бүген дә зур дулкынлану белән, Бөек Ватан сугышында тиңсез җиңү яулаган совет солдатының музыкаль истәлеге итеп тыңлыйбыз. Тыныч төзелешкә күчү елларында туган «Шауласыннар яшел урманнар», «Татарстан нефтьчеләре маршы», «Комсомол» җырлары белән янәшә 70 нче елларда Кама буендагы зур төзелешләрне данлаган «Чаллы», «Яңа кала» җырлары яши.

1966 елда Тукай премиясенә лаек булган «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Җәлил йолдызлары», «Исеңдә тот, иптәш» кебек көрәш җырлары белән бергә, концерт программаларын күп еллар элек туган «Гармонь», «Бәйрәм бүген», «Кем уйлаган» җырлары да тулыландыра.

Җәүдәт Фәйзи җырларында халыкның йөрәк тибешен ишетәсең, сафлыкка һәм батырлыкка өндәүче көчле мәхәббәт хисен тоясың. Совет халкы тормышындагы хәлиткеч һәр борылыш, һәр үсеш Җ. Фәйзи иҗатында яңа җырлар агымын тудыра. Музыкаль җәмәгатьчелек, бигрәк тә илебезнең күренекле рус совет композиторлары, аның беренче җырларын ишетүгә, музыкаль теленең көйле булуына басым ясадылар. Әйе, Җ. Фәйзи көйгә бай иҗатчы. Ул заманга аваздаш интонацияләр белән эш итә. Аның ачык, затлы, ягымлы көйләре күңелгә тиз үтеп керә, хәтердә нык саклана.

Татар совет композиторларының җыр жанрындагы хезмәте турында сүз кузгалганда, гомумән, Җ. Фәйзи исеме зур ихтирам белән телгә алына. Чөнки ул җыр жанрын башлап җибәрүчеләрнең һәм шул жанрның үсүенә юнәлеш бирүчеләрнең берсе булды.

Балалар өчен язган җырлары композиторның яшь буынны эстетик тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, төрле яшьтәге балаларның психологик үзенчәлекләрен һәм тормышын яхшы белүе турында сөйлиләр. Җәүдәт Фәйзинең Муса Җәлил белән бергә 1936 елны иҗат иткән җырлар альбомы татар музыкасының гүзәл сәхифәләреннән санала. Ике кайнар йөрәкле автор балаларны бик яратып, зур осталык белән илебездәге кызыклы вакыйгалар турында сөйлиләр («Шмидт бабай», «Беренче дәрес»), табигатьне яратырга, аның серләрен аңларга өндиләр («Чишмә», «Күке», «Әтәч», «Маэмай»). Алар арасында юмор белән язылган җырлар да бар («Карак песи», «Сәгать»). Композиторның нәниләргә адресланган җырлары 50 гә якын.

Җ. Фәйзи җырларының халык арасында тиз таралуы, уңыш казануы тагын шуңа да бәйләнгән: композитор җыр өчен татар поэзиясенең матур үрнәкләрен сайлап ала белә. Бу исә аның әдәбиятны тирән белүеннән, югары зәвыклы булуыннан килә. Җ. Фәйзи — Тукай шигырьләрен беренче башлап музыкага салган композиторларның берсе. Аның җыр иҗаты Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Әхмәт Ерикәй шигырьләре белән башлана. Әдәбият мәйданына яңа талантлар чыга барган саен күзәтүчән табигатьле Җ. Фәйзи алар белән иҗади багланышка керә, аларга җыр тудыру серләрен төшендерә килә. Нәтиҗәдә Әхмәт Исхак, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Мәхмүт Хәсәен белән берлектә үзенчәлекле җырлар туа.

Җ. Фәйзи республикабыз театрларында барган 25 спектакльгә музыка яза. Сәхнәдә барган конкрет образларның кичерешләреннән туганлыктан, театраль музыка иҗат итү сурәт тудыруда, хис-кичерешләр чынлыгына ирешүдә аеруча зур осталык таләп итә. Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасына хәзерләнгән музыкадан тол хатын Гайнавал җырын искә төшерик. Ул гади, авыл хатыны образына ифрат якын көй. Ә көй агылышында никадәр хәсрәт, күңел газабы сизелә! Шуңа да Гайнавал җыры күптән инде халык күңелендә яши. Моңар охшаш мисаллар итеп «Хуҗа Насретдин» спектакленнән бик җитез, күтәренке «Яшә, Хуҗа Насретдин» җырын, «Тормыш җыры» спектакленнән Басыйр җырын алырга була.

Спектакльләрдә туган җырларның да бик күбесе массовый җырлар хәзинәсен баеттылар.

Җ. Фәйзинең тирән эчтәлекле җырлары, тормышка чиксез мәхәббәт белән тулы көйләре халык иҗатына да яңа интонацияләр алып килделәр. Безгә Җ. Фәйзи йогынтысында халык чыгарган «Рәйхан», «Вәгъдә» кебек хәзерге заман көйләре мәгълүм. Халык композиторның җырларын үзенчә дә җырлый. Халыкныкы дип җырлана торган «Яшь наратлар» көен чынында Җәүдәт Фәйзи иҗат иткән. 1935 елны шагыйрь Ф. Кәримнең «Кәтәм сине» шигыренә Җ. Фәйзи лирик җыр-романс язган иде. «Кәтәм сине» тиз арада зур уңыш казанды, тик, аерым сәбәпләр аркасында, 1940 елны тукталып калды. «Кәтәм сине» җыр-романсын моннан кырык еллар элек ишетеп, отып калган халык бүген аны шагыйрь Илдар Юзеевның «Яшь наратлар» шигыренә яраклаштырып җырлый.

Җ. Фәйзи үзе дә халык иҗатыннан илһам-рух ала. «Рамай», «Матур булсын», «Яшә минем республикам», «Ай, йолдызым», «Бәгърем», «Ачма тәрәзәңне» һәм башка шундый хәзерге заман татар халык көйләрен авылларда йөреп, шунда табып кайтып, аннан танылган җырчылар аркылы яңадан халыкка җиткерүче һәм, гомумән, заман көйләренә башлап колак салучы, аларны эшкәртүгә профессиональ музыкантларның игътибарын иң актив юнәлтүче дә Җ. Фәйзи булды. 1952 елның башында 25 яңа татар халык көен Композиторлар союзында тыңлауга тәкъдим иткәч, өлкән композитор Мансур Мозаффаров Җ. Фәйзине музыкаль фольклорыбызны өйрәнүдәге беренче уңышлы хезмәте белән кайнар котлады. 20 ел буе хәзерге заман музыкаль фольклорын җыю һәм өйрәнүнең йомгагы итеп Җ. Фәйзи «Халык җәүһәрләре» дип аталган зур фәнни хезмәтен киң җәмәгатьчелек хөкеменә тапшырды — халык иҗатыннан 235 көйне ноталары һәм тарихи аңлатмалары белән туплаган җыентыгын 1971 елда Татарстан китап нәшриятында бастырды. Аның хәзерге заман көйләре турында фикер йөртүе, көйләр тарихы һәм аларны җырлаучылар белән таныштыруы, халык көйләренең композиторларыбыз иҗатында ничек нагылуы турындагы мәгълүматлары зур кызыксыну тудыра. «Без Җәүдәт Фәйзине халыкның музыкальлеген сабыр гына күзәтүче, аның иҗатын тәгәл теркәп баручы фольклорчы итеп түгел, ә чын иҗатчы, үзе белән бергә халык талантларын оештыручы итеп күрәбез. Композитор халыкның музыкаль тормышындагы процессларны йөрәге аша иҗади уздырып, тирән уйланулар белән яңадан халык хөкеменә тапшыра»,— ди Н. Җиһанов.

Совет Татарстаны өчен яңа жанр булган музыкаль комедиянең мәйданга килүе дә Җәүдәт Фәйзи исеме белән бәйле. Яңа жанр илебез иң авыр сынау кичергән чорда— Бөек Ватан сугышы барган вакытта туа. 1942 ел. Халык тормышы киеренке. Композитор үзе дә авыр шартларда тора. Аның бу әсәре шәм яктысында языла (Казанда ул елда электр фәкать дәүләт учреждениеләренә һәм госпитальләргә генә бирелә). Казан купецлары тормышыннан лирик музыкаль комедия менә шундый чакта иҗат ителә. Моны ничек аңларга? Соңыннан Җ. Фәйзи үзе болай дип искә ала: «Җиңүгә ышаныч бер генә минутка да кимемәде. Ул киләчәк! Сугыш кырыннан җиңүчеләр кайтачак. Без, тылда эшләүчеләр, алар каршында ничек эшләвебез турында җавап тотарга тиешбез. Җавап, бүләк—үзебез өчен яңа жанрдагы әсәр булсын, дидек без Таҗи ага белән. Икенчедән, авыр хезмәттән арганнарга, кайгы-хәсрәт кичергән җаннарга ял бирәсе, күтәренке, дәртле музыка белән сугыш китергән авырлыкларны вакытлы гына

медиясе өстендә ару-талуны белмәстән эшләдек.»

«Башмагым»ның беренче спектаклен 1942 елның 1 мартында Татар дәүләт опера һәм балет театры коллективы куйды. Шул көннән бирле ул репертуардан төшми уйналып килә. Яңа әсәр рус, украин, үзбәк, казакъ, бурят, тува телләренә тәрҗемә ителә һәм илебезнең бик күп музыкаль театр сәхнәләрендә куела.

Беренче әсәрнең шундый уңышы композиторны тагы да илһамланыбрак иҗат итәргә рухландыра. 1944 елның 25 августында Татар дәүләт опера һәм балет театры аның «Акчарлаклар» исемле икенче музыкаль комедиясен тамашачыларга тәкъдим итә. Әхмәт Фәйзи либреттосына язылган бу әсәр колхоз яшьләренең бәхетле яшәүләре, аларның кыю хыяллары турында. Заманга авааздаш шатлыклы музыка композиторның профессиональ ныгуын, аның күп төрле көйләргә, бию музыкасына юмарт булуын тагын бер кат раслады.

Татарстанның 30 еллыгын Җ. Фәйзи драматург Гамир Насрый либреттосына «Идел буенда» исемле музыкаль комедиясен язып каршылый. Яңа әсәр авыл һәм шәһәр арасында культура аерымлыгының бетә баруы, талантлы авыл яшьләренең сәнгатьтә танылуларын бик тормышчан гәүдәләндерә.

Татарстан республикасының 40 еллык бәйрәменә килгән кунаклар Җ. Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» операсы премьерасында булалар. Гадел Кутуйның мәгълүм повесте сюжетына корылган бу операда Җ. Фәйзи, үзенчәлекле композитор буларак, заман көйләреннән, аларның интонацияләреннән киң файдалана. Әсәрдә композиторның халыкчан җыр осталыгы аеруча өстенлек ала. Мәсәлән, Галиянең студентлар кичәсендәге ариясе нигезенә «Хатлар язам» дигән хәзерге заман халык көе салынган.

Үзенә гаять таләпчән композитор әсәренең кимчелекле якларын сәхнә яктысында ачык күрә, хор, симфоник оркестр яңгырашында анык ишетә. Операдагы вакыйгаларны симфонизацияләү, уңай һәм тискәре образларны кискен контрастлар белән сурәтләү, настроение үзгәрешләрен калкурак бирү теләге белән, ул операның яңа редакциясен рухланып эшләүгә керешә. Аяныч каршы, эшне аяусыз үлем өзә.

Җ. Фәйзи үзенең белгәннәрен башкалар белән уртаклашырга һәр вакыт ашкынып яши. Киң массага, бигрәк тә яшьләргә, музыкаль тәрбия бирү турында уйлана. Шул ашкыну, борчылу аны радиога, телевидениегә китерә, ул газета-журнал битләрендә даими чыгышлар ясый. Музыка сәнгате, аның төрләре, башкаручылары турында радиода алып барган концерт-лекцияләр соңыннан «Музыкаль кичәләр» дигән китапка әверелде. Татарстан районнарына чыгып колхозчылар һәм авыл интеллигенциясе каршында музыка сәнгатенең үсеше турында лекцияләрне иң күп укыган композитор да Җ. Фәйзи булды. «Татарстан яшьләре» газетасында «Музыка, башкаручы, тыңлаучы» исемле мәкаләләр циклы, һичшиксез, яшьләр күңелендә тирән эз калдыргандыр.

Җ. Фәйзи — үткен әдәби каләмле музыкант. Узган чор сәнгать осталарына, музыкаль культурабызга нигез салучыларга, талантлы халык музыкантларына ул тирән ихтирамын кызыклы истәлекләр һәм очерклар язып та белдерде. Халык талантларының фидакарь хезмәтләрен киң массага таныту юнәлешендә өзлексез эшләп килде. Балаларны симфоник оркестрдагы музыка кораллары белән таныштыру нияте белән язган «Кызыклы кунаклар» әкиятенең Мәскәүдә рус телендә чыгуы һәм Татарстан китап нәшриятында кабат басылуы авторның әдәби осталыгы турында да сөйли.

Җәүдәт Фәйзи иҗаты кешеләргә һәр вакыт шатлык алып килде. Гаять сөйкемле, кешеләргә үтә игътибарлы, аларга һәр вакыт чын күңелдән ярдәм итәргә хәзер торучы композиторның үзе белән очрашу да күңелдә куанычлы тойгылар уята иде. Зөләйха Хисмәтуллина, Рәйсә Тимофеева, Флера Сөләйманова кебек талант ияләрен сәнгать юлына Җ. Фәйзи бастырды. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Коммунист Җ. Фәйзи Татарстан радиокомитетында музыкаль тапшырулар редакциясе редакторы — (1939—1942), Татар дәүләт филармониясенең директоры һәм художество җитәкчесе (1944—1958), Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары (1954—1964) вазифаларын зур фидакарьлек белән үтәп, үзе белән эшләгән, очрашкан иптәшләрдә онытылмас истәлекләр калдырды.

Минем хәтеремдә ул ару-талуны белмәс иҗатчы булып саклана. Җәүдәт Харисович һаман эш белән мәшгуль. Аңа карап, кайчакларда аптырап та каласың. Кайчан гына ял итә соң бу тынгысыз кеше?— дигән сорау туа иде. Композитор пассив ялны — курортларга, ял йортларына йөрүне чит күрде: «Мин алай ял итә алмыйм. Мине борчый, газаплый торган андый ялдан авырый башлыйм»,—ди торган иде ул. Җәйләрен композитор кечкенә генә бакчасында яши. Биредә аның үз проекты белән төзелгән бик гади, әмма эш өчен бик уңайлы, зәвык белән корылган иҗат беседкасы бар иде. Анда пианино, язу өстәле, йокы урыны. Иҗат итеп аргач ул бакчага чыгып эшли иде. Кышларын исә иртәнге чәйдән соң эш бүлмәсенә кучә һәм көндезгә ашка кадәр — рояль янында. Аннан соң инде — иҗади очрашулар, кичләрен әдәбият уку, йорт кирәк-яракларын карау. Композитор гомеренең соңгы көннәренә кадәр һаман хәрәкәттә, хезмәттә булды. Кәгазьгә төшми калган уйлары, ноталары язылып өлгермәгән музыкасы күп иде...

## МӘХМҮТ ГАЗИЗОВ



Мәхмүт Газизовның исеме шигырь укучыларга инде күптән билгеле: ул өч-дүрт китап авторы. Чаллы зонасы яшь язучылары конференциясен уздырганда без аның соңгы елларда язган шигырьләре белән дә таныштык.

Бездә хезмәт турында шигырьләр күп языла. Шулар арасында Мәхмүт Газизовныкылар табигый, тормышчан, уй-хисле булулары белән аерылып торалар. Аларга буш риторика, гомумилек ят. Шигырьләрдә — конкрет фикер, конкрет хис. Эшнең ритмын, гармониясен заманча бирергә омтылыш көчле. Чаллы якларындагы зур үзгәреш, яңарыш Мәхмүт Газизов шигырьләрендә дә үзенчә, яңа образларда ачыла. Автор күп кенә шигырьләрендә төзелеш панорамасын гына түгел, шул төзелешләрне барлыкка китерүче төзүченең рухи халәтен тасвирлауга ирешә.

Яшь шагыйрь ашыкмый, шулай да иҗатында актив.

КамАЗ заводларының берсен карап йөргәндә, Мәхмүт шул корылманы төзи башлаганда геодезист булып эшләгәнен әйтте. Ул әле һаман да КамАЗ төзүчеләр арасында. Шагыйрь буларак үсә, эзләнә. Поэзиядә инде аның табышлары һәм ачышлары бар.

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ,**
**Муса Җәлил премиясе лауреаты.**

## РАВИЛ ВӘЛИЕВ



Равил Вәлиев язучылык эшен үзенең биографиясен иҗат итүдән башлап җибәрде. Совет Армиясендә хезмәт итү, КамАЗ төзелешендә ташчы, бетончы, монтажчы һөнәрләрен үзләштерү һәм эшләү аның өчен университет биргән белемне актив көчкә әверелдерүче бай тәҗрибә мәктәбе булдылар.

Художестволы эшкәртү өчен аңа материалны уйлап чыгарасы юк — сюжетлар һәм конфликтларны, характерларны тормыш аңа үзе әзерләп бирде, хәтта жанрны да алдан ук билгеләп куйды — очерк, документаль проза. Р. Вәлиевнең беренче очерклары ук укучыны вакыйгалар чынлыгы, аларның табигыйлеге белән җәлеп итте. «Казан утлары» журналында 1972 елда басылып чыккан «Каурыйлар чыныкканда»

исемле очерклар циклыннан соң «Шәһәр булсын бүләгем» дигән документаль повесть язып, автор тормыш материалын сәнгать фактына әйләндерә алу сәләтен күрсәтте. Заманның иҗади пафосы, хезмәт батырлыгы конкрет, документаль сурәтләрдә гәүдәләнде. Өлешчә «Казан утлары»нда басылган һәм китап булып берләшкән «Таяну ноктасы» исемле цикл — шушы зур эшнең дәвамы.

Р. Вәлиев документаль жанрда яңа әсәрләр иҗат итә. Чаллы якларының үткәне һм бүгенгесе хакында уйланып, тагын да киңрәк масштаблы очерклар җыентыгы әзерли. Шуның белән бергә, художестволы әсәр — повесть тәгәлли.

Мин аның киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешәчәгенә ышанам.

ӘХСӘН БАЯНОВ.

# ШАМИЛ МАННАПОВ



Һәр язучының иҗади үсеше төрлечә, үзенчә. Шамил Маннапов тыйнак үсештәге, дәвамлы үсештәге шагыйрь. Ләкин әдәбият өчен шагыйрьнең нинди манерада үсүе әһәмиятле түгел, ә үсүнең факт булуы, китаптан-китапка ачыла, яңара, сәнгатен үстерә баруы әһәмиятле. Шамил Маннапов дүрт китап авторы. Шушы дүрт китапта аның иҗаты күзгә күренеп җитлегә, яңа күренешләргә байый бара. Аның беренче китабы 1967 елда чыккан, чираттагысы 1976 елда. Ике елга бер китап бирел бару язучының иҗат активлыгын раслый.

Соңгы шигырьләрендә автор тагын да яңа ягы белән ачылган — шигъри формасы камилләшкән, фикере тирәнәйгән. Аның «Хәят көндәлеге», «Тамырлар», «Тугрылык алиһәсе» дигән китапларында беркемнекенә дә охшамаган, Шамил Маннаповныкы гына булган әсәрләр байтак.

Шуны да әйтергә кирәк, Шамил Маннапов проза өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Быел аның «Әти урманы» исемле хикәяләр, парчалар һәм нәсерләр җыентыгы дөнья күрде.

ГӘРӘЙ РӘХИМ.

# ТҮРЕБЕЗДӘ — БЕЛОРУС КЛАССИКЛАРЫ

## Франтишек Богушевич

*1840 — 1900*

*ФРАНТИШЕК БОГУШЕВИЧ — белорус әдәбияты классигы. Элекке Виленский губернасында вак шляхтич семьясында туган. «Студентлар чуалышында» катнашкан өчен Петербург университетыннан куыла. 1863 елгы восстаниедә катнаша һәм яралана. Шул ук елда юридик лицей тәмамлый, аннары суд тикшерүчесе һәм адвокат булып эшли. «Белорус курае» исемле беренче китабы 1891 елда Краковта чыга.*

### Бүре белән Сарык

Бер бәрәнне көпә-көндез
Бүре алып китә.
Ә әнкәсе, көн-төн елап,
Нарасыен көтә...
Янәсе шушы моң-зарны
Ишетә дә Бүре,
Сарык тиресенә төренеп
Кырга килә кире.
Һәм елмаеп сүз башлый ул—
Гүя ачыш ясый!
«Улыгыз сезнең урманда
Җир җимертеп яши.
Күрәйде. Тырнак үстерде.
Ә мөгезе—төште.
Арабызда хәзер ул да
Инде казык тешле.
Куркыныч юк аңа—безнең
Белән бергә атлый.
Тынчык һавалы һәм кысан
Абзарларда ятмый.
Син безгә кунак булып кил!
Урман гәбен гәплләп,
Ит һәм сөяк мул табында
Сыйланырбыз шәплләп!..»
— Бик рәхмәт! Бергә килегез,
Үзегезне көтәм.
Бик беләсем килә, улым
Ничек улый икән?!.
Әйтәләр бит: «Бүре белән
Син бүречә ула...»
Әйе, сезне бары шулай
Белеп-аңлап була.
Күреп торам, синең өстә
Әнә безнең тире...
Һәм казык тешең күренә...
Аңлашыла, Бүре!
Мылтыклы кеше килгәнче
Элдерт моннан кире.

## Альгерд Абухович

*1840 — 1898*

*АЛЬГЕРД АБУХОВИЧ (граф Бандынелинең кушаматы) — алпавыт семьясында туа, гимназия тәмамлый, Көнбатыш Европа илләре буйлап сәяхәттә йөри, 1863 елгы восстаниедә катнаша. Әдәби эшчәнлеге халыкчанлык һәм критик реализм карашларына нигезләнгән була. Рус классикасы әсәрләрен, Мицкевич, Конопницкий, Гете, Шиллер, Гюго, Байрон, Данте иҗатыннан үрнәкләрне белорусчага тәрҗемә итә. Белорус әдәбиятында мәсәл жанрын башлаучыларның берсе.*

## Староста

Дөньяда, дускаем, ни генә итсәң дә,
Иң ерак җәһәннәм читенә китсәң дә,
Көчле зат җиңәчәк көчсезне-мескенне,
Көчлеләр ягында булачак өстенлек.
«Панның иркен бакчасына көн дә кереп
Көтү-көтү сарык йөргәнен күреп
Җаным әрни,—ди бер Бүре Арсланга.—
Шунда алар бик еш кына үзләре дә
Юкка чыга—калмый хәтта эзләре дә.
Чөнки башлы башлыклары юк аларның
Өйрәтергә ничек яшәү кирәклеген!
Староста итеп мине куй шуларга—
Кирәк монда, олуг, минем зирәклегем!»
Бүре шулай үзенә пост таләп итә.
Шуны хуплый, шуны яклау китә... китә...
Яклаша тырышып бер Төлке хатыны—
Арсланбикәнең ахири якыны.
Әшнәләр оеша, әшнәләр хуплыйлар,
Ришвәтләр бирергә бик күп мал туплыйлар...
Һәм куша Арслан зур җыен җыярга,
«Бүре кем?» дигән зур мәсьәлә куярга:
Җәнлекләр-җанварлар әйтсеннәр һәммәсе—
Бүре ул яхшымы, яманмы, янәсе...
Киләләр башлыклар, киләләр түрәләр:
«Без бүре яклыбыз! — дип җавап бирәләр. —
Бернинди суд аны җавапка тартмады!
Тормышта гел туры юл сайлап атлады!»
— Димәк ки, көтүгә башлык та ул була! —
Арслан карары шул була.
Ә нәрсә диде соң сарыклар үзләре?
Бу хәлне ишеткәч шар булды күзләре:
«Чалт аяз күктә ник бу яшен яшьнәде?
Ник безне җыенга беркем дә дәшмәде?..»
Беркетмә языла: көтүдә йөреп, дип,
Сарыклар хөр яши — без бирдек ирек, дип!

## Янка Купала

*1882 — 1942*

*ЯНКА КУПАЛА (Иван Доминикович Луцевич) — халык шагыйре, Дәүләт премиясе лауреаты, Белоруссия һәм Украина академияләренең академигы. Минск өлкәсенең Вязинка авылында крестьян семьясында туган. Башлангыч мәктәптә, Петербургтагы курсларда һәм халык университетында укыган. Кече яшьтән башлап күчереп язучы, приказчик, завод эшчесе һәм китапханәче булып ялланып эшләгән.*

*1903 елда яза башлый, беренче китабы 1908 елда Петербургта чыга. Бөек Ватан сугышы елларында дошман басып алган Минск шәһәреннән күчеп китеп вакытлыча Татарстан АССР Югары Ослан районының Печище тегермәне поселогында (октябрь 1941 — май 1942) тора.*

## Итек һәм чабата

Чабатадан үзен өстен итеп
Әйтә икән Итек:
«Син бит тузган. Син бит сансыз нәрсә...
Бөтен читең китек...»

Ә Чабата кул селти дә әйтә —
Сүзе җыйнак, тыйнак:
«Мин—юкәмен, ә бит кеше сине
Ала иттән тунап!»

## Ишәк һәм күләгә

Чишмә буйлап узган чакта Ишәк
Күрә икән суда үз шәүләсен.
Һәм аптырый: Кем ясаган шулай
Шыксыз итеп аның төз гәүдәсен?!.
«Колакларым нигә шыксыз озын,
Сыртым нигә кәкре ителгән?
Ә корсагым минем кайчан, кайда,
Нәрсә ашап шулай күпергән?..»
Исе китеп суга карый-карый
Бер урында озак таптана ул.
Һәм... пычрата башлый саф чишмәне—
Тояк белән җирне актара ул.

# Якуб Колас

*1882 — 1956*

*ЯКУБ КОЛАС (Константин Михайлович Мицкевич) — халык шагыйре, академик, Дәүләт премиясе лауреаты, күп санлы шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, берничә повесть һәм романнар авторы. Урманчы семьясында туган. Укытучылар семинариясе тәмамлаган, аннан Полесьеда укыткан. Укытучыларның яшерен съездын оештыруда катнашканы өчен 1908 елда өч елга төрмәгә ябылган. Аннары хәрби хезмәттә булган. Беренче әсәрләре 1906 елда басылган.*

## Пан һәм елга

Йөз кешенең сүзен бер үзе
Кире каккан юньсез пан була.
«Даны» аның—«Явыз... Дуамал...
Мәрхәмәтсез...» дигән дан була.
Карар кыла ул зур елганың
Күптән аккан юлын буарга:
«Ник тиеш ул минем биләмәм
Суын моннан читкә куарга?!.»

Ә мужиклар килә зар елап:
«Эшләнелсә әгәр ул буа,
Су баса да безнең кырларны
Ач калабыз—безгә шул була..
Нигә кирәк сиңа андый күл?
Тимә син, пан, тимә елгага!
Һичбер кемгә зыян итмичә
Ул бит инде күпме ел ага.
Аксын елга, аксын, түрәбез,
Ризыкны без шунда күрәбез!..»
Юк, тыңламый, колак салмый пан,
Әйткән сүзен кире алмый пан.
Ялчыларын тиз-тиз җыйдыра,
Зур елганы... ашыгып будыра.
Ә бер төнне нәкъ таң атканда,
Үзе изрәп йоклап ятканда
Кинәт яңгырый панга боерык:
«Кара болыт килә куерып!
Уян түрә!..»
Яшен ялтырый.
Күкләр күкри. Ә пан калтырый
Кинәт күреп ташкын дулкынын...
Алалмыйча тетри ул тынын...
Күз акайган... Ул шыр ялангач...
Халык көлә: «Элдерт давай, кач!»
Күпләп ага киртә-куралар...
Таллар ава, ишелә буралар...
Әсирлектән шулай котылып,
Шаулы елга ага котырып.
Һәм... Панны да корбан итә ул—
Җәһәннәмгә агызып китә ул!

## Максим Богданович

*1891 — 1917*

*МАКСИМ БОГДАНОВИЧ — шагыйрь, бик күп теллрдән тәрҗемәче һәм теоретик. Минск шәһәрендә укытучы семьясында туган. Нижегородта гимназиядә, Ярославльдә юридик лицейда укыган. Каты авырып, Ялтада дәваланган һәм шунда үлгән. 1907 елдан башлап язган.*

### Карга һәм Сары чыпчык

— Мин бөркеткә охшаганмы,—
Әйт шуны, Сары чыпчык?!
— Бик охшыйсың! Килдең менә
Нәкъ бөркет кебек очып!

Нишләсен шулай димичә,
Җан сакларга җай барда.
Юкса бит нәни кошчыкны
Юк итәчәк дәү Карга.

Ә хәзер исә әнә ул
Куанып кар-кар итте—
Куркәм аваз салып гүя
Киң урманны тар итте...

Аннары Сары чыпчыкка
Соры дусты бәйләнде:
— Шуны бөркет дип әйтергә
Ничек телең әйләнде?

Ә Сары әйтте:—Мин шулай
Озайттым яшәү көнен.
Бөркетне Карга дияргә
Юк, һич тибрәнмәс телем!

# Кондрат Крапива

*КОНДРАТ КРАПИВА (Атрахович Кондрат Кондратьевич) — элекке Минск өязендәге крестьян семьясында 1896 елда туа. Заманында патша армиясендә хезмәт итә. 1920 елда Кызыл Армиягә алына. Көнбатыш Белоруссияне азат иту походында, ак финнарга каршы сугышта һәм Бөек Ватан сугышында катнаша. Совет иленең эчке һәм тышкы дошманнарына, дингә каршы юнәлтелгән, тормыштагы куләгәле якларны яктырту өчен язган юмористик хикәяләре, романы, комедияләре һәм драмалары, поэмалары һәм күп санлы мәсәлләре белән танылган халык шагыйре, академик.*

## Әти Куян

...Киң аланда җитез колын
Уйнап чапканын күрә дә,
Барча туган-тумачасын
Тиз-тиз җыеп бер тирәгә,
Шуны мактый башлый Куян:
«Койрык кыска, төс коламы?
Күрәмсез, йөреше нинди!
Беләмсез, ул кем оланы?
Минеке диеп белегез!
Шуңа шук та ул, җилле дә!
(Димәк, беләм эш рәтен мин...
Арагызда менә кем мин!..)
Телим икән, нәкъ шулай ук
Ярата алам филне дә».

Һәм барча куян кычкыра:
«Чөяргә моны, чөяргә!
Безнең матурыбыз да бу,
Батырыбыз да!—дияргә!»

Шул чакны аланга чыгып
Айгыр кешнәргә тотына.
Ә куяннар нишли димсез?—
Тиз генә качып котыла.

Барча мактанчык затка да
Һәркем шуны әйтә ала:
— Нәфесен филгә сузса да,
Куян куян булып кала.

Материалларны белорусчадан **ЗӘКИ НУРИ** әзерләде.

# КУШАМАТЛАР ТАРИХЫННАН

Кушамат — авыз иҗатының үзенчәлекле бер тармагы, аңарда халык акылының тирәнлеге, фикер һәм тел үткенлеге чагыла. Аның үз максаты, эчтәлеге, җыйнак формасы һәм үзенә күрә кыскача гына тарихы да бар. Фольклорның барлык жанрлары кебек үк, ул халкыбызның бай тормыш тәҗрибәсе, күзәтү житезлеге, иҗади сәләте җирлегендә барлыкка килә.

Кушаматларда халыкның борынгы һәм соңгырак заманнардагы тормышы, хәлəхвәлләре, кешеләрнең теге яки бу затка мөнәсәбәте, кешенең үз-үзен тотышы һәм әхлакый йөзе үзенчәлекле кыска формалар аша яктыртыла. Аларның күпчелеге кешеләрдә очрый торган тискәре сыйфатларны, кешеләрнең үзара мөгамәләсендәге кимчелекләрне ачы тәнкыйть астына алулары белән, әхлакый бозыклыкны, начар гадәтләрне кисәтү үзлекләре белән әһәмиятле.

Кушамат — табигате белән катлаулы һәм каршылыклы күренеш. Шулай да кушаматларның элекке чорларга хас булганнары аркылы без хезмәт ияләренең революциягә кадәрге авыр тормышын, җәфалы кичерешләрен күрәбез, өстен катлауларның җәбере, руханилар, түрәләрнең әр-хуры астында сыкранып яшәүләрен күзаллыйбыз.

Халкыбыз элек кушаматларга бай булган. Борынгы заманнарда кушаматсыз кешеләр бик сирәк очрагандыр. Бүгенге социалистик җәмгыятьтә исә кушаматларның активлыгы нык кими, чөнки аның социаль җирлеге тарая бара. Яңа шартларда алар нигездә теге яки бу шәхеснең характер үзенчәлекләрен ачыклауга, аның ялгызлык исемен тагын да калкурак итеп күрсәтүгә хезмәт итәләр. Кушаматлар шулай ук билгеле бер төбәктәге адаш кешеләрне бер-берсеннән аерып күрсәтү өчен дә кулланыла.

Соңгы заман кушаматларының күбесе, әлбәттә, яңача, чорыбызга хас үзгәчә эчтәлектә барлыкка килә (Комсомол Рәхи, Партизан Сәлим, Комитет Гариф, Егермебишменче Сабир, Колхоз Левитаны һ. б.). Дөрес, алар арасында кешедән көлү, кемнедер кимсетү өчен генә кушылганнары да юк түгел, ләкин алар тормыш чынлыгы тудырган уңай эчтәлекле кушаматларга күләгә төшерә алмыйлар.

Без биредә укучыларны кайбер кушаматларның тарихы, ничек һәм нинди шартларда килеп чыгулары белән таныштырып үтәргә уйлыйбыз. Алар кушаматларның көнкүрештә тоткан урыннарын тагын да ачыграк күзалларга ярдәм итәр.

## Ата Хәернисa

Революциягә кадәр безнең авыл бик ярлы, бик кечкенә иде. Анда хуҗалыклар саны да илле-алтмыштан артмагандыр.

Безнең ише малай-шалайларга аларның һәрберсе таныш. Без һәркемнең исемен генә түгел, кушаматын да беләбез. Шунсыз мөмкин дә түгел. Авылда адашлар азмыни! Абайламый йөрсәң, ялгышуыңны көт тә тор. Мондый вакытта безгә адаш абзыйлар һәм адаш апайларның кушаматы ярдәм итә иде.

Әниләребез берәр йомыш кушып, безне Түбән очтагы берәүгә (мәсәлән, Хәерниса абыстайга) җибәрә башласа, без аның кушаматын сорамый булдыра алмыйбыз. Авылыбызда Түбән оч бер генә булса да, анда Хәерниса апалар икәү бит!

Аларның берсен Ата Хәерниса дип йөртәләр иде. Бу авыр кушамат аңа тикмәгә генә, кызык өчен генә бирелмәгән. Аның, кечкенә генә булса да, үзенә күрә «тарихы» бар.

Хәерниса түтинең ире эшкә яраксыз авыру иде, солдат хезмәтен үтеп, шуннан чирләп — Чирле Шәрәфигә әйләнеп кайткан ул. Шуңа күрә тормышның бөтен авыр йөген Хәерниса түти гомере буе берүзе тарткан, бала-чага тәрбияләгән, иген иккән, терлек-туар асраган.

Без бала чакта ул, шактый олы яшьтә булуына карамастан, ирләр белән беррәттән бөтен эшне башкара: француз яулыгы өстеннән иренең мескен бүреген киеп, биленә аның кызыл әзәрен бәйләп ала иде дә, тегермәнгә бара, җыенга чыга, базарга йөри иде.

— Йөрми хәлем юк! Атабыз авырый бит, — ди торган иде ул.

Бу бичара хатынны иске тормыш әнә шулай җәберләгән, аңа шул заманда ирләр генә башкара торган авыр эшләрне дә йөкләгән һәм, җитмәсә, әлеге хурлыклы кушаматны да тагып, яралы йөрәген әрнеткән.

Билгеле булганча, ул заманда хатын-кызларга җыенга чыгу, базарга бару гаеп санала иде. Шуңа күрә авылның диндар картлары Хәерниса түтине дә ирләр эшенә катнашудан туктатырга тырышып караганнар:

— Хатын-кыз башы белән мир эшенә тыгылмасын!

— Базар буенда ирләр күңеленаздырып йөрмәсен! — дип ярсыганнар.

Эшне муллага җиткергәннәр. Әмма ул ярсып кына эш барып чыкмаслыгын яхшы аңлаган, шуңа күрә, шәригатьчә итеп, бер хәйлә («хәйләи шәргый») корган:

— Кушаматы ата булгач, кыяфәте дә ирләргә охшасын: башында — бүрек, биләндә әзәр булсын! Шунсыз җыенга чыкмасын, базарга бармасын! — дип, дин хөкемен җиткергән Хәерниса абыстайга.

Авыл фанатиклары мулланың бу фәтвасы белән килешкәннәр:

— Башында — бүрек, биләндә әзәр булгач, ирләрдән ни аермасы кала аның! Йөрсен шунда ни ир, ни хатын булып! — дигәннәр.

Хәерниса түтигә, әлбәттә, мулла кушканга буйсынудан башка чара калмаган. Шушы вакыйгадан соң инде ул кушаматы белән генә түгел, кыяфәте белән дә Ата Хәернисага әверелгән һәм, авыр язмышын каргый-каргый, тирән сагыш эчендә гомер кичергән.

Туры килсә килә бит: бу Хәерниса түтинең күршесе дә Хәерниса исемле иде. Шуңа күрә, беренчесе белән бутамас өчен, аңа да кушамат такканнар—Ана Хәерниса дип йөртә башлаганнар. Бу мескен хатын, җаны әрнегәнгә түзә алмыйча, күрше адашын тирги икән:

— Минем башыма бәлагә син ата булгансың, — ди икән.

Ата Хәерниса бүреген тагын да басыбрак кия икән дә:

— Син миңа рәнҗемә, күрше, эзләп алган кушаматым түгел! — ди икән.

Тегесе һаман сукрануыннан туктамаса, монысы, ачуын-мәзәген бергә кушып:

— Атасы булгач, анасы да кирәк бит инде, күрше! — дип куя икән.

## «Күшәми»

Күршебез Әкмәл абзый аз сүзле, авыр сөякле бер кеше иде. Аның яшьлек еллары ягада[1] үткән. Олыгая төшкәч, революция алды елларында гына, бөтенләйгә авылга кайтып, крестьян хезмәте белән көн итә башлаган. Хатыны да үзе төсле сүзгә саран иде, аяк өсли йокымсырап йөри иде.

Шуңа күрәдер, Әкмәл абзыйны, Түбән очтагы Елгыр Әкмәл белән бутамас өчен, Үшән Әкмәл дип, ә хатынын Йомык Сәхия дип йөрделәр .Көнкүрешләре авыр иде, ничек кирәк алай бер мүкләк сыер асрадылар.

---

[1] Ягада — читтә.

Көннәрнең берендә Әкмәл абзый шул мүкләгән сатып (бераз акча да өстәптер инде), Яңа базардан үзе белән яшьтәш, үзе төсле үшән, чагыр күзле җирән алаша алып кайтты. (Кеше рәтенә кереп булмасмы, янәсе.)

Ат алып кайткач, куанычы куенына сыймый Әкмәл абзыйның. Көне-төне алашасы янында чуала, хәлдә бары белән сыйлый ул аны: башагын да болгатып бирә, солысын, печәнен дә алдыннан өзми.

Алаша юаш та, күндәм дә булып чыга. Тик аның кайбер гадәтләре генә сәеррәк тоела Әкмәл абзыйга.

Үзе болай азыкка да һәвәсле күренә: солысына да сузыла, печәнен дә авыз итеп карый, әмма ләкин бирсен дә кинәндереп ашамый, чемченә генә... «Азык талымлый булса кирәк,— дип уйлый Әкмәл абзый,— назлы кунакмыни! Кыстаганны көтәдер, ахры...».

Тагын бер сәер гадәте билгеле була алашаның: алдындагы азыкны, сөмсез сыер кебек, астын-өскә китереп, айкап ташлый да, хуҗасының Йомык Сәхиясе төсле, аяк өсли йокымсырап тик тора!

Анысы гына бер хәл: күшәми дә икән әле ул!

Әкмәл абзыйның күңеленә, барыннан да бигрәк, менә шул нәрсә шом сала. Ни өчен күшәми соң әле ул? Чирләме икән әллә? Хайван булсын да күшәмәсен, имеш! Әнә аның мүкләк сыеры бар иде: бүселгәнче ашый да ята, ята да күши иде бит...

Шулай да өмет өзәргә ашыкмый әле Әкмәл абзый. «Рәтләнеп китәр әле, шәт. Хайван булса да, җан иясе бит. Ятсына торгандыр. Ияләшә төшкәч күшәр әле»,—дип юана ул.

Шулай әчтән генә сызланып йөри, шик-шөбһәләрен Сәхиясенә дә сиздерми Әкмәл абзый. «Үшән алаша кебек, йокымсырап йөри бирсен... Югыйсә, йокысыннан айнып, ярсып китүе бар. Аз булмады аның мондый чаклары... Сыер дуласа, аттан яман, диләр бит»,— дип уйлый.

Ләкин иртәгесен дә шул ук хәл: алашаның бер дә рәтләнер исәбе юк, ятмый да, күшәми дә! Чагыр күзләрен ачалак-йомалак иткәләп, йокымсырап тик тора!

«Хәерлегә түгелдер бу!»—дип шомлана Әкмәл абзый һәм, күңеленә юшкын булып утырган бу хафадан арыну өмете белән, Гыйбуч карт янына киңәшкә керә.

— Алашадан уңмадым, ахры,— ди Әкмәл абзый.

— Нигә алай дисең? Начар ашыймы әллә?

— Ашавын ашый да...

— Алай булгач, нигә пошынасың? Ашаган малда өмет бар, диләр бит.

— Ашавын да ашый ул, Гыйбадулла абзый, әмма никтер бер дә күшәми, шул эчне пошыра. Чирләме икән әллә дип куркам.

— Әй, энем, энем. Ат күшимени! Шуны да белмисеңмени? Дөньяда лабаса син! Сыер түгел бит ул!— ди карт.

Бер мәлгә аптырап кала Әкмәл абзый, аңын җыя алмыйча миңрәп тора.

— Йөрмә кеше көлдереп! Берәүгә дә сөйли күрмә моны! Кеше ишетсә, адәм мәсхәрәсе буларсың, — ди Гыйбуч карт.

Бу күңелсез хәлне Әкмәл абзый берәүгә дә сөйләми, әлбәттә. Кемнең үзе теләп, адәм мәсхәрәсе буласы килсен, ди.

Әмма, гонаһ шомлыгына каршы, бу хәбәр икенче көнне үк бөтен авылга тарала.

— Үшән Әкмәлнең алашасы күшәми икән, ха-ха-ха!

Соңыннан гына белә Әкмәл абзый: күрше килене Такылдык Сәрия тараткан икән бу хәсрәт хәбәрне. Әкмәл абзый Гыйбуч картка зарын сөйләгән чагында, почмак якта Сәрия дә булган, барысын да үз колагы белән ишетеп торган икән.

Менә шулай искәрмәстән генә ике кушаматлы була да куя Әкмәл абзый! Берәүләр Үшән Әкмәл дисә, башкалары Күшәми Әкмәл диләр.

Тора-бара бу күңелсез хәл кушамат кына булып калмый, мәзәккә әйләнеп китә. Җор телле кешеләр хәтта такмак та чыгарып өлгерәләр:

Әкмәл абзый алашасы
Үшән дә, күшәми дә;
Үшән Әкмәл кушаматы
Әйләнде «Күшәми»гә.
Әкмәл абзый баеды хәзер:
Ике кушаматы бар.
Җигим дисә, чагыр күзле
Карт алаша аты бар.

Бу вакыйгага күп еллар узды. Әкмәл абзый күптән гүр иясе инде.

Үткән ел мин, авылга кайткач, Сәхия әбине очраттым. Ул озак еллар буе фермада алдынгы савучы булып эшләгән, аны бик олылап, лаеклы ялга озатканнар. Элекке Йомык Сәхия дигән авыр кушаматы инде күптән онытылган. Хәзер аны «Безнең Сәхия әбиебез» дип, «орденлы әбиебез» дип кенә йөртәләр.

Мин аның белән озак сөйләшеп утырдым. Үткән заманнарны искә төшердек. Мәрхүм Әкмәл абзый Такылдык Сәриягә гомере буе рәнҗегән: «Шул гына мине кеше арасында хур итте. Берьюлы ике кушамат күтәреп йөри-йөри, бөкрем чыкты»,— дип сыкрана торган булган ул.

Сәрияне дә искә алдык. Сәхия әби аның турында бер мәзәк сөйләп алды.

Бер елны Сәриянең ире колхозда плугарь булып эшләгән. Хезмәт көне дә күп чыга икән. Сәриягә менә шул җитә калган, очраган берәүгә сөйләп, мактанып йөргән.

— Умыра сутыйны минем Хәйбулла!— ди икән.

Шулай мактанып йөри торгач, халык аның үз сүзен үзенә кушамат итеп таккан. Кем дә булса берәү: «Кайсы Сәрия?» — дип сораса, икенчесе аңа: «Такылдык Сәрия!»— дип җавап бирә, өченчесе: «Умырау Сәрия!»— дип өстәп куя икән.

Сәхия әби, шушы мәзәкне сөйләп бетергәч, тагын картын искә төшереп алды:

— Әкмәл абзаңа икенче кушаматны менә шул Такылдык Сәрия таккан иде бит. Хәзер инде үзе дә ике кушамат күтәреп йөри... Мәрхүм картымның каргышы төште аңа!— дип куйды.

ШӘРИФ САЙКИН.

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

### Фәнис Яруллин

# МЫШТЫМ ГАЙСӘ

ЮМОРЕСКА

Гайсә ишектән килеп керүгә котлаулар ява башлады. Иң беренче булып башка вакытларда авызыннан бер сүз алу өчен ике сәгать көттерергә ярата торган Ишмөхәммәтов котлады аны.

— Молодец, молодец. Булдыргансың!

Гайсә: «Нәрсә булдырдым икән соң мин», — дип уйларга да өлгермәде, кабалана-кабалана профорг килеп басты.

— Мә бишне, туганкай, ун булсын, — дип Гайсәнең кулын кысты ул.

Әнә шулай котлау арты котлаулар яуды. Кемдер дусларча гына җилкәсеннән кагып узды, кемдер күңелне күтәрерлек матур сүз әйтте, кемдер серле генә күз кысты. Ә иң гаҗәбе, бер карауда биш егетне аягыннан егарлык чибәр секретарь кыз Флюра һуштан яздырырдай серле күзләре белән сокланып Гайсәгә карап торды. Башка вакытта ул Гайсә кебек ир-атны үзенең тырнак шомарта торган игәве кадәр дә күрми иде. Гайсә иңенә ишелеп төшкән мондый бәхеттән бөтенләй аптырады. Аңа идән каядыр читкә шуышадыр кебек тоелды. Ә Флюра яздырган-яздырган моны бөтенләй акылыннан яздырыйм дидеме, кызыл тырнаклы, әптик мамыгыдай ап-ак, йомшак кулын Гайсәнең учына салды.

— Котлыйм, Гайсә абый, ихлас күңелемнән котлыйм!

Бу минутта, бу сүзләрне әйткәндә Флюраның күзләре диңгездән тирән, карурманнан серле, таулардан мәһабәтрәк иде.

Гайсә мондый игътибарны, мондый бәхетне нәрсәгә юрарга да белмәде. «Әллә соң Сафа Сафыч урынына директор итеп куйдылар микән», — дип игъланнар һәм приказлар эленә торган такта янынnan да урап килде. Тик анда сөенерлек нәрсә күренмәде: әллә кайчандагы саргаеп беткән кәгазьләрдән башка һични юк иде. Хезмәттәшләренең котлауларын нәрсәгә юрарга белмичә ул үзе эшли торган лабораториягә китте. Ләкин аңа бүген тынгылык бирмәделәр. Әле берсе, әле икенчесе килеп котлады. Ә бераздан аны Сафа Сафыч үз кабинетына чакыртты. «Мөгаен, теге вакыт «Техника» журналына җибәргән мәкаләмне басканнардыр», — дигән нәтиҗәгә килде Гайсә, директорга керешли.

— О, Гайсә туган, — дип кочаклап ук алды директор һәм менә син нинди икән дигән кук баштан-аяк Гайсәне карап чыкты... — Безнең институтны бөтен илгә шаулаттым диген, ә? Молодец, молодец!

— Сез инде бигрәк, — дигән булды Гайсә.

— Кара инде моны, — диде директор, үзе янына кереп килүче местком председателенә ишарәләп. — Тыйнакланып маташа.

Гайсә аңа каршы нидер әйтмәкче иде, тик ул авызын ачарга өлгергәнче директор:

— Ярый, ярый, тыйнаклык кемгә дә килешә ул, — дип Гайсәгә сүз әйтергә ирек бирмәде. Аннары ул местком председателенә карап: — Ну, нәрсә синең анда, барып чыгамы? — диде.

— Чыга, Сафа Сафыч. Йорт өлгереп җиткән. Мәнә-менә квартиралар бирә башлаячаклар. Тиешле кешеләрегезгә документлар тутыра башлагыз диделәр.

— Әйбәт, әйбәт.

Местком председателе белән директор серле итеп бер-берләренә карашып алдылар. Соңыннан Сафа Сафыч Гайсәгә борылды.

— Фатир мәсьәләсе ничегрәк әле синең?

— Өченче ел гариза биргән идем дә...

— Алайса бигрәк шәп. Әнә яңа микрорайонда siксән фатирлы йорт өлгертеп бетергәннәр, шуннан дүрт бүлмәле бер фатирны сиңа бирсәк каршы түгелдерсең бит?

Гайсә бу сүзләрне ишеткәч дерт итеп куйды. Аның әле бервакытта да бу кадәре нәрсә хакында хыялланганы юк иде. Директор шаярганга ошамый. Шулай да Гайсә бик ышанып җитмәде.

— Миңа ике бүлмәлесе дә бик җитәр иде, — диде ул көрсенеп.

— Ярар-ярар, артыгын кыланма. Бирәләр икән — ал. Ил шаулатырлык эш эшлә дә ике бүлмә дип тор, имеш. Тегенди-мондый делегация килеп керсә, кем эшчесе дигәндә шундый-шундый тикшеренү институтының фәнни хезмәткәре диярлек булсын. Бәлки әле... Хәер, ансы соңыннан. Ә ордерны кесәңдә дип уйла.

Гайсә директор кабинетыннан гел иләсләнеп чыкты. Үзен нинди-дер зур белгеч, дәүләт премиясе лауреаты итеп тоя башлады. Шулчак аның янына икенче бүлектә эшләүче тел бистәсе Нургали килеп керде.

— Ну, малай, егет икәнсең. Дөнья шаулаттың бит. Мыштым гына йөргән була тагын. Әйтми дә...

— Нәрсә инде ул кадәр. Бер мәкалә өчен шаулап йөрергәме?

— Бер мәкалә, имеш, — дип кызып китте Нургали. — Эш мәкаләдәмени? Дүртәү бит, дүртәү. Җитмәсә нindiләр әле: һәрберсе өчәр килограммлы.

Нургали менә кара дигәндәй, кулына тотып кергән газетасын Гайсә каршысына җәеп салды. Анда дүрт игезәк малай табучы бер хатын — аның моннан биш ай элек аерган хатыны ике кулына да икешәр бала тотып елмаеп басып тора иде.

Шул вакыт Гайсәнең күз алдына мыштым гына өйдән чыгып киткән чаклары һәм мыштым гына башкалар белән йөри башлавы исенә төште. Ә хәзер ул ничек кенә шулай кире кайтып керү турында уйланып утыра иде.

# Гамил Афзал

## Утырышу

*Г. Тукайга ияреп*

Бер вакытны, чепи кузле, пеләш башлы
Мыжык белән утырам мин кара-каршы.
Шуннан теге, игътибарга күңеле булып,
Моң-зарларын, җәнҗалларын сөйли башлый:

— И дускаем, кемгә барыйм син барында!
Карьеристлар юл бирмиләр югарыга.
Начальнигым, сәбәп табып, иртә-кичен
Ашый мине туры сүзле булган өчен.

Ял итәргә тиеш идем мин барырга
План буенча, быел Карловы-Варыга,
Хәйләкәрләр төртә миңа Сочи гына,
Кирәк иде Сочи миңа пычагыма!

Әләкчеләр, ялагайлар уңлап-суллап,
Шеф алдында чабышалар койрык болгап.
Помы-замы, инженеры, профсоюзы
Томаларга тырыша минем авызны.

Шулар белән якалашып җаным чыга,
Кыен яшәү көрәшүче намуслыга.
Конторада текә тотам горур башны,
Бөтенесе кабәхәт, мин генә яхшы.

Өйгә кайтсам, баҗа килә акча сорап.
Күршеләрем берсе жулик, берсе дурак.
Хатын йөри кәнтәйләнеп чалбар киеп,
Бер сүз әйтсәң елый башлый китәм диеп.

Башым алып олагамын мин дачага,
Ачу итеп кода белән кодачага,
Бер минут та торалмыйлар алар минсез,
Җыен ялкау, җыен көнчел, җыен юньсез.

Бәйрәм булса, миннән котлау, миннән бүләк,
Бөләм, дускай, анда түләп, монда түләп.
Синең янга изге өмет белән килеш,
Минем кебек ветеранга ярдәм тиеш!..

— Мә йөз тәңкә,—дидем мин кесәдән алып,—
Пинжәгемне, чалбарымны бирәм салып.
Күлмәгемне, ыштанымны бирәм төреп,
Зинһар, мине ялгызымны калдыр берүк!!!

## «Кыска» шигырьләр

●

Кабинетлы, телефонлы
Җылы постлар дөнья тулы.
Мин халыкның әйбәт улы—
Онытмагыз әле шуны.

●

Авызыңда сигарет, кулыңда саз,
Дан-шөһрәтне син көрәп аласың.
Новатор бул да, модный шигырь яз,
Беркем дә берни дә аңламасын.

●

*Ирләр сөйләшә*

— Минем хатын бик тә булган,
Шәле асыл чуклы.
— Бу заманда кем хатыннан уңган,
Сөйләмә дә юкны!

●

*Философ*

Патшалар этлеген чутлый,
тиранны кыса.
Демократ булудан туктый
тамагы туйса.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан Язучылар союзының партия оешмасында отчет-сайлау җыелышы булды. Аны партбюро члены, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачып җибәрде. Партоешма секретаре Туфан Миңнуллин доклад белән чыкты.

Күп мәсьәләләр күтәрелде бу җыелышта. Татарстан язучыларының, шагыйрьләренең, драматургларының коммунизм төзүче җәмгыять кешесен тәрбияләүдә партиябезгә ничек ярдәм күрсәтүләре турында сүз кызып җеп булып сузылды.

Татарстан язучыларының май аенда булып узган IX съездында татар совет әдәбиятының, социалистик реализм әдәбияты традицияләренә таянган хәлдә, аңа үзеннән лаеклы өлеш кертүе, партиябез куйган бурычларны тулысынча башкарып чыгарга сәләтле булуы билгеләп үтелде. Соңгы бер ел эчендә үзенең идея юнәлеше һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан күп милләтле совет әдәбиятында лаеклы урын алырлык шактый әсәрләр иҗат ителде. Үзәк нәшриятның татар әдипләре китапларын бастырып чыгаруга һаман күбрәк әһәмият бирүе юкка түгел. Отчет чорында язучыларыбызның Казанда һәм үзәк нәшриятларда дөнья күргән йөздән артык басмасы үз укучыларына барып иреште.

Аннан докладчы һәр жанрга тукталып, отчет чорындагы уңышлы һәм кимчелекле якларны барлады. Газета-журналларның язучы сүзенә ышаныч белән каравын, аңа урынны түрдән бирүен билгеләп үтте, шушы ышанычны акларга, вакытлы матбугат битләрендә тагын да активрак чыгыш ясарга чакырды. Әлегә язучыларның, бигрәк тә яшьләрнең, публицистик мәкаләләр, очерклар язу белән җитәрлек шөгыльләнмәүләрен әйтте.

Югары идеяле, художество эшләнеше ягыннан камил, замандашыбызга чын мәгънәсендә лаеклы әсәрләр иҗат итүдә төп таяну нокталарыннан язучының эрудициясе, идея-теоретик белеменә, җәмәгать активлыгы мәсьәләләренә дә докладта зур урын бирелде. Күпчелек язучы КПСС өлкә комитеты каршында даими эшләүче иҗат интеллигенциясе семинарларында белемен күтәрде. Иҗат союзы каршындагы «Фән-техника революциясе һәм әдәбият» (җитәкчесе тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Рафаэль Мостафин) теоретик семинары шулай ук нәтиҗәле эшләде.

Докладчы яшь язучыларның иҗтимагый-политик активлыгын күтәрергә, аларны җәмәгать эшләренә мөмкин кадәр күбрәк тартырга кирәклеге турында ассызыклап әйтте. Отчет чорында уздырылган зона конференцияләре, диде ул, талантларны барлау, үстерү белән беррәттән, аларда дөньяга коммунистик караш формалаштыруда зур роль уйнады. Чөнки әлеге конференцияләрдә әдәби осталыкны үстерү генә түгел, ә бәлки бик мөһим булган теоретик мәсьәләләр дә каралды.

Фикер алышуларда катнашкан коммунистлар докладта әйтелгән фикерләрне тагын да тулыландырдылар, конкретлаштырдылар. Өлкән шагыйрь Сибгат Хәким татар совет әдәбиятында В. И. Ленинның монументаль образын иҗат итү өчен җирлекнең гаять бай булуына тукталды. Геннадий Паушкин Язучылар союзы партоешмасының республикабыздагы әдәби берләшмәләр эше белән җитәкчелеге мәсьәләсен яктыртты. Отчет чорында драматургиябезнең үсеше, бу юнәлештә алдагы бурычлар, язучының иҗтимагый активлыгы, җәмәгать эшләрен башкаруы, әдәбиятта гражданлык мәсьәләсе, проза һәм поэзиябез, яшьләр һәм балалар әдәбияты алдында торган проблемалар, язучылар партоешмасын сан һәм сыйфат ягыннан тагын да үстерү мәсьәләсе буенча Риза Ишморат, Әхсән Баянов, Фәрваз Миңнуллин, Хәкимҗан Халиков, Роза Хафизова, Рәфкать Кәрами һәм башка язучылар чыгыш ясады.

Җыелыш, доклад һәм фикер алышулардан чыгып, партоешманың эшен тагын да җанландыруга юнәлдерелгән карар кабул итте. Партбюроның еллык эше канәгатьләнерлек дип бәяләнде. Туфан Миңнуллин (секретарь), Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Венера Ихсанова, Геннадий Паушкин, Илдар Юзеев, Ринат Мөхәммәдиев иптәшләрдән партбюроның яңа составы сайланды.

Партия оешмасының отчет-сайлау җыелышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ИДЕОЛОГИЯ РАБОТНИКЛАРЫ КИҢӘШМӘСЕ

КПСС өлкә комитетында партия өлкә комитетының идеология бүлекләре работникларының, КПССның Казан шәһәре район комитетлары һәм шәһәр тирәсе район комитетлары секретарьлары, республика газеталары, телевидение һәм радио-

тапшырулар җитәкчеләренең киңәшмәләре булды.
КПСС өлкә комитеты секретаре иптәш М. Ф. Вәлиев идеология работникларының Бөтенсоюз киңәшмәсе йомгаклары турында һәм КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары һәм Бөтенсоюз киңәшмәсендә КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре М. А. Суслов докладында яктылыгында партия оешмаларының, массовый информация һәм пропаганда средстволарының бурычлары турында сөйләде.

## ГОРЬКИЙГА БАГЫШЛАНГАН КОНФЕРЕНЦИЯ

24—25 октябрьда Казанда бөек пролетар язучы А. М. Горькийга багышланган XX фәнни конференция булды. Казанның М. Горький музее, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, ТАССР Язучылар союзы тарафыннан оештырылган бу традицион конференциядә әдәбият белгечләре, галимнәр, язучылар, студентлар һәм китап сөючеләр катнашты. Конференция эшендә катнашу өчен Мәскәү шәһәреннән дә Горький иҗатын өйрәнүче галимнәр килде.
Фәнни конференцияне кереш сүз белән Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы профессор М. К. Мөхәррәмов ачты.
Конференциянең беренче көнендә филология фәннәре докторы профессор Б. А. Бяликның (Мәскәү) «А. М. Горький мирасы һәм коммунистик тәрбия мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Г. С. Мөхәммәдованың (Казан) «20—30 нчы елларда Татарстанда әдәби хәрәкәтне оештыруда А. М. Горькийның роле», СССР Дәүләт премиясе лауреаты, язучы Г. Б. Бәшировның (Казан) «А. М. Горький һәм татар совет әдәбияты» (докладны тәнкыйтьче Р. Ә. Мостафин укыды), филология фәннәре кандидаты С. Д. Островскаяның (Мәскәү) «А. М. Горький шәхси китапханәсендәге совет прозаиклары китаплары җыелмасы», язучы Л. Ф. Ихсанованың (Казан) «А. М. Горький һәм татар балалар әдәбияты» дигән докладлары тыңланды.
Икенче көнне конференция Казанның А. М. Горький музеенда дәвам иттерелде һәм анда «А. М. Горький тормышының Казан чорын өйрәнүдә мемуар чыганаклар», «СССР язучыларының I съездыннан соң татар халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастырып чыгару», «М. Горький һәм С. Найденов», «М. Горький һәм И. Бунин иҗатларында автобиографик хикәяләр», «Татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрдә М. Горькийның художестволы-прозаик сөйләме», «1979—1985 елларга А. М. Горький музеен үстерүнең төп юнәлешләре» дигән докладлар белән филология фәннәре докторы профессор Е. Г. Бушканец, филология фәннәре кандидатлары Х. Ш. Мәхмутов, Л. В. Пожилова, Т. Д. Фролова, И. Б. Бәширова (барысы да Казаннан), Казандагы А. М. Горький музее директоры Л. Г. Алексеева чыгыш ясады.
Фәнни коференция эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ ФИЛИАЛЫ

10 октябрьда Кама тамагы районының Красновидово авылында М. Горький музее филиалы ачылды.
Бәйрәм тантанасын ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев ачты. Красновидово кешеләрен музей ачылу белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, КПССның Кама тамагы райкомы секретаре М. Г. Заһидуллин, Казандагы М. Горький музее директоры Л. Г. Алексеева, Красновидово урта мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы В. А. Яшина һ. б. иптәшләр котладылар. Аннан соң тантанага килгән кунаклар белән бергәләп музей янәшәдәге бакчага агачлар утырттылар.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Башкортстанның халык шагыйре, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Мостай Кәримгә 60 яшь тулу уңае белән Казанның Актерлар йортында әдипнең иҗат кичәсе булды. Анда Мостай Кәримнең шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары уйнавында «Ташлама утны, Прометей!» спектакленнән өзек күрсәтелде. Свердловск киностудиясендә иҗат ителгән «Ай тотылган төндә» исемле нәфис фильм да тамашачылар күңеленә хуш килде.
Соңыннан Татарстан Язучылар союзы һәм кичәдә катнашучылар исеменнән шагыйрьгә котлау телеграммасы җибәрелде.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев Казан дәүләт университеты каршындагы «Әллүки» әдәби түгәрәге членнары белән очрашуда булдылар. Кичәдә сүз «Казан утлары» журналы турында барды.
Соңыннан кунаклар да, студентлар да үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

*
* *

Татар дәүләт драма һәм комедия театрының җәйге гастрольләре уңышлы тәмамланды. Коллектив И. Юзеевның «Бәхетемнән узып барышлый», «Кыр казлары артыннан», Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт», Т. Миңнуллинның «Алай түгел, болай ул», Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр» әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр

белән Свердловск, Первоуральск, Пыжма, Кировоград, Чиләбе, Троицк, Куйбышев, Саратов, Әстерхан шәһәрләре тамашачылары алдында чыгышлар ясадылар. Завод һәм фабрика эшчеләре, авыл хуҗалыгы алдынгылары, үзешчән сәнгать коллективлары белән кызыклы очрашуларда катнаштылар. Гастроль дәвамында барлыгы 94 спектакль уйналып, 57 меңнән артык тамашачыга культура хезмәте күрсәтелде.

Тамашачылар һәм җәмәгатьчелек артистларның уенын, спектакльләрне бик җылы кабул итте һәм уңай бәяләде.

Коллективка Свердловск, Куйбышев, Әстерхан өлкәләре культура идарәләреннән, Чиләбе, Саратов, Троицк, Первоуральск шәһәр культура бүлекләреннән Мактау грамоталары тапшырылды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет драматургиясе өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 3 октябрь Указы белән язучы Илдар Гафурович Юзеевка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы Сания Нургалиевна Исмәгыйловага Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 10 октябрь Указы белән Татарстан АССРның халык артисткасы дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

Совет музыка сәнгатендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең эстрада җырчысы Римма Мөбараковна Таишевага (Ибраһимова) Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 10 октябрь Указы белән Татарстан АССРның атказанган артисткасы дигән мактаулы исем бирелде.

*

* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 17 октябрь Указы белән түбәндәге иптәшләргә Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелде:

БӘДРИЕВА Илүсә Әхмәтовнага — Минзәлә татар дәүләт драма театры артисткасы.

ЗӘЙНЕТДИНОВА Фәнисә Сәләховнага — Минзәлә татар дәүләт драма театры артисткасы.

МӘРДЕХАНОВ Рәшит Мәрдехановичка — Минзәлә татар дәүләт драма театры артисты.

НУРУЛЛИНА Кәримә Әхмәтовнага — Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы.

ШӘКҮРОВА Һаҗәр Закировнага — Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы.

*

* *

«Волга» журналының быелгы 6 нчы саны тулаем татар әдәбиятына багышлап чыгарылды. Шушы уңайдан СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Юрий Суровцев журналның әлеге санын укыганда туган уй-фикерләре белән уртаклаша.

«Бу санда яхшы әсәрләр күп, — ди автор.— Публицистика саллы итеп бирелгән... «Волга» тарафыннан тәкъдим ителгән бүгенге заман татар лирикасы стиль һәм эмоциональлек ягыннан күп кырлы, һәм ул укучылар күңеленә хуш килә...»

Мәкаләдә экономика һәм культура ягыннан күзгә күренеп үсүче Совет Татарстанының журналда әле тулысынча чагылып җитмәве дә күрсәтеп үтелә.

*

* *

Казакъ совет музыкасына нигез салучыларның берсе композитор Латыйф Хәмиди белән татар шагыйре Муса Җәлилнең иҗади дуслыгы 1920 елның башларында Казанда башлана, һәм аларның хезмәттәшлеге Мәскәү шәһәрендә дәвам итә. Алар бергәләп балалар өчен күп кенә җырлар иҗат итәләр. Бу җырларның кайберләре «Октябрь баласы» журналында да басылып чыга.

Алма-Атада чыга торган «Ленинская смена» газетасында «Герой-шагыйрь тормышыннан яңа сәхифә» исеме белән дөнья күргән язма (авторы — А. Ибраев) шагыйрь белән композитор арасындагы менә шушы иҗади дуслык турында сөйли.

*

* *

1812 елгы Ватан сугышы герое Надежда Андреевна Дурова картлык көннәренә кадәр Алабуга шәһәрендә яшәгән. Аның язучылык талантына үз вакытында А. С. Пушкин да югары бәя биргән.

«Правда» газетасы үз укучыларын Россиянең менә шушы легендар кызы — Н. А. Дурова белән таныштыра. «Геройны истә тоталар» исемле мәкаләдә Татарстан китап нәшриятында Н. А. Дурованың «Кавалерист кыз язмалары» исемле китабы яңадан басылып чыгуы, Алабуга шәһәрендәге паркта аңа һәйкәл куелганлыгы һәм ул торган йортның кадерләп саклануы бәян ителә.

## «ЛӘЙСӘН» БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

Чаллы шәһәренең «Энергетик» культура сараенда «Ләйсән» әдәбият-сәнгать берләшмәсенең отчет-сайлау утырышы булды. Анда бюро председателе Равил Вәлиев берләшмәнең отчет чорындагы эше турында доклад белән чыкты.

Фикер алышуларда Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, Мәхмүт Газизов, Рәшит Юнысов, Фирая Хәлиуллина, Газиз Кашапов, Фаяз Дунай һәм башка иптәшләр катнашты. Берләшмәнең шеф-консультанты, прозаик Эдуард Касыймов йомгаклау сүзе белән чыкты.

Алабуга районының «Батыр кул», Тукай исемендәге һәм «Кама» колхозы колхозчылары, өлкән класс укучылары Чаллыдагы «Ләйсән» әдәбият берләшмәсе членнары язучы Эдуард Касыймов, шагыйрьләр Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, яшь шагыйрә Фирая Хәлиуллина һәм язучы Газиз Кашапов белән очраштылар. Очрашуда Чаллы язучыларының иҗаты, матбугат һәм әдәбиятның бүгенге тормышта тоткан роле турында сүз барды.

## ЧИТ ТЕЛДӘ

Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» исемле әкият-повесте белән безнең укучылар күптән таныш.

Халыкара балалар елы уңае белән, «Прогресс» нәшрияты «Шуктуган»ны инглиз телендә бастырып чыгарды. Китап зур форматта, төсле рәсемнәр белән бизәлгән. Тиражы — йөз мең данә.

## АВТОРЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Редакциягә бары тик машинкада басылган кулъязмаларның беренче нөсхәләре генә кабул ителә. Әсәрләр 210×297 мм лы форматтагы ак кәгазьгә кара төстәге тасма аша ике интервал калдырып басылырга тиеш.

Бер биттә ин күбе — 30 юл, һәр юлда — бары тик 60 (сүз араларын да исәпләп) тамга була.

Кәгазь битендә сулдан — 25 мм, өстән — 20 мм, уң яктан — 10 мм, астан 25 мм чиста ара калдырыла.

Әсәрнен исеме һәм бүлек исемнәре төп тексттан астан да, өстән дә өчәр интервал белән аерыла.

Кызыл юл өч хәреф урыны кадәр бушлык белән ясала.

Күләме ун биттән арткан кулъязмалар ике экземпляр жибәрелергә тиеш.

Редколлегия таләпләренә жавап бирә алмаган һәм шунлыктан журналда басылмаячак кулъязмалар анализланмый, рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.

**РЕДАКЦИЯ**

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Журналның быелгы беренче саны белән танышып чыккач, Сездә ихтыярсыздан аның алдагы саннарында ниндирәк әсәрләр булачагы турында кызыксыну уянгандыр. Февраль аенда чыгачак журнал инде тупланып куелды, аның битләрендә ниләр басылачагын әйтеп үтәргә дә мөмкин.

Күргәнегезчә, бу санда зур күләмле әсәрләр бирелә башлады. Февральдә сез аларның ахырын укый алачаксыз. Шагыйрь Илдар Юзеевның поэмасы да, Мәхмүт Хәсәновның «Шәгеровлар» романыннан сайлап алынган өзекләр дә алдагы санда тәмамланачак.

Февраль аенда илебез халкы Совет Армиясе төзелү көнен билгеләп үтә. Шул уңайдан укучылар игътибарына яшь язучы Р. Вәлиевнең «Яшисе килә» исемле яңа повесте тәкъдим ителә. Күпләрнең хәтерендәдер: моннан берничә ел элек газеталар комсомолда тәрбияләнгән Рифкать Миргазизовның армия сафларында күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы турында язып чыктылар. Рифкать — Татарстан егете. Язучы аның тормыш юлын җентекләп өйрәнгән һәм гыйбрәтле әсәр иҗат иткән. Повесть яшь укучыларны аеруча нык кызыксындырыр, мөгаен.

Язучы Марсель Галиевның «Төнге кыюлык» хикәясе исә һәр укучыны уйга салырлык. Монда кешенең яшәү мәгънәсе турында фикер кузгатыла. Күңелен бушатырдай бер фикердәше, эч серләрен уртаклашырдай бер дусты булмаган кеше гомерен дөрес уздырамы?..

Р. Кәраминең «Кәккүк тавышы» исемле хикәясендә гаиләсез калган ир кешенең фаҗигасе сурәтләнә.

Журнал В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстан төзелүгә 60 ел тулу вакыйгаларына багышланган язмалар бирүне дәвам иттерә. Икенче санда М. Әмирханов белән Р. Кильматовның «Юл» очеркы, У. Беляловның «Ныгу» исемле язмасы, К. Кәримовның «Кайту» очеркы — шундый материаллар.

Икенче санда әдәбият теориясенә, культура һәм әдәбият тарихына караган язмалар да шактый. Тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевнең «Шигъри сүзнең җегәре» исемле мәкаләсе әдәбият белгечләрен генә түгел, шагыйрьләрне дә тирәннән уйландырырлык.

Гадәттәгечә, журналда «Китап күзәтү», «Безнең календарь», «Мәсәлчеләр мәҗлесе» кебек рубрикалар бар. Соңгы битләргә татар әдәбиятына һәм сәнгатенә караган яңалыклар урнаштырылачак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210